
ISSN 0206–4189
Индекс 73210

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.2007





**Галимҗан Ибраһимов**
*(1887–1938)*

**Казан утлары**
**Qazan utları**

*2007*

# 3
**(1013)**

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

*«Татмедиа» массакүләм коммуникацияләр буенча
Татарстан Республикасы агентлыгы
һәм Татарстан Республикасының
Мәдәният министрлыгы*

*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Раиф Мәрданов, Рашат Низами, Рәдиф Сәгъди.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

---

✉: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎: Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, фән һәм сәнгать бүлеге—541-38-77.
Шигърият һәм публицистика бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Компьютер үзәге һәм гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16.
**Факс**—(843) 541-38-77.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


*Бу санда*


**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Чатырлар. *Шигырьләр.* ..... 5
Җәүдәт ИЛЬЯСОВ. Еланнар әфсенләүче. *Роман.* ..... 9
Чулпан ЗАРИФ. Төркиядән — илгә, Иделгә. *Шигырьләр* ..... 37
Зәки ЗӘЙНУЛЛИН. Мәүлет гусар. *Повесть.* ..... 41
Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛОВА. Бизмән. *Шигырьләр.* ..... 76
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Җир өстенә минем хисләр сибелә. *Шигырьләр.* ..... 78
Халисә ШИРМӘН. Мәхәббәтнең соңгы көне. *Хикәя.* ..... 80
Ләлә ГЫЙМАДИЕВА. Үсмерләр өчен хикәяләр. ..... 181

**ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ**

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Хәтерләрнең хәтәр чигешендә. *Шигырьләр.* ..... 88
Эльвира ҺАДИЕВА. Зәңгәр таң канаты. *Шигырьләр.* ..... 90

**ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ**

Галимҗан Ибраһимов *(редакцион язма).* ..... 91
Галимҗан Ибраһимов турында күренекле әдипләр. ..... 94
Шәриф БАЙЧУРА. Бергә узган еллар. ..... 98
Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре турында истәлекләр. ..... 101

**НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВКА 70 ЯШЬ**

Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Дәвамчанлык. ..... 108

**СӘНГАТЬ**

Расим МӘҺДИЕВ. Урал-тауның бер кыйтгасы. ..... 113
Әзһәр ШАКИРОВ. Язмыш һәм узмыш *(артист язмалары).* ..... 120

**ФӘН**

Адлер ТИМЕРГАЛИН. Миллият сүзлеге. ..... 125
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ..... 130
Раиф МӘРДАНОВ. Мәрҗани-Фәезханов хезмәттәшлеге: яңа фактлар. ..... 136
Равил ӘМИРХАН. Г. Камалның татар матбугатындагы эшчәнлеге. ..... 163
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ..... 168

**ХӘТЕР**

Рашат НИЗАМИ. Мәңгелектер Сәйдәш моңнары. ..... 141
Салих ШАМОВ. Яшьлекнең ерак таңнары. ..... 142
Рәйсә ЮСУПОВА. Күкләрдән иңгән мәхәббәт. *Очерк-хат.* ..... 148

«Казан утлары» архивыннан. ..... 184
Берлекнең яңа әгъзалары. ..... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ..... 189

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: роман Дж. ИЛЬЯСОВА «Заклинатель змей» (продолжение), повесть З. ЗАЙНУЛЛИНА «Гусар Мавлют», рассказы Л. ГИМАДЕЕВОЙ, Х. ШИРМАН; стихи Р. ЗАЙДУЛЛЫ, Ч. ЗАРИФ, Ф. ИСМАГИЛОВОЙ, А. СИТДИКОВОЙ, Л. ГИБАДУЛЛИНОЙ, Э. ХАДЕЕВОЙ.
«К 120 летию Г. Ибрагимова»: редакционная статья и воспоминания известных людей о жизни и судьбе Г. Ибрагимова.
«К 70-летию Н. Хисамова»: статья Т. ГАЛИУЛЛИНА «Преемственность».
«Искусство»: статья Р. МАГДЕЕВА о творчестве А. Абзгильдина; воспоминания актера А. ШАКИРОВА.
«Наука»: А. ТИМЕРГАЛИН. «Словарь нации» (продолжение); Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (продолжение); статья Р. МАРДАНОВА «Новые факты о сотрудничестве Марджани и Фаезханова»; Р. АМИРХАН. «Г. Камал и татарская пресса». Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Память»: статья С. ШАМОВА о вечности мелодии Сайдаша; статья Р. ЮСУПОВОЙ «История первой и единственной любви Ш. Хусаинова».
«Юмор-сатира»: афоризмы М. АХУНОВА.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: картина Б. УРМАНЧЕ; писательница Р. МУЛЛАНУРОВА.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novel by J. ILYASOV «Snake charmer» (continuation), story by Z. ZAYNULLIN «Hussar Mavlut», stories by L. GIMADEEVA, H. SHIRMAN; verses by R. ZAYDULLA, CH. ZARIF, F. ISMAGILOVA, A. SITDIKOVA, L. GIBADULLINA, E. HADEEVA.
«To 120th anniversary of G. Ubragimov»: editorial article and memoirs of well-known people about life and destiny of G. Ubragimov.
«To 70th anniversary of N. Hisamov»: article by T. GALIULLIN «Succession».
«Art»: article by R. MAGDEEV about creativity of A. Abzgildin; memoirs of actor A. SHAKIROV.
«Science»: A. TIMERGALIN. «Dictionary of nation» (continuation); F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation); article by R. MARDANOV «New facts about cooperation of Marjani and Faezhanov»; R. AMIRHAN. «G. Kamal and Tatar press». Pages from «Tatar encyclopedia».
«Memory»: article by S. SHAMOV about eternity of Saydash melody; R. YUSUPOVA. «History of first and unique love of Sh. Husainov».
«Humour-satire»: aphorisms of M. AHUNOV.
From photoarchive of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: picture by B. URMANCHE; writer R. MULLANUROVA.

* Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
* Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
* Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 21.02.2007 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С–228 Тираж 6451.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2007 ел.



Ркаил
Зәйдулла

# ЧАТЫРЛАР

• • •

Арзанайды сүзләр. Гүя томан,
Гүя рәшә, гүя күләгә...
Ә чын шигырь — Тукайдагы сыман —
Тишек үпкә белән түләнә...

Ком шикелле әрсез иреннәрдән
Нинди сүзләр шытар үлгәндә?
Чын шигырь ул — Җәлилдәге кебек —
Баш бәясе белән түләнә...

Учлап-учлап шигырь өләшәләр,
Һәрбер кулда — купшы гөлләмә.
Ә чын шигырь — Туфандагы сыман —
Сөрелүләр белән түләнә.

Хан йортының капкасыннан, шакып,
Кемнәр үлемсезлек теләнә?
Чын шигырь ул — Мөдәрристәгечә —
Сукбай гомер белән түләнә.

Соңгы сулыш тиеп ялгыш кына
Кәгазьдәге эзне өзгәндә,
Чын шигырьгә әверелә шагыйрь
Онытылу дигән үзәндә.

• • •

Иелдем суга, йөгерде учларым буйлап,
акты бармак арасыннан тын гына,
тын гына акты күзләрен йомгалап
бераз,
әллә кая, ерак диңгез ягына.

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) – *шагыйрь, прозаик, драматург, публицист; «Урыс кышын озату», «Ил», «Мәгарә» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Иелдем суга, уянды хәтере суның:
мең ел элек монда төшкән боланның
ишетеп гамьсез, кайгысыз авазын,
бераз
нечкәрде дә күңелем, мин еладым.

Иелдем суга, кагылды йөземә йомшак,
Күрдем анда бер яралы яугирне, —
иңрәде яугир, ярдәмме сорады
бераз,
колагымда һаман шул өн яңгырый.

Иелдем суга, пышылдап үзенә дәште,
аннан күчте, тамырларда гүләде.
Яр өсте төсле көпшәктер җәсәдем,
бераз
каплар аны яшел бәбкә үләне.

* * *

Ике сәгать инде ява — ишелә кар.
Миңа кадәр яуган. Миннән соң да явар...

Нигә моңайтадыр? Күңелемә тия...
Тышта берәү йөри — әзлиме дирбия?

Кап-кара ат анда түбән игән башын,
Шулай сабыр гына күтәме юлдашын?

Ә иртәнгә таба каршы чыгар томан.
Ат кына тик йончу, камыт тигән сыман.

Ә иртәнгә таба сызгырырлар юллар,
Күкрәгемә ятып нигәдер күк елар.

Кап-кара ат чабар ерып куе карны.
Үрәчәле чана — саламы сап-сары...

* * *

Куакларны ап-ак ялкын ялмап алган тышта...
Карт бүредәй! — көчсез, тешсез... — мин дә камалышта.
Яктыртам дип, юлны бүлеп, кем учаклар якты? —
Язу карасыдай саркый кап-караңгы якты.
Карга баткан атлар кешни — тавышлары тонык.
Күңелемне билəп алды якты караңгылык.
Кышкы төннең керфегендә боз тамчысы әнә
Дер-дер килә, әйтерсең лә җаным бәргәләнә.
Утлар яна! Утлар яна! — карга ята корым.
Анда шәүлә... минем сыман үзгә ул, аерым.
Шыпырт аваз — кар астында үлән борын төртә.
Адашкан бер ялгыз йолдыз тәрәзәмә чиртә.

* * *

Төшемдә мин бер төш күрдем:
Инешкә таба йөгердем.

Чыландым иртәнге чыкка,
Әвереледем сыерчыкка.

Очарга дип канат кактым!
Тик канатларымны канаттым.

Табылмады эзләгәнем.
Аваз салдым, өзгәләндем.

Кемнәр сиздә минем сүздән
Дөнья бераз үзгәргәнен?

Томшыгым күккә тигәнче,
Ботарлады кара мәче.

Уяндым. Таң ата иде.
Тышта буран. Сәгать җиде.

Хәзер инде төшенәмен:
Яшим һаман төшемдә мин...

* * *

*Ж. Сөләйманга*

Аккош күле урманында
балан чәчәгенең исе...
Искә төште исерек төн,
инде онытылган исем.

Кара-кучкыл болытларның
касыгына яшеренгән
утлы тамчы чәчрәде дә
эвереледе күз яшенә.

И яшеннәр камчылады,
телгәләде...
Күңел тулып
мин кушылдым шул яшенгә—
сулык-сулык, сулык-сулык...

Ник сагайта үләннәрнең
кыяклары сынган төшләр?..
Суалчандай җиргә сеңә
оялчан тын үкенечләр.

Нинди сагыш ләззәте бар
ялгышуда, авышуда!
Сискәнү булып түгелә
ятим кәккүк тавышы да...

Аны бүлеп аккош чаңрый.
Шулмы соң бу — акку, акку!
Янды сөю чатырлары...
Үтте инде...
юк инде,
юк...

* * *

И-и ыңрәде җил,
Тәрәзәгә ябышты.
Кемнәр аңлый сагынуны,
Шушы ялгыз сагышны?

У-у улады ул —
Ярала үксез бүре.

Төнне ерткан утлы куздай
Тәрәздән күзен күрдем.

А-а ашкынды җил,
Аңлыйм мин аның телен...
Аш бүлмәсендә тын гына
Сулкылдады яшь килен.

* * *

Офыктагы ерак эңгерләрнең
Дулкыннары сарыла бүзәреп...
Ефәк пәрдә, шыпырт дулкынланып,
Тәрәзәнең каплый күзләрен.

Күңел төпкелендә яткан хисне
Нинди көчләр өскә күтәрде? —
Саташулы авыртыну белән
Чакыруы сине бу тәннең...

Мәҗүсиләр тартылгандай утка,
Мин ымсынып синә төбәләм.
Талпына да кинәт янәшәдә
Канат җилпи ялгыз күбәләк.

* * *

Чалкан ятты җир өстенә
Киң яланның оланы.
Керфек какты. Өскә бакты.
Өстә — Тәңре.
...Елады.

Киң ялан буйлап йөгерде
Бер яшь кыз... шундый көяз!
Кызыл җиләк төсе иде
Ак итәгендә бераз.

Киң ялан буйлап йөгерде —
Чәч тузган, күз томанлы...
Йөгерде кыз, йөгерде кыз.
Беркем арттан кумады.

Киң ялан буйлап йөгерде...
Ул кыз шундый яшь иде —
Аста үләннәр йөзләрен
Учларына яшерде.

* * *

Ул күзләрдә ни ишарә?
Сөрмәләнгән рәшә тик.
Кайда дус бар?
Кайда соң яр?
Тоташ, тоташ әшнәлек.

Син кара шагыйрь күзенә, —
Анда Галәм...
Һәм үлем...
Тарихи сиңа тартыла
Бу борынгы күңелем.

Аһ, син, назга сөмсез хатын!
Югалттым бит оятым:
Мәдәни бер катлам булып
Аяк астында яттым.

Өрфиядәй ап-ак яулык,
Сары күлмәк итәге.
Казанның хан капкасыннан
Нурсолтандай үт әле!

Текә тотарсың башыңны,
Нәфесең югарыда...
Йөгерә тик җеп буйлап ут
Гыйффәтең диварына.

* * *

Караңгыда яралганмын.
Аннары нурга түрдең,
Тәңрем!—
Бу туң заманда
Ник йомшак бәгырь бирдең?

Карашым сынды тарлыкта.
Күрмәгәнемне күрдем,
Тәңрем!—
Бу җәһаләттә
Ник шикчел акыл бирдең?

Кайнады сусыл үләннәр.
Атларга мендем, йөрдем,
Тәңрем!—
Тын мазарларда
Ник гамьле хәтер бирдең?

Юллар уралыр бугазга,
Югалыр җирдән гүрем,
Тәңрем!—
Шуның өченме
Син миңа гомер бирдең?

Җәүдәт
Ильясов

# ЕЛАННАР ӘФСЕНЛӘҮЧЕ

РОМАН

• • •

Каян барлыкка килә соң бу ханнар?! Иран һәм Туранга аларның нинди мөнәсәбәтләре бар? Элегрәк кем белгән аларны? Бирегә кем чакырган да кем сайлап куйган? Алла белсен. Житмәсә әле үзләрен хөрмәт ит.

Эш менә болай була. Бөек карагруһчы, хак диннеләр хәлифе көнчыгыштагы бай Хорасан һәм Елга аръягы вилаятләрен югалту белән риза булмый, әле күптән түгел генә ислам динен кабул иткән төрекләрне хак динне төрек-иран хөр фикерлелегеннән якларга котырта. Ашыгыч төстә «пәйгамбәр сүзләре» уйлап табыла: «Көнчыгышта минем төрек дип аталган гаскәрләрем бар; кайсы да булса халыкка ачуым килсә, мин аларга каршы шуларны жибәрәм». Ә тегеләргә шул гына кирәк тә—күптәннән кызыга инде алар кояшлы көньяк далаларның икмәге белән балына.

Ярый соң, һәркайда галимнәрне юк итеп, алар хак динне унышлы якладылар. Әнә шул чакта даны чыга да инде явыз Мәхмүт Газнәвинең. Әмма хак диннән үзенә дә эләгә аны «яклаучылар»дан. Сәлжукның оныгы солтан Тугрылбәк, көнбатышка таба барып, Багдадны камый, коты очкан хәлиф аңа буйсынырга мәжбүр була. Нәкъ менә төрек мәкалендәгечә килеп чыга: беткә ачу итеп тун утка ташлана.

Ләкин явыз Мәхмүттән соң Хорасанны сәлжук-төрекмәннәр басып ала. Елга аръягына башка күчмә төрек кабиләләре—караханилар күчеп утыра. Һәм, әлбәттә инде, тегеләр белән болар арасында дошманлык уты кабына, аны хәтта аларны аерып торучы мул сулы Жәйхун[1] да сүндерә алмый.

Тугрылбәк үлеп, аны Алыпарслан алыштырганда Гомәргә унбиш яшь була. Елга аръягында хәзер Шәмселмөлек Насыйр хакимлек итә. Ишетелгәнчә, ул әле дә күчмә тормыш гадәтләрен югалтмаган, далаларда йөри, фәкать кышын гына Бохара янындагы торагында яши. Хан үз сугышчыларының төнгә Бохарада калмауларын нык тикшереп тора, чөнки аларның үз-үзләрен тотышларына борчыла, дип сөйлиләр. Өстәвенә, ул—төзүче, Бохарада күп яңа бина төзеткән.

Димәк, жирне туктаусыз талап, анда ныклы зур дәүләт төзеп булмаячагына ышанган, дип уйларга кирәк. Бик күңелле бу. Йолдызлар һәм саннар белән тулы булганы өчен безнең башны кисмәсләр дип ышаныйк. Хәер, карарбыз әле...

Кайнар жил йокы китергеч тавышы белән дивар ярыкларында йөри, күптән сүнгән учактагы көлне әкрен генә тарата. Корый башлаган агачның тузанлы яфраклары уртасында ялгыз кош сызгыра. Корыган канау төбендә вак ком буразнасы жил көче белән кузгалып-кузгалып куя, әкрен генә хәрәкәт итә.

[1] Жәйхун – Амударья.

*Дәвамы. Башы узган санда.*

Монда кайчандыр авыл булган. Монда кайчандыр кемдер көлгән, кемдер елаган, кемнендер кайнар пышылдавы һәм ыңгырашуы ишетелгән. Гомәрнең аяк астында ялтыравыклы зәңгәр чүлмәк ватыгы чытырдады. Бу йортларда яшәүчеләр матурлыкны аңлаганнар, күрәсең, югыйсә алар чынаякларын ялтыратмаслар, диварларын ачык төстәге чәчәкләр белән бизәмәсләр иде. Тирән ярыклар белән ярגаланган, кояшка һәм җилгә ачык бу диварларга карап тору сәер һәм куркыныч—чибәр хатынның котырган үтерүче тарафыннан актарылып ташланган эченә карап тору белән бер.

Ул хатынның ымсындыручы—матур, ачык елмаюы ачык капка аралыгында, түбә ярыкларында, буш кишт әләрдә әле дә булса сакланадыр кебек.

Елан, ташбака эзләре. Баш сөяге. Әнә икенчесе. Ярым тузанга баткан сөякләр. Вакытлар үтү белән, алар бөтенләй кибәрләр, тузанга әверелерләр һәм комбалчык белән кушылырлар. Кышкы яңгырларда җебеп, хәрабәләр тигезләнер, һәм авыл урынында тыгызланган, тигезләнгән калкулык кына калыр.

Чүлмәк ясаучылар балчыкны менә шундый калкулыклардан алалар. Һәм шәрабне, иң аек бер китап сөючене баш сөягеннән яки кайчандыр сәлҗүк угыннан һәлак булган авыл кызының таз сөягеннән ясалган касәдән эчәләр.

Кояш яндырган хәрабәләр арасында Гомәр яшен суккандай катып басып торды. Бөтен җир йөзендә шундый хәрабәләр күпме дә, аларда күпме кешенең баш сөяге аунап ята! Нәрсә хакына! Әлбәттә, изге дин хакына. Хакыйкать, ягъни дөреслек хакына. Әй-е, кыйммәткәрәк төшә шул ул бичара кешелек дөньясына!

—Әй!— дип кычкырды Гомәргә кәрван башлыгы. —Монда кил, җимерекләр арасында адашып йөрмә. Үзенне чүлнең явыз рухы—кеше ашаучы гүлнең алып китүен телисеңме әллә?

—Монда булып киткән кешеләрдән соң гүлләргә эш калмаган инде,— дип кайгылы гына көлемсерәде Гомәр.

—Хәрабәләр—аларның яраткан урыны. Күп алар монда.

—Димәк, озакламый кеше бетә. Гүлләр кешеләргә караганда күбрәк. Хәзер кешеләр дә гүлләрдән яхшырак түгел бит.

—Нишләп?

—Киттек, киттек—бөтен җирдә хәрабә...

—Аллаһыга табын, тинтәк!

...Хорасанлы өч кеше бергә яшәгән. Алар лампа чыгымын исәпләп чыгарганнар һәм аны тигез бүлеп тотарга булганнар. Әмма берсе нигәдер ут мае өчен түләүдән баш тарткан. Шуннан соң теге икесе лампаны яндырганда монын күзләрен яулык белән бәйләп куялар да, сүндереп, йокларга ятканда гына чишәләр икән...

Әмир Әлҗаһизның «Әлбухал китабы»ндагы Басра гарәбенең данлыклы Хорасан саранлыгыннан көлүен тасвирлаган бу күренеш юлда барганда Гомәрнең хәтеренә берничә тапкыр төште.

Тукталышларда һәркем аерым ашады, бер-берсенең ризыгы белән уртаклашу булмады. Ә бу—гарәпләр һәм төрекләр өчен күз алдына да китерә алмаслык хәл. Кәрванга тауларда кушылып, Гомәр белән бер арбада баручы да шулай эшләде. Төенен ачканда куллары калтырый, үзе, кинәт кенә кулыннан төенчеген тартып алып, эссе чүлдә эзсез югала күрмәсеннәр, дигәндәй, куркып, агарынып, шикләнеп, күз кырые белән генә Гомәргә карый.

Юк, Гомәр аның итенә, икмәгенә, кыздырылган тавыгына, тутырмасы һәм балыгына да кызыкмый. Ул тыныч кына үзенең арпадан пешерелгән, киптерелгән ипиен ашый да тозлырак кое суы эчеп куя.

Әмма юлдашын һаман нидер борчыды.

—Беләсеңме нәрсә,— дип ачуланып әйтте ул ана Серахс янында .—Син мин ашаганда йә читкә борылып тор, йә өч фельс түлә.

—Ни өчен?

—Ис өчен! Карап торганың өчен!

Гомәр аның тоныҡ усал күзләренә карады. Шаяртамы? Юк, чынлап әйтә.

—Ала-ай!— дип гаҗәпләнде Гомәр. —Син, мөгаен, атаклы саранннар шәһәре Мәрвдандыр? Безнен Нишапурда юк мондыйлар.

—Ә син Нишапурданмыни?— дип җанланып китте юлчы. —Сездә бер йөк шалкан күпме тора?

—Бер йөк шалкан? —Гомәр аптырап калды. Аның беркайчан да шалкан, житмәсә әле йөге белән сатып алганы булмады. —Белмим.

—Һм... Ә бер кәрзин йөзем?

—Э-э... анысын да белмим.

—Алай икән. Ә бер батман арпа?

—Белмим.

—Ә анар?

—Белмим.

—Хөрмә?

—Белмим!!!

—Тоз?

—Белмим!!! Нигә дип бәйләндең әле син, әрекмәннән әрекмәне—тигәнәк? —Һәм Гомәр, үз галәтенчә, аның муен тамырына берне кундырып алды.

Юлчы, авыру кеше кебек калтыранып, үзенең авыр төенен эләктерде дә абына-сөртенә кәрван башлыгы янына йөгерде.

—Ай, эшләр харап! Харап!

—Ни булды? —Башлык карт дулкынлануыннан карлыгып ук калды.

—Минем белән бергә баручы егет үзен Нишапурныкы ди, ә үзе андагы бәяләрне дә белми.

—Ә-ә... —Башлык тынычлана төште. —Шуннан ни булган?

—Минемчә, ул—карак, йә булмаса дошман шымчысы. Каян да булса Чиннан[1], йә Румнандыр[2].

—Теләнә ни килсә—шуны такылдама!—дип ачуланды аны кәрванчы. —Ул чыннан да Нишапурныкы. Мин аның әтисен беләм, абруйлы, билгеле кеше.

—Шулаймыни?

«Сизгер» юлчының кәефе төште. Әмма баштагы уеннан—куркыныч дошманны тоттыру һәм бәлкем әле бүләк тә алу уеннан кайту жинел түгел иде аңа. Бераз уйланып торгач, —ул үзен уйлый ала дип исәпли иде, —болай диде:

—Нишапурныкы, дисезме? Ялган.

—Мин аны беләм, дим бит сиңа.

—Син дә алдыйсың! Син аны яшереп калмакчы. Ничек инде ул алай: үзе Нишапурда яши, үзе андагы бәяләрне белми?!

—Ә ни өчен белергә тиеш ул аларны, тинтәк?— дип кызып ук китте кәрван башлыгы. —Базар хезмәтчесеме әллә ул? Китап кешесе ул! Тапкан кемнән сорарга! Күктә ничә йолдыз бар, дип сорасаң, әйткән булыр иде. Ә шалкан, суган, кишернең күпме торганын каян белсен ди ул?! Кит моннан!

—Барыбер болай гына калдырмыйм мин моны,— дип мыгырданды фаш итүче, табак башын инбашы аша борып. —Мавәраннәһергә барып житкәч, кирәкле кешесенә житкерәм.

—Кеше булсаң, кыйнама безнең җаныбызны, бар кит. Юкса мин сине таяк белән кыйнатып, чәнечкеле әрәмәлеккә ыргытырга кушам.

Кәрван башлыгы белән чын күңелдән саубуллашып, аның аша туганнарына сәлам тапшырып һәм исән-сау Бохара кәрванына кушылгач, Гомәр тыйнак кына яңа юлдашларына мөрәҗәгать итте:

---

[1] Чин – Кытай.

[2] Рум – Византия.

—Әй, мөселманнар! Башта ук әйтеп куям: мин—Нишапурдан Сәмәркандка барам. Миңа егерме ике яшь. Буйдак. Исәп-хисапны һәм астрономияне беләм. Әмма пәйгамбәр исеме белән үтенәм: Нишапурда йомырка, шалкан, борчак күпме тора, дип сорамагыз миннән. Хәзер үк әйтеп куям: белмим. Белмим—һәм вәссәлам! Сатып та алмадым, сатмадым да. Әгәр инде бик теләсәгез, әйтәм: бер йөк шалкан, хәтта бер арба көмеш бездә фәкать бакыр бер фельс тора.

Шуннан соң ул каһкаһә белән уйлады: «Хәзер бөтен вак-төяк сәүдәгәр халкы арзанга гына көмеш сатып алырга Нишапурга агылачак. Йә булмаса, шул хакта бөтен Туранга сөрән салачак. Һәм кем дә булса берәү тиз генә баю нияте белән юлга чыгачак. Баегыз, тинтәкләр, баегыз!

Әмма шаярту файдага булды. Бәяләр турында сорап бүтән аптыратмадылар. Шулай да бөтен юл буе юлдашлары өчен йолдызларга карап күрәзәчелек итәргә туры килде. Аның каравы, Аллага шөкер, моның өчен ашаттылар-эчерттеләр, югыйсә акчасы беткән иде. Бөтенесе юл өчен түләүгә китте.

Әйе, Гомәргә инде—22, финики алфавитына—2350. Аристарх 1300 ел элек үлгән. Александрия китапханәсе аннан соң 182 ел үткәч янган. Джордано Бруноны учакта 530 елдан соң яндырачаклар.

—Саксаул?— диде кәрванны озата баручы шикләнеп кенә.

—Әйе, шул бугай. Корыган ике ботагы бергә кушылган, ә вак ботакларын җил сындырып бетергән. Күрче, моннан караганда шәрә хатынны хәтерләтә. Дөньяда нинди генә гаҗәеп нәрсәләр юк!..

Мәрвадан Җәйхунга барганда булды әлеге хәл. Туранда иң куркыныч урыннарның берсе бу. Гомәр кәрван башлыгы янына Бохара турында сораштырырга дип килгән иде. Ишәккә атланып кәрван юлыннан башлык белән янәшә атлаганда ком өеме өстендә кешегә охшаган бер кара шәүлә күрделәр.

—Бәлкем ул борынгы кыргыйлар балбалыдыр?— дип гаҗәпләнеп әйтте Гомәр. —Бирелә, коры комлыкта, беркайчан да авыл булмаган урында...

Чүл әкәмәтен яхшырак күрү өчен ул, ишелә барган комга бата-бата, калкулыкка менеп китте.

Кара ботак кечкенә шәрә хатынга шул кадәр охшаган, әйтерсең лә, күзләрен йомып, башын игән дә кәрванның җиз кыңгыраулары тавышын тыңлый. Хәтта чәчләре дә бар—куе, калын. Күрәсең, бер диндары сарык тиресе элеп киткәндер. Гадәттә шулай эшлиләр. Юл буендагы куакларга әллә нәрсәләр эленгән. Җирле әрвахларга бүләк...

Һәм шул чак, Фирүзгән юлында булган кебек үк, Гомәрнең башы шаулый, аяклары калтырый башлады. Күкрәгеннән тамагына авыр кара таш килеп, тын юлын каплады. Корыган агач... сулыш алды, бер аягыннан икенчесенә басты һәм күзләрен ачты. Гомәр моның берниндн дә тырпаеп торган корыган агач түгеллеген, ә нәкъ менә кечкенә шәрә хатын икәнлеген күрде.

—Син... кем?— дип шаккатып, башка ни дип тә әйтергә белмичә сорады Гомәр фарсыча. Көтелмәгән бу хәлдән ул чак егылып китмәде.

Кашларына, бакыр төсендәге җилкәсенә төшеп, ялтырап торган кара бөдрә чәчләре, бала кулы зурлыгындагы бакыр имчәкләр һәм пешкән чия кебек куе-кызыл имчәк башлары. Тар борынының очы аз гына күтәренке. Өске ирене елмайгандай калкыбрак тора.

Кысык, искиткеч якты зәңгәр күзләрдә берниндн җавап юк. Әйтерсең лә, нинди дер болыттан эре ике яңгыр тамчысы аерылып, зынлавык очышы вакытында күкнең бөтен зәңгәрлеген үзенә алган да, як-якка керфекләр чәчрәтеп, мәҗүси алиһәнең бакыр йөзенә килеп төшкән күзләр әнә шулай барлыкка килгән!

—Кем син?— дип кабатлады Гомәр бу юлы гарәпчә.

Үзен акылдан шашкан кешедәй хис итте ул. Каһәр суккан Нишапурдагы борчылулар, барыннан да бигрәк Фәйрүзә өчен кайгыру нәтиҗәседер, күрәсең.

Шәрә хатын, берни дә анламыйча, янадан аякларын алмаштырып басты. Озын, төз балтырлары юан, калын, әмма ана ишәкнеке кебек кыска кара йон баскан. Гомумән дә йон белән капланган ул: йон—тыгыз ботларында, касыгында, кечерәк кенә түгәрәк корсагында, күкрәк уентыгында, куркып күтәрелгән кулларында. Ә шулай да борынгы Элладаның аучы алиһәсе кебек гүзәл. Кайнар җил Гомәргә кипкән тирнең, тынчу мәгарәнең әчкелтем исен һәм кешесез зур чүлнең тозлы исен, иң борынгы заман тормышы исен алып килде.

—Син кем?— дип бу юлы төрекчә сорады ул тагын һәм ирексездән ана кулын сузды. Башкача булдыра алмый, ана тартыла иде.

Куркынган караштa ул үзе белән кызыксынуның бик кечкенә мизгелен абайлады. Хатын, үткен азау тешләрен ыржайтып, карлыккан тавыш белән кычкырып җибәрде, кинәт кенә борылды һәм түбәнгә атылды.

Аның гадәттән тыш куе һәм ат койрыгыдай озын чәче, йөгергәндә чайкалып, сирәк йон үскән тар һәм сыгылмалы аркасына бәрелә. Гаҗәп: гәрчә дала кыргыеның аяк табаннары комда батмыйча йөрергә яраклашкан дөя табаннары кебек киң түгел, ә ун яшьлек кызныкы булуга карамастан, җил дулкыннар ясаган йомшак комда эзләре бөтенләй дә калмый диярлек, бары тик очып барганда җилелчә кагылып киткән кебек кенә.

—Аргамак белән дә куып җитеп булмый инде аны хәзер,— диде дөя куучы төрек. Мөгаен, күпне күргән кешедер.

—Ул... күземә генә күренмәде сон?— дип мыгырданды Гомәр, әлеге карачкы ерактагы ком өеме артында югалгач.

—Юк, мин дә күрдем. «Нас-нас» ул. Бик сирәк очрый. Кыргый чүл хатын-кызы. Ишеткәнең бар идеме?

—Әйе. Тик әкияттер дип уйлаган идем.

—Менә хәзер үз күзләрең белән күрдең инде. Син, туганкай, онытырга тырыш аның турында. Юкса гомерең буе эзәрлекләр үзеңне.

Әйтүе генә ансат ул, онытырга тырыш, дип. Хисләр һәм кичерешләр белән кием-салым кебек эш итә алса икән ул кеше дигәнең! Теләсәң— киден, теләсәң—салдың...

Хатын-кызга искитмәле охшаган бу җан ияләре кайда яши икән? Коры чокырларның сөзәк ярларындагы мәгарәләрдәме? Чүлдә күп алар. Әллә соң Бәдхызның чишмәләргә бай пестә[1] әрәмәлекләреннән килгәнме? Моннан туры көньякка барсаң, күпмедер вакыттан соң аның бай, яшел калкулыкларына килеп чыгасың.

Күпме сер яшеренгән чүлдә! Һәм гомумән җир йөзендә! Кайдадыр салкын тауларда һәм тынчу, дымлы урманнарда яшәүче кыргый кешеләр турында күп ишетте Гомәр. Әмма шау-шулы чиста шәһәрдән чыгып киткәч үк диярлек йөнтәс кыргый хатынны очратырмын дип уена да китермәде.

Ул—акылы буенча һәм төс-кыяфәте белән кеше түгел, тик кыргый җанвар да түгел инде. Моңлы кыңгыраулар чакырып китергәндер әле аны. Әллә йөксез генә алдан баручы дөя-нарның өстендәге чуклы аляпмамы, йә булмаса аның йөгәнендәге ачык-сары чачакмы? Димәк, аның караңгы җанында әлеге моң һәм төсне кабул итә алырдай нәрсәдер бар. Димәк, әнә каян килеп чыга икән юлчыларны ерак чүлләрдә көтеп торучы искитмәле чибәр пәриләр турындагы риваятьләр.

Нигә качып китте соң ул? Гомәр дә хәзер үк ияреп китәр иде. Алар белән мәгарәләрдә куныл, ташбакалар һәм таулардагы әче җимешләрне ашап, ерткыч

---

[1] Пестә—җимеш агачы.

жанвар кебек яшәр иде. Утны да белмәсеннәр, үзләреннән җәйран исе дә килсен, ди. Аның каравы аларда борчак һәм шалкан бәясен кеше бәясеннән мең тапкыр артыграк күргән мескен эшмәкәрләр юктыр. Тыштан чиста һәм шома, эчтән йөрәгенә йон үскән тинтәк канунчылар һәм хак дин өчен көрәшүчеләр дә юктыр...

Хыялмы? Базар янәшәсендәге тыкрыкта яшәүче, тотып, капшап, тиешле акчан булса, берне түгел икене дә сатып алып була торган хатын түгел инде бу.

Гомәр чыннан да авырды. Бохарага барып житкәнчегә кадәр дәшмәде. Җәйхунны үтеп, кәрван Бохарага килеп кергәч тә шәһәрне карарга китмәде. Ул кәрван-сарайның юка аслыгында:

—Кем син? Кайда син? Җавап бир!— дип ялварып ятты.

* * *

Еракта, сыек зәңгәр томан эчендә, борыны белән зәңгәрсу-яшел дулкыннарны яручы баһадир кораб кебек Сәмәрканд күренә. Ул, әйтерсең лә, бөдрә әрәмәлекләр һәм бакчалар, ундырышлы басулар диңгезендә йөзә.

Капка янында бакыр акча түләп, Гомәр базарга эләкте. Казый Әбутаһирны нәкъ менә шушында табачак ул. Сәмәрканд Нишапурдан зуррак, халкы да күбрәк. Шәһәр шау-шуы, колагын тондырып, Гомәрне җиргә сендерде. Ят-читтән килгән күпме кеше монда?! Греклар, яһүд, әрмән, чегәннәр. Каян килгәннәр алар? Их, язмыш! Аны ике төрле хис биләде: бу шанлы калага килеп эләгүдән туган шатлык һәм алда торган билгесезлектән, сынаулардан курку хисе.

Шунда ук, кинәт кенә күкрәкне эчтән яндырып алучы сагыш. Туган йортны, ерактагы туганнарны һәм, әлбәттә, мәңгегә югалткан Фәйрүзәне сагыну. Әллә кыргый хатынныммы? Ул аны колакка ятышсыз «Нас-нас» урынына Зәңге-Сәхра—Чүл Кыңгыравы дип атады.

Гомәр очраган кешеләрдән Әбутаһир Алакның кайда яшәгәнлеген сорарга ашыкмады. Кыймады. Юл тузаны, хәерче киеме белән ничек күренсен инде ул баш казыйга? Башта мунча кирәргә инде әллә? Һәм Гомәр, тәбәнәк гөмбәзләр өстеннән чыгып торган төтенне күреп, мунчага китте. Ләкин анда барып житә алмады, китаплар рәтендә тукталып калды. Йә Ходa, күпме китап! Их, акча булса...

—«Дәва китабы»,— дигән тавышын ишетте ул китап сатучының. —Даһи Әбугалисинаның гыйльми хезмәте. —«Дәва китабы». —Сатучы артык кычкырмый, тирә-ягына күз ташлап әйтә—Әбугалисина үзе турында базарда кычкыра торган кеше түгел.

Кибет янына сабыр, акыллы карашлы, бик үк купшы булмаган, әмма чиста киенгән кешеләр җыелды. Китап сөючеләр.

—«Дәва китабы»...

—Нәрсәдән дәвалый?— дип сорады шаян бер юаны. Аның бирелә ят кеше икәнлеге күренеп тора.

—Жанны ялгыш фаразлаулардан,— дип коры гына җавап бирде ябык кеше. —Бирәнлектән кабарган корсакны дәвалый алмый. Эчең авыртса, «Табиблык кануннары» н укы.

—Ә?! Эч авыртмый анысы, җан авырта. Аңа нәкъ менә рухи дәва житми. Күпме тора?

—Өч дирһәм дип бәяләдем. Кем күбрәк бирә? Тик тавышланмагыз, туганнар. Базарда әхлак сакчысы мөхтәсиб йөри.

«Әбугали монда да тыелган икән,— дип күңелсезләнеп уйлады яшь Хәйям. —Әгәр кешене акылы өчен үз ватанында эзәрлеклиләр икән инде, ул чакта нәрсә соң ул ватан?

Ул Әбугалисинаның Бохарадан икәнен белә, әлбәттә, ә бит Сәмәрканд аның белән бер илдә.

—Өч ярымны бирәм,— диде төркемдәгеләрдән берәү.

—Дүрт ярым,— дип арттырды башкасы.

Гомәр бөрешеп калды. Анын бөтенесе дүрт даникы, ягъни өчтән ике дирһәме калды. Ул акчага китап алу турында уйлап та булмый. Еласан да.

—Кем күбрәк бирә?

Тынлык. Дүрт дирһәм зур акча инде ул. Ана берничә көн ачыкмыйча яшәп була. Күбрәк бирүче булмас, ахры.

—Дүрт дирһәм—бер, дүрт дирһәм—ике, дүрт дирһәм...

—Биш!

—Сатылды!

Көнләшү һәм ачу кабарды.

Җанына рухи дәва кирәк булган теге тәбәнәк, ертык халатлы, яланаяклы юан кеше, түгәрәк иренен тәкәббер генә бүрттереп, авыр китапны зур ал яулыкка төрде һәм, борынын күтәреп, күнелләре сүрелгән көндәшләре арасыннан чыгып китте. Китапсыз калганнар, йөрәкләре сыкраса да, ана юл бирделәр. Кыйммәтле китаплар алырга хәленнән килгәч, дәрәҗәле кешедер, күрәсен. Ертык халаттан булса да. Кием-салымга акча җәлли торган бер сарандыр.

Барысыннан да артта басып торган Гомәр янынннан үткәндә бәхетле сатып алучы анын күзләрендә яшь күрде һәм әдәпле генә елмайды. Кәефе кырылган Гомәр, мунча турында онытып, бөтенләй дә башка якка китеп барды.

Аһ, бай булса иде ул... Әмма бай кеше, гадәттәгечә, акчасын юкка әрәм итә: күп ашауга, кием-салымга. Келәм, кыйммәтле савыт-саба сатып ала, ә китаплар турыннан битараф кына үтеп китә. Нигә кирәк алар ана? Хәерчедә дә китап кайгысы түгел, исәбе—корсакны ни белән булса да тутыру. Алайса, кем ала сон китапны? Галим-голәма белән биш дирһәмне беркайдан да таба алмаган шәкертме? Димәк, кешеләр китапны юкка гына яза? Әрәм хезмәтме?

И, мескен язучы! Кәгазь өстендә иртәдән алып кичкә кадәр бөгелеп утырып, бөкре чыгарып, сукыр калып, колакларында кук күкрәгәнче, барлык буыннарын сызлаганчы эшләп, ул тиле үз китабы белән дөньянын астын өскә китерергә уйлыйдыр, мөгаен. Ә ул—беркемгә дә кирәкмәс, кирәк кешенең кулы җитмәс китап, базар рәтләрендә тузан җыеп ята.

Китапны, гадәттә, бүләккә өмет итеп, күренекле кешегә—ханга, шаһка, бүтән бер түрәгә багышлыйлар. Әмма китапны урнаштыруга караганда аны язу күпкә җинелрәк! Бөек «Шаһнамә»сен иҗат итүгә егерме биш ел гомерен биргән Фирдәүси танылуны шундый озак көтә, солтан бүләкләре төялгән кәрван инде Туска бер капкадан килеп кергән вакытта икенче капкадан җиргә индерү өчен шагыйрьнен мәетен алып чыгалар.

Ипи пешерүче булу яхшырак. Һичьюгы ачтан үлмисен. Кем һәм нәрсәгә дип уйлап тапкан ул язу-сызуны? Бәла генә бит ул, бигрәк тә язу-сызучынын үзенә.

> Колак салмак исә хикмәткә, анга—
> Үгез саумак белән бер, дустым, анла!
> Исәрлән, сал башынны гел юләргә,
> Акыл бит берни тормый бу заманда.

—Әй, дус!— дип дәште кемдер Гомәргә. Караса: кадерле китапны эләктергән теге юан кеше. —Күрәм, син бу китапны бик тә алырга теләгән иден бугай?— дип мөлаем гына сорады ул.

—Әйе. Күптәннән хыялланам. Тик күзгә чалынмады.

—Алайса, мә—ал! —Юан ана төенен суздьг.

—Китегезче! Минем фәкать дүрт даникым бар...

—Бир аларны мина! Ашарга җитәр. Иртәдән бирле ач мин. Ә китапны букчана сал.

Гомәр аптырап калды:

—Ничек инде...

—Китапны сиңа бирәм. Ниемә кирәк ул миңа? Мин бит укый белмим.

—Укый белмисен? Алайса ник сон...

—Сатып алдыммы? Менә син кибет алдында басып тордың. Үзеннән вак-төяк бакырларың белән син беркемгә дә кирәкмисен. Ә мин, беркемгә дә кирәкмәс бер бәндә, базарга йөрим һәм күрәм: китап рәтләре янында абруйлы кешеләр басып тора. Мин аларга кирәкмим, алар миңа төкермиләр дә, чөнки мин аңгыра, ахмак, ә алар—укымышлы. Карыйм, күрәм: артык бер дирһәм өчен калтыраналар. Үзләре—галим, үзләре—карун. Каяле, мәйтәм, шаккатырыйм, борыннарына чиртим әле үзләренең, акылга утыртыйм шул кәчекләрне. Һәм утырттым да. Бүген хуҗадан унбиш көнлек эшем өчен алган биш дирһәмемне чыгардым да салдым. Шәп бит, ә? —Ул үз эшеннән канәгать калып, рәхәтләнеп көлде. —Уйласаң, ахмаклык инде дә... Без—хәерчеләргә мондый кылтаю бик үк килешеп бетми анысы. Ярый инде. Бир әле, дускай, дүрт даникыңны. Әйдә хәрчәүханәгә киттек. Син erakтан килгәнсең бугай, ачыккансыңдыр да әле. Әйдә, сыйлыйм үзеңне. Исемең кем?

—Гомәр.

—Умар?— дип сорады сәмәркандлы үзенчә. —Ә мин Галиҗаффар. Беркатлы кеше мин. Тазалыгыма карама. Нишләп тазарамдыр—үзем дә белмим инде, югыйсә коры көлчәдә генә яшим. Бүген—җомга. Хуҗам ял итәргә җибәрде. Казыйларның казые Әбутаһирның хезмәтчесе, каравылчысы мин.

—Ә?! Миңа нәкъ менә шунда барырга кирәк тә инде!

—Ай-яй! Туганымы әллә?

—Юк. Аңа хезмәт итәчәкмен.

—Кем булып?

—Әлегә белмим.

—Әйдә, алып барам.

Күркәм кыяфәтле, зур гәүдәле Әбутаһир шәех Нәзирнең хатын укыганнан соң Гомәргә ягымлы елмайды һәм хезмәтчесе Галиҗаффарга әйтте:

—Мунчага алып бар, минем искергәнрәк киемнәремне кидерт, әйбәтләп ашат һәм йоклат. Сораштырып бимазаламаска. —Аннары Гомәргә карап әйтте: —Ә синең белән, улыкаем, иртәгә сөйләшербез, хәзергә мин ашыгам. Акчаң юк инде, әлбәттә? Менә әлегә вак-төяккә ун дирһәм. Ял ит.

Ул китте.

—Мә үзеннән дүрт дирһәм белән ике даникыңны,— дип, Гомәр Галиҗаффарга китабы өчен артыгы белән түләде.

—Кирәкми.

—Ал, ал!

—Рәхмәт. Яхшы егет икәнсең.

Ят калада, ят кешеләр арасында Гомәр үзен уңайсыз тойды. Әйбәтләп юынып, тамагын туйдырса да, барыбер йоклый алмый ятты. Кунакны такылдавы белән борчымаска кушылса да, алар барыбер Галиҗаффарның кечкенә бер чоланында очрашып, гәп кордылар.

—Әбутаһир ниндиерәк кеше?— дип сорады Гомәр. Кем йортында яшәп, кемгә хезмәт итәсеңне белергә кирәк бит, туры килсә, әлбәттә.

—Ниндиерәк? Кушаматы юкка гына Алак түгел бит аның. Алак ул гарәпчә, э-э... кыйммәтле дигән сүз, шулаймы? Анысын син яхшырак беләсең. Син гыйлемле. Ул яхшы күңелле, юмарт, сукми дә, кыйнамый да. Әйбәт ашата, түли. Шәһәргә дә чыгара. Әйбәт кебек инде.

—Ничек ул «кебек инде»?

—Ә чынлыкта ничек икәнен кем белә аның. Әчтән нинди икәнен, күңелендә, уенда ни барлыгын? Бер вакыйганы сөйлим әле үзеңә. Бабамнан ишеткән идем. Укый-яза белмәсә дә, ул әллә нинди хәлләр турында белә,

аларны көн саен сөйли иде. Әйбәтләбрәк утыр да тынла.

...Безнең Сәмәркандта эчкерсез, хыялый, ышанучан бер егет яшәгән.

«Минем кебек икән,— дип көлемсерәп уйлап куйды Гомәр. —Мин дә бит сарык бәтие кебек: хыялый, ышанучан, беркатлы».

—Кояш баер алдыннан ул салкынча һавада йөреп керергә чыккан,— дип дәвам иттерде Галижаффар. —Янынннан гына монарчы күз күрмәгән чибәр кыз үтеп бара икән. Егеткә караган да йөрәкне яндырырлык итеп көлемсерәгән. Тегесе акылыннан шаша язган. Кыз артыннан киткән бу. Куып житкән дә әйткән:

—Безнең шәһәргә каян килеп чыктың син? Синең белән бер генә тапкыр булса да очрашып булмыймы, чибәркәй?— дигән.

Кыз әйткән:

—Андый теләгең булгач, ник очрашмаска?! Тик мин монда яшәмим, мин— ерак даладагы калкулыклар итәгендәге авылдан. Курыкмасаң, энгер-менгер төшкәндә кил, юлда көтеп торырмын.

—Килермен.

Кыз күздән югалган.

Егет хәнҗәр, акча алган да, дәртләнәп, теге авыл ягына чыга торган капкага килгән. Капка янында кайчандыр үзе белән бер мәдрәсәдә укыган элеккеге танышын очраткан.

—Кая ашыгасың болай?— дип сораган танышы. Карашы әллә нинди сәер үзенең. Әмма гыйшык утында янган егет моны абайламаган.

—Уңыш, дустым, уңыш! Калкулыкта яшәүче гүзәл кыз белән очрашырга барам.

—Әйдә бергә киттек. Мин шунда яшим.

—Бик яхшы. Киттек.

Авылга киткәннәр болар. Карыйлар: юлда нидер күренә.

Кыз!

«Хикәяте озынрак бугай,— дип уйлады Гомәр, —әмма кызык.

Мавыктыргыч итеп сөйли. Бу Галижаффарның табигый сәләтенә белем дә өстәсәң икән! Шәех Нәзирнеке кебек чын, югары белем».

—Дустыңны да үзең белән ал,— ди кыз. —Аның да күңелен табар нәрсәләр булыр.

Авыл читендәге кечерәк кенә балчык өй. Монда инде барысы да әзер: кыздырылган ит, тәм-том, шәраб. Кыз кунакны кочаклый. Тырнаклары озын, тар. Кысып үбә. Егет бөтенләй эреп китә.

—Син хәзергә ял ит, шәраб эч,— ди ана кыз. Киң янбашлары ишеккә чак сыя, ә биле шундый нечкә—ике учка сыярлык. —Мин дус кызымны алып киләм.

Аллага шөкер, егет колакка сак. Кыз ишек янында теге дустына пышылдый:

—Син аны исергәнче эчерергә, хәнҗәрен алырга тырыш. Сенлем белән кайткач, суярбыз, сыйланырбыз. Ул яшь, таза, ите бик тәмле, йомшактыр.

Егет аның иреннәрен чәпелдәтеп куюын ишетә. Менә сиңа мә! Кая килеп эләкте ул?

Ул шундук айнып китә, сикереп тора да, хәнҗәрен селтәп, ишеккә атыла.

—Син кая?— дип кычкыра танышы әллә нинди ят, үзгә тавыш белән.

—Китмә инде, чибәрем!— дип ыңгыраша кыз.

—Якын киләсе булма! —Егет караңгылыкка атылып чыга һәм, сыенып урын эзләп, авыл уртасындагы утка таба китә. Бер капка төбендә кулына фонарь тоткан мөлаем йөзле карчыкны күрә.

—Ни булды, балакаем?— дип сорый ул.

—Тизрәк качыр мине, әбекәй!

Әби аны ишегалдына алып керә, зур тут агачы төбендәге келәмгә утырта. Картын чакыра. Егет үз башыннан кичкәннәрне сөйли.

—Тиле,— дип кызганып әйтә карт. —Ул кыз—убырлы, кеше ашаучы гүл. Синең танышың—аның абыйсы. Ул да убыр. Колакка сак булуың коткарган сине. Ят, ял ит, сиңа монда берәү дә тимәс. Иртән өеңә илтеп куярмын.

Кунак, тынычланып, йокыга китә башлый. Һәм кинәт йокы аралаш баскычта сөйләшкәнне ишетә:

—Ашыгырга ярамый. Куркытырбыз. Катырак йоклап китсен, шуннан соң гына тотынырбыз. Пычагың әзерме?

—Аһ, күптәннән ашаганым юк кеше ите!

Кая инде ул йоклау! Егет тегеләрнең өйгә кереп киткәнен көтә дә, киртә аша сикереп, далага чаба.

Юлда аны бер җайдак куып җитә:

—Гүлләрдән качасыңмы? Каһәр суккыры авыл! Үзем дә көчкә котылдым. Әйдә, атлан тизрәк минем артка, шәһәр капкасына кадәр алып барырмын. Алла сакласын, җыйнаулашып куа чыкмагайлары.

Акча түләргә вәгъдә биреп, егет атка атлана. Җайдак, атын юлдан читкә борып, бөтен көчкә коры дала буйлап ерактагы утка таба чаптыра башлый.

—Кая алып барасың син мине?— дип кычкыра куркуга калган егет.

—Тавышланма!— дип ысылдый серле җайдак һәм янып торган сары күзле кара йөзен аңа таба бора. —Бездән качмакчы булдыңмы? Юк инде, телисеңмеюкмы, без сине кыздырып ашаячакбыз. Безгә алтын кирәкми! — Һәм аны йонлы куллары белән кочаклап ала.

Шулчак егет яшерен уйлар белән: «Бу авылдан коткарчы!»— дип Аллага ялварып, хәнҗәре белән кара йөзле җайдакның аркасына кадый. Кадый да сикерә. Күкерт исе чыгарып, яман төтен тарала. Ат белән җайдак, кыргыйларча үкереп, төнге караңгылыкка кереп югалалар.

Мажаралар эзләүчебез, арып-талчыгып, таң атканда гына шәһәр капкасы янына кайтып җитә. Бу төнне аның чәче агарган. Шуннан соң ул таныш булмаган кызлар белән очрашуга йөрми башлаган.

Гомәр гайре табигый хикәятләрне яратмый. Балачагында төннәрен ишектән дә, тәрәзәдән дә кергән йөнтәс, кызыл авызлы кара җеннәрне төшендә күреп күп курыкты ул. Алар аның балачак шатлыкларын агуладылар. Бәлкем аның балачактан ук ышанычы югалуы да әнә шул тәмуг газаплары һәм шайтаннар турындагы тозсыз әкиятләрдәндер әле.

—Очраган бер кешедән—чибәр кызлардан, дуслардан, мөлаем күршеләрдән, юлдашларыннан—кеше ашаучы гүлләр түгелме бу, дип шикләнә башласаң, дөньяда ничек яшәмәк кирәк?— диде Гомәр карлыккан тавыш белән.

—Барысыннан да шикләнергә ярамый анысы,— диде Галиҗаффар, —әмма сакланырга кирәк. Шуны исеңдә тот: уннын берсе яки әле өченең берсе—барыбер кеше ашаучы убыр.

* * *

Күксел шоңкар көннең кара каргасын, куркытып, көнбатышка куды. Аның артыннан якты таң фазаны канатларын кагу белән үк, Әбутаһир Алак Гомәр Хәйямны үзенә чакыртты. Ул аны келәмнәр җәелгән иркен айванда[1] бик җылы каршы алды һәм кайнар көлчәләр, бал, май куелган тәбәнәк өстәл янына дәште.

Күзләренә чыгып торган янак сөягенә караганда, хуҗа кеше—төрек. Әмма күренеп тора: җирле телдә—дарича яхшы сөйләшә.

—Кем, нәрсә, ни өчен, дип сорап тормыйм, Нәзирнең хатында барчасы

[1] Айван – терраса.

язылган. Бер генә соравым бар: син, улым, Сәмәркандта ни белән шөгыльләнергә теләр идең?

«Ни белән?— дип уйлады Гомәр. —Йә Хода, теләсә ни белән, тик чит илдә ачка үләргә генә язмасын. Аннары кире Нишапурга кайту өчен бераз юллык эшлисе иде».

—Мин... мәдрәсәдә кечкенә балаларны укыта алыр идем. Яисә күчереп язучы була алам. Язуым матур минем.

—О! —Күркәм казый елмайды. Гомәр унайсызланып калды. Колачын шулай артык кин җәйдеме, анын теләге гамәлгә ашмаслык, хәтта мәгънәсез үкмени?! Әйе, әлбәттә, монда үзләренен укымышлы кешеләре дә күптер. Ярый сон, ишегалды себерергә дә ризамын. Бирсәләр...

—Әгәр дә көчле фил була торып та, аннан зур гранит кисәкләре, авыр бүрәнәләр ташыттырмыйча, бер-ике бәйләм корычыбык ташыттырган кешегә син ни әйтер иден, улым? Ягъни филдән ишәк эшен эшләттерүчегә? Ә югыйсә бит ишәк тә күп күтәрә.

—Акыллы эшләми, дияр идем.

—Кара әле мина: акылсыз кешегә охшаганмынмы мин?

—Аллам сакласын! Юк!

—Шул-шул! Мин тамак туйдыру өчен генә түгел, күнелен теләгән эшне күздә тотам. Үзеннен иң изге хыялынны әйт.

—Трактат!— дип канатланып әйтте Гомәр. —Гыйльме хисабта[1] бик күп билгесез, бәхәсле нәрсәләр җыелды. Нишапурда кайберләрен эшли башлаган идем дә...

—Эшләп бетерергә бирмәделәрме? Улым! Бу җирдә сугышчан томаналык дулкыны купты. Әмма караханилылар сәлҗукларга караганда иртәрәк акылга килделәр. Фәнне юк итү—авыр һәм ерак юлга чыкканда күзләренне чукып алу белән бер. Аша, улым.

—Мин тынлыйм.

—Аша һәм тынла. Шулай итеп, хәзер без галим-голәмага әйбәт караштабыз. Чөнки әлеге караңгы елларның авыр нәтиҗәләреннән хәзер дә котылып бетә алганыбыз юк. Мина милек, төзелеш, җир мәсьәләләре буенча күпләрчә катлаулы эшләрне тикшерергә туры килә. Явызлык кин таралды, һәркайда алдашу, урлашу, әмма без боларга каршы берни дә эшли алмыйбыз, чөнки саннарда буталып беттек. Казна малын урлаучылар шуннан файдаланалар да. О, алар арасында шундый шомарганнары бар! Күз алдында ачык, төгәл, тулы математика буенча җитәкче кулланма булмый торып, аларны фаш итү ифрат кыен. Ә каян аласың ул кулланманы? Аша, туганым.

—Рәхмәт.

—Безнең заманда чын галим—сирәк күренеш һәм зур байлык. Аны сакларга, тиешенчә файдаланырга кирәк. Хакан Шәмселмөлек тә шулай уйлый. Узган ел ул миңа болай диде:

«Аллаһы кушып, без бу гүзәл илгә хуҗа булганбыз икән инде, без аны үз кулларыбызда тотарга тиеш. Шуңа күрә ана яраклашырга, яшәү рәвеше, тәртипләренә, гореф-гадәтләренә яраклашырга кирәк. Биредә борынгы, акыллы, оста халык яши. Аның белеме зур. Үзен өстеннән хакимлек иткән халыктан акылсызрак булырга ярамый. Дөресме? Шуңа күрә дә эшкә биредәге галимнәрне тартырга, алардан өйрәнергә кирәк. Юкса биредә яшәп китә алмабыз без. Ә алар бездән башка юкка чыкмаслар. Аларга бездән өйрәнер нәрсә юк. Сарык көтәргә өйрәнергәме? Моны алар үзләре дә белә. Сугышырга гына булса инде. Без мактана ала торган бердәнбер нәрсә шулдыр, мөгаен.»

Әле Орхан һәм Җәнүкәй далаларында кара дин вакытларында ук төрекләрнен

[1] Гыйльме хисаб—математика.

үз язулары булган. Югары Кытай казанышларыннан да йөз чөермәгәннәр. Сонрак та, Жидеелгада христиан-несторианнар аша грек, сүрия һәм согдиана фәнен үзләштергәннәр. Әбунасыйр Фараби бөек фикер иясе, 0трар төреге булган.

Әмма дә бит хәзер без монда, бөтен эш-мәшәкатьләребез шушында.

Баласуганда минем Йосыф Хасхәжиб исемле дустым бар. Ул ханга үгет-нәсихәт итеп «Кудатку-билик» дигән китабын язды. Узган ел тәмамлады. Бик тә акыллы кеше. Әмма математик түгел. Яз үзеңнең трактатыңны! Син моны минем гозерем дип исәплә. Мин синең китабыңны үзебезнең данлы каганыбызга бүләк итәрмен. Эшең дәвамында кирәкле бар нәрсә белән тәэмин ителерсең. Аны тәмамлагач, тиешенчә бүләкләнерсең. Ризамы?

Йөзе качкан Гомәр иреннәрен кыймылдатты, тик бер сүз дә әйтә алмады. Дулкынланудан тамагына төер утырды.

...Ә бит, төрекләрдә юләрлек күп, акыл аз, дигәннәр иде. Имеш, аларның акылы сай, ялкау акыл, аларда барысы да өстән-өстән, якынча, килделе-киттеле генә, имеш. Чеп-чи ялган! Булдыклы, анлы халык. Төгәл фәннәрне үзләштерсә, ерак китәчәк.

—Әй, Юныс!— дип әкрен генә дәште Әбутаһир.

Хезмәтче, күрәсең, якында гына булгандыр, шундук айван баскычы янына килеп житте.

—Бу кеше, —казый жиңелчә генә Гомәргә баш иеп куйды, —минем кадерле кунагым. Аның турында бөтенесен кайгыртуны сиңа йөклим. Тәрәзәләре айванга чыккан зур бүлмәне бир аңа. Якты һәм жиләс булсын. Уңайлы өстәл, иң яхшы Һинд кәндиле куй. Бер үтенечен дә кире какмаска! Ишетәсенме? Берсен дә—ашау-эчү мәсьәләсендә дә, үзен тәрбияләү мәсьәләсендә дә. Берни белән дә аптыратма, борчыма. Ишегалдында тыныч булсын. Анлашылдымы?

Юныс ярарга тырышып әйтте:

—Анлашылды, хужам, барысы да эшләнер.

—Кичә Әбутаһир үзенең иске халатын кигән Гомәргә карады.

—Кыяфәтең әллә нинди... боек, ятимнәрнеке кебек. Балачагында курыккан иденме әллә? Катырак бул! Син галимнең бөек исеменә лаек рәвештә киенергә тиеш,— диде казый кырыс кына. —Әйбәт, әмма тыйнак, артык күзгә бәрелеп тормаслык итеп. Шәех кебек. Менә сиңа ике йөз дирһәм—эшең өчен түләнәчәк бүләк исәбеннән булыр. —Гомәргә чигүле янчык тоттырды.

Юнысның тонык күзләре ялтырап китте. Әйтерсең лә, бу акчалар аның кулына керә язды. Хужа аңа күз карашы белән генә китәргә боерды һәм, Гомәр белән генә калгач, чын күңелленнән болай диде:

—Улым! Мин киң күңелле һәм юмарт кеше, әмма бүләгемне теләсә кемгә таратмыйм. Мин хәер-садака өләшүче жебегән түгел. Анладыңмы? Бу—алышбиреш. Ачыктан-ачык әйтүем өчен гафу ит, әмма шуны исеңдә тот: элеккеге дустымның шәкертләре күп булды. Күбесе булдыксыз—аларны мин белергә дә теләмим. Миңа синең башың, зиһенең кирәк. Минем өстә торучы хакимнәр өчен һәм, димәк ки, үземнең дә унышым өчен кирәк. Чөнки синең хакта мин кайгыртам. Син миңа намуслы һәм тугрылыклы хезмәтең белән түләргә тиеш. Ике-өч көн ял ит, Сәмәркандны карап йөр. Гатфар мәхәлләсенә бар, данлыклы кипарисларга карап хозурлан—алар бездә әйбәт үсә. Аннары эшенә утыр. Тырышлыгыңны күрсәм, бөтен бәхетсезлекләрдән якларммын. Ә инде хатын-кыз мәсьәләсенә килсәк, аларын үзең табарсың. Сау бул!

«Кадерле кунак... мактаулы коллыкка төште бугай,»— дип көлемсерәп уйлап куйды Гомәр.—Йә, ярый ла! Галижаффар әйткәндәй, казый кире уйламасын гына.

Аһ, иртәсе дә иртәсе! Менә иртә, ичмасам! Уйга да килмәгән нинди бәхет!

Гомәр бу хәлдән башын ук югалтты дип уйларга ярамый анысы. Әлбәттә, беренче мәлне башы әйләнеп китте-китүен, йөрәге дөп-дөп типте, колагы шаулады. Әмма яшь Гомәр үзенен ниндидер бөек унышка ирешәчәгенә тиз күнекте. Шулай булырга тиеш тә! Эш менә нәрсәдә. Сәләтле кеше үзенен сәләтлелеген һәрдаим сизеп-тоеп тора. Фаразлау сәләтенә ия булган кеше үзенен бу сәләтен һәрвакыт яхшы белә. Гомәр үз стихиясенә эләкте.

Зур елгада җәтмәгә эләгеп, ни өченлер тынчу буада тотылганнан сон пычрак канау аша янадан үз елгасынын салкынча саф суына чумган балыкны күз алдыгызга китерсәгез—Гомәр шул хәлдә иде.

Ишегалдында, бинаһая зур ябалдаш астында, әле салкынча энгер-менгер. Әмма кайдадыр хатын-кыз ягында инде уянган бала-чага тавышы ишетелә.

Гомәр тыныч. Күнеле белән тыныч. Анда күнел көрлеге. Зиһене искитмәле ачык. Язачак ул трактатын! Язачак!

—Өч дирһәм!— дип пышылдады ана Юныс ишегалдында.

—Ә?— диде Юныснын мәшәкатьләреннән бөтенләй ерак Гомәр, анламыйча.

—Синнән өч дирһәм.

—Ә, алай икән... —Шатлыгыннан Гомәр унны бирде.

—Алгебра, альмукабала...—дип ачу белән мыгырданды Юныс. Баш хезмәтче үзе базарда йөри, ә анын тинтәк уйларынын карак шакалы яшь Гомәр Хәйям тирәсендә әйләнә. —Без дә укыдык ул мәдрәсә дигәннәрендә. Беләбез: дөньяда алгебрадан да тинтәгрәк фән юк. Бактын исә, ул кадерле икән, ә? Мин аны карарга-тәрбияләргә тиеш! Юк инде. Бөкрәеп утырсын шунда үзенең томанлы томаннары өстендә, ә мин аларны кире кагачакмын. Әллә мин анардан томанаракмы? Мин укый-яза белмимме? Ул әле манкасы да кипмәгән вакытында ук шундый нәрсәләрне үзләштергән икән, мин, буй җиткән, тәҗрибәле, акыллы егет, эһ дигәнче үзләштерәм бит аларны! Яз, кадерлем! Яз үз трактатынны. Вакыты җиткәч, мәсхәрә итәчәкмен мин сине. Бармы алгебра турында берәр нәрсә?— дип сорады ул китаплар рәтендә.

—Мөхәммәд әл-Хорәзминен «Алгебра вә альмукабала китабы»,— дип җавап кайтарды ана сатучыларнын берсе.

—Нәкъ мина кирәге! Күпме? Дүрт дирһәм? Аһ! Ярый, бир монда!

Китапны култык астына кыстырып, чәйханәгә юл алды. Ана себеркә сатып алган Галиҗаффар очрады.

—0!— дип гаҗәпләнде Галиҗаффар. —Күрәм: китап алгансын. Ниемә кирәк ул сина?

—Сабыр ит,— дип зәһәрләнеп әйтте Юныс, —күрсәтәм әле мин синен галим дустына.

—Күрсәтәсен? Ни өчен?

—Яратмыйм мин аны!

—Нишләп?

—Сон, шундый булганы өчен.

—Нинди?

—Сон, мондый түгел инде, шундый булганы өчен...

—Анлашыла!— дип көлемсерәде Җаффар. —Әмма кинәшем шул: тимә ана. Чынлап та ул мондый түгел. Тимә!

—Юк, болай гына калдырмыйм мин аны... ул исән чакта. —Юныс китабы белән лапаска кереп китте.

Китапны күргәч, ана киез җәелгән сәкедән шундук урын бирделәр. Әһә! Бездә, Көнчыгышта, гади халык укымышлыларны хөрмәт итә икән. Анын каравы, әйтүләренчә, кояш баешындагы кайсыдыр бер илдә, әллә инде Румда, әллә Русьта, акыллы булган кешене томаналар бик тә җәберлиләр икән.

Алгебра, альмукабала. Мин аннан ахмагракмы әллә? Мин укый-яза белмимме әллә?

Ул түземсезлек белән китапны ачты, битләрен актарды. Йә Ходаl Саннар! Билгеләр! Һм... Йә, ярый. Төшенербез. Менә, мәсәлән... «Э-э...квадратка кирә, э... квадрат кубка кирә... Э-э... шуннан инде котылгысыз төстә квадрат белән кубны үз эченә алган тигезләмә теге нәрсәне һәм квадратны эченә алган тигезләмәгә тигез». Э-э... нәрсәне аңлата соң бу?

Китапны ачу белән актарып озак утырды Юныс. Әмма файдасыз. Үткер тимер белән суксаң, иң каты урам ташында да эз кала. Әмма Юныснын мие иң каты таштан да катырак иде. Шунлыктан китапта сурәтләнгән бер генә очлы почмак та анда эз калдыра алмады. Юныс гашиш тутырылган төребкә сорап алды, тик аны суырганнан соң башы тагын да ныграк шаулый башлады.

Бу шайтан саннарының рәтен бик яхшы белеп кенә калмыйча, ә бәлки аларны кире кага яки дәлилли ала торган кешегә булган ачуыннан баш хезмәтче хәтта калтырана ук башлады.

— Беренче мәгълүматлардан башларга кирәк икән бит. Мәдрәсәгә математик Зөбәер янына керим әле, дигән карарга килде Юныс. Хәтта хужа да берничә тапкыр ярдәм сорап мөрәҗәгать итте аңа. Хак анысы, калган алты дирһәмне бирергә туры киләчәк, әмма белем эстәү өчен нинди генә корбанга бармассың!

... Алгебра, алгебра! Альмукабала!

Яз, әйдә, яз үзеңнең трактатыңны!

Сәгате сугар...

Таза гәүдәле Зөбәер Юныснын килүенә бик шат.

—Хөрмәтле казыйлар казые чакырдымы мине? Хәзер...

—Ашыкма,— диде баш хезмәтче коры гына. —Хөрмәтле казыйлар казые синең хезмәтенә башка мохтаж булмас. Хәзер аның өендә үз математигы бар. Үтә дә сәләтле яшь егет.

—Яшь егет? —Зөбәер куркуга ук калды. —Сәләтле? —Шундук хәлсезләнеп, таза арт ягы белән киезгә утырды. —Нинди сазлыктан килеп чыккан соң ул?

—Нишапурныкыннан.

—Каһәр суккыры! —Зөбәер сикереп торды, хөҗрә эчендә йөренә башлады. Анын зур корсагы, як-якка селкенеп, сарыкның койрык мае кебек чайкалды. —Әкрен генә, тыныч кына, кайгы белми генә яши идек. Каян килә безнең башка шундый сәләтлеләр? Инде бөтенесен себереп түккән идек югыйсә. Димәк, мин кулга керәсе акчамны югалтам булып чыгамы? Синең әфәндең миңа бүтән мөрәҗәгать итмәячәкме?

—Итмәячәк,— дип раслады Юныс. —Ул хәзер акчасын яна ярдәмчесенә чәчә. Бүген иртә белән ике йөз дирһәм бирде ул аңа.

—Йә Хода! Исеме кем соң анын?

—Гомәр Хәйям.

—Ишеткәнем юк.

—Ишетмәсән, ишет...

—Хәйям, Хәйям... Сәер исем! Гарәпчә «хайма»—чатыр дигәннән.

—Яисә «хәйф»—елан.

—Шунысы дөресрәктер. Нишләргә соң? —Зөбәер аптырап Юныска карады. —Ниндидер яшь кенә бер килмешәкнең безнең икмәкне тартып алуына юл куярга ярамый бит инде.

—Өстәвенә әле ул казый өчен алгебрадан фәнни трактат язачак,— дип агу өстәде рәхимсез Юныс.

—0! Хәбәрләрен берсеннән-берсе хәтәр! Ул безнен башка житәчәк. Нишләргә соң, ә?

—Мин монда... өйрәнергә, аңа каршы чыгарга уйлыйм. —Юныс китабын күрсәтте.

—Синме?!— диде Зөбәер. —Йә Аллам! —Ул шундый итеп кычкырып көлә

башлады, бу тавыш чак кына анын үзенен эчен, ә хезмәтчесенен колак пәрдәсен шартлатмады.

—Кадерлекәем!— диде ул. —Ин яхшысы—тотына күрмә! Сон инде. Мин алгебра белән гомерем буе шөгыльләнәм, алай да кайчакларда шундый аптыраштa калам, башны диварга бәрердәй булам.

—Алайса ниемә кирәк сон мина бу китап?— дип боегып әйтте Юныс. —Кая куйыйм мин аны?

—Калдыр. Мөхәммәд әл-Хорәзми? Күз салырмын. Кулга эләккәне юк иде.

Хезмәтче алдады:

—Мин аны алты дирһәмгә сатып алдым.

—Яхшы. Түләрмен. Кайчан да булса... —Ул янадан киезгә утырды. —Бәлкем, аны мәдрәсәгә чакырып, сынап карап, бөтен жыен белән үзен оятка калдырыргадыр? —Зөбәер учы белән мангаен ышкып куйды. —Юк, куркыныч. Әгәр чыннан да гыйлемле икән, үзебезне оятка калдыруы ихтимал. Бөтен илгә мәсхәрә итәр! Мәсхәрә, мәсхәрә... Карале!— дип сикереп торды Зөбәер. —Син сизмәденме, берәр кимчелеге, юньсез гадәте юкмы анын?

—Егерме ике яшендәме?

—Кем белә бит! Исенә төшер, егерме ике яшендә син нинди кабахәт иден! Ә бәлкем ул ирләрне яратучы яки эчкечедер?

—Охшамаган. Хәтта гашиш та тартмый, хәсис!

—Кызганыч! Көтик. Кайчан килде дисен әле?

—Кичә.

—Ярый, сабыр итик. Әгәр анын эчендә шайтан оялаган икән, озакламый сиздерәчәк ул үзен. Ә син күзәт. Бөтен Туранга күпертерлек берәр гаебен күзәт. Йә булмаса тозакка үзен үк тартып кертергә тырыш. Хатын-кызларсыз яшәмидер бит? Кызынны биреп тор. Анын белән булсын да, мине көчләде, гыйффәтемне алды, дип тавыш-гауга куптарсын.

—Барып чыкмас, дускай. Анын гыйффәте әллә кайчан алынган инде.

—Сон, анысы гына комачауламас...

—Тукта! Мине зинданга тыкмакчы буласынмы? Яклаучысы кем икәнлеген оныттынмы әллә?

—Әй-е-е,— дип авыр сулады Зөбәер. —Казыйларнын казые. Урам каравылчысы түгел. Йә, ярый, кайгырма, ни дә булса уйлап табарбыз әле. Барыбер башына житәчәкбез анын.

—Сон?

—Чыгырыннан чыгарырбыз, шикләнмә! Беренче тапкыр гына түгел лә!

Алгебра, алгебра, алгебра!

Альмукабала.

Яз, әйдә, яз үзеннен трактатынны...

• • •

Гомәр ни-нәрсә ашаганын-эчкәнен белми ашап-эчте. Юныс ни бирә—табыкмы, каткан ипиме, әллә әче тормамы—шуны кабул итте. Ризыкны кулына алуы була, башында яна фикер туа, яисә искесе ачыклана, үзенен төпле рәвешен ала. Ашау турында онытып, Гомәр эш өстәле янына ашыга, кулына каләмен ала. Чынбарлык белән төш арасындагы аерма сизлерми генә юкка чыга.

Гомәр учы белән битен сыпырып куйды, уч төбенә куе май сыланды. Янакларда, ияк астында, ирен өстендә—йон. Чәчен тузгытып куйды—каты, пычрак.

Житәр! Болай ярамый. Шәраб, мәсәлән, файдалы, әмма зарары файдасыннан күбрәк, шуна күрә чамасын белеп эчәргә кирәк. Эш тә шулай.

Артыгын тырышып, өзлексән, берни дә эшли алмыйсың. Жилләнеп алырга, ял итәргә вакыт.

Ул кайдадыр бакчада, хужалык бинылары артында, авыр итеп туктаусыз суккан тавыш ишетте. Гомәрнең элегрәк тә иртәләрен ишеткәне булды бу тавышны, әмма эшенә бирелеп, артык игътибар итмәде. Ә менә хәзер, эшен тәмамлагач, әле еш, әле сирәк, әле ачык, әле тоnык, нииндидер аңлашылмаган тупас шыгырдаулы әлеге тавыш, әйтерсең лә, ярык агач торба аша чыгып, нәкъ аның колакларында яңгырый. Шайтан! Әйтелде бит инде тавышланмаска дип!

Бүлмәсеннән ачулы чыгып, Гомәр ишегалды аша бакчага керде. Һәм бераз суына төште. Бакчада салкынча. Кара инде, көз житкән! Агачларда яфраклар коела. Алар чегән яулыгы бөркәнгән кебек. Нинди генә төсләр юк монда: ачык-сары, яшелле-сарылы, кызыл, жирәнсу-коңгырт, соры-зәңгәр. Әмма өрек яфракларының төсе барысыннан да ачыграк, матуррак: куе кызыл, куе шәмәхә, ачык кызыл, сары. Бигрәк тә менә хәзер, дым кагылган, салкын һава белән өретелгән өрек агачы сүнә баручы кояш астында бераз гына ялтырап күренә.

Бакчада давыл булганмы әллә? Ул сирәкләнгән, шәрәләнгән, төрле урында төпләр аунап ята.

—Язга чыккач, бакчаны яңартабыз,— диде Галижаффар, елмаеп. —Авыру карт чикләвек агачлары барысы да диярлек корыган. Чистартырга кирәк.

Базарда кычкыралар:

—Ведар тукымасы! Әмир һәм вәзирләрнең хыялы. Кыш житә. Кемгә ведар тукымасы кирәк?

Чапкан атның талагы кебек, Гомәрнең йөрәге жу итеп китте. Әмирләргә, дәрәҗәле вәзирләргә теләсә нинди хыялны үтәү жиңел. Ә ярлы яшь галимгә?

Данлыклы тукыма! Әлеге искиткеч тукыманы Сәмәркандтан ике фәрсәх[1] ераклыктагы Ведар авылында эшлиләр. Гажәеп тукыма. Матур, саргылтрак төсмердә, йомшак, шул ук вакытта тыгыз—кайбер якларда юкка гына Хорасан парчасы дип йөрмиләр шул. Әмма кызганыч, аның өчен бик кыйммәт. Ведар киже-мамык тукымасыннан тегелгән күлмәк өчен икедән алып ун алтын динарга кадәр түләргә кирәк.

Ярый, берни эшләр хәл юк. Булыр әле. Вакыты житкәч, безнең дә ведар тукымасыннан тегелгән киемебез булыр. Һәм яхшырагы да. Әлегә, бу кышта, киләсе һәм өченче кышта да, тупас, арзан постаудан тегелгән чапаннан да йөрербез.

—Хәзәрдән килгән кунаклар!— диде сулышына ут капкандай берәү. — Базарның иң почмагында—Хәзәрдән килгән кунаклар.

Ярый, барып карарга кирәк. Көзен, салкыннар башланыр алдыннан, Согда белән Хорасанда иң көтеп алынган кунак—Хәзәр сәүдәгәре. Ул Окуз дәрьясы Хәзәр диңгезенә койган урыннардан арзанлы балык алып килә. Әмма аның төп байлыгы—кеш һәм ас, ләтчә, көзән, төлке, сусар тиреләре. Ул шулай ук шәм һәм уклар, балык жилеме, балык теше, гамбәр, каен тузы, иләнгән тире, бал, славян кол хатын-кызлары алып килә. Боларның барысы да— Болгардан. Ару-талуны белмәс хәзәрләр анда зур кәрваннар белән еш баралар.

Дәрәҗәле сатып алучылар арасында бераз йөргәннән соң, Гомәр өйгә кайтырга булды. Кондыз тиресеннән тегелгән бүрек тә, ак тәнле славян кызын да сатып ала алмый ул. Булыр әле. Күнеле рәнжүдән иреннәре калтырады. Жанны кыймас өчен иң яхшысы—базарга йөрмәү. Чәнчелеп китсеннәр лә шул тиреләре белән!

* * *

Кайткач, Гомәр йөзе ачык кызны күрде. Асраугa болай йөрү гаеп ителми. Ул жыештыру эше белән мәшгуль. Гади, матур йөз. Нәрсәсе беләндер аз

[1] Фәрсәх—ераклык үлчәве.

гына Фәйрүзәне искә төшерә. Фәйрүзә белән нindидер охшашлык булганга күрә игътибар итте дә инде ул ана. Аһ, Фәйрүзә! Бөтен гомере буе эзәрлекләр микәнни ул аны? Мөгаен, Фәйрүзә яшьлегендә шушындый ук гади, сөйкемле булгандыр. Әйе, шулай иде. Ул хәтерли.

Әмма Фәйрүзә эрерәк, тазарак гәүдәле иде, ә бу—бигрәк бәләкәй. Буе да кечкенә, авызы да, борыны да; куллары, аяклары—бөтенләй балаларныкы кебек. Тик күзләре генә зур, алтынсу-коңгырт, нindидер үзенчәлекле. Карашы да олыларныкы кебек—житди. Ничектер авыру да кебек әле. Менә хәзер кычкырып жибәрер сыман. Шунлыктан анын ничә яшьтә икәнен белү дә читен: әллә унике, әллә унсигез үк инде.

Гомәр белгән барлык хатыннар барысы да аннан өлкәнрәк иде. Шуна күрә иртә олыгайды, күрәсен.

—Исемен кем синен?

—Рәйхан.

...Бик артык карышмады. Ахрысы, үзе дә анын күнеленә хуш килгәндер. Ул аны кинәт төртеп жибәрде:

—Алтын бирсән, төнлә янына киләм.

—Алтын? Нәрсәгә ул алтын?— дип сорады Гомәр, гажәпләнеп.

—Ничек инде, нәрсәгә?— дип аптырады тегесе, үз чиратында. —Һәрвакыт кирәк булачак. Кызганасынмы? Әллә акчан юкмы?

—Акча бар. Кызганыч та түгел,— дип кыенсыныбрак әйтте Гомәр. —Тик...

«Өсте-башы бөтен, тамагы тук, яшәргә урыны бар. Нәрсәгә кирәк икән ана акча? Табигый комсызлыгын канәгатьләндерергәме? Һәм ничек, күпмегә бәһаләргә үзендә кайный башлаган хисләр өерен? Аларны динар белән үлчәп булмый бит...»

—Беләсенме, мин монарчы гел мәхәббәткә мәхәббәт белән түләдем. Аны акчага сатып алып булганлыгын белмәдем. Хәзер инде белермен.

Рәйхан ана үзенен якты, гадәти булмаган күзләре белән текәлде. «Алтын күзле албасты,— дип уйлады Гомәр, янадан дәртләнә башлап. —Юк, жибәрмим мин сине. Алтын беләнме? Алырсын».

—Мин... йолым өчен жыярга телим. —Ул елый башлады. —Коллыктан котылып... өйгә... Ходжентка кайтырга.

Әнә ничек икән! Гомәрнен йөзе карангыланды, үзе бөкрәйде, арып, сәкегә утырды. Әйе, тормышнын бит әле бу ягы да бар. Яхшы, сакларга унайлырак булсын өчен ул үз дирһәмнәренен бер өлешен динарларга алыштырды. Утыз биш көмеш тәнкәне бер алтынга. Гомәр теге чәчтараш алдагандыр дип шикләнде, әлбәттә. Ярый, ни булса, шул булган. Үлмәбез әле.

—Мин сина биш алтын бирәм,— диде ул ачулы төстә. —Ә төнлә... килмәсән дә була.

Әмма Рәйхан килде.

Озын, газаплы төннән сон ул шулай да күтәренке күнел белән торды. Рәйхан инде юк. Күренеп торган урында, үзенен исәп-хисаплар белән тулы өстәл өстендә ул кичә карангыда ана биргән биш тәнкәсен күрде.

* * *

—Авырып киттенме әллә?— диде Әбутаһир, анын кабарган иреннәренә карап.

—Өшетеп тора, калтырата,— диде Гомәр, кызарып.

—Булгалый... —Казый анлагандай елмайды. —Сәламәтлекне сакларга кирәк. Калтыраудан хуш исле базилик—рәйханнын файдасы күп, диләр. Бәлкем, барырсын?

—Барам. Һичсүзсез барам.

—Ярый, хәерле юл. —Казыйның йөзе кырыс, житди, ә күзләрендә—яшерен көлү...

—Мохтар бу, минем язу-сызу эшләремне башкаручы,— дип таныштырды казый озын, ябык, ак йөзле үсмер белән. —Игенчеләр токымыннан. Ярыйсы математик. Җир эшләрен дә яхшы белә—сиңа мондагы эшләр турында сөйләр.

Көз. Кечкенә сугару каналларында су юк инде. Зурларында ул хәрәкәтсез, чиста, пыяла кебек өслеге коелган яфраклар белән капланган. Күк тә пыяла сыман, җил дә—пыяла. Буш бакчаларда—әкрен тавыш. Соңгы яфраклар оча. Аларның җинелчә кыштырдауларында, —шәрә ботакларда, салкынча һавада, —кайгы, уйчанлык. Бу вакытта бакчаларда ни өчендер күнелсез, сагышлы.

Һәм, күрәсең, шушы сагыштандыр, җир үлчәүче асылмалы букчасыннан сыбызга[1] алды, Гомәрнең иреннәренә карады һәм аны Мохтарга сузды.

Моңлы янгыравыклы тавыш куе салкын һавада еракка таралды. Әйтерсең лә, кешеләр онытткан юл кычкырып җибәрде, булачак салкыннардан куркып, җимеш агачларының нечкә ботаклары шыңшыды, әле күптән түгел, җәен, бакчада йөгерешеп йөрүче балаларның көлүе елауга әверелде. Юк, чыдап булмый. Сыбызга түбән калтыравыклы ыңгырашу белән туктап калды. Авыр сулап, Мохтар аны җир үлчәүчегә бирде. Гомәр аңа рәхмәт әйтеп баш иде.

Аттан төшәргә иде дә, аны үз иркенә куеп, коры яфракларны кыштырдата-кыштырдата, кешесез зур бакчаларның кызыктыргыч, серле ерак почмакларына кереп китәсе иде. Иң тыныч, юлдан ерак бер урында чатыр корып, шунда яшисе иде. Үзен генә. Юк, Рәйхан белән. Алма ашап. Йоклап. Беркемне дә күрмичә. Баш арыды.

Алмалар? Гомәр үзенең беркатлы хыялыннан көлеп куйды. Юк алар. Уныш җыелган. Алып китеп бетергәннәр. Ул агачларга үткен караш ташлады һәм бер ботакның иң югары очында онытылган бер эре ачык-яшел алма күрде. Бөтен бакчага бердәнбер. Менә табыш!

Ул аттан сикереп төште, җимешле ботакларны терәтеп куя торган кәкре озын таяк күтәреп, теге алманы алырга тырышты. Тик таяк кыска булып чыкты. Аны ташлап, коры җир кисәге алды, ыргытты—тими үтте! Икенчесе дә тимәде! Мохтар түзмәде, аңа кушылды.

Әмма үзсүзле алма һич кенә дә төшәргә теләмәде. Шау-шу, көлеш китте. Гомәр исә авыру иреннәрен кызык итеп бүлтәйтеп көлде: «гю-гю-гю!» Шушы тавыш кына да башкаларны рәхәтләнеп көләргә мәҗбүр итте. Җир үлчәүчеләр белән бергә казыйлар казыен озата баручы сакчы яшьләрне кызганды: өзәнгеләренә басып, тәкәббер алманы сөңге очы белән бәреп төшерде.

Шат күңел белән, битләре алсуланып, янадан атларга атландылар.

—Кимер,— дип, Гомәр, теге алманы Мохтарга сузып.

—Ә үзен?

—Минем алмага бик исем китми.

—Минем дә. Сенлемә бирермен. Рәхмәт. —Мохтар алманы куенына яшерде.

Гомәр үзенең сенлесен исенә төшерде. Анын елыйсы килде. Әтиәниләреннән хәбәр һаман да юк.

«Бөтенләй балалар гына әле,— дип уйлады күңеле нечкәргән Әбутаһир. —Шушы үсмерләрнең Сәмәркандта иң яхшы математиклар икәненә ышанасы да килми. Аллаһының кодрәте зур! Бөек акыл яктылыгын кем башына индерергә кирәклеген ул белә».

Ары киттеләр.

—Көнләшерлек. —Гомәр агачлар арасында ботаклар, коры яфрак җыеп йөрүче диһканга[2] ымлап күрсәтте. —Файдалы хезмәт. Гел саф һавада.

---

[1] Сыбызга—флейта кебегрәк уен коралы.

[2] Диһкан—игенче.

Тегесе аларга ачулы гына карады, теләмичә генә тырмасын ташлады һәм, агачтай катып, аларны сәламләп иелде. Бу анын дәрәжәле юлчыларга хөрмәт күрсәтүе булып санала, әмма чынлыкта ул, кинәт кенә йөгереп килеп, башы белән синен йөзенне канга батырырга әзерләнгән сугыш чукмарын хәтерләтә иде.

—Көнләшерлек берни дә юк,— диде Мохтар кырыс кына. —Хезмәтеннән ана бернинди дә файда юк. Саф һавага өстәп ана әле тагын икмәк тә кирәк. Яна пешкәне булмаса, катканы булса да. Күрәсенме, ничек бетерешкән ул!

—Шундый бакчаң була торып та...

—Бәла дә шунда шул, бакча бүтәннеке. Бакча да, тирә-яктагы басулар да. Жүфти-гаунын нәрсә икәнен беләсенме син?

—Сукачы бер жәйдә ике үгез белән эшкәртә ала торган жирме?— диде Гомәр, бик үк ышанып бетмичә.

—Әйе. Йә Хода! Нинди берәмлекләр кулланабыз бит, ә? Суны тегермәнгә күпме кирәк булганча үлчибез, йөкне—ишәк күпме күтәргәнчә, ераклыкны—тавыш, адымнар белән, озынлыкны—терсәк, карыш белән. Шунысы гажәп, без әле нидер эшләгән булабыз. Гали халыкка, һөнәр кешеләренә, тыйнак осталарга рәхмәт. Аларнын аек башына, зирәклегенә, төгәл күз үлчәменә, сизгер кулларына рәхмәт... Юкса бик төзер иден дә... Жүфти-гаунын нәрсәгә тигез икәнен кем әйтә ала?

—Төрек кышлугына,— диде Гомәр, исенә төшереп.

—Ә кышлут?

—Белмим.

—Беркем дә белми. Буталчыклык! Синен кебек галим булсам, мин ин элек гомерлеккә барлык үлчәүләрне—авырлык, күләм, өслек, аралык үлчәүләрен төгәл билгеләр идем. Явыз ниятләргә юлны ябар өчен...

• • •

Яшь елан туя белми.

Ул үзенең убырлыгын басар өчен бернинди каршылык алдында да туктап калмый. Гомәр аек акылы һәм ачык йөрәге белән кешелек гыйлеменен, кешелек хисләренен бөтен дөньясын колачлап алырга тырышты. Күнелендә Фәйрүзәнен, ә хәзер инде Рәйханнын урын алуы да шуннан микән әллә? Ә нигә шуннан булмаска ди?

Ул үзләре арасындагы мөнәсәбәттә, арыгач эчә торган чиста шәраб кебек үк, гаепкә алырлык нәрсә күрмәде. Алар ана файдага гына. Ул таза кеше. Ул эч авыртуы, теш сызлавы кебек нәрсәләрне монарчы белмәде һәм гомере буе белмәс тә.

—Син ник биш тәнкәне алмадын?— диде Гомәр, чиста шәраб салып, Рәйхан үз исемен аклап, тәмле базилик исен таратып, анын янына тагын килгәч.

—Биш тәнкә? Әй! —Рәйхан ваемсыз гына кулын селтәде. —Йолымга барыбер житми бит ул. Аннары... син мине оялттын. Минем дә... мәхәббәткә мәхәббәт белән түлисем килә. Ә аннары... ни булса шул булыр.

—Аһ син, алтын күзле албасты! —Ул аны каты итеп үзенә кысты.

Бу кызый аңа комачаулар дип юкка гына борчылды Гомәр. Киресенчә! Рәйхан анын тормышын тулыландырды, янартты гына. Хәзер ул тигез генә, акылдан шашарлык киеренкелексез эшләде, тоткынлык эшеннән хайвани эшсезлек арасында бәргәләнми башлады. Бөтенесе үз урынына утырды. Рәйхан бар. Авыр хезмәткә бүләккә бер чәркә кечкенә шәраб бар. Аларда—тынычлык, ышанычлылык, түземлелек.

Мохтар көн саен диярлек килде. Ашау-эчу, тормыш-көнкүреш турында онытып, алар сәгатьләр буе тузанлы такта өстендә циркуль, линейка белән эшләделәр. Кайчакларда кишәрлекләр үлчәргә шәһәр читенә чыктылар. Әмма

Гомәр хәнакага, дәрвишләр янына бүтән бармады. Галиҗаффар белән аның әшнәләре йөрсен әнә...

Түземлелек түземлелек белән, әмма ару үзенекен итә. Тимер булып тимер дә туза—сына. Кыш үтте. Әгәр Гомәрдән аның ничек булуын—салкынмы, карлымы, юешме, корымы икәнен сорасалар, ул җавап бирә алмас иде. Ул сизмәде аны. Язны да игътибарсыз үткәреп җибәрде.

Һәм менә бервакыт, гадәттән тыш эссе җәй башында чәче-башы тузган, агарып калган Гомәр аның хәлен белергә кергән казый Алак белән Мохтарга линейкасын һәм циркулен болгады:

—Өченче баскыч тигезләмәләренме? Аларны шушы уенчыклар белән чишәргәме? Юк! Фәкать тиешенчә сайлап алынган конус кисемнәр белән генә. Конус кисемнәр! —Үз-үзен бөтенләй онытып, сугыш чукмарыдай, ул казыйның күкрәк турыннан эләктереп алды.

—Килешәм, туганкай, килешәм! —Казый шаярту катыш куркып артка чигенде. —Кем каршы килә? Без ул каһәр төшкере тигезләмәләр белән күп газапландык инде.

—Менә. —Гомәр Мохтарга сызым сузды.

—Конус кисемнәр белән?— дип аптырап иреннәрен тешләде, тирләп чыккан маңгаен сөртте Мохтар. —Дөрес. Башкача була да алмый. Котлыйм! Син бу хакта беренче булып әйттең. Дөньяда беренче булып.

...Европада Декарт шул ук нәтиҗәгә килгәнче 566 ел, Ванцель шуны ук исбат иткәнче 200 ел үтәчәк әле.

Гомәр исенә килде, кызып китүе өчен оялды.

—Шулаймыни?— дип сорады ул аптырап һәм шатланып әйтте: —Әйе, чынлап та! Тик... Ничек элегрәк башыгызга килмәгән бу фикер? Шундый гади генә...

—Сине көттек. Ачыш ел саен ясалмый ул.

—Әйе, әйе, әлбәттә...

...Ун-унбиш көннән ул ишегалдына чыгар һәм, казыйдан да кыенсынып тормыйча, ниндидер битарафлык белән Галиҗаффарга әйтер:

—Шәраб ясаучыга йөгер, зур бер кувшин шәраб алып кайт. Иң яхшысын! Мәҗлес ясыйбыз!

Өянке төбендәге сәке янына авыру кеше кебек килер, аркасына сузылып ятыр, кулларын баш астына куяр, газаплы ыңгырашып, башын селкер.

—Ни булды сиңа?— дип борчылып сорар Әбутаһир.

—Мин... трактатымны тәмамладым!

Алгебра, алгебра. Альмукабала...

Гомәр, тор! Гомәр...

Ишегалдындагы тавышка уянып, яшь математик, әле айнып та җитмичә, айванга чыкты һәм җан-фәрманга сугышучы Галиҗаффар белән Юныска карады. Сугенеп, алар тирәсендә Алак мәш килә.

—Ул синең трактатыңны урлады! —Галиҗаффар ачу белән хезмәтченең күлмәген умырып төшерде, җиргә язылган кәгазь кисәкләре чәчелде. —Иртәдән бирле күзәттем мин аны. Син йокладың, бүлмәңә кереп, трактатыңны урлады! Куенына яшерде, каһәр суккыры!

Хезмәтче ерткычларча каранып, кинәт җиргә иелде, тиз генә кәгазьләрне җыйды һәм читкә атылды. Капка төбендә—сакчы. Күсе кебек өзек-өзек чыелдап, ул ишегалдында әрле-бирле чаба башлады. Күзләрендә ачу да, хәтта курку да юк, тик нигәдер тонык, аңлашылмый торган ярсулык һәм кабалану гына.

Галиҗаффар куып тотам дигәндә генә Юныс җәйге аш-су әзерләү урынына керде һәм кульязманы ачык учакка ташлады...

Ялкын югары үрләде.

Утыннан аермалы буларак, кәгазь тавышсыз-нисез генә яна. Әмма ачык аңлаешлы юллар белән бизәкләнгән әлеге кәгазь битләреннән күккә ниндидер тавышсыз-тынсыз, әмма коточкыч үкенү күтәрелде! Барча кеше күз алдында Әбутаһирның исәпләре һәм чыгымнары төтен белән көлгә әверелде. Жирсез дикъаннарның өметләре, аларның балаларының ягымлы сөйләшүләре. Гомәр Хәйямның өметләре. Галижаффарның яхшырак яшәүгә булган ышанычы.

—Тураклыйм! —Акылдан шашкан кешенекедәй күзләрен ялтыратып, Галижаффар кулына балта алды һәм аның белән жинаятьчегә кизәнде.

Һәм Ходай шаһит: казый аны жилкәсеннән ныклап тотып алмаса, тураклый да иде.

—Хезмәтен харап булды!— дип елады Галижаффар, балтасын ташлап. —Күпме көч, күпме вакыт...

—Харап булмады,— дип авыз ачып испәнде йокысыннан айнып житмәгән Гомәр. —Ул караламаны урлап якты. Трактат—биктә, сандыкта.

—Ә? —Юныс тораташтай катты.

Ачу-нәфрәт Гомәрнең күкрәгенә һәм башына кайнар дулкын булып китереп бәрде. Һәм ул, ярсып, тегенең каршысына китте:

—Әйдә. Сөякләреңне чәрдәклим хәзер... Мә! —Һәм Юныснын алгы тешләре юк. Канга батып, ул тезләренә егылды. Аяк белән—мә! —Юныс ишегалдының кытыршы ташлары өстенә ауды.

—Житәр, үтерәсең бит!— дип акырды Алак.

Галижаффар белән икәүләп алар ерткычка әверелгән егетне корбанынннан чак аердылар.

Бөтен тәне белән калтыранып, тыны кысылып:

—Гомәр Хәйямны озак оныта алмассың әле син, эттән туган!— диде Гомәр.

Әбутаһир аның жилкәсеннән сыпырды:

—Тынычлан, туганым, тынычлан. Үзем хәл итәм мин аның эшен. —Әй!— дип кычкырды ул капка янында тавышсыз-нисез карап торган сакчыларга. —Зинданга ябып куегыз үзен!

—Кирәкми,— диде Гомәр, тын алып. —Шунысы житәр. Өенә илтеп куйсыннар.

Казый гажәпләнеп сорады:

—Кызганасыңмы?

—Кызганам. —Гомәр күз яшен сөртте. —Мин... бүтән бервакытта да кешене кыйнамаячакмын.

—Аһ, улыкаем! Кыйнарсың. Юкса, таптаячаклар. Ярый, синеңчә булсын. Әй, бу тиләне хатыны янына илтеп куегыз. Ул бүтән бу йортта эшләми. —Әйдә, Гомәр, миңа синең белән сөйләшергә кирәк. —Иреннәре агарган, куллары калтырый.

Гомәр уйлап куйды: күпме генә куәтле булмасын, казыйларның казые әлеге искитмәле рәхимсез дөньяда бөтенләй көчсез-яклаучысыз һәм анда үзе генә бернәрсәне дә хәл итә алмый. Гомәрнең трактаты да ана, мөгаен, берни бирмәс.

—Сөйләшү ни турыда?— дип кырыс кына сорады Гомәр. Тормыш тагын нинди капкын корып куйган аңа? Хәзер ул беркемгә дә һәм бернигә дә ышанмый.

—Хәзер белерсең,— диде Алак серле генә. —Бик мөһим сөйләшү. Бик зур сөйләшү.

—Ярый соң. Киттек. —Гомәр авырттырып бармакларын ныклап уды. —Минем базарга, китаплар рәтенә, төпләүчегә барып киләсем бар иде дә...

—Аллаһы хакы өчен дип әйтәм, йөрмә. Өйдән чыкма. Куркыныч. Кем белә аларны. Кульязманы хәзер үк миңа бир. Күчереп язучыларны да,

төпләүчеләрне дә монда, үз өемә чакырырмын, шушында ук, күз алдында бөтенесен эшләрләр дә.

Утырдылар. «Хәзер ул мине шаккатырачак».

Казый сак кына әйтте:

—Улым, Сәмәрканд туйдырмадымы әле сине?

«Ул мине куарга тели!» —Гомәргә эсселе-суыклы булып китте. —Кульязмамны тартып алачак та урамга куып чыгарачак. Рәйхан аркасында. Аның байлыгы, бәлкем, мәхәббәттер. Их, нигә минем башыма бәйләнде ул кыз! Әгәр казый трактат өчен түләүдән баш тартса, кая барам инде мин? Нинди тормыш инде бу, ә?! Үз-үзем булырга кайчан ирек бирерләр дә, кайчан үз дигәнемчә эшли башлармын?»

—Сәмәрканд—гүзәл шәһәр,— диде Гомәр дә сак кына. —Ул беркайчан да беркемне дә туйдыра алмый.

Казый әкрен, әмма катгый итеп әйтте:

—Ә шулай да сиңа аны калдырып китәргә туры киләчәк! Бик тиздән. Шушы көннәрдә.

—Ни өчен? Монда нәрсәм белән ярамадым?

—Ярадың. Бик яхшы ярадың! Шуның өчен китәсең дә.

—Бу ничек була инде? Аңламыйм .

Казый һаман сузды, ашыкмады, күрәсең, менә хәзер Гомәрнең бик тә нык шатлык хисләре атылып чыгуын көтәдер. Аның түземсезлегеннән кызык табып, җинаятьчене гафу иткән кебек, тантаналы төстә һәм мәрхәмәтлелек күрсәткәндәй әйтергә булды:

—Хан Шәмселмөлек Насыйр галиҗәнапләре сине үз янына, Бохарага сорый!

Әмма бу Гомәрдә бары гаҗәпләнү генә тудырды:

—Нигә?

—Аның сараена яхшы математик, галим әңгәмәдәш, катлаулы хәлләрдә эчкерсез киңәшче кирәк.

—Минем турыда каян белә ул?

—Белә,— дип көлемсерәде Әбутаһир.

Күрәсең, Гомәр турында каханга ул үзе язгандыр. Шуңа ошаган.

—Мин сарайдамы?! —Гомәрнең иңбашлары бөкрәеп аска иелде, әйтерсең лә, аларга авыр йөк бастырдылар, ә ул аның астыннан ни эшләргә белмичә карана. —Булдыра алырмын микән? Математикада, әйтик, ничек тә ерып чыгармын. Әмма сарайда хәйләләргә, ярарга тырышырга, хәкимнең барлык гамәлләрен хуплап кына торырга кирәк, диләр бит. Миннән булмас...

—Бала-чага! —Казыйның ачуы чыкты. —Телисеңме-теләмисеңме, барасың—бетте-китте! Каханның вәкиле шәһәр хакиме сараенда көтә. Өстәвенә, —Алак маңгай астыннан гына кысык күзләре белән Гомәргә карады, —ул үзе белән менә дигән сакчылар алган. —Аннары мыскыллы кыяфәт чыгарып мыгырданды: —Күр инде, нинди тәкәббер... Башка берәү булса, шатлыгыннан елар иде! Ниндидер мескен Зөбәер мондый бәхет турында хыяллана да алмый. Булды! Әкрен генә әзерлән. Иртәгә трактатың өчен исәп-хисапны өзәрмен. Ичмасам, рәхмәт әйт, кадерсез.

Гомәр боек кына әйтте:

—Рәхмәт! Ходай сезгә гел игелекле булсын...

* * *

—Китәсең икән, диләр? —Ул аның янына өскә, түбәгә күтәрелде. Чөнки аста артык эссе булганлыктан, Гомәр төнгә шунда менеп урнашкан иде. Бу юлы Рәйхан, —оныткан мы, әллә теләмәгәнме,—юынмаган, базилик яфраклары белән чайканмаган. Шуңа аннан хезмәтчедән килгән кебек тузан, тир, төтен исләре килә иде.

—Сөйлиләрмени инде?

—Безнең хатын-кызлар ягында синең китүеңә барысы да кайгыра. Кече капкадагы ярыктан карап, гел сокланалар иде: җыйнак, тыныч, уйчан. Казый да синең аркада мәрхәмәтлегә әверелде.

—Син дә... кызганасыңмы?

—Мин? —Ул аның коры, усал, кискен көлүен ишетте. —Мина соң нәрсә? Мин ирексез, ә син иректә кеше, кая телисең, шунда барасың. Ә мин үз анамны күрүдән дә мәхрүм. —Ул елый башлады.

—Йә инде, кирәкми. —Ул аның янына утырды.

—Син! —Рәйхан кисәк кенә аңа ташланды, балаларныкыдай җинел куллары белән аңа суккалый башлады. —Каян килеп чыктың син минем башка? Төштәге кебек кенә яши идем шунда... тыныч кына, берни уйламыйча, берни турында да хыялланмыйча... Түздем. Син минем җанымны актарып ташладың. Йөрәгемдәге... йолдызны уяттың... инде хәзер ташлап китәсең. Хәзер нишләргә инде? Мин бит элеккечә яши алмыйм. Менә монда яна. —Ул учы белән күкрәген тотты. —Их! Агу эчәр идем... агу. Тик кызганыч, туганнарны күрми үлү кызганыч...

—Тынычлан, Рәйхан, үзеңне кулга ал,— дип мыгырданды Гомәр, ни эшләргә белмичә. —Мин ирекләмени? Мин дә кол. Үз белемнәремнең колы. Күккә кара әле әнә. Ярар, котырма инде, кара! Менә шулай. Көньякта, таулар өстендә, офыктан биектә гаҗәеп ачык йолдызларны күрәсеңме? Әл-Хавва ул, Еланнар әфсенләүче. Көнбатыш илләрендә аны Еланнар хуҗасы диләр. Кара әле. Әгәр зур йолдызларны үзара сызыклар белән тоташтырсаң, очлы башлы һәм нәзек аяклы кеше барлыкка килә. Ул кулларында бик зур, усалланып бөргәләнүчә елан тотып тора. Почмаклырак бөтен фигурадагы искитмәле киеренкелекне күр син. Артык көчәнүдән аяклары калтырый. Бөтен көченә кысып, искиткеч зур томаналык һәм карагруһчылык кобрасы белән көрәшә бит ул. Бер генә мизгелгә тынычланса, кулларын йомшартса, кобра ычкынып китәчәк тә, бөтен коточкыч үлем агуын аңа чәчәчәк. Һәм һәрвакыт шулай. Ул аның белән гомере буе сугышырга мәҗбүр. Нәкъ менә шулай—Елан йөртүче дип түгел, Елан белән сугышучы, Еланнар әфсенләүче дип атарга да инде аны. Аңлыйсыңмы?

Күрдеме ул берәр нәрсә, аңладымы-юкмы—Ходай белә, әмма Рәйхан, ничектер сәер тынып калып, әкрен генә киемнәрен салды да, тирән сулап, аңа елышты. Алтын күзләре нәкъ менә шул ерактагы, бик ерактагы йолдызлар кебек җемелдәде. Алар төнге күктә, буй җитмәс йолдызлыклар арасында аның соңгы көненә кадәр, вакыт үткән саен һаман яктырак җемелдәрләр...

• • •

Көнчелек, тәкәбберлек, яшерен һәм ачыктан-ачык пычрак гайбәт, арттан килеп кадау—болар Гомәр Хәйям күнеленә ята аламы соң? Изге Бохарада яшәгәндә нәкъ менә шуның өчен болай дип язды да ул:

> Риза козгын да бит сөяк-санактан,
> Ә син һаман ашыйсың ят табактан;
> Түбән җаннар сыеннан мең кат артык
> Үзең хезмәттә тапкан бер сынык нан[1].

Зур таш текә кыяда йөз ел ята. Яңгыр да юа алмый, җил дә өреп төшерә алмый. Әмма бервакыт җирнең эчендә нидер кузгала, һәм таш, селкенеп, һичбер начарлык турында уйламыйча, бер яшел үзәнлектән икенчесенә әкрен генә баручы ялгыз юлчының башына килеп төшә.

---

[1] Нан – ипи.

* * *

—Исфаханга җибәрәсезме?!— дип сорады Гомәр. —Обсерватория төзергә! Йә Хода! Бу бит... минем эш. Низамелмөлек тә шундамы?! Уртак тел табарбыз без аның белән!

Кахан усал гына әйтте:

—Монда безнең үзебезгә дә кирәк астрономнар. Әллә без үзебез дә адашмадыкмы ике календарь арасында? —Үпкәләп, өстәде. —Тәкәббер дә инде Маликшаһ! Һавалы. Илче итеп күкрәкле, түрә бер кешене түгел, ә, көлеп, нindидер бер йолкышны җибәргән бит. О күкләр! Нинди хәлгә төштек бит!

—Каханның йөрәге минем сүзләремә рәнҗемәсен, әмма... бу хакта элегрәк уйларга иде.

«Мондый бәндә беркайда да озак яши алмас,— дип уйлады кахан, ачуы килеп. —Туранда да, Иранда да, Исфаханда да, Хамаданда да. Артык туры. Үзеннән калдырмый йөртә торган линейка кебек. Һәм дорфа. Әмма дә ләкин икәү генә калгач минем турыда чын дөресен әйтүен үзем сорадым бит»,— дип исенә төшерде кахан.

—Сез әйбәт башладыгыз, падишаһ. Зур корылмалар төзедегез. Дошманнарыгызны кире кактыгыз. Авылларыгыз һәм шәһәрләрегез кешеләрен төрле кысрыклаулардан якладыгыз. Әмма, ачы хакыйкать өчен гафу итегез, бушкуык сүз осталарыгыз, ялагайларыгыз, аңгыраларыгыз: «бөек», «кояш йөзле», «чагыштыргысыз» дип сезнең башыгызны әйләндерделәр һәм сез, күңелегезгә авыр алмагыз, ялкауландыгыз. Шуңлыктан Маликшаһ табаны астына эләгүегезне сизми дә калдыгыз...

Келәм өстендә юан аякларын бөкләп, авыр бөкрәеп утырган хәлендә һәм имән бармагы белән сул итегенең кәкре очына суккалап, кахан тирмәнең бөкләнгән япма итәге астыннан җәйге станга карады. Инде олы яшьтә, кырыс, дала җилендә йөзе каралып беткән бу кеше, Гомәрнең гаҗәпләнүенә каршы, бүген үсмерләрчә тыныч, уйчан, кайгылы иде.

Якындарак кына, дөя чәнечкесе үскән комлы инкүлек артында, иске манара, дивар калдыклары сакланган уйсу калкулык китә. Варахша дип атала бу җирләр.

—Маликшаһның бик яхшы вәзире бар,— диде Шәмселмөлек. —Дәүләт акылы үзендә. Ә минем ялагайлар... илне талыйлар, мине харап итәләр. Маликшаһ ясакка озак риза булып тормаячак, килеп, мәмләкәтебезне талап китәчәк. Жизгәнсунын Тугрыл Карахан Йосыфы миннән Фирганәне тартып алды. Тагын да ерактарак, Төркстанда, нindидер каракытайлар пәйда булган (ул чакта Төркстан дип Кашгарны, Алтай һәм Монголияне атаганнар). Йә, Ходa! Безнең белән ни булыр? Сизәм: иксез-чиксез бәлаләр киләчәк... —Ул Гомәргә борылды, аның якасыннан эләктерде һәм төрекләрчә кайнар ярсу белән кычкырды: —Кал! Миндә вәзир булырсың, Маликшаһтагы якташың кебек. Әллә син булдыра алмыйсыңмы?

—Мин? —Гомәр аның юан кулын сак кына якасыннан ычкындырды, аны читкә этәрде. —Тәҗрибәм юк, әмма, өйрәнеп, мөгаен булдыра алыр идем. Теләсәм... булдырыр идем. Әмма мин, ачуланмагыз, галиҗәнап, теләмим.

—Ә ни өчен?

—Ни... күңелемә ятмый. Мин математик. Һәм шагыйрь. Һәркем үзе булдыра алганны эшләргә тиеш. Бары тик шуны гына.

—«Телим, теләмим!» Талымчан кеше син. Үзең теләгәнчә генә яшәргә ярамый.

—Ә ничек яшәргә соң?

—Аллаһы кушканча!

—Мин Аллаһы кушканча яшим дә инде!— дип кызып китте галим.—

Үзенчә булу, ягъни Ходай сине ничек булдырган, шулай яшәү гөнаһмыни? Бөтен нәрсә Алла кулында, дип әйтелгән бит!

* * *

Гомәр балачагында еш кына ачык зәңгәр һәм ак чынаяк кирпечләр белән тышланган, төнге күкне, йолдызларны гәүдәләндергән бик тә зур бинаны төшендә күрә иде; ул искитмәле зур мәрмәр бассейнның үтә күренмәле зәңгәр суында ничек булса шулай ялтырап, мәһабәт булып чагыла; аның артында, ак алебастр рәшәткә өстендә, салкынча тут агачларының куе, яшел тимгелле кәүсәләре каралып күренә.

Зәңгәр бассейн янындагы әлеге зәңгәр Йолдыз бина матур төшләрдәгечә, нәкъ мираж кебек килеп басты.

Ә башкалар—таза, тук, укый-яза белүче, рухлары азат кешеләр—кырларда һәм остаханәләрдә җырлап эшләячәкләр. Күп газаплар күргән әлеге җиргә яңа тормыш алып килергә фәкать фән генә сәләтле.

—Йөз динар да өч фельс! Шәп каршылыйлар монда кунакларны. Итсез төрекмән төрекмән түгел! Ә безгә кысыр тары өйрәсе ашаталар...

Гомәр килүчеләрне еракта, стан читендәге аерым чатырда тапты.

Кыйммәтле парчадан тегелгән киемле яшь кешене күргәч, бу бик күркәле кешедер, дип уйладылар һәм сикерешеп тордылар, нык иелеп, сәламләделәр.

—Кайсыгыз башлык?

—Сезне хөрмәт итүче хезмәтчегез,— дип алга чыкты озын, урта яшьләрдәге, буй-буйлы озын чапан кигән сугышчы. —Ни боерасыз, әфәндем?

—Ә-ә!— дип гаҗәпләндерде Гомәр. —Мин сине беләм.

Төрекмән аптырап калды, артка чигенде.

—Мин... сез...— дип кыенсынып мыгырданды ул, — кайда да булса очрашуыбызны... хәтерләмим.

—Очраштык! Уналты ел элек Фирүзгән юлында. Син—кыңык нәселеннән Ораз. Зур кеше булсам, сине онытмавымны сорадың. Менә мин шундый кеше хәзер! Һәм сине онытмадым.

—Йә Хода! —Төрекмән кинәт хәлсезләнде. Ул Гомәрнең аякларына егылды, башын аның итекләренә куйды. —Кызганыгыз! Зинһар, җәзаларга кушмагыз. Аңгыралыгым аркасында...

—Тор! Безнең Әхмәтне суйганда бер дә мондый юаш кеше түгел идең син.

Ораз авырлык белән генә аягына басты, күзләрен күтәрмичә, буйсынганны белдереп, кулларын җәйде.

—Син алырга килгән галим мин инде ул,— диде Гомәр, тегене тәмам аптырашта калдырып.

«Беттем!— дип уйлады Ораз. —Беттем, үлдем мин, каһәр суксын үземне!»

—Юлга җыенырга... боерасызмы?

—Юк әле,— диде Гомәр.

Зәңгәр Нишапур, Чәчәкле Баге-Санг. Кайгылы Мөхәммәд карт. Туганнар. Исфаханга барганда аларны күреп чыга алыр иде ул.

—Әйдә минем белән, бераз йөреп килик,— диде Гомәр тыныч кына. Ораз, куркуыннан як-ягына каранып, аны танымыйча һәм инде танып, аның янәшәсендә атлады.

«Үз башыма кызганганмын икән. Шул чакта Фирүзгән юлында башын бетергән булсам, хәзер бернинди мәшәкать калмас, күптән инде бөтенесе онытылыр иде».

—Йә, Хорасанда ниләр бар?

—Һаман элеккечә. Байлар баетый, хәерчеләр тагын да ныграк хәерчеләнә.

Их, сагыш! Күптән сүнгән кебек иде дә, юк, менә хәзер, учактагы пыскып яткан күмердән ялкын дөрләп киткән кебек, кара тәтен булып өскә калыкты.

Хәтта шушы башкисәр Ораз да Гомәргә күз яшьләрен китерерлек якын булып тоелды. Чөнки ул кинәт шундый тупас һәм күзгә күренеп, тере һәм сау-сәламәт килеш, якты күзләре, көчле тавышы белән туп-туры анның балачагыннан калкып чыкты.

«Исфаханга кайтканда үтерергә кирәк. Ә солтанга: юлда авырып үлде, диярбез. Дусларым сатмас әле. Әллә—кем белә? Сатулары да ихтимал».

—Бар, кайт. —Гомәр карамыйча гына аңа бер алтын бирде. —Тәкә сатып алып суй да, кыздырып, дусларыңны сыйла. Һәм аларны юлга чыгарга әзерлә, һәр мизгел юлга чыгарга әзер булып торыгыз. Китәмме мин сезнең белән, юкмы—сиңа монда ятудан файда юк.

«Ә! Анын миндә эше юк. Үз кайгысы да башыннан ашкан. Үч алмас микәнни? Ярый, күз күрер әле».

Ул юлда төрекмәннәрне туйганчы ашатты, тукталышлар вакытында, зур белемлелеге белән масаймыйча, чын күнелennән жир турында, анда яшәүче халыклар, планеталар һәм йолдызлар, әйберләрнең үзенчәлекләре турында сөйләде, кыскасы, үз кешегә әверелде. Һәм Оразның шикләнү ташы арасыннан чыккан яшел ышаныч сабагында алсу хөрмәт гөле чәчәк атты.

—Бөек Тәнрем! Ул тотып калган минем кулымны. Ул чакта сиңа тигән булсам, нинди акыллы башны харап иткән булыр идем! Уйларга да куркыныч хәтта, йөз динар да өч фельс...

—Рәхмәт. Тик шулай да ничә акыллы башка тидең син?

—Күп. Хәзер аңлыйм: юкка тигәнмен. Солтанга яхшы аңа. Ә мин ничек ач-ялангач булсам, хәзер дә шулай. Кем иренми, шул куа тегендә-монда. Энекәшем сугышта һәлак булды. Ни гаебе бар иде энекәшемнең? Унтугыз яшендә бит...

Жәйхун.

Юлдашларын шаяртмакчы булып, Гомәр ялтырап яткан су өстенә тоныκ караш ташлады да муенын жыерды.

—Утырмыйм мин көймәгә.

—Куркасыңмы?— дип сорады Ораз, гажәпләнеп.—Менә сиңа кирәк булса! Монда ел саен егерме мең кеше йөзеп чыга, берәүнең дә батканы юк. Утыр.

Елга өстендә төрекмәннәр хәйләле генә күз караштылар да шагыйрьне шаяртмакчы булдылар:

—Батучыга салам да бүрәнә, диләр, дөресме шул?

—Дөрес. Батучысы кандала булса.

—Берәүнең кызы көчле агымга егылып төшкән. Әтисе аңа: «Мин сине тартып чыгарырдай кеше тапканчы урыныңнан кузгалмый тор!»—дип кычкырган, ди.

Хәвеф-хәтәрсез генә икенче ярга чыктылар. Төрекмәннәр:

—Чынлап та курыктыңмыни?— дип сорадылар. —Их, галим! Димәк, башлы булсаң да, бик ук батырлардан түгел икәнсең, ә?

—Батып үлү куркыныч түгел анысы,—дип тыныч кына жавап бирде Гомәр. —Килер буыннарның: «Шундый-шундый сукбай шагыйрь, хөр фикер иясе фәлән елны Жәйхунда батып үлгән»,—дип әйтүләре куркыныч. Оят!

—Ә нигә оят?

—Шагыйрьгә елгада тончыгып үлүгә караганда хәрчәүханәдә шәраб эчеп үлү килешәрәк.

Төрекмәннәр рәхәтләнеп көлде. Тик Оразга гына ошамады бу. Ул Гомәрне читкәрәк алып китте:

—Үз-үзеңә алай бәла якма,— диде ачулы гына.—Кешеләрне белмисеңме әллә? Син шаяртып әйтерсең, ә алар чынга алырлар, дөньяга таратып, гомерлеккә даныңны сатарлар.

—Әй!—Гомәр исә китмичә генә кулын селтәде.—Шагыйрь гайбәт

таратучылар турында уйлап яши алмый. Үз акылын, үз йөрәген тынлап яшәгәнгә шагыйрь дә инде ул.

—Уйламыйча сөйләгән сүзләренә үкенерсең әле бер.

—Күрербез...

Әмма барыбер шаярту бушка булмады. Шуннан соң Гомәр яна танышларын яхшырак белде. Алар эссе кояш астында шайтан таягының ачык чәчәкләре кебек ачылдылар. Үзләренә беркем тимәгәндә, беркем кыйнарга, тотарга, ватарга мәҗбүр итмәгәндә, төрекмәннәр шат күңелле, игелекле, дуслыкка тугрылыклы халык икән. Кешене үзе теләмәгәнне эшләргә мәҗбүр итмәсәләр, җир йөзендә күптән тынычлык булыр иде, мөгаен.

Тау артында—Нишапур. Ул тиздән туганнарын күрер. Ниһаять, аларга ярдәм итә алыр. Аннары—Исфахан. Күнелгә яткан эш. Исфаханда ул Бохарада эшли алмаганнарны да эшләр.

• • •

—Әтиен?— дип кабатлап сорады таныш түгел карт. —Кемнең әтисе? Аһ, синеке! Кайда ул, дисеңме? Әтиен юк инде синең...

«Үлдемени?» —Елганы кичкән вакытта өчлы ташка бәрелеп ертылган тыгыз күннән чыккан һава кебек, Гомәрнең йөрәгеннән авыртулы сыкрау бәреп чыкты, шул мизгелдә яшьлек шатлыгы үтеп китте, һәм ул, бөтенләй бушап, карт алдында башын иеп басып торды.

Искитмәле пычрак, укмашып беткән ак чәчле, сәләмә киемле карт остаханә ишеге янында тишкәләнеп беткән чыптада утыра һәм буш күзләре белән каядыр карый иде. Кем ул, ни өчен бирелә утыра? Баге-Сангтан Мөхәммәд түгелме соң бу?

Гомәр аны яхшылабрак күрер өчен иелде һәм җирәнеп кире тайпылды: борынга черек ис килеп бәрелде. Юк, Мөхәммәд түгел.

«Остаханәгә керим, шунда бөтенесен белермен».

—Гомәр!

Анын муенына кырыс йөзле бер карчык ташланды. Гомәр башта уйлаганча буарга түгел, кочакларга. Ул бик кыенлык белән генә анын үз әнисе икәнен таныды. Менә нинди хәлгә төшкән ул! Нибарысы дүрт ел эчендә. Хәерченең бер көне өч көнгә тора, дип белми әйтмәгәннәр шул. Шуннан башланды. Кычкырыш, күз яше, үксү.

—Әтигә ни булды?

—Ничек? Син анын белән исәнләшмәдеңмени? Менә бит ул. —Әнисе җирәнеп кенә исе анкып торган картка ымлап күрсәтте. Ә тегесе бар нәрсәгә битараф кыяфәттә җирдә утыра иде. —Хәзер ул суфый...

Гомәр катып калды.

Элеккегә караганда өч тапкыр ябыккан Ибраһим селкенә-селкенә улый башлады:

—О Аллаһ! Мин шәригатьне өйрәндем һәм Ходайга бер баскычка якынайдым. Үз ихтыярымнан ваз кичеп, кодрәтле Ходай кулында юучы кулындагы мәеткә әверелеп, икенче баскычка—тарикатка күчтем. Хәзер мин өченче баскычны—марифатны үтәм. Мин инде иң югары хакыйкатьне аңлауга якын, ул мине яктырта инде.

«Үтәли яктырта»,— дип ачынып уйлады Гомәр.

—Мин инде игелек һәм явызлыкның теге ягында! Ходам, мин синең йөзеңнән башка берни дә күрмим. Фана фи-лла! Мин дүртенче баскычны—хакыйкатьне күрәм. Миндәге барлык фанилык сүнә, мин Аллаһыга кушылам, якты мәңгелеккә чумам!

Ул тынып калды, күзләрен йомды һәм, чыннан да, ниндидер томанлыкка, баткаклыкка, бушлыкка чумып, үзен мәңгелек рәхәтлектә итеп тоядыр.

Йокладымы? Юк, фанатлык күп сүзле. Аны берничек тә туктата алмыйсың. Бәлки үлем генә туктатыр. Күзләрен ачмыйча һәм көчле селкенеп, Ибраһим кычкыра:

—Минем күнелемдә уй юк! Сөйлим, әмма минем сөйләмем юк! Күрәм, тик күрү сәләтем юк. Ишетәм, ләкин ишетү сәләтем юк. Ашыйм, тик тәмне тоймыйм! Хәрәкәтем дә юк минем, тынычлыгым да, шатлыгым да, кайгым да юк. Фәкать Алла гына... Фәкать Алла!!!

—Әти! Нишләттеләр сине, әти? —Күз яшьләренә тыгылып, Гомәр инде күптән кипкән ботаклы агачны алган кебек картны җирдән күтәрде һәм, аннан килгән искә түзеп, битеннән үбә башлады: —Кулларыма күтәреп, хәзер мин сине мунчага алып барам! Шундук җанланып китәрсең син. Чиста кием алып кил әле.

Әтисе усал итеп кулын селтәде: янәсе, булышма, барыбер файдасы юк.

Улы аны сак кына чыптага төшерде.

—Уян, әти! Мин күп итеп акча алып кайттым. Хәзер бөтенесе башкача булачак. Моннан соң ачыкмаячаксыз.

Анын каравы сенлесе Гөлмохтар сөендерде Гомәрне. Мондый сөйкемле, акыллы, ягымлы, матур итеп сөйләшүче кызны аның әле күргәне юк иде. Әмма шунысы кызганыч, шунысы бәгырьне телгәли—ул бик ябык, юынмаган, сәләмә киемнән иде.

—Аны, аның язмышын кайгырт!— дип караңгы йөз белән әйтте әнисе. Алар Гомәр акчасына мул итеп алынган ризыкларны ашаганнан соң өчәүләп чоланда утыралар иде. —Синең атаң инде берни дә кирәкми. Ул бүген булмаса иртәгә... Аллаһысы белән кушылачак. Акча бирмә аңа, әрәмтамак остазына илтәчәк. Миңа калдыр. Безне иктадан коткара алсаң, остаханәне минем исемгә яздыр. Ишетәсеңме?

—Ишетәм. Шулай эшләрмен, әни. Фәйрүзә турында берәр нәрсә белмисеңме?

—Юк! Каһәр генә төшсен үзенә!

—Ә Мөхәммәд карт ничек?

—Үлде. Каһәр...

—Ә Баге-Сангтагы йорт ничек?

—Бикләнгән килеш! Каһәр...

Авыр сулап, Гомәр әкрен генә ишегалдына чыкты. Әвеслектә, чүпрәк-чапрак өемендә Ибраһим түшендә ыңгыраша иде. Гомәр күккә карады.

«Ни өчен? Һәр адымымда коточкыч газапларга очрап тору өчен бу җирдә нинди ярамаган эш эшләдем соң мин? 0, күкләр! Кодрәтемнән килсә, сине җимереп, башка белән алыштырыр идем. Тагын нәрсәләр әзерләп куйдың син миңа? Нәрсәләр?»— дип акылдан язар дәрәҗәгә житкән ачу белән сорады ул салкын күктән, гәрчә аның дәшмәсен белсә дә.

*Ахыры киләсе санда*



Чулпан
Зариф

## ТӨРКИЯДӘН—ИЛГӘ, ИДЕЛГӘ

### Исәнме, Истанбул!

1

**Исәнме, Истанбул—солтаннар каласы!**
**Тагын мин әле бу—бер татар баласы...**

**Дөньялар үзгәргән, ә даның һаман шул.**
**Җиңелме, авырмы дан саклау—«йөк ташу?»**

**Исәнме, Истанбул! Синең күк томанлы**
**Диңгезләр һавасын эчкәннәр аманмы?..**

**Даны гел дәүләтле, тарихы тәхетле**
**Шәһәрдә яшәве чыннан да бәхетме?..**

**Баязит мәчете, Сөләйман, Шаһзадә...**
**Бер дога кылучы булыр бит безгә дә?..**

2

**Юлдагы һәр ташың алтынга тиң, диләр.**
**Мәрмәрдән коелган кочагың киң, диләр...**

**Яуларга килгәннәр, сине бер күрүгә,**
**Әсиргә әйләнеп, даныңа күмелгән.**

**Мин сине, Истанбул, җиңәргә килмәдем,**
**Тәхеткә утырып, кеш туннар кимәдем.**

**Мин монда бары тик бер гариб, юлаучы.**
**Мин—сиңа йөрәгем җибәргән бер яучы...**

---

Чулпан ЗАРИФ-ЧЕТИН—*шагыйрә, әдәбият галимәсе; «Кояшка юл тота кәрваным» исемле шигырь китабы һәм Сәгыйть Рәмиев турында фәнни җыентык авторы. Төркиядә яши. Мугла университетында төрки әдәбиятлар укыта.*

Зәп-зәңгәр гөмбәзгә хыялдай очынган
Күгәрчен кебек мин, беркемне борчымам.

Истанбул! Учыңа талчыккан күңелдән,
Шигырь күк, мин бүген үзем дә түгеләм...

3

Кәнизәк назлаган солтандай җил исә...
Аһ! Шушы назларга тагын бер җиңелсәм!..

Кем идем үткәндә, көрпә бер киленме?
Солтаннар каршымда башларын идеме?

Әллә соң сугышта алынган ганимәт
Идемме? Базарда сатылган кол, димәк...

Ханлыкмы, хурлыкмы яшәгән бу җаным,
Өметен өзгәч тә, яшәрме ышанып?..

Тузанлы китапта кайсысы минем бит?!
Юк! Миңа бүген дә яшәргә насыйп ит!..

Истанбул! ...Яңгырмы сибәли түбәгә?
Яңгырлар астында рөхсәт ит үбәргә

Синең чал йөзеңне, күшеккән кулыңны,
Кояштан каралган куркусыз улыңны..

4

Истанбул! Тынгысыз, тетрәнгән заманда
Килдем дә катыңа, киталмыйм һаман да...

Югыйсә еракта көткәннәр, Казан бар!..
Анда да бәйрәмнәр, мәчетләр, азан бар!..

Идел-йорт! Бәлки ул синнән дә данлырак,
Күңелгә бик якын, кайтырга—бик ерак...

Талчыккан, ачыккан хәтергә ял эзләп,
Истанбул, мин сиңа юнәлдем бу көздә!..

Яраннар тибрәлә, җил исә. Җил исә...
Бу кадәр сөюнең сәбәбен бер белсәм!..

Җир тетрәп, хәрабә хәленә килсәң дә,
Мин янә дәшәрмен:—Истанбул, исәнме!..

* * *

Бадәмнәр чәчәктә... һавада—бал исе...
Яз белән килгәнсең, яз булып кал дисең...

Булмас шул... куйса да күңелләр җилкенеп—
Мәңгелек түгел без, йөгәнсез җил кебек.

Җил... җирнең хәтерен яшәткән риваять...
Мәҗүси китаптан өзелгән бер «аять»...

Исәр дә, тузгытыр чәчәкләр галәмен,
Очыртыр күкләргә язның ал әләмен!

Илемнең дәүләтле язларын уздырып,
Чулпылар чыңлатып, толымнар туздырып,

Сүндереп даланың мең еллык учагын,
Имәндәй ирләрнең суытып кочагын,

Иделдән килгәнме? Шул якка китәме?
Сагышлы ирендә мәҗүси җил тәме...

Чарасыз бадәмнәр бәс кебек чәчәктә:
Җил белән китәсе, яз булып килсәк тә...

* * *

Син яшәгән ул якта
Тауларга карлар яткан...

Ә мин монда тауларга
Йөрим сагыш «ауларга»:

Агачлар арасыннан
Яралы болан сыман—

Ялваргандай үземә,
Сагыш карый күземә...

...Үзәннәргә таулардан
Агыла куе томан.

Эрбетләрнең ылысын
Кочып, килә елыйсым...

* * *

Учларымда—мөлдерәмә күңел...
Түгеләсең килсә—әйдә, түгел!

Бармак очларымнан—тезләремә
(Эссесенә генә түзәрмен лә!),

Тезләремнән—аяк очларыма,
Җирнең тетрәп торган кочагына

Түгел, күңел! яшькелт күзләремнән—
Әфлисунлы, җылы козләренә

Түгел, әйдә, мөлдерәмә күңел!
Чит булса да җире, шул ук күге!..

...Күңелемнең кайнар күлдәвеген
Әлсерәгән кояш эчсен бүген!

Күңел бит ул җиргә махсус түгел,
Җирне җиңеп, күккә күчә күңел...

* * *

*Луиза Янсуарга*

Яшәү дә, сүнү дә—бар да бар!
Өзелгән өметләр азмыни?!
Көз дә бар, кар да бар... Күңелдә
Һәр заман кояшлы язмыни?..

Җир буйлап йөгергән җаннарның
Карашы (ни гаҗәп!) гел күктә.
Күкләргә агылган җаннарны
Бу җиргә Күкләрдән кем түккән?!.

Комнарда чагылган шәүләләр
Мәңгегә күмелгән йолдызга...
...Күкләрдән ни генә сорарга
Су эзләп чүл гизгән бу кызга?!

* * *

Бу ни гаҗәп иртә! Кәлтә елан ташта,
Башын сузып күккә, нурга күмә тәнен.
Кояш—юмарт, Кояш һәр көн яңабаштан
Килә бу дөньяга, бозып төн матәмен.

Кошлар гаҗәп... кошлар, басып юл читенә,
Карап кала арттан, кырын салып башын.
Лалә чәчәк аткан... белмим, ничек кенә
Шытып чыга алган бәгыреннән ташның...

Ташбакалар чыккан кояш җылысына,
Таш калыпка салып көрпә күңелләрен.
...Эрбет агачының һәрбер ылысыннан
Чыклар тама.
Җылы.
Тик җәй түгел әле...

*Мугла—Истанбул.*
*Төркия.*



Зәки
Зәйнуллин

# МӘУЛЕТ ГУСАР

ПОВЕСТЬ

Пугачне тотып, Мәскәүнең Болотное мәйданында зур тамаша ясап, башын чабалар. Шул вакыйгадан соң утыз еллар чамасы вакыт узгач, Бәхтиярдә есаул булып сугышкан һәм үзен тоттырмыйча, аның белән бергә качып чыгып киткән Зәй-Каратайның Төхфәтулла исемле кешесе туган авылында пәйда булды.

Таякка таянган, сакал-мыегы агарган, чалмалы, сырган озын чапанлы, башлары өскә таба кәкрәебрәк торган, читек дисәң читек түгел, итеккә дә бик үк ошап бетмәгән аяк киеме кигән ул карт Бөгелмә каласы ягыннан килгән юл белән, ниһаять, Зәй-Каратайга житте.

Кабаланмый гына атлап, тау ягынарак урнашкан күп өянкеле урамга чыкты. Авыз эченнән генә укына-укына, урам башыннан дүртенче, зур бакчасы елга ярына барып терәлгән, жил капкалы, янарак кына үргән яшел читәнле йорт янында тукталды. Сүзсез генә йорт каршында, яшел каз үләне өстендә басып, ике куллап таягы башына тотынган хәлдә, йортны, абзар-кураны, яна матур читәнне, жил капканы бик тә жентекләп карап чыкты. Чит кешенең килгәнен сизеп, кечкенә, соры төстәге йөнтәс көчек, капка астыннан тәгәрәгән йомгак кебек кабаланып килеп чыкты да, очлаеп киткән кыска гына койрыгын тиз-тиз боргалап, селкеткәләп, өрә белгәнен күрсәтеп тавыш бирде:

—Лән! Лән!

Бабай көчеккә карап, бөтен йөзен балкытып елмайды:

—Әллә танырга итәсең инде мине, мәхлук жан!

Иелеп көчекнең аркасыннан сыйпады, колак артларын, тамак төбен кашып алды. Көчек исә телен чыгарып, картның бармакларын ялап алды. Бабай, турайды да, капкага карап атлады.

—Әгүзе билләһи минәшшәйтаанир-рахиим...

Бабай кечкенә ян капканы ачып кереп берничә адым атлауга, өйдән арырак салынган читән абзардан аркан белән сәнәк тоткан кырык биш яшьләр чамасындагы, кырма сакал-мыеклы бер ир кеше килеп чыкты. Аркан белән сәнәкне абзар алдында торган кабык арбага салды да, кереп килгән мосафирне күреп, аңа таба атлады. Йөзендә якты нур пәйда булды.

—Әссәләәмугаләйкүүм сиңа, ерак юллар үтеп безне шатландырырга килгән жанга! Әссәләәмугаләйкүүм!

—Вәгаләйкүм... эһ-һем, эһ-һем... вә галәйкүм әссәләәм сиңа... хужа кеше...

Зәки ЗӘЙНУЛЛИН (1933)—*язучы, галим, техник фәннәр докторы; «Полковникны озату», «Ник ямансу бу күзләр?», «Агыйделнең арьягында...» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

—Әййе, абзый! Хуҗасы мин бу йортның.

—Алай икән?! Йортың яңа икән! Күптән бетерденме?

—Бу йортны җиткергәнгә сигез ел тулып, тугызынчыга китте инде. Әйдә, керик. Чәй эчәрбез!

Картның күзеннән бер-бер артлы яшь тәгәри иде. Хуҗага таба атларга итте—аяклары тыңламады. Тавышы тагын да ныграк карлыгып чыкты:

—Исем... Исем-шәрифең синең Әмәметдинме?

—Ә син минем исемне каян белдең, абзый?

Картның җавап бирергә хәле җитмәде, ахрысы, баскан җиреннән күкрәге белән таякка ябышкан ике кулына ята биреп, ул тавышсыз гына елый иде. Хуҗа сискәнеп китте, күзләрендә гаҗәпләнү катыш аптырау чагылды.

—Син?! Син бит... и-и-и!..

Картны кочаклап алды. Таныды!

—Әтием бит син минем! Төхфәтулла әтием!

Бабай, таягын уң кулында тоткан килеш, сакланып кына ике куллап улын кочаклады. Ике таза гәүдәле ир кочаклашкан хәлдә елыйлар иде.

—Әйдә, әти! Үз йортыңа! Тик әни генә бу бәхетне күрә алмады. Әйдә, кер өйгә!

—Үзегез ничек соң, исән-иминнәрме?

—Әнинең вафатына ике ел тулып өчкә китте. Абый исән-сау. Үз йорты белән яши. Бала-чагалары бишәү. Чагалары дисәң дә, зурлар инде. Өчесе башлы-күзле. Ул Түбән очта, Чулак Газулла бабай күршесендә яши. Чепи Әхәт урынында. Сенелкәш ерактарак—Аю авылында кияүдә. Кияү бик асыл зат—мулла нәселеннән.Ике малайлары бар. Үсеп киләләр...

Шулай диде дә улы, өй ягына карап кычкырды:

—Мәфтуха-а! Мәфтуха-а ди-им! Чык әле бире!

Өй ишегеннән кулларын тастымалга сөртә-сөртә, ак яулыгын башына арттан тарттырып бәйләгән, чиккән алъяпкыч буган, аякларына йон оекбаш өстеннән күннән теккән чүәкләр кигән бер чибәр генә хатын пәйда булды. Үзе матур итеп елмая иде.

—Әй, шушы гадәтеңне-е! Берәр нәстә исеңә төшсә, тотынасың «Мәфтуха» дип сөрән салырга. Ни булды тагын?

Ире янында басып торган бабайны күргәч, яулык чите белән авызын, ияген каплады.

—Исәнлек-саулыкмы... абзый? Әйдә, уз өйгә! Кыстыбый пешергән идем, чәем дә өлгергән. Ризыкка язган булсын. Әйдә, кер! Хәзер җылы су салам комганга. Өй эчендә, таска гына юдыр кулларын...

Ире, сул кулын аз гына күтәрә биреп, хатынны туктатты.

—Мәфтуха! Бу безгә кунак кына түгел. Пугәч явы белән чыгып киткән әтиебез Төхфәтулла бу. Әййе, Пугәч явында Әби патшага каршы сугышып йөргән әтиебез безнең. Исән-сау кайткан менә туган якларга. Үз йортына кайткан...

Аннары әтисенә борылды:

—Киленең бу, әти! Биш малай анасы!

Күзләре тулы ярату җылылыгы иде улының. Мәфтуха тартынып кына, көтелмәгәннән бар булган иренең әтисенә таба, ике кулын алга сузып, исәнләшергә атлады.

—Кая, күрешик-исәнләшик... Әт-ти! Мин киленең булам инде. Югары Оч Читән Фәйзулла кызы мин. Әйдә, әти! Кер үз йортыңа, үз нигезеңә! Аллага мең шөкер! Исән-иминсең икән! Инде без сине исәндер дигән өметләрне дә өзгән идек. Ничәмә-ничә еллар бит инде синең гаип булганыңа. Әйдә, әтиебез, кер өйгә!

Догалар укый-укый баскычтан күтәрелеп өйгә керделәр...

Мунчадан соң, аркасына тун салган Төхфәтулла келәт алдындагы бүрәнәләр өстендә ике улы белән гәп корып җибәрде.

—...Казан каласын алганда урыс тубы шартлап, бер тимер кыйпылчыгы тигән иде мина. Шул тәндә йөри. Инде аска төшеп билгә житеп килә. Аяккул авырайды соңгы өч-дүрт елда. Йөрүләр читенләшә. Өстәвенә картлык баса башлады. Аннан соңгы елда ашау да кысыла башлады. Юк-бар ашасаң, ашказаны авырта. Күбрәк катык-сөт, кымыз кирәк. Мин яу белән чыгып киткәндә берегезгә унзүрт, икенчегезгә унике яшь иде. Сеңлегезгә әле биш тә тулмаган иде. Бармак озынлык кына кара төстәге ике чәче бар иде үргән. Ул инде мине хәтерләмидер дә...

—Хәбәр иттердек. Кече малайны ат мендереп жибәрдем. Иртәгә килеп житәрләр, шәт!

—Рәхмәт, улларым! Килсеннәр! Күрешеп, сөйләшеп калыйм барыгыз белән дә. Дөнья йөзендә бүген миннән дә бәхетле кеше юктыр...

Зур улы сорыйсы итте:

—Әти! Әби патшаның куллары бик озын булган бит! Ничек эләкмичә котыла алдың син? Кайларда гомер кичерден бүгенге көннәргә кадәр?

Төхфәтулла тамагын кыргалап алды:

—Казанны ташлап качканнан соң, Идел буйлап аска төшеп киттек. Байтак шәһәрләрне алдык: Самар, Сарытау, Сары Чин...

Аннары авыр гына көрсенеп куйды.

—Аннан безне туздырып ташладылар. Палкауник Бәхтияр Пүгәч патшаның качканын каплап торып калды. Арабызда татар, чуаш, мари иде. Яртыбыздан күбебез кырылды Михельсон дигән, Әби патшаның палкаунигы белән сугышып. Аннан инде качтык ат менеп төн житкәч, тукталдык. Безнең һәрберебездә икешәр ат иде. Ял итеп тормадык. Жан кадерле, балалар—төне буе чаптык кыргыз-кайсак далалары ягына. Ырымбурны сулда калдырып, Тозтүбәгә чыктык, аннан инде бик ныклап кин дала башланды. Көндез күбрәк йокладык, төнен йолдызларга карап, тавыш чыгармаска тырышып, атлар менгән хәлдә бардык та бардык. Хәтта жирле халыкка да күренмәскә тырыштык...

Өч йөз кеше чамасы идек. Бәхтияр читтән килеп кушылып иярергә тырышканнарны, без аларны белмәгәнлектән, үз арабызга кертмәде, иярмәде. Чөнки шулар арасында Әби патша шымчылары булуы бик ихтимал иде. Туктый-туктый, кышын жир чокып кереп, атларны тибенгә күчереп, шуларны суеп ашадык. Шунда кышладык. Даланың кеше яшәмәгән урынында идек, килгән-киткән кеше булмады. Михнәт хәттин ашты....

Кар эреп, дала ачылу белән тагын кузгалдык. Көньякка карап киттек тә киттек. Кышын егермеләп кеше үлде. Шулай да без байтак идек, коралланган барыбыз да. Кыргыз-кайсаклар, үзебез тимәгәч, безгә дә тимәделәр. Барабара, Кашгар якларына барып чыктык. Элекләре бу якларга сәүдәгәрләр белән йөргән ике кеше бар иде. Юлны беләләр иде алар.

Бәхтиярнең үзе белән хатыны, ике улы, кызы бар иде. Кашгарга житәрәк, алты атка салып алып килгән зур төеннәрне, капчыкларны бушаттырды Бәхтияр. Шул төеннәрдә, капчыкларда бик күп алтын, көмеш тәнкәләр булып чыкты. Шул алтын, көмеш акчаларны барыбызга да тигез итеп бүлдерде. Бала-чагага да, зурларга да өлешне тигез чыгарттырды. Үзен дә өстен куймады—кеше алганны алды. Соңгы сүзен әйтте шунда. Акча бүленеп бирелгәч:

—Безгә туган-үскән жирләргә кайту насыйп булмас инде. Кылыч тагып йөрү дә килешеп бетмәс чит якларда. Моңдагы халык үзенчә яши, без алар арасына корал тотып килеп кермик инде. Тынычлык, солых белән, елмаеп керик. Таралышыйк. Тик, ялгыз гына калып, берәмләп китмәгез. Барыгызда да алтын-көмеш бар эш башларга, сәүдә итәргә житәрлек мая сездә. Икешәрөчәр булып китегез. Бергә урнашып, бергә яшәргә тырышыгыз. Пүгәч балалары сез! Шуны онытмагыз! Шулай булса да, Пүгәч гаскәрендә сугышканыгызны юк-бар жирләрдә сөйләнеп йөрмәгез. Ул турыда, сугышканны әйтүем, онытыгыз! Урыс патшаларының һәрчак кулы озын

булды—безне эзләп табарга тырышырлар,—диде ул. Бераз тын торгач, сүзен янә дәвам итте:

—Минем уйлавымча, һәм дә азрак хәбәрдар булуымча, безнең Кинҗә батырыбыз да урыс кулына эләкмичә, шушы якларга юл тоткан булырга тиеш. Алай-болай очрап куйса, таныганыгызны сиздермәгез, башлап сүз кушмагыз. Чөнки Кинҗә батыр Пүгәч патшаның иң ышанычлы сугышчысы, аның уң кулы иде. Ул турыда үзегез дә беләсез. Чөнки Пүгәчтә күпчелек татар, чуаш, башкорт, мари сугышты. Үзегез күрдегез, башкорт якларында күпчелек урыс Әби патшаны яклады. Шунлыктан Пүгәч патша андагы урысны Көнгер ягына кудырды...—Шулай диде дә Бәхтияр, безнең алга чыкты. Колакчын бүреген салып башын иеп хушлашты. Дүрт иптәшен алып китеп барды. Шуннан соң мин аны күрмәдем...

Куй белән сәүдә иттем. Баеп та китеп булмады, бик нужа-михнәт тә күрмәдем. Әфган якларына барып чыктым, Кандагар каласында яшәдем. Өйләнмәдем. Чөнки үлем җитә башлагач, туган якка кайтып китәремдә шигем юк иде. Чит якларда туган сабыйларны туган якларыннан аерып алып кайтып китәсе була иде. Әнкәгезне бик тә сагындым. Сез балаларымны! «Безне ташлап качкандыр», дип уйлаган чакларыгыз да булгандыр. Инде кайттым. Җыйган алтын-көмешем дә бар азрак. Өчегезгә дә тигез итеп бүлешеп алырсыз. Иншалла, бәхәскә кермичә!

Ярар! Кайттым, сезне күрдем. Кызым килсә, аны да күрербез, иншалла! Инде үлсәм дә үкенмим хәзер! Тик менә Мәүлет улыгыз өйдә юк икән...

—Иртәгә кайта ул, әти. Минзәлә базарына киткән иде, ике йөк бодай оны белән. Хөкүмәт кешеләре килеп базардан күпләп он җыялар. Хакны да ярыйсы гына түлиләр. Ык белән Агыйдел елгалары аша Чулманга, Иделгә озаталар. Урысны ашатабыз.

Абзасына карап алды да, бик күңелледән булмаган хәбәрне әйтте:

—Җирәбә анарга төште,—Мәүлет улыбызны ак падишаһ хезмәтенә алалар бит әле, әти.

Төхфәтулла карт дәшмичә байтак утырды. Аннары акрын гына:

—Урыс бөкте, сындырды без татарны,—дип сүз башлады, чын ир-егетләр бик сирәк хәзер татарда. Урыс үзе патшасын «ак» дип атаса да, патшаларының эче тулы кара елан, юлбасарлык һәм урыс булмаганнарны юк итү теләге. Кулга кылыч, сөңгеләр, ук-җәяләр алып, ат иярләп менеп урыска каршы чыгарлык көч тә, ир-егетләр дә юк бездә хәзер. Гайрәт-тәвәккәллек беткән без татарда. Ә башкорт, урыс кулы астында, кыргыз-кайсакларны буйсындырып, аларның канын коеп, сугышып йөри. Урыска яңа җирләр яулап ала. Чөнки башкорт табигате белән хуҗасыз яши алмый. Башта башкорт өчкә бүленеп татар ханнарына хезмәт итте. Казан, Әстерхан, Себер ханнарына. Аннан мангулларга чыгып китте. Инде урыска баш иеп бирелде башкорт.

Татарга килсәк, минем кебекләргә, яңа туып-үсеп килгәннәргә нәрсә кала инде? Миңа инде көче беткән кулларны йомарлап, сез буйсынган, аңа ярарга тырышып хезмәт иткән исерек урыска карап уртны чәйнәп, капка төбендә утыру кала...

* * *

Икенче көнне, көтү кайтыр алдыннан, ике буш олау белән Әмәметдиннең зур улы Мәүлет кайтып төште. Атларны тугарышырга дип ишек алдына чыккан әтисе белән ике куллап күрешсә дә, өй болдырында басып торган олпат гәүдәле ак бабайны күргәч, сораулы күзләрен әтисенә күчерде. Анысы елмаеп шатлыгын белдерде:

—Улым, бу инде синең Пүгәч патшада, палкауник Бәхтиярдә ясаул булган Төхфәтулла бабаң була. Исән-имин менә! Исәнләш, бар, дәү әтиең Төхфәтулла белән!

Кин җилкәле, таза бәдәнле, көчле егет иде Мәүлетдин. Төхфәтулла бабасы

янына килде дә, кочаклап алды. Төхфәтулла, әйтерсең лә, үзенең яшь чагын күрде. Нур чәчеп торган, картаюның нәрсә икәнен дә белмәгән коңгырт күзләре белән оныгына сокланып карады.

Мәүлетдин телгә килде:

—Мин, дәү әти, синең турыда дәү әнидән сораша торган идем. Бәләкәй чактан ук. Ул синең ниндилегеңне болайлар итеп сөйли торган иде: «Олпат гәүдәле, көчле зур куллы, киң күнелле, матур, кешеләргә һәрчак ярдәмчел иде синең дәү әтиең!» Инде мин үсеп, егет була башлагач, сине сорый башласам, башымнан сыйпар иде дә, әйтер иде:

—И-и, Мәүлетдин балам! Тач син иде инде дәү әтиең! «Аны күрәсең килсә, бар, көзгедән кара!» Үзе кет-кет килеп көләр иде әбекәй...

Чыннан да, бабай белән онык нык охшаган иде бер-берсенә. Шунлыктандыр инде, Мәүлетдин мәрхүмә әбисенең яраткан оныгы иде. Бабай белән оныгы, икесе дә олпат гәүдәле, киң күкрәкле, төптән юан чыккан затлар иде. Тик Төхфәтулла сугышлардан алган җәрәхәтләреннән, картлык авыруларыннан сулыга башлаган бабай булса, Мәүлетдин көч-гайрәте ташып торган, һәрчак елмаеп, «кая, тагын нинди эшегез бар»,—дип һәрчак эшләргә атлыгып торган, үзе сабыр холыклы егет иде.

Дәү әтисе кайтканга сигез көн дигәндә, Мәүлетдинне урысларның Минзәлә кальгасына солдат хезмәтенә алып киттеләр. Җирәбә буенча...

• • •

Ипи-тозлык та урысча белмәгән утызлап татарны Минзәлә кальгасындагы зур, кызыл кирпечтән салган ике катлы йортка кертеп урнаштырдылар. Тылмач булып йөргән керәшен татары Дангаев бу «казарма» исемле урыс йортында ничек яшәргә кирәклекне өйрәтте:

—Бәдрәф—урамда. Казармадан чыккач, койма буйлап салынган озын такта бина. Бер катлы. Унике ишекле. Суны монда атлы мичкә белән ташыйлар. Сез йоклаган бүлмәнең ишек төбендә, тумбочкада чиләк белән эчәргә су сезгә. Янында бакыр кружка. Берәмләп, ялгыз гына казармадан чыгып йөрмәгез. Урысларның кыйнаулары ихтимал. Аннан уяу булыгыз—урысларның сезнең янга кереп ризыкларыгызны, акчаларыгызны талаулары, имгәтүләре дә бик ихтимал. Сез татарларны һәр елны кыйныйлар монда...

Икенче көнне үк «каралу» башланды. Анда анадан тума чишендерәләр икән. Ә теге керәшеннең исеме Никодим икән. Мунчада юынганда, кеше юк җирдә генә тоташ чишенә торган татар егетләренең «тик торганнан анадан тума калып» чишенәселәре килми иде. Тик монда синең эссе ташлы үзеннән мунчаң юк, үз белдегең белән генә бернәрсә дә кыла алмыйсың! Патша казармасы монда! Чишенеп ялангач калган татарларны берәм-берәм, өстәл артларында тезелешеп утырган әфисәрләр, доктор-фельдшерлар алдына кертеп бастыра башладылар.

Керәшен Никодим дәдәй зур бүлмәдә, шәрә хәлдә ике учлап ят җирен каплап каткан татар егетләре арасыннан, кулындагы кәгазьдән берәрсенең исемен, әтисенең исемен әйтә:

—Сәмигулла Тайгун улы...

Ялангач татар үзенең исемен, әтисенең исемен кычкырып әйткәнне ишеткәч, тагын берәр Сәмигулла Тайгун улы юкмы дип, диварга сөялгән якташларын ике якка да карап барлап чыга да, юк икәнне аңлагач, шыбыр тиргә төшә. Күршесе бөеренә төртмәсә, исеменең Сәмигулла икәнен исенә төшерергә, чалгы пәке белән зәңгәре чыкканчы ялтырап кырган татар башы эчендәге татар миенең кыюлыгы да, тәвәккәллеге дә, сыры да җитмәс иде. Калганнары үзләренең «тере» калганнарына сөенеп, «Аллага шөкер, мин калдым бит әлегә!»—дип уйлап, авыз эченнән генә дога укый башлый. Яшен атканда, күк күкрәгәндә, курыкканда укый торган доганы: «Ләхәүлә вәлә куәти!..», «Ләхәүлә вәлә куәти!..», «Ләхәүлә вәлә куәти...»

—Мәүлетдин Әмәметдин улы!

Мәүлет дивардан аркасы белән этенеп аерылды да, керәшеннән житәклтмичә, бер кулы белән гаурәтен каплап, икенчесен гәүдәсе буйлап салындырып, «каралырга» кереп китте. «Караучылар» тезелеп утырган өстәл алдына идәнгә дүрткелле кечкенә келәм кебек нәрсә җәелгән. Никәдим дәдәй Мәүлетдинне шунда этәрде. Келәм өстенә басты да, тынды Мәүлетдин...

Бераз вакыт бүлмәдә тынлык хөкем сөрде. Чөнки алларында басып торган шәрә татар егетенең гәүдәсе табигать тарафыннан сирәк бирелә торган чибәр, таза гәүдәләрнең берсе иде. Мәүлетдин бик нык, авыруның, гариплекнең нәрсә икәнен белмәгән татар нәселеннән иде. Аннан соң ул, дөньяга килгәннән бирле күп эшли белеп, бик тә көч утырткан иде. Күкрәк, корсак, арка-билләр ишкән бау кебек мускуллар белән капланган. Җәй көннәрендә печән вакытында, урта кул чүмәләләрне ул озын саплы агач сәнәк белән бер генә кадап алып биек кибән башына ыргыта белә. Шундый чакта барлык эшләгән халык бер мизгелгә генә булса да туктап, аның ыргытканын карый, соклана, тел шартлата. Мәүлетдин уналты яшеннән (шуңа кадәр көч утыртсын, дип аны картлар көрәшкә кертмәделәр) тирә-як авылларда уздырылган Сабан туйларында катнаша башлады, атаклы батырлар белән бил алышты һәм аларны җинә башлады. Өч ел үтүгә, Сабан туйларында Мәүлеткә тиң батыр юк иде инде...

Менә шул Мәүлет бүген «каралуда» басып тора. Өстәл артында утырган, кырлары алтыннан ясалган күзлек кигән зур борынлы карт доктор җайлап кына урыныннан кузгалып торды да, вак кына адымнар белән атлап никрут янына килде. Гәүдәсе белән Мәүлетдиннең кулбашына да җитми иде карт доктор. Нечкә озын бармаклары белән капылт кына арттан никрутның биленә төртте. Мәүлетдин көлеп җибәрде.

—Син нәстә, татар баласы?!—диде врач акрын гына татарчалап.

—Кызык бит, тик торганнан төртәсен,—диде Мәүлетдин. Тавышы көр иде егетнең. Доктор Мәүлетдиннең алдына чыкты да, бик зур булмаса да, каты йодрыгы белән аның корсагына китереп сукты. Агач чиләк төбенә суккандай тонык кына «дыңк» сымаграк аваз чыкты. Мәүлет доктор сукканга кымшанмады да. Егетнең корсагы калын такта кебек каты иде. Доктор урысчага күчте.

—Мина таба иел!

Никодим керәшен тәрҗемә итте. Доктор егетнең тешләрен карады, күз кабакларын күтәреп тикшерде. Акрын гына пышылдап татарча сорады:

—Исемең ничек?

—Мәүлетдин мин. Зәй-Каратай егете.

Доктор тагын пышылдады:

—Патша солдаты буласың киләме?

—Килми,—диде егет.

Аз гына уйланып торгач, болай дип өстәде:

—Мин бит игенче. Патшага икмәк кенә үстерәсем килә минем. Сугышчы солдат буласым килми.

Карт доктор елмайды да, Мәүлетдиннең кул-аякларын, күкрәк, бил тирәләрен тоткалап тикшерә башлады. Мәүлетдин түзмәде:

—Ярар инде, абзый кеше, сәрмәнмә! Мине тоткалыйсың, ә минем кытык килә. Мин бит сиңа базарга сатарга алып килгән айгыр яисә сыер малы түгел.

Доктор көлеп җибәрде дә, уң кулы белән биш бармагын тырпайтып егетнең түгәрәк күт битенә шапылдатып китереп сукты:

—Айгырдан да шәпсең син, татар малае! Нәсел айгырыннан да!

Өстәл артына кереп утырды да, үзеннән уң яктагы мыеклы, бакенбардлы әфисәргә урысчалатып мөрәҗәгать итте:

—Николай Николаевич! Игътибар итегез бу гололобыйга. Бик сирәк очрый торган экземпляр. Мондыйлар урыс милләтеннән булганнар арасында

күптәннән юк инде. Эчәләр урыслар. Шунлыктан, физик яктан да, башка яктан да вакланалар, йомшаралар. Патша галиҗәнаплары кул куйган әмергә таянып, бу татарны гусарлыкка җибәрик!

Полковник шик белдергәнрәк тавыш белән әйтеп куйды:

—Анда бит—атлар. Хәрби атлар. Һәм бик югары кылыч һөнәре. Баш кирәк, җитезлек кирәк.

Доктор Мәүлетдингә татарча дәште:

—Хуҗалыгыгызда атлар бармы?

—Бар. Дүрт ат. Икесе эш аты, берсе колынлый торган бия. Ә дүртенчесен Сабан туйлары өчен тотабыз. Чабыш аты анысы.

Полковник сөйләшмәсә дә, татар телен яхшы аңлый иде. Мәүлетдинне тыңлагач, баш какты:

—Яхшы! Мин риза! Барсын гусарлыкка! Бик җитез, башлы егеткә ошаган. Күзләре тулы уй! Ике-өч айда урысчага да өйрәнер. Ә кылыч һөнәре, джигитовка татарлар өчен авыр түгел ул. Алар туганда ук егет булып туалар. Беләм мин аларны. Сугышларда бергә күп булырга туры килде...

Казарма эчендә кичен йокларга яткач, Мәүлетдин йокыга китә алмыйча, байтак боргаланды. Аның нык итеп тәне кычыта иде. Бик озак җәфалана торгач, Чулман елгасы буендагы Яр Чагыл авылыннан килгән Сәмигулла исемле егетнең бөеренә төртте:

—Сәми! Нигәдер йоклап булмый бит, әй! Бөтен тән кычыта. Тәндә әллә нәрсә йөргән кебек. Нәрсә икән? Бездә бет юк бит инде? Бөрчәме әллә?

Сәмигулла да йокламый икән:

—Борча сиңа! Кандала!

—Нәрсә-ә! Нәрсә дисең син?

—Кандала, дим.

—Нәрсә була ул?!

—Кан эчә торган сасы бер нәстә инде. Кан-да-ала! Беттән әллә ничә тапкыр зур. Сасы үзе. Чебеннән дә зурраклары була. Илләмә эчә инде канны. Кып-кызыл була эчеп туйгач. Ә кан эчмәгәндә кибәк кебек төссез бер нәстә инде.

—Син каян беләсең ул кандаланы? Бездә юк бит ул.

—Мин аны урысларның Родионовка дигән авылларында өй бураганда белдем. Илләмә дә ашадылар инде. Әле кар китмәгән иде. Март аенда эшләдем. Идәннәрендә ятып түзеп булмый. Өскә түшәмнән сикерәләр. Шунда менеп. Шуннан, шул кандала ашаганга мин түзә алмыйча, сарай кыегы астына, печәнлеккә чыгып киттем. Ул кандалага каршы бернәрсә дә эшләп булмый, Мәүли. Түз инде син дә минем кебек. Йокларга тырыш!

—Тырыш, имеш! Тырышырсың бу хәтле ашауга!

—Иртән яктыргач күрерсең син аларны! Дивар ярыкларында, менә бу без яткан сәндерә агачларында инде алар. Иртән күрсәтермен...

Күрсәтте иртән Сәмигулла Мәүлетдингә. Сәндерә башларында, такта ярыкларында эреле-ваклы, тон буе кан эчкән кып-кызыл кандала иде.

—Сасылар, әй, үзләре!—диде Мәүлетдин җирәнеп карап.—Ходай бу канэчүчеләрне нәрсәгә дип яраткан икән инде?!

Шулчак таза гәүдәле биш урыс егете болар яткан сәндерәгә якынлашып атлыйлар иде. Чабата киндерәсен тезенә каләр уратып мендергәннәр барысы да. Ыштыр өстеннән. Озын, керләнгән сары чәчле, таза гәүдәле урыс уң кулын күтәрә биреп, артыннан килгән иптәшләрен туктатты.

—А ну, гололобыйлар! Капчыкларыгызда нәрсә бар, чыгарыгыз! Акчаларыгызны миңа бирегез!

Мәүлетдин Сәмигуллага карады:

—Нәрсә кирәк бу кара йөрәккә бездән?

—Безнең ашамлыкны, акчаны бирүне таләп итә.

Урыстан суган, сарымсак һәм тагын нәрсәләр кушылган сасы ис килә

иде. Күптән юынмаган тән исе иде бугай. Сәмигулла баш астына салып яткан бишмәте янындагы капчыкка үрелде:

—Кыйный башламас борын биреп котылу хәерлерәк. Өченче ел безнең күрше Мәнәхетдин абзыйны «каралугаъ барган җиреннән, әтисе арбага салып алып кайтты. Кан косып, өч көннән үлде...

—Күп сөйлисең!—диде сары урыс.—Бир тизрәк? А то!..

Сәндерәдән торып утырды Мәүлетдин. Зур кулын күршесенең аркасына салды.

—Чишми тор капчыгыңны, Сәмигулла дус! Мин сөйләшим аның белән башта татарчалап.

Мәүлетдиннең әйткәнен урыс анламаса да, тавыш кискенлегеннән чамалады. Йөзе кырысланды. Сәндерәдән төшкән Мәүлетдингә җикерде:

—Мен кире нарга!

Мәүлетдин урысның килгән ягына кулын сузып күрсәтте:

—Алдыннан артың матур, урыс. Каян килгәнсең, әйдә, шунда ычкын!

Урыс күп сугышып, кеше кыйнап өйрәнгән бәндә иде, ахрысы. Ул китереп сукканнан Мәүлетдиннең күзеннән ут көлтәсе белән очты. Беренче сугуга икенчесе, тагын да нығрагы өстәлде. Тик Мәүлетдин егылмады да, чигенмәде дә, аяк өсте басып калды.

—Син нәрсә, урыс?!—диде ул гаҗәпләнеп.—Сиңа бит әле тигән кеше юк, ә син кул озынайтасың.

Урыс сул кулы белән биленә таянды да, мыскыллап елмайды:

—Мин сораганны бирегез тизрәк! Югыйсә!..

Кулы белән Мәүлетдиннең күлмәк якасыннан эләктерде дә үзенә таба тартты:

—Ну, Мамай! Ычкынып кара инде хәзер минем кулдан!

Мәүлетдин кабаланмыйча гына сары чәчленең күлмәк изүеннән тоткан уң кулы беләзегеннән эләктереп алды да, кыса башлады. Урысның зәңгәр күзләрендә башта аптырау хасил булды, аннан гаҗәпләнү килеп чыкты. Шулардан соң инде авыртудан яшь ага башлады күзләреннән. Ә Мәүлетдин дәшми генә кысуын дәвам итте. Зәңгәр күзләр, авыртудан төсләрен югалта башлап, агара башладылар.

Тегенең тез буыннары йомшарды, ул чүгәли башлады. Мәүлетдин аңарга чүгәргә ирек бирмәде. Аның кулын нығрак кыса биреп, аз гына гәүдәсен турайтып, өскәрәк күтәртте дә, уң кулынын уч төбе белән төсләрен югалтып бетерә язган ике күз уртасына, маңгайгарак китереп манчыды. Әле генә гайрәтле булган сары чәчле, артында басып торган иптәшен аяктан егып, аның аша очып, сәндерә астына кереп китте. Шул чакта бу урысның сул ягында, бер генә адымга арттарак торган житү җирән чәчле, кып-кызыл битле икенче иптәше, акырып, пычак белән Мәүлетдингә ташланды. Каршы сугу каты булды. Тегенең тешләре тешкә тиеп шыкырдадылар, борыныннан, колак тишекләреннән атылып кара кан бәреп чыкты. Пычагы белән бергә беренче урыс артыннан очты монысы да.Өченчесенең сукканын көтмичә, өстән лепкәсенә китереп бирде. Анысы, тавыш чыгармыйча, Мәүлетдиннең аяк астына ишелеп төште. Дагалы итеге белән Мәүлетдиннең касыгына тибәргә чамалап, дүртенче урыс аягы белән селтәнде. Мәүлет, ике куллап, итекле аякны һавада, үкчәсеннән эләктереп алды да, кискен итеп сулга борды. Аяк тубыктан шартлады—сенерләр өзелде, сөякләр урыныннан чыкты. Йөрәк өзгеч тавыш белән акырып, урыс пычрак идәнгә тәгәрәде. Юан гына таяк тоткан бишенче «кәсепче», таягын атып бәреп, ишеккә ташланды...

Ярты сәгать чамасы үтеп китүгә, Мәүлетдин белән Сәмигулла казармада командалык иткән фельдфебель Ляшенко алдында, каптеркада басып торалар иде инде. Сәмигулла да урыс телен бөтенләй белмәмешкә салынды. Ипитозлык сукаласа да. Хохол фельдфебель егетләрне алып кергән көйгә үк акыра башлаган иде, Мәүлетдиннең күз карашына барып төртелгәч, коелып төште.

Егетнен күзләрендә курку дигәннен әсәре дә юк. Фельдфебель алдында, «Инде синнән нәрсә котәргә була инде?!»—дигән караш белән, зур куллы, кин күкрәк, җилкәле, әзмәвер «Мамай калдыгы» тыныч кына басып тора иде.

Инде ун елдан артык шушы «никрутларнын» карала торган казармасында «набор вакытларында служитъ итеп» уздыра фельдфебель Ляшенко. Елга ике мәртәбә—иртә җәйдә һәм көзнен сонгы аенда солдатка алу бара. Һәр елны берничә гаярь урысны оештырып татар, чуаш, чирмеш, мукшы никрутларын талата шулардан фельдфебель. Табышнын яртысы—Ляшенкога, яртысы—талаган урысларга. Фельдфебельгә «таладылар» диеп жалу белән кергән никрутлар шул төнне ук аннан язганчы кыйналалар. Акча таланган, ризык ашалып беткән, казарма эчендә елга ике тапкыр була торган талаунын, кыйналунын очы суга салынган һәм юкка чыккан. Тылмач Никодим да белә ул турыда, белми түгел. Тик дәшми. Фельдфебель анарга дәшмәгән өчен өлеш тә чыгармый. Тик Никодим «чучмекларны»—урыс булмаганнарны яклап чыкса, үзенә нәрсә буласын яхшы анлый. Ляшенко аны бу дөньяда яшәтмәячәген белә тылмач. Чөнки ул православный, чукынган булса да, урыс өчен ин башта ул—татар! Та-а-атар! Аннан сон гына, урыснын кирәге өчен генә ул крещенный... татарин! Вакытлыча гына анысы да. Кирәге беткәч, ул тагын «татарин вонючий»!

Һич тә курыкмыйча алдында басып торган олпат гәүдәле «татаринга» карап фельдфебель шомлана төште. Нәрсә эшләргә? Бик тәвәккәл, гайрәтле егеткә ошаган бу татар калдыгы! Курку-каушавын сиздермәскә тырышып, тавышына «корыч» кушып сорады фельдфебель:

—Закон бозып, син нигә никрутларны кыйнадын? Тюрьмага утырасын килдеме? Утыртырбыз, теләгән булса алай.

«Закон», «Тюрьма»—ике сүзне анлады Мәүлетдин.

Сәмигуллага карады:

—Әйт бу салынкы мыекка! Тылмач чакырсын! Мин урыс телен белмим бит.

Тылмач килде. Сугышунын сәбәбен тылмач тәрҗемә иткән унайга ук, Ляшенко бер карарга килгән иде инде: «Бу Мамайларнын икесен дә бүген төнен юк итәргә! Һәм бетте-китте. Югыйсә, үзеннен бетүен бар!»

Никодим тылмачтан әйттерде:

—Барыгыз, чыгыгыз казармага! Иртәгә иртән полковник Егоровка, ул килгәч тә, доложить итәрмен! Барыгыз!

Никодим тылмач тонык кына тавыш белән тәрҗемә итә иде. Фельдфебель әйткәннәрне тәрҗемә итеп бетергәч, тавыш барышын үзгәртмичә өстәде:

—... моннан чыккач, бәдрәфкә барыгыз. Мине шунда көтегез!

Такта бәдрәфкә кабаланып килеп керде дә, сүзне кыска тотты:

—Сезнен икегезне дә бүген төнлә үтерәчәкләр. Суеп, яисә буып, йоклаган җирегездә. Хәзер үк, моннан чыгу белән, байтак ара калып мина иярегез. Мин полковник Егоров яшәгән йорт янында туктап, башны өскә күтәреп карармын. Аннан сон казармага китәрмен. Курыкмагыз, мин янында туктаган ишекне шакыгыз. Полковникнын денщигы—бик шәп мишәр егете. Исеме—Гайнулла. Әйтегез, срочно, диегез, полковник кирәк, диегез. «Срочно»—дигән сүз «бик тиз кирәк» дигәнне анлата. «Срочно»ны исегездә калдырыгыз! «Срочно!» Полковникка кергәч, тылмач кирәк безгә, диегез. Курыкмагыз! Ул мине чакыртыр. Сөйләрбез барысын да. Ничек килеп чыкты, ничек сугыштыгыз, шул хакта!

Һәммәсе дә тылмач сөйләгәнчә булды.

...Гайнулла Мәүлетдин белән Сәмигулланы тынлады да, өйгә кереп китте һәм ике татарнын полковникны күрергә теләүләрен адъютантка җиткерде. Эшчәнлеге, тырышлыгы, аз сүзлеге һәм хәмерне капмаганлыгы өчен денщик Гайнуллага хөрмәт белән караган, ел ярым эчендә анарга кул күтәреп бер генә мәртәбә дә сукмаган адъютант башын ия биреп тынлады... Гайнулла сүзен бетергәч, акрын гына кулбашына сукты:

—Якташлармы әллә?

—Никак нет, господин капитан! Үзебезнең татарлар!

—Яхшы. Хәзер әйтермен полковникка.

Полковник адъютантын утырган килеш тыңлады да, татарларга керергә рөхсәт итте. Ике никрут кереп ишек төбенә бастылар. Икесендә дә буйлы, киң төпле киндер ыштан, ак күлмәк, кара камзул. Берсенең башында кара төстәге искерәк кенә бәрхет түбәтәй, икенчесендә киез эшләпә. Аякларында тула оек, берничә генә көн киелгән чабата. Күрә-белгәннән бирле Егоров һәрвакыт татарларга сокланып карый. Тик бу халыкның холкын, үзен тотышын, хәтта киенүләренең тәртибен дә аңлап, төшенеп бетерә алмый. Татар һәрвакыт юынган, кырынган, киемендә пычрак та, ертык-тишек җире дә юк. Искедәнрәк киенгән булса да, ямавы да матур итеп салынган була. Хәмер эчкән татарны үз гомерендә Егоров күрмәде. Альп явы вакытында авангардта—иң алдан барган штурм отрядындагы солдатларның яртысыннан күбесе татар егетләре иде. Упкын аша салынган Жен күперен французлар шартлатып җимергәч, яңа күпер сала башларга иң беренче булып зур куллы, киң җилкәле татар гренадерлары тотынды. Әле бүген дә Егоров тагын бер нәрсәгә шакката. Альп тауларын уңышлы үтеп, австриялеләр белән кушылгач, батырлык күрсәткән офицер һәм солдатларны бүләкләү башлана. Шунда Суворов күрсәтмә бирә:

—Татар солдатларына тәреле орден-медальләр бирмәскә! Тәреле бүләкне алар алмаячаклар! Бүләкне татарларга акчалата, яисә түгәрәк медальләр белән генә бирергә!

Походлар тәмамлангач, шулай эшләделәр дә...

Ишек төбендә басып торган ике татар никрутына полковник дәшмичә генә карап утырды. Аннан соң сорады:

—Нигә кердегез миңа?

Гәүдәгә тазасы, башын бормыйча гына күршесенә нәрсәдер пышылдады. Тегесе, чабаталы аякларын кузгаткалап куйды да, азрак шом сизелгән тавыш белән, полковникка карап, акрын гына урысчалады:

—Толмач нады! Урыски язык нашыныкы плухы знай!—Полковник ымлавы буенча денщик чыгып йөгерде. Берничә минут үтүгә, хәле-тыны бетеп, керәшен Никодимны алып та килде. Мәүлетдин сөйләгәнне тылмач полковникка тәрҗемә итеп тә бирде. Егоров байтак уйланып утырды. Өй эче тып-тын. Тик диварга эленгән ике герле сәгать кенә вакыт саный:

—Тек! Тек! Тек! Тек!

Полковник башын күтәреп, керәшенгә туп-туры карады:

—Син монда тылмач булып ничә ел катнашасың инде?

—Алтыга китте.

—Нинди телләр беләсең?

—Татар, чуаш, мари телләрен әйбәт беләм. Ә мукшы теле белән удмуртныкын каралу комиссиясенә җитәрлек дәрәҗәдә сукалыйм.

—Яхшы, алай булгач. Бу татарлар турында син нәрсә уйлыйсың һәм нәрсәләр беләсең? Сөйлә!

Никодим үрә катып басып тора иде. Егоров анарга үзеннән аз гына читтә торган артлы урындыкны күрсәтте.

—Шуны ал да, минем алга утыр, Никодим Петрович. Сөйлә белгәннәреңне.

Никодим, урындыкны алып, Егоров каршысына куйды да, утырды. Башын азрак кырынрак салып, үзенең итек башларына карап уйланып утырды да, полковникка карады. Керәшеннең күзләрендә тәвәккәллек утлары яна иде.

—Господин полковник! Мин инде монда алтынчы ел күрәм мондый гаделсезлекне һәм урыс милләтеннән булмаган никрутларны талауны, кыйнауны, имгәтүне. Мин хәзер сезгә үзем белгәнне һәм үзем уйлаганны тоташ сөйләп бирәм. Беткән баш беткән—башкача минем түзәр әмәлем калмады. Мин сөйлим, ә сез шул мин сөйләгәнне тикшерергә боерык бирерсез дип уйлыйм. Чөнки минем сөйлиселәр бар да дөрес.

Мондагы никрутларны талау, кыйнау, үтерүләр безнен пунктта фельдфебель Ляшенко килгәннән сон башланды. Ул килгәнгә ел тулар тулмаста. Кичә, үзләрен талатмыйча, менә бу татарин...—Бармагы белән төртеп Мәүлетдингә күрсәтте:

—... берүзе дүрт урысны кыйнады. Икесе бүген дә лазаретта ята. Берсенен тубыктан аягы чыккан, сенерләре дә өзелгән бугай. Икенчесенен колагыннан кан килү бүген иртән генә тукталган. Минем уемча, талауны оештырган никрут белән пычак күтәргән никруттан сорау алырга кирәк. Лазареттагыларыннан да. Бу талауны туктатырга вакыт һәм аны сез генә эшли аласыз...

Полковник тылмачны бүлдермичә тынлады. Никодим сөйләүдән туктагач, анын күзләренә карап сорады:

—Курыкмыйсынмы, Никодим Петрович?

—Куркам, әлбәттә. Жан берәү генә бит. Курыксам да, өмет сездә. Ел саен талау, кыйнау, имгәтү бара. Бигрәк тә татарларны. Мөселманнар бит. Берничә үтереш булды. Имгәнгәннәрне авылларына озаталар. Шунда үләләр инде алар, яисә гомерлек гарип булып кан төкереп, юньләп эшли алмыйча, капка төпләрендә утыралар инде...

—Ә бу татарин курыкмыймы икән? Сора әле?

Мәүлетдин, сорауны тынлагач, жаваплады:

—Нигә мин ул урыстан куркыйм ди инде? Иртәме, сонмы—без Ходай тарафына китәчәкбез. Якты дөньяда кемнән дә булса куркып, өркеп яшәгәнче, безгә мөселманча, шәһит булып китү фарыз. Курыкмыйм мин. Үзем тимим мин кешегә, һәм дә үземә дә берәүдән дә суктырмаячакмын...

Никодимнын тәржемәсен тынлап бетергәч, полковник Егоров адъютантына боерык бирде:

—Татарларны таларга кергән өч никрутны аерып төрле урынга бикләгез. Сорауны үзем алырмын. Лазаретка барып... теге ике ... татар кулы аша үткәннәрдән сорау ал. Кем кушкан аларга татарларны таларга? Әллә беркем дә кушмыйча, үз белдекләре белән тотынганнармы? Нык итеп ачыкла!

Шул вакыйгалардан сон дүрт көн узгач, фельдфебель Ляшенко, погоннары өзеп алынган хәлдә, ике жандарм сагы астында Казанга озатылды. Никрутларны талау жинаяте туктатылды. Тагын кабатланмасын дип, никрутлар яшәгән казарма бүлмәләренен ишек төпләренә гарнизон солдатларыннан дневальныйлар куела башлады.

• • •

Ай ярымга якын вакыт узып китте. Казан каласыннан да, Мәүлетнен туган авылы Зәй-Каратайдан да бик еракта, урысларнын беренче башкаласы Мәскәүдән кояш баешында, икенче башкалалары Санкт-Петербургка житмәс борын сулдарак, Волхов елгасынын зур ике ярында утырган бик тә борынгы Новгород каласы бар. Урыслар аны «Великий Новгород» дип атаганнар. Шул Великий Новгород каласыннан Волхов елгасы агымы белән су агымына каршы унбиш чакрым чамасы үтсән, бер хәрби гарнизонга барып житәсен. Бу гарнизон—гусарларныкы. Аны заманында татар каны катыш тынгысыз, үтә дә урыс жанлы Александр Суворов салдырган. Анын шулай икәнлеген ныклап әйтәләр...

Гарнизон төзелә башлау белән, анын янындагы Александровка исемле урыс авылы да үсә башлый. Бирелә жан асраучы кешеләрнен күпчелеге патша хезмәтендә егерме биш ел гомерен уздырган, мылтык, кылыч тотып, кеше үтерүдән башка һөнәрне белмәгән һәм белергә дә теләмәгән, инде иллегә житеп килгән, картая башлаган солдатлар—гусарлар, уланнар, артиллеристлар көн күргән. Тик матрослар гына юк. Аларны, дингезче булганлыктан, патша әмере белән чик буендагы дингез портларында калдырып утырткannар.

Волхов елгасы ярына сузылган, кызыл кирпечтән салынган, гусарлар яши торган дүртәр катлы казармалар, ат сарае-конюшнялар уртада дүрткелле зур мәйдан ясап утырганнар.

Ат сарайлары артында тимерлекләр, ияр ясау остаханәләре, каеш эшкәртү өчен зур чаннарны җиргә утыртып эшләнгән алачыклар, зур-зур—егермешәр кеше сыярлык мунчалар тезелеп киткән. Казаннан чыкканнарына өч ай тулып килгәндә, инде солдат хезмәтенә алынган кичәге никрутлар шул Волхов елгасының уң як ярында утырган Кречевицы исемле гусарлар гарнизонына килеп җиттеләр. Атлы олаулар белән алып килгән утыз кешене арбалардан төшерделәр дә, биек такта койма буенда яткан юан, озын бүрәнәләргә тезеп утырттылар. Авылдагы «әбрәкәй» солдат хезмәтендә «туалет-уборная» икән. Мәүлетдин инде көн дә ишетелеп-сөйләнә торган «вставай», «садись», «иди», «бегом»,« мать твою», «хлеб», «татарская морда», «гололобый», «чаплажка», «вода», «фельдфебель» кебек иң кирәк сүзләрне исендә калдыра алды. Кеше ишетмәгәндә үзе өчен генә дип кабатлый да иде. Акрын гына итеп. Чит-ят телнең яңгырашын үзе үк исе китеп тыңлый да, аптырый: «Бу хәтле ят-чит сүзләрне бу урыслар үзләре ничекләр итеп аңлый алалар икән? Менә хикмәт!» Инде шул сүзләр ишетелгәндә нәрсәләр эшләргә кирәклеген аңлый да башлады. Мәсәлән, фельдфебель: «...мать твою!»—дип акыра башласа, Мәүлетдин аның янынннан читкәрәк тая...

Урысларның Мәскәү дигән күп чиркәүле калаларын узгач, Мәүлетдиннең чабаталары тузды. Арбадан аякларын салындырып утырган жиреннән мыек тәрткән, инде үкчәләре дә тишелеп, салам олтыракларын урамга чыгарган, тарала башлаган чабаталарына карап-карап алды: «Беткән инде болар!» Чабаталарны салып, арба эчендәге саламга куйды. Йон оекбашлар өстеннән ураган киндер чолгауларны да, оекбашларын да салып чабаталары янына салды. Арба алдында яткан капчыгын үрелеп алды да, аны чишеп, эченнән бергә бәйләнгән өр-яңа ике пар чабата тартып чыгарды. Әтисе үреп, тукып биргән чабаталар! Кызыл, ак төстәге юкәләрне аралаштырып тукыган. Әзер юкәне ике-өч көн ләгәндә, суда тотсаң, ул кызыл төс ала. Дүрт кат тукыган, калын табанлы чабаталар иде алар. Юкәле Аклан юкәләреннән ясалган чабаталар бит алар!

Бармаклары чабата сырлары өстеннән узган чакта, Мәүлетдингә шул «юкәле Аклан» да үсеп утырган юкә яфракларының җилдә шаулаганы ишетелгәндәй булды. Авылны, туган якны сагыну иде бу!..

Бик кадерле булып тоелган ике чабатаны, кирәгең бетте инде дип, ташлап китәсе килми иде. Шунлыктан, нәрсәдер эзләгәндәй, юл читендә үсеп утырган урманга карады, дүрт-биш аршин озынлыктагы пар чыршыга күзе төште. Юлдан читкә чыкты да, «бисмилласын» укып, чыршылар астына иелеп, киң булып җәелгән бер ботакны азрак күтәрә төште дә, хезмәт итеп тузган чабаталарны чыршы агачы төбенә салды. Йөгереп барып, инде байтак китеп өлгергән арбага утырды да, артта калган ике чыршы ягына, алар күздән югалганчы, карап барды. Янында утырган Микалай исемле чуаш аның аркасына, дусларча иттереп, учы белән сукты.

—Нигә ул чабаталарны, кызганмыйча, ташлап китәсең? Алып бар үзең белән гусарлыкка,—диде татарчалап.

Гәүдәгә уртача, үзе гайрәтле егет иде чуаш Микалай.

Великий Новгородтан бик ерак булмаган Кречевицы хәрби гарнизонына Казан ягыннан Микалай белән икәү генә килеп җиттеләр. Кызыл кирпеч казарманың арт ягында урнашкан агач йортның идәнендә җәйгән саламда йокладылар. Һәммәсе утыз дүрт кеше. Күбесе Серпухов дигән урыс каласы тирәсеннән җыелган урыслар.

Егерме бер яшенә кадәр Зәй-Каратайдан сирәк-мирәк кенә башка авылларның, яисә Бөгелмә каласының базарларына гына баргалаган, ярминкәләргә чыккалаган татар баласы Мәүлетдин арбада утырып, Рәсәй

буйлап барды да барды. Телләрен әле юньләп анлап бетермәсә дә, урыс авылларын үтеп киткән чакларда карап, гыйбрәт алып, исендә калдырып барды. Эш вакыты, печән өсте, ә капка төбе саен көнбагыш чиртеп утырган салмыш ирләр, юан, симез хатыннар.

Авыл урамнарында тигәнәк, кара әрем үсеп утыра, койма-читәннәр җимерек. Урыс ирләре дә, маржалары да ярлы, ертык, ямалмаган тишек-ертык киемнәрдән, үзләре юньләп юынмаганнар, чәч-баш каралмаган, үзләренен дә, балаларынын да ач икәнлеге әллә каян күренеп тора...

Килеп житкәннен икенче иртәсендә «яна гусарларны» «подъем!»—дип акырып, мангаеннан борыны аша иягенә кадәр сузылган кызыл-зәнгәр төстәге яра эзле фельдфебель уятты. Тавышы каты, корыч кебек чынлап торса да, анын йөзендә усаллык сизелми иде. Башын култык астына тыгып, ятканны ишетмичә һаман йоклый биргән берәүне аркасына зур учы белән суккалап уятты.

—Вставай, сынок! Тиздән полк командиры килә.

Тавышы йомшак иде.

Барысын да ишек алдына чыгарып, уртада урнашкан кое янына алып китте. Барып житкәч, «гусарларны» тиз генә карап чыкты да, Мәүлетдинне үз янына чакырды. Кое сиртмәсендә асылынып торган зур тимер кыршаулы агач чиләккә, кое янындагы тирән агач улакка күрсәтте:

—Работай!

«Работай»нын эшләргә кушу икәнен белә иде инде Мәүлетдин. Чиләкне, сиртмәгә беркетелгән чылбырдан тотып, коега төшерде дә, улакка су тутыра башлады. Улак тулгач, биленә кадәр чишенеп ташлады да, шау-шу килеп юынган иптәшләренә кушылды. Төнлә борча-кандалалар ашаган тәнен салкын кое суы белән рәхәтләндереп юды, киндер тастымалы белән кызарганчы ышкыды. Юынмаганнары калмасын дип, «гусарларны» күзәтеп торган фельдфебель бармагы белән Мәүлетдинне үз янына чакырды:

—Фамилиян?

—Мәүлетдин Төхфәтуллин.

—Ну-у, брат!—диде фельдфебель.—Син бит—Илья Муромец... Беләкләрен тоткалап карады. Сорады:

—Татаринмы?

Мәүлетдин баш какты. Таныштылар...

«Яна гусарлар» тимерлекнен ун ягында, кайсы бүрәнә өстендә, кайсы жирдә асларына бишмәтләрен җәеп утырыштылар. Фельдфебель аларны шунда утыртты да, үзе каядыр китеп югалды. Бераз утыргач, вакыт әрәм итмик әле дип, берничә «яна гусар» жиргә ятып йокладылар. Тыныч кына, сүзсез утырган чакта тимерлек янына дүрт чын гусар килеп чыкты. Берсе, ике алгы аягынын да бәкәлләре ап-ак, үзе чем-кара, сөлек кебек бер айгырны житәкләгән иде. Гусар айгырны ат дагалау станогынын баганасына бәйләде дә, тимерлеккә кереп китте. Өч иптәше урамда калдылар. Ике-өч адымга айгырдан читкәрәк киттеләр дә, үзара акрын гына нәрсәдер сөйләшә башладылар. Икесе, кызыл балчыктан ясалган төрөбкә чыгарып, тәмәке көйрәтә башлады. Тимерлек ишегеннән азрак иелә биреп, кара сакал-мыеклы, таза гәүдәле тимерче һәм айгырны алып килгән гусар чыкты. Гусар, атлаган унайга, ризасызлык белдергән тавыш белән сөйли иде:

—... синен эшен—ат дагалау. Ә мина каршы телләшү түгел. Безнен гарнизонда Христос куенындагы кебек яшисен. Әгәр тынламасан, әгәр эшне булдыра алмасан, полк командиры сине бариныңа кире кайтарып җибәрәчәк. Ә синен бариныӊ Державин сине конюшнясында чыбык белән суктырачак...

Гусар сөйләгәннән тимерче елмая иде.

—Барин мине оста тимерче булганым өчен хөрмәт итә. Әле ул өйдә дә юк...

—Кайда?

—Петербургта. Патшага үзенең язган шигырьләрен укырга китте, диләр.
—Ярар инде, Петрович! Дагалыйк айгырны.
—Ике көн болашып карадык бит инде. Аякларын бирми бит.
—Бүген бирер.
—Ай-һай, бирерме икән?
—Бир-рер! Моны мин әйтәм сина! Гусар Данилов!
—Ай, әйдә! Дагалап карыйк тагын.

Кара айгырны станокка алып кереп, башын югары күтәртеп, шакартып бәйләп куйдылар. Ике арткы аякны бәкәлләреннән, тезеннән уратып баганага бәйләп ныгыттылар. Тимерче чүкеч, дага, кадаклар тутырылган тимер чиләген алып, айгырның алгы аягы янына килде. Ул килеп җитә башлау белән айгыр ике колагын да шомартып, бармак озынлык ак-сары тешләрен күрсәтеп, бәйләгән нуктадан тартылып карады. Тик шакартып бәйләгән башын кузгата алмады. Тимерче айгырның уң аягы бәкәленнән тотты да, күтәрергә итте. Тик атның аягы урыныннан кымшанмады да. Тимерче ат аягын тагын өскә күтәрергә итте, тик көче җитмәде. Станокның икенче ягына чыгып атның сул аягын күтәрергә маташты. Тик булдыра алмады.

—Ярар! Тукта!—диде гусар.—Без аны бүген акылга утыртырбыз.

Аннары тәмәке тарткан иптәшләренә борылды:

—Семен! Арканны бир әле монда!

Айгырны нуктасыннан тотып станоктан чыгарды. Калын каештан тегелгән нукта авызлыгы янындагы корыч боҗрага юан сүс арканның бер очын бәйләделәр дә, айгырны тимерлек алдындагы зур, түгәрәк мәйданга алып чыктылар. Озын арканның икенче очын таза гәүдәле бер гусар кулына алды. Айгырны алып килгән гусар киндер капчыктан тыгылып кыска саплы, уралган озын каеш чыбыркы чыгарды. Гусар чыбыркыны җирдән бераз өстерәтеп барды да, һавага каратып селтәде. Мылтыктан аткан тавыш кебек, чыбыркы шартлады... Артында кара елан кебек сузылып яткан каеш чыбыркыга карап алды да, киң итеп кизәнеп, бернәрсә дә көтмичә басып торган кара айгырның сыртына китереп сукты. Көтелмәгән сугудан айгыр башта азрак чүгеп куйды да, аннан арт аякларына басып, кешнәп һавага сикерде. Тик корыч авызлык аның ирен төпләрен яндырып дүрт аягына басарга мәҗбүр итте.Чыбыркының икенче мәртәбә сыртын ярып сугуыннан айгыр алга ыргылды. Тартылган аркан аны түгәрәкне әйләнеп чабарга мәҗбүр итте. Чыбыркы туктамастан айгырның сул як сыртын «эшкәртә» башлады. Гусар «чыбыркы остасы» икән, айгырның сыртына суккан бер урында баш бармак юанлыгы булып тиресе бүртеп чыга башлады. Дүрт түгәрәк үтүгә, айгырның арткы ике боты арасыннан бүрек-бүрек булып ак күбек җиргә коела башлады. Ә гусар чыбыркының йөрешен тизләткәннән тизләтте. Айгыр чыбыркы астында чабу тизлеген арттырганнан арттырып, арка үзәгенә кадәр кара тиргә батты. Тын алуы гыжлауга күчкәч, айгырны түгәрәктән алып чыгып, дагалау станогының юан баганасына башын күтәртеп, баганага терәп, шакартып тагын бәйләп куйдылар...

Айгыр авыр итеп гыжлап сулый, бөтен гәүдәсе белән дер-дер килеп калтырый һәм куркудан урынында бертуктаусыз таптана, боргаланырга маташа иде. Чыбыркысын өстерәп, гусар бәйләнгән айгырга якынлашты. Кара елан кебек каеш чыбыркы гусар артыннан өстерәлеп килә иде. Айгырга җитәргә бераз ара калгач, гусар туктады. Сул кулы белән азрак җирәнләнеп торган мыегының ике очын да бөтереп тәртипкә салды. Уң кулын читкәрәк сузып, кулбашы биеклегендә арткарак күтәрде дә, ныклап кизәнде... Башы юан баганага терәп бәйләп куелган айгырны кансыз рәвештә каеш чыбыркы белән кыйнау башланды. Бу вәхшилекне карап торган тимерче белән ике гусар, түзмичә, алачыкка кереп киттеләр. Айгыр елау тавышлары чыгарып кешни-кешни, суккан саен артын сикертә биреп, пошкырды, кешнәде, арткы ике аягын бергә күтәреп һавага типте. Ә каешлы гусар, тәмам кеше кыяфәтен

югалтып, ерткычка әйләнеп, үзенен инде ни кыйланганын аңлаудан узып бара иде. Койма буендагы бүрәнәдә утырган Микалай чуаш чукына башлады:

—Иисус Христус! Аллам! Мөхәммәт Пәйгамбәребез! Туктатыгыз бу үтерешне!

Башын аска иеп, айгырны үтергәнче кыйнаганны күрмәскә тырышып утырган Мәүлетдин торып аягына басты да, буйлы киндер ыштанын сул кулы белән арттан каккалап, чыбыркылы гусарга карап атлады...

Ул чыбыркысын селтәргә әзерләнгән гусарның кул беләзегеннән эләктереп кысып тотты.

—Ты что-о, с-с-сволочь!—диеп еландай ысылдады гусар.—Пшш-шол вон!

Мәүлетдин җавап биреп тормады, чыбыркыны тартып алып, җиргә ташлады. Гусар Мәүлетдингә кизәнде.

—Ах, ты! ... твою мать!

Мәүлетдин аны ике кулы белән эләктереп һавага күтәрде дә, станок ягына ыргытты. Гусар «гых» дигәнрәк аваз чыгарып, арты белән җиргә барып төште дә, мәтәлеп китте. Сикереп торып аякларына басты, тирә-ягына каранып Мәүлетдингә сугар өчен берәр нәрсә эзли башлады. Шунда, түгәрәк уртасында аркан очы бәйләү өчен кагып куйган казыкка күзе төште. Йөгереп барып казыкка ике куллап ябышты да, аны какшата башлады. Мәүлетдин күзләрен казыкка ябышкан гусардан алмыйча, җирдә яткан чыбыркының сабын сәрмәп уң кулына алды. Күп ат сыртлары үткән озын каен чыбыркы, ныклы ир кулына эләккәненә шатлангандай, сызгырып, һавада тавыш чыгарып чажылдады. Гусарның арттан шома түгәрәк итеп киелгән ак тостәге рейтузы каеш чыбыркы сукканнан ярылып китте. Икенче сугу ялангач калган артның тиресен ярып җибәрде. Кып-кызыл булып кан атылып килеп чыкты. Гусар акырып җиргә егылды. Тимер тоткан өч гусар алачык ягыннан Мәүлетдингә карап акыра-акыра йөгерәләр иде. Мәүлетдин аларга табан борылды. Чыбыркы тагын һавада чажылдады. Кулындагы тимерне селти-селти акырып алдан йөгергән гусар, тимерен кулыннан ычкындырып, җиргә тәгәрәде. Каеш чыбыркы аның йодрыгын кисеп каты итеп китереп сукты. Бармак тирeләре, кул сырты ярылып китте. Гусар канга баткан кулын ике бот арасына тыгып, чайкала-чайкала акыра иде. Аның артыннан йөгергән ике иптәше кире борылды, тимерләрен ташлап, алачыкка кереп бикләнделәр.

Мәүлетдин айгыр янына килде. Атлаган унайга чыбыркы сабын күкрәгенә терәде, ә чыбыркыны артка салындырып куйды. Кыйналып, кара тиргә баткан хайванга иркәләгән тавыш белән дәшә башлады:

—Тынычлан, хайванкай! Тынычлан! Мин сине башкача беркемнән дә кыйнатмам. Тынычлан!

Учы белән айгырның тирләп чыккан юеш муенына акрын гына итеп берничә мәртәбә шапылдатып, аны иркәләп сугып алды. Баш бармагы белән айгырның яшьтән юешләнгән күзләрен сөртте. Ике колак төбен, тамак астын кашып алды. Ат тынычлана төште. Мәүлетдиннен йомшак, иркәләү тавышын тыңлап, аның сизгер бармакларының үзенә кагылганын тоеп, бу егетнен үзенә явызлык эшләми торган җан икәнен аңлап, айгыр куркудан, ачуыннан туктала башлап, авыртудан шомарткан ике колагын турайтып торгызды да, авыр итеп сулады, аннан соң иркенләп пошкырып җибәрде.

—Мен-нә шула-ай! Курыккан чакта эчтә калган һаваны чыгарып җибәр тизрәк. Шул һава белән курыкканың да чыгып китсен. Тынычлан, хайванкай. Тынычлан!

Үзе сөйләнгән арада ике куллап атны баганага шакарып куйган тезгенне чиште. Атның авызлыгын салдырды. Тезгенне урталай бөкләп сул кулына тотты да, айгырга дәште:

—Әйдә, дус, йөреп кайтыйк азрак! Бот араннан җил үтсен—суын азрак! Без кайтканчы монда калганнар... ак ыштаннарын ямый торсыннар...

Айгырны тезгеннән житәкләп казарма ишегалдыннан капка аша алып чыга башлады. Капка янында тукталды. Озын чыбыркыны сабыннан тотып жилкәсеннән алды да, божра ясап жыйды. Артына, сулга, унга карап алды да жыелган чыбыркыны капканың юан баганасы төбенә ташлады. Инде тынычланып бетә язган кара айгырны житәкләп Волхов елгасы ягына китеп барды...

Кара айгырга менгән Мәүлетдин кайтканда ишегалдында да, тимерлек алачыгы янында да беркем юк иде.

Атны бәйләп куйгач, Мәүлетдин станок янына барды да, тимерче тартмасыннан чүкеч, ике рашпиль, дүрт дага һәм уннан артык дүрткырлы дага кадагы сайлап алды.

—Микала-ай! Минем янга кил әле.

Мәүлетдиннен хәрби киемдәге гусарларны каеш чыбыркы белән кыйнаганын күреп, куркудан коты очып исемен дә оныткан чуаш үзен чакырганны башта анламады. Анлагач, исәбе бармаска иде дә, тик үзе дә сизмәстән урыныннан тора башлады.

—Курыкма, дус!—диде Мәүлетдин.—Кил, айгырның аягын тотып торырсың. Дагалыйк әле без бу хайванны.

Үзе атны учы белән сыйпады, сөйде. Башта муеныннан, аннан күкрәк, корсак тирәсеннән. Ат та иркә, яхшы кулга эләккәнен анлады, тиресе йомшарды һәм егетнең кулы астында жылына башлады.

Куллар бәкәлгә житә башлагач, айгыр ике колагын шомартып пошкырды. Мәүлетдин үзенең нәрсә эшләргә уйлаганын айгырга белдерергә теләп, сөйли башлады:

—Син бит инде гади ат түгел, сугыш аты булачаксың. Әййе. Шунлыктан сине дагаларга кирәкме? Кирәк. Менә хәзер син мине тынлап аягынны күтәреп торырга тиешсең. Мин сине дагаларга тиешмен. Колакларыңны шомартма да, пошкырып мине куркытырга да маташма. Курыкмыйм мин синнән. Син дә миннән курыкма...

Уйлап кына, сакланып кына айгырның анлавында шиге булмыйча, өстәде:

—Сине мин дагаламасам, тагын теге урыс гусары кулына барып эләгәсең бит син. Ә аннан син тере килеш әллә чыгасың, әллә юк!

Янында басып торган чуаш Микалай телгә килде:

—И-и, Мәүлетдин! Син әллә пу кайван анлый тип уйлыйсынмы? Ә? Жүләр пулма инде, син пит акыллы татар паласы инде...

Мәүлетдин чуашка карап елмайды да, кулына рашпиль алып эшкә кереште. Атның бәкәленнән ике куллап тотып, анын аягын өскә күтәрә башлады:

—Күтәр, күтәр аягынны! Күтәр дим бит, ишетәсенме? Акыллы бит син, күтәр!

Айгыр башын ия биреп, Мәүлетдин ягына борылды да, ахак кебек сары күзләре белән ике куллап бәкәленә ябышкан егеткә карады да, ике мәртәбә акрын гына пошкырды. Аннан сон кабаланмыйча гына, Мәүлетдин тоткан аягын күтәреп, аны тезеннән бөгеп, артка таба каратты. Тояк жайлы булып, өскә карап тора иде.

—Тот, Микалай дус! Яхшы итеп эшләп, без бу мәхлук жаннын аякларын дагалап куйыйк әле.

—И-и!—дип сузды Микалай.—Мондый сихерне пезнең чуаш сихерчеләрендә дә күргән түгел. Син пит зур сихерче, Мәүлетдин. Ат та анлый пит син сөйләгәнне. Инде мин дә куркам синнән. Гусарларны кыйнаган өчен сине нәстә эшләтәләр инде хәзер? Атачакларны? Ә?

—Тот инде, Ходай чуашы! Күп сөйлисен. Башладык!

Ун аякка дип ясалган корыч даганы кулына алды да, ат тоягына чамалап куеп карады. Айгыр яшь, шунлыктан тоягы бик үк түгәрәк булмыйча, азрак алгарак карап, очлаебрак үскән иде.

Мәүлетдин атнын иренен күтәреп тешләрен карады:

—Өче тулып, дүрткә генә киткән әле бу хайван. Тоягы тагын үсәчәк әле. Өч-дүрт айдан янадан дагаларга туры киләчәк моны...

Рашпильнын эрерәк тешлесен алды да, чаж-чож китереп ышкып, атнын тоягын дагасына таман килерлек итеп түгәрәкләп иги башлады. Эшләгән унайга берничә мәртәбә даганы куеп, үлчәгәндәй иттереп, туры килгәнен чамалады. Үз эшеннән үзе канәгать булып елмайды да, рашпильнен икенчесен, ваграк тешлесен кулына алды. Түгәрәкләнгән тоякны шул рашпиль белән шомартып тигезләгәннән сон, даганы тоякка калаклый башлады...

Үзе оста булган кеше яхшы белә: һәр эшнен үз жае, үз хәйләсе була. Бер караганда, ат дагалау да әллә нинди катлаулы эш түгел кебек бит инде. Даганы ат тоягына чәпә дә, кадак белән как та куй. Белеп эшләгән кеше алай уйламый. Әгәр дә ат тоягынын читләрен рашпиль белән аз алсан, кадак кага башлагач тояк читенен кителүе бар. Күбрәк алып куйсан, каккан кадагын тоякнын итле жиренә, мускулларына кереп китүе мөмкин. Ат аяксыз калды дигән сүз.

Чуаш бик тә тырышып атны бәкәленнән тотып торды. Ә Мәүлетдин атка иркәләү, мактау сүзләрен кызганмыйча мулдан сөйләп, анын алгы ике аягын дагалап та куйды. Дагалап бетергәч, алачык ишегеннән күренмәскә тырышып карап торган тимерче Петрович чыкты. Мәүлетдиннен эшеннән житешсезлек эзләп маташты. Тик таба алмады.

Мәүлетдин кышларын әтисенен туганнан туган Тимергали абзасы (үзе Тимергали, үзе тимерче!) янында эшләп, тимерче эшен дә ныклап өйрәнгән иде.

—Яхшы! Яхшы!—диде Петрович.

Мәүлетдин, тимерченен биленә кыстырган чуар чүпрәккә кулын сөртте дә, Микалайга кушты:

—Син бу мәхлук жанны башка атлар янына алып бар да, ат караучылардан солы сорап алып алдына сал. Дагалагач, солы бирү кирәк.

Атны алып китеп тә өлгермәделәр, казарма ягыннан полк командиры полковник Федин, эскадрон командиры Соколкин һәм тылмач күренделәр. Алардан берничә адым арттарак иртәнге дүрт гусар атлый иде. Жир астыннан килеп чыккан кебек пәйда булган фельдфебель Мухин «яна гусарларга» боерык бирде:

—Будущие гусары! В две шеренги становись!

Ничек житте, шулай тезеп чыкты да, тагын команда бирде:

—Равняйсь! Смирно-о! Равнение налево!

Кабаланмый гына атлап килгән полк командирына каршы китте. Саф адымы белән, аякларын тездән катырып, каты итеп басып барды да, өч адым кала туктап рапорт бирде:

—Ваше благородие! Яна килгән гусарлар сезнен каравыгызны көтәләр. Мунча, киемнәр әзер. Себеркеләр сулы тасларда. Фельдфебель Мухин!

—Вольно!

—Вольно!

Полковник алдында басып торган «яна гусарлар» төркеменә карап алды:

—Минем гусарларны чыбыркылап кыйнаганы кайсысы? Сафтан чыгар әле.

—Тухфатуллин!

Мәүлет кырында басып торган Микалай тавыш бирде:

—Тута мы!

Фельдфебель тавыш килгән якка барып Мәүлетдинне кулыннан тотып сафтан чыгарды да, полк командирына таба каратып аркасыннан этте:

—Атла!

Мәүлетдин Төхфәтуллин тыныч кына, кабаланмыйча, каушамыйча фельдфебель күрсәткән якка атлады. Олпат гәүдә, кин кулбашлар, бишмәте

астында да калкып торган күкрәк, көчле, юан аяк-куллар—бар да тиешеннән дә артык иде егеттә. Полк командиры якынлашып килгән Мәүлетдиннән күзен ала алмады. Егет таза да, чибәр дә иде. Атлавы да җинел һәм анардан көч ташып торганны күрсәтә иде. Мәүлетдин фельдфебель белән бергә тукталды да, курку белмәс күзләре белән полковникка карап тора башлады. Полковник тылмачка таба башын аз гына борды:

—Сора әле бу гололоб... э-э-э... Сора әле, ни өчен ул гусарларны чыбыркылап кыйнаган?

Мәүлетдин тылмачның татарчалап сораганын тынлады да, җавап бирде:

—Айгырны, үзләре дагалый алмаганга ачулары чыгып, чыбыркы белән каты итеп кыйный башладылар. Шул вәхшилекне карап торырга йөрәк тә, баш та чыдамый башлады. Мин аны туктатырга гына иткән идем, ә ул суга башлады...

—Син килеп кысылмасаң, алар атны дагалаган булырлар иде.

—Юк, булдыра алмаслар иде. Чөнки мондый айгырны тик иркәләп, үгетләп кенә дагалап була.

—Күрсәт!

—Нәрсә күрсәтим?

—Әйткәч, дагалый да беләсендер. Дагала. Иркәләп!—Полковник Мәүлетдиннән көлгән кебек елмая иде. Мәүлетдин ике кулын ике якка җәя биреп, бөтен битен балкытып елмайды. Казыкка бәйләнгән хәлдә тыныч кына басып торган айгырга карап алды, тагын елмайды:

—Айгыр дагаланган инде. Ике алгы аягы да.

Тылмачның тәрҗемәсен полковник аңламады, ахрысы. Сорады:

—Ничек инде дагаланган?

Мәүлетдин, тылмач сорагач, тагын җаваплады:

—Дагаланган дим бит инде. Ышанмаса, барып карасын айгыр янына.

Полковник тылмачны тынлады да, кулындагы стек белән кара күн перчаткаларын тылмачка тоттырып, айгыр янына китте. Мәүлетдин белән тылмачны үзе белән барырга чакырды.

Барып җиттеләр. Полковник айгырның колакларын шомарта башлаганга игътибар итеп тормады. Уң кулының учы белән айгырның муенын сыйпады да, тыныч кына итеп әйтте:

—Тыныч кына! Басып тор!

Иелеп, айгырның сул аягын тезеннән түбәнрәк җиреннән тотты да, өскә тартты. Айгыр, бик курәсең килгәч, күр инде дигәндәй, аягын күтәрде. Полковник тояктагы даганы бармаклары белән кармалап та, баскалап та карады. Дага шәп утырган иде. Икенче аякны да карады да, турайды. Тылмач белән Мәүлетдинне ияртеп, полковник кире саф янына килде. Туктады. Тылмач кулыннан стек белән перчаткаларын алды да,боерык бирде:

—Башбаштак гусарларны биш көн буена конюшняда, чираттан тыш, ат бугы тазартырга куярга. Яңа килгән ... э-э... булачак гусар...

Тылмач пышылдады:

—Тухфатуллин!

—... булачак гусар Тухфатуллинны, гусарча киендергәч, беренче эскадронга тәгаенләргә. Хәзергә аңа бер җәза да бирмәскә. Чөнки әлегә анты юк. Безнең аңа карата киләчәк мөнәсәбәт үзенең тәртибенә, эшчәнлегенә карап булачак... Ә хәзер яңа килгәннәрне—мунчага! Чәчләрен алыгыз, кырыгыз. Киемнәрен иске кием җыйгычка илтеп тапшырып, акчасын үзләренә бирегез.

Башларын иеп, күңелсез генә басып торган гусарларга кисәтеп әйтте.

—Татариннан үч алырга уйламагыз да. Беренчедән, бу татар—чын ир-егет, икенчедән, сез ничәү генә тотынсагыз да, аны ала да, сала да алмаячаксыз. Чөнки аңа Алласы иксез-чиксез көч-куәт һәм тәвәккәллек биргән. Өстәвенә, анарда батырлар йөрәге...

—Мунчага, мунчага!—дип өстәде дә, итегенә стек белән суга-суга китеп тә барды.

Эскадрон командиры фельдфебельгә боерык бирде:

—Мунчага алып кит! Киендер! Һәрберсенә кием, итек таман булсын. Үзен беләсен, сине өйрәтәсе түгел. Бүген мунчада чәчле, йонлы җирләрне кырып бетерегез—бет кермәсен казармага. Чолгау урап, итек кия белү ин мөһиме—аяк уелырга тиеш түгел. Чолгау дөрес уралса, гусар бар. Дөрес итеп уралмаса—гусар юк дигән сүз! Анлашылдымы?

—Так точно, ваше благородие! Бала ураган кебек итеп урарга өйрәтербез!

Өчәрләп тезелгән тәртипсез өер булып, фельдфебель командалыгында мунчага киттеләр...

Мунчадан хәрбиләрчә киенеп чыкканнан сон, «яна гусарлар» бер-берсен таный алмыйча, исемнәрен әйтеп эзләштеләр, көлештеләр. Нык үзгәртә икән кием кешене.

Китте хәрби күнегүләр. Казарма тормышы башлангач кына анладылар яна гусарлар: алар, хәрбиләрчә әйткәндә, хәтта йөри дә белмиләр икән! Гусар тормышы аларны иртән үк «подъем!» белән эләктереп ала да, кич «отбой» белән тәмамлана. Ятакка барып тәгәрәгән көенә гусар тирән йокыга да чума. Хәтта төш тә күрмичә йоклый.

Кара айгырны дагалаганга өч көн үтүгә эскадрон командиры Төхфәтуллин Мәүлетдинне ат абзарына үзе алып керде. Ике яктагы араннарда атлар тора. Уртада калдырылган коридор кебек җирдән командир Мәүлетдинне бер аран янына алып килде. Мәүлетдин, ярым карангы бүлеккә жентекләбрәк карады да, шатланып көлеп куйды. Күзләрен елтыратып, ана таныш кара айгыр карап тора иде. Таныган Мәүлетдинне—шуна тавыш биргән. Айгыр, пошкырып, алгы ун аягынын дагалы тоягы белән так-ток китереп такта идәнгә тибә, урынында таптанып та ала. Капитан, елмаеп, айгырнын сыртына учы белән сукты:

—Бу айгыр сина, Төхфәтуллин! Полковник боерыгы!

Урысча булса да, барысын да анлады Мәүлетдин.

Айгырга куанып карады. Урысча сукалады:

—Ыспачиба, гаспадин капитан. Хоруший гусар будим.

Капитан гусарнын иненә кагылды да, көлде:

—Гусарларны кыйнама башкача. Гауптвахта булыр.

—Вахта ни нада. Гусар Мәүлет будит харуший. Түлке харуший...

Өч ай чамасы үтүгә, Мәүлетдин ярыйсы гына урысча сукалый иде инде. Гусар хезмәте Мәүлетдингә җинел бирелде дип әйтеп булмый. Ин авыры—чабып барган ат өстеннән, фехтование дип аталган ысул белән кылыч селтәп чабарга өйрәнү иде. Башта, кылыч урынына, шунын озынлыгындагы таяк тоттырдылар Мәүлетдиннен кулына. Шул таяк белән ат өстендә чабып барганда ике якта басып торган кеше карачкыларына сугарга кирәк. Йөз аршын чамасы араны чабып узганчы ике якта егерме карачкы басып тора. Һәрберсенен башына гусарларнын иске кивере киерелгән. Шуларны син таяк-кылыч белән сугып төшерергә тиеш. Ун яктагы карачкыга суккач та «кылычны» яисә сул кулга күчереп сугасын, яисә сул якка янтая биреп борылып ун кул белән тондырасын.

Беренче мәртәбә Мәүлетдин тик алты гына карачкынын «башын чаба» алды. Шулай гына булса да, икенчегә чабарга дип әйләнеп килгәч, капитан мактады аны:

—Молодец, Төхфәтуллин! Беренче керүгә алты баш күп санала ул! Молодец!

—Лушат бистра бижит бит! Бистро учин!

—Тагын да тизрәк кирәк! Сугышта тере каласын килсә! Тизрәк!

Атна үтүгә гусар Төхфәтуллин егерме карачкынын берсен дә «тере калдырмыйча» башларын чаба иде инде. Мәүлетдинне мактаган капитан янына бераз аптыраган вахмистр елмаеп килде. Ул әле генә Мәүлетдин кылыч белән чапкан ике киверны алып килгән. Киверләр икесе дә урталай өзелгәннәр.

—Господин капитан! Бу татарин киверләрне шулай чабу белән чапса, бер атнадан бетәчәкләр алар безнең.

Капитан киверләргә карап алды да көлде:

—Чапсын! Табарбыз иске киверләрне! Күрше полктан алырбыз. Менә, господин вахмистр, күз алдына китер инде, шундыйрак кивер эчендә дошман башы дип. Ә?!

—Ходай сакласын аның кулындагы кылычтан!

* * *

Ярты ел чамасы үтәр-үтмәстә Мәүлетдин Төхфәтуллин полкның иң шәп гусарына әйләнде. Ул сугыш өчен атларны өйрәтә торган плацка кара айгырын менеп чыкса, хәтта күрше полк әфисәрләре һәм гусарлары да, корпус командиры генерал Барклай де Толли кушуы буенча «как татарин джигитует» иткәнне карарга дип җыелышып киләләр иде.

Барклай диңгез эчендәге Шотландия дигән утраудагы илдән килеп, Русия армиясендә хезмәт итеп, офицердан генерал булган шәхес. Гусар халкын юк-бар, вак-төяк белән изаламыйча, үзе кирәк тапса гауптвахтаны, шпецрутенны (кыйнау таягы) кызганып тормыйча, үз корпусында һәрчак «тимер тәртип» тотты. Ул командалык иткән хәрби частьларда урысча килделе-киттеле хезмәт итү, эчкечелек, ялкаулыкның эзе дә булмады. Күп хезмәт итсә дә, мона кадәр татар Мәүлетдин кебек гусарны күргәне юк иде әле. Кара айгырына атланып плацка чыкса, аты белән бербөтенгә әйләнә! Атка менгән көенә йөгән тезгенен ияр кашагасына кидереп куя да, ат өстендә кылыч белән эш итсенме, яисә зур тизлек белән чапкан атның ияре өстеннән уңга яисә сулга «егылып китеп» юкка чыксынмы, янадан ияргә күтәрелсенме, чапкан аттан җиргә сикереп төшеп тагын ияргә сикереп менсенме—шуларның барысын да ике полк гусарлары бер генә тавыш та чыгармыйча, күзләрен ала алмыйча сокланып карап торалар. Иң алда, күн йомшак кәнәфидә күмелеп генерал Барклай де Толли үзе утыра. Мәүлетдиннең иярдән «егылып төшкәненә» кычкырып җибәргәннәр ягына Барклай кул гына селти—берничә минут үтүгә кеше арасында үзенең теленә хуҗа була алмаган гусар сак астында гарнизон гауптвахтасына китеп тә бара: тәртип, һәр җирдә тәртип!

Бер чыгышында бик тә оста «джигитовать» иткәннән соң, тирләп-пешеп ат өстендә утырган гусар Мәүлетдин Төхфәтуллинны кәнәфи алдына аты белән бергә бастырып куйдылар. Генерал ишарәләде—Мәүлетдин атыннан сикереп төште дә, «строевой шаг» белән каты итеп атлап килеп генерал кәнәфие алдында «во фронт» басып үрә катты. Җәһәт кенә, матур итеп кивер козырегы янына уң кулын китереп честь бирде һәм «доложить» итте:

—Ваше высокородие! Гусар Мәүлетдин Төхфәтуллин сезнең боерык буенча килде!

Олпат гәүдәсен кабаланмый гына кузгатып, Барклай кәнәфидән тора. Шулай ук кабаланмый гына атлап, бик җентекләп карый-карый, Мәүлетдин янына килә дә, урап, аның басып каткан гәүдәсен карап чыга. Гусарның тирләп чыккан йөзенә, конгырт күзләренә карый да, сорый:

—Син тумышың белән кайсы яктан, гусар?

—Казан губернасыннан, ваше высокородие!

—Русский?

—Никак нет! Нит урыс! Татар мин!

—Һм! Татар?! Ә ни өчен гәүдәң бик зур? Татар бит ул кысык күзле, кечкенә гәүдәле, кәкре аяклы булырга тиеш.

Мәүлетдиннең күзләрендә очкын уйнап ала, авызы елмаеп ерыла:

—Мин үзебезнең авылда гәүдәгә иң бәләкәйләрнең берсе әле.

Барклай да егетнең шаяртканын аңлап елмая:

—Әйт әле, татар егете! Тезгенне тотмыйча, син ничекләр итеп айгырны

үзенә кирәкчә чаптыра, бора, сикертә, туктата беләсең? Шпорны да сирәк кулланасың.

—Мин аны бик яхшы карыйм. Юам, тазартам, ашатам, иркәлим. Кул күтәреп сукканым юк. Аннан ул бик тә акыллы җан—кеше телен аңлый. Мин аны татарча сүзләрне аңларга өйрәттем. Кирәкне мин ана татарча әйтәм—ул үти.

Барклай гусар алдында баскан хәлдә аны бик бирелеп тыңлый. Хәзерге Англиянең төньягында урнашкан Шотландиядә туып-үсте ул. Шотландия—үз иреге өчен берничә гасырлар Англия короленә каршы сугышкан ил. Аның һәрчак үз короле булган. Барклай де Толли үзе бай пир нәселеннән. Үз иреге белән килеп Русия патшаларына тугрылыклы хезмәт итеп, зур генерал дәрәҗәсенә ирешкән кеше ул...

—Син, димәк, үзеңнең айгырына татар сүзләре белән дәшәсең һәм ул шуларны үти?

—Так точно!

—Ә нигә урысча әйтмисең айгырына? Ул бит урыс айгыры.

—Милләте булмый хайванның. Ат ул, айгыр! Аннан соң мин үзем урысча начар беләм.

Барклай уң кулын сузып Мәүлетдиннең сул кулбашына ике мәртәбә акрын гына сукты да, үзенең канәгать икәнлеген белдерде:

—Молодец! Чын егет син! Чын!

Артына борылып бармагы белән адъютантын чакырып алды:

—Бу егеткә бүләккә алтын белән ун тәңкә акча бирегез! Шулай ук полк командирына да унбиш тәңкә бүләк! Эскадрон командирына—ун, вахмистрга—биш! Бик шәп гусар әзерләп өлгерткәннәр. Кыска гына вакыт эчендә. Молодцы!

* * *

1805 елның 14 июнендә Пруссиядә Фриндланд дигән урында француз гаскәрләре үзләренең императоры Наполеон Бонапарт җитәкчелегендә Россия армиясен тар-мар итеп ташладылар. Җиңелгән Россия Франция белән тынычлык солыхы төзергә мәҗбүр булды.

1805 елның 7 июль көнендә Көнчыгыш Пруссиядә Неман елгасы ярында утырган Тильзит исемле калада Франция һәм Русия императорлары солых төзү максаты белән очрашалар.

Неман елгасының нәкъ уртасында юан арканнар белән ныгытылган, уннан артык якорьларга утыртылган зур сал су өстендә тора. Елганың ике ярыннан да, су өстеннән бер аршын чамасы калкып торган такта басмалар эшләнгән.

Императорлар сал өстендә очрашалар, күрешәләр, бик тә матур итеп елмаешалар бер-берсенә һәм... очрашуны башлап, сал уртасындагы чатырга керәләр. Шул салда ике ил арасында тынычлык солыхы төзелеп ана ике император тарафыннан кул куела, мөһерләр басыла. Елмаюлар күп була...

Солых буенча Россия Европада Франция тарафыннан яулап алынган илләрне аның кул астына буйсынган дип таный. Франция исә, үз чиратында, Россиянең Көнчыгыш ягында булган илләргә, җирләргә «бәйләнеп басып керүенә күз йомарга» ризалык бирә. Кан коеп яна җирләргә басып керүче, башкалар ирегең юк итүче ике ил бер-берсен яхшы аңлыйлар...

Тик...

Тынычлык солыхлары көчле илләр арасында киләчәк сугышлар өчен көч җыю, гаскәр туплау, яңа корал ясау һәм сугыш вакытына азык-төлек җитештерү өчен генә төзеләләр.

Шул ук 1805 елның 20 ноябрендә (бүгенге календарь белән 2 декабрьдә) Австрия һәм Россиянең берләшкән хәрби көчләре белән Франция хәрби көчләре арасында тагын зур сугыш башлана. Ул сугышның төп бәрелеше Чехия җирендә, Моравияда Аустерлиц каласы янында була.

Россия императоры Александр I нең исәбе—австриялеләр белән килешү төзеп, Наполеонны тар-мар итү һәм Россиянең яулап алу сәясәтен Европа эченә кертеп җибәрү.

Ноябрь аенда, Кутузов җитәкчелегендәге урыс армиясе Моравияда (Чехия) Наполеон җитәкчелегендәге француз көчләреннән сугыша-сугыша котылырга тырышып, Ольмюц исемле урында оборона өчен уңайлы позицияләрдә урнаша. Наполеон үзенең таралып урыс-австрия армияләрен кысып килгән гаскәрен, бер урынга туплау өчен, Брюнин (Брно) дигән җирдә тукталып лагерь кора. Хәйләкәр, хәрби сугышлар остасы бөек француз полководецы Наполеон үзенә каршы союзникларны оборона өчен ныгытылган позицияләреннән алдалап чыгарырга тырыша башлый. Наполеонның яшерен боерыгы буенча дошман белән бәрелешләрдә французларга таркаулык, курку, оешмаганлык күрсәтү фарыз ителә һәм ничек кенә булса да каршы торучы союзникларда французларда җитәрлек көч юк дигән уй тудыру кирәк була.

Бонапарт тарафыннан союзникларга җибәрелгән француз армиясенең генерал-адъютанты француз императорының көч ягыннан зәгыйфь икәнен күрсәтергә тиеш була. Һәм ул шул бурычны яхшы итеп үтәп кайта да. Шул ук вакытта Наполеон урысларга сиздерми генә австриялеләр белән солых төзү турында сөйләшүләр башлый...

Союз командованиесендә, французларның зәгыйфьлегенә ышанып, аларга һөҗүм итәргә карар кылына. Русия императоры Александр I дә һөҗүм яклы була. Урыс полководецы, Русия гаскәренең башкомандующие фельдмаршал Кутузовның холкында бик зур җитешмәгән ягы була. Ул патша сараендагы көрәштән, гайбәтләрдән читтә тора, аларга катнашмый һәм беркайчан да патшаның әмеренә каршы төшеп, үз фикерен тормышка ашырырга омтылмый да, тырышмый да. Үзенең дөреслегенә ышанган чагында да, ул патша фикеренә каршы чыгарга үзендә көч таба алмый. Патша Александр I «Һөҗүмгә»!—дигәч, Кутузов каршы чыкмый, сүзсез риза була.

* * *

Генерал Багратион җитәкчелегендәге урыс гаскәрләрендә Мәүлетдин Төхфәтуллин хезмәт иткән гусар полкы да була. Атаканың башында торган гусар полкы Вишауны алганнан соң, Брюннага һөҗүмен дәвам итеп, алга ыргыла. Вишаудан чыккач, урыс гусарлары маршал Лан кавалеристлары белән очрашалар. Китә ат өстендә кылыч сугышы. Бәрелеш вакытында французлар сөрән салып сугышуларын көчәйтәләр. Аларга өстәмә көчләр килеп кушыла. Бу инде Наполеон тарафыннан җибәрелгән шатлыклы җиңү хәбәре белән бергә өстәлгән француз кавалеристлары була. Урысларның гусар полкы французларның атлы сугышчылары тарафыннан уратып алына. Урыс кылычыннан бик күп француз кавалеристлары үз үлемен таба. Тик гусар полкының да яртысыннан күбесе туракланып ташланган була инде. Үзе янында тупланган гусарларны полк командиры соңгы атакага чакыра. Кылычын баш очына күтәреп акыра:

—Гусарлар! Безнең һөҗүм атакасы туктатылды. Ярдәм юк безгә! Кире борылыйк! Бәлки үзебезнекеләргә бәреп чыгарбыз! Беренче эскадрон безнең чигенгәнне каплап, аръергард булып сугыша! Атакага, гусарлар!

Чолганыштан чыгарга омтылып, атакага ыргылалар. Блашовиц авылына җитәрәк, полкның калдыгын ике яктан француз кавалеристларының куе болыты һөҗүм итеп камый башлый. Кылычын баш өстенә күтәреп, полк командиры полковник Федин үзенең батыр гусарларын соңгы атакага алып китә. Бożраны бикләргә Мюрат җибәргән француз кавалеристлары урыс гусарлары белән бәрелешәләр. Кылыч сугышы җан ачуы белән бара. Аръергардта килгән ярты эскадрон гусарлар полк калдыгын уратып алган французлар бożрасы тышында калган була. Арттан китереп французларга

бәрәләр. Байтак француз башлары оча гусарлар кылычы астында. Французларга яна көчләр өстәлгәннән-өстәлә...

Ун-унбиш минут чамасы үтүгә, урыс гусар полкыннан егермеләп кенә тере гусар кала. Алар һаман да сугышуларын дәвам итә. Шул гусарлар арасында Мәүлетдин Төхфәтуллин да бар. Ул барлык гусарлар арасында мәһабәт гәүдәсе белән аерылып тора. Ялан баш, канга буялган ак күлмәктән. Чабага белән иген ындырында иген суккандагы кебек, аның өстеннән бу күтәрелә. Арыган, җәрәхәтләнгән гусарларны французлар бөжра ясап уратып алалар. Алар да, сугышып арысалар да, бөжра уртасындагы гусарларга исләре китеп карап торалар. Берсе туры кылычы очына ак әләм кисәге элеп алгарак чыга:

—Император Наполеон әмере белән сезгә, әсирлеккә бирелсәгез, тормыш бүләк ителәчәк. Сез батыр гусарлар, туктагыз, ташлагыз кылычларыгызны! Әгәр бирелмәсәгез, без сезне юк итәчәкбез! Сез чолганышта! Бирелегез!

Командирлар үлеп беткән иде. Гусарлар уртада торган Мәүлеткә карыйлар. Мәүлетдиннең күләгәсе кебек ана ияреп сугышкан гусар—чуаш Миколай телгә килә:

—Мәүлет! Син ин батырыбыз, гайрәтлебез! Син нәрсә әйтсәң, без шуна ризабыз! Хәзер син командир!

Мәүлетдиннең көчле тавышы янгырый:

—Гусарлар! Минем тәкъдим—атака! Әсирлеккә төшкәнче,—үлем!

Бердәм булып әләктереп алалар:

—Үл-ле-ем! Үле-ем!

Берничә минут үтүгә, гусарлар француз кылычлары астында юкка чыгалар. Тик канга буялган ак күлмәкле, кара айгыр өстендәге Мәүлетдин генә япаялгызы французлар белән сугыша... Якын килгән һәр француз Мәүлетдиннең елтыр кылычыннан башсыз кала, яисә урталай өзелә. Акырышкан французлар арасында озын сөнге тоткан ике француз кавалеристы күренә. Өч француз уртасында кылыч белән алышкан Мәүлетдиннең артыннан сөнге белән кадыйлар. Кылычын сугарга дип күтәргән Мәүлетдин иярдән ычкынып китеп, гөрселдәп җиргә барып төшә. Хуҗасын иярдән югалткан кара айгыр ачыргаланып кешнәп җибәрә, арт аякларына басып тагын кешни дә, французларның атларына бәрелә-сугыла бөжрадан чыгып чабып китә.

Французлар, кулларын җәеп, җирдә яткан батырны уратып алалар.

—Батырның батыры!—ди француз офицеры, кылычын кынысына тыгатыга.—Илләмә дә оста, батыр сугышчы икән! Сөнге белән көчкә алдык!

Хәбәр белән җайдак килеп житә:

—Тулы жину-ү! Дошман юк ителә, кача!

Кояш болытлар, төтен арасында. Караңгы төшеп, кич була башлаган вакыт. Еракта французлар быргыда «отбой» уйный...

• • •

1812 ел. Гыйнвар аеның чатнап торган салкын бер көнендә бик елгыр алмачуар айгыр җигелгән җинел чана Бөгелмә каласына килеп керә. Төньякка караган, калын имән такталардан ясалган ачык капка янында, аклы-каралы итеп буялган шлагбаум кырында кулына озын штыклы мылтык тоткан, култык асты сүтелгән ак толып кигән, шулай да ярыйсы гына өшегән олы яшьтәге мыеклы солдат таптана. Шлагбаум янында туктау белән, чанадан таза гәүдәле бер ир төшә, солдат янына килә. Урысчалатып сорый:

—Здорово, служивый! Мин—гусар. Чакыру урынына ничек барырга?

Солдатның кулына зур түгәрәк ипи тоттыра. Тегенең йөзе яктыра, ипине кулына алып сындыра да башлый. Ул—ач. Ипи сыныгы тоткан уң кулы белән төртеп күрсәтә:

—Шушы урам белән туп-туры бар. Ярты чакрым чамасы узгач, мәйданга чыгарсың. Шул мәйданның теге ягында өч гөмбәзле чиркәү, чиркәүнең уң

ягында кызыл кирпечтән салган ике катлы йорт булыр. Шул инде—сезне җыйный торган урын...

Кузгала башлаган гусарның артыннан әйтеп тә кала:

—Ипиең өчен рәхмәт сиңа!

Гусар туктала:

—Постоялый двор кайда?

—Шул чиркәүгә каршы мәйданның икенче ягында гына.

Чанада толып киеп утырган энесенә дәшә гусар:

—Әйдә, Нигъмәтулла, кузгал! Башта постоялый дворга керик, урнашыйк. Җиңгәң белән син шунда калырсың. Атка да урын табылыр. Сезне урнаштыргач, мин китәрмен казармаларын эзләп. Патша хезмәте качмас!

1804 елда ак патшаның гусар полкына хәрби хезмәткә эләккән Мәүлетдин Төхфәтуллин була бу таза егет...

Аустерлиц янындагы сугышта урыслар ягыннан үлгән, яраланып сугыш кырында ятып калган халыкның исәбе 21 меннән артык була. Австриялеләр—6 мең кешесен югалталар. Французларның югалтуы 12 мең чамасы була... Союзникларның соңгарак калган дүртенче колоннасы ярдәмендә Кутузов тоташ тар-мар булдырмыйча, таркалган гаскәрнең бер өлешен генә Працан калкулыклары артына—Аустерлиц—Раусниц сызыгына чигендереп коткарып кала. Шуңа да карамастан, союзникларның тар-мар ителүе бик ныклы була...

Караңгы төн канлы сугыш кырын үз кочагына ала. Факел яндырган француз солдатлары яралыларны җыеп, сугыш кыры буйлап эзләнәләр, үзләренең яралы иптәшләренә ярдәм итәләр, аларны лазаретларга озаталар...

Наполеон Бонапарт төнгә каршы, бәрелеш тәмамлангач, гадәте буенча, атка атланган хәлдә сугыш кырын карап чыгарга була. Күп сугышлар үткән, хәрби карьерасын Франция императоры дәрәҗәсенә кадәр үстерә алган элекке артиллерия офицеры бүгенге җиңүдән соң тыныч кына яу кырын карап килә. Гаскәре дошманныкыннан 12 меңгә ким булуга карамастан, ул бүген дә җиңүгә иреште. Ходай тарафыннан бирелгән гениаль сәләтенә таянып иреште ул җиңүгә...

Шау-шуга игътибар итеп, император атын шунда бора. Императорның бер төркем солдатлары түгәрәк ясап басканнар да, акрын гына сөйләшәләр. Үзләре түгәрәк уртасына текәлгәннәр. Император атын солдатлар артында туктата да, сүзсез генә түгәрәк уртасындагы могҗизага карап тора башлый. Императорны күрмәгән французлар да сөйләшүдән туктап калалар. Чөнки түгәрәк уртасындагы күренешкә карап тынмыйча мөмкин түгел...

Анда чем-кара айгыр дүрт аягын да бөкләп, корсагына яткан. Урыс гусары атның ияренә ике куллап ябышкан да, олпат гәүдәсен ияр өстенә өстерәргә маташа. Ак күлмәге аркасындагы зур, ертык җәрәхәттән канга манчылып каткан. Гусарның көче дә, хәле дә юк—ул туктап тора да, тагын ияр өстенә тартыла. Кара айгыр башын борып хуҗасына карый, акрын гына пошкырып куя, кешнәгәндәй авазлар чыгара. Бөтен гәүдәсе белән гусар ягына авышкандай итә. Тик хуҗасының көче юк. Ул хәлсез башын ияргә терәп һушын җуя ахрысы—хәрәкәтләнүдән туктый. Шулчак Бонапарт телгә килә:

—Хуҗасын алырга килгән бу тугрылыклы хайван. Гусарның яраларын бәйләгез. Урыслар лагерына илтегез! Батыр гусарга, батыр дошманга безнең яктан зур хөрмәт күрсәтелергә тиеш! Атын да калдырмагыз.

Гусар—татар егете Мәүлетдин Төхфәтуллин. Бер сәгать чамасы узгач, дүрт француз солдаты урыс лагеры янындагы гусар дозорына батырны китереп тапшыра. Айгырны җитәкләгән француз офицеры урыс дозорына честь бирә:

—Француз императоры Наполеон батыр гусарыгызны сезгә китерергә боерык бирде. Виват гусарга! Атын да алыгыз! Хуҗасын ташламады.

Урыс дозорының дүрт гусары атларыннан төшеп, Мәүлетдин һушсыз яткан ятакны күтәрәләр дә, учак янган лагерь ягына, Працан калкулыгына атлыйлар. Дозор начальнигы, ияреннән төшмичә генә, французларга честь бирә...

Мәүлетдиннен аркасында—канлы зур яра. Анын җуйган егетне лазаретка кертеп салалар. Яраларын юып тазарталар. Күкрәген, аркасын ак чүпрәк белән урыйлар. Яра тәнгәлендә зур түгәрәк тишек ясалган такта ятакка салалар. Айдан артык лазаретта яткач, Санкт-Петербургка хәрби госпитальгә озаталар батыр гусарны. Башкалага барып җиткәнче диярлек Мәүлетдин ныклап һушына килә алмый. Олы, кече тәһарәте астында була. Гусарны карарга лазаретта куелган карт фельдшер—бик тырыш һәм миһербанлы. Эшен дә яхшы белә.

—Бу гусарны император Наполеон үзе безгә бирде. Батырлыгына сокланган ул гусарнын. Шунлыктан, бу гусар үләргә тиеш түгел!—диләр ана.

Петербургка җитәрәк, йөз чакрымнар чамасы калганда, Мәүлет анына килә. Кургаш төсендәге болытлар агылганга озак карап бара ул. Болытларга карау—балачактан калган гадәте. Зәй-Каратай авылы каршындагы Каравыл Тау башына менәр иде дә, шунын ин түбәсенә ятып озак-озак итеп күктә аккан болытларга карап ятар иде. «Кая агыла бу болытлар? Нигә җиргә егылып төшмиләр алар? Яисә киресенчә, нигә очып күккә, югарыга менеп китмиләр? Янгыр явар алдыннан нигә кара-кучкыл, күгелҗемгә әйләнәләр? Ә инде янгыр яумаган көннәрдә ни өчен акка әйләнеп күпереп кабаралар, күктә күчеп йөрүдән туктыйлар? Яшен каян чыга? Нигә башта яшен үзе ут булып күренә, җиргә үрелә, аннан сон гына күкрәгән тавышы килеп җитеп безгә ишетелә?»

Менә инде ул салмак кына тәгәрәгән арбада зур толып белән өсте ябылган хәлдә каядыр китеп бара. Кузгала башлаган саен аркасындагы ярасы, бөтен гәүдәсен хәлсезләндереп, сызлап авырта. Башы сызлый һәм вакыт-вакыт күз аллары карангыланып гусар анын югалта. Арба акрын гына чайкалып, Мәүлетдинне бишектәге кебек иттереп тирбәтеп тагын анына китерә. Гусар яткан арбаны тарткан ике бурлы бия бер унайга атлыйлар да атлыйлар. Кузлада утырган зур якалы чикмән кигән кучерга ныклап әйтелгән: атларны атлатып кына алып барырга, юыртуга күчмәскә! Ялалы батыр гусарны селкетергә ярамый!

Санкт-Петербург госпиталендә Мәүлетдин алтын көз җиткәнче дәваланып ята. Алтын күзлекле карт яһүд табибы карый аны. Кәкре буынлы бармаклары белән тоткалап, кысып, төрткәләп озак тикшерә аркадагы өзгәләнгән зур яраны. Үзе әллә нинди телдә акрын гына сөйләнә дә сөйләнә. Берничә көн килеп, һәр кергәнендә ике, өч сәгать Мәүлетдин янында утыра. Кем ул, тумышы белән каян, туганнары, әти-әнисе бармы? Өйләнгәнме, юкмы? Гусарлыкка ничек килеп эләккән?

Өченче мәртәбә керүендә Мәүлетдинне анадан тума чишендереп, гәүдә торышын тоташы белән сәрмәп, суккалап, баскалап, кыскалап тотып карап чыкты. Женси әгъзасына күзе төште. Бераз карап торды да, сорады:

—Син мөселманмы?

—Мөселман!

—Мөселман булгач, син «Бисмилла»ны беләсендер инде?

—Әгүзе билләәһи-минәшшәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим...

Карт табибнын йөзе бик җитди иде.

—Яраланганнан сон лазаретта күпме яттын?—дип сорады.

—Белмим. Бәрелеш ноябрьнен егермесендә булган иде. Шуннан сон кайда, нәрсә булганын мин хәтерләмим. Мин әле кайда?

—Санкт-Петербургта, хәрби госпитальдә.

—Ә ай нинди?

—Февраль башы инде.

—Февраль башы? Ә бит мине арба белән алып килделәр монда.

—Каты ялалыларны ташу өчен махсус ясалган арба ул. Сиртмәле итеп ясалган. Әгәр сине чана белән китерсәләр, каты юлда суккаланып-бәргәләнеп, синен үлеп калуын да бар иде.

Мәүлетдингә карап бераз уйланып утыргач, акрын гына янә сөйли башлый:

—Сөңге белән кадаганнар сиңа. Үләсе булгансың. Тик кадаган чакта синең сул ягына борыла биреп, кылыч белән селтәнгән чагың булган ахрысы. Сөңге башы уңга таба китеп арканны актарган, ләкин эчкә, тирәнгә үк кереп китә алмаган. Шул коткарган сине. Шулай булса да, яраң бик тирән. Ләкин син тумышың, яшәешең белән бик тә нык кешесең. Табигать сине көчле һәм нык бәдәнле итеп яраткан. Мине тыңлап, кушканнарымны эшләсәң, дүрт-биш айдан терелерсең...

—Йөри алырмынмы?

—Полкыңа кайтып, тагын да гусарлык итәрсең әле!

Мәүлетдиннең күзләре сагышлы.

—Минем полк юк бит инде ул...

—Булыр! Шул исемдәге яңа полк булыр. Һәм син шул полкта иң өлкән, тәҗрибәле, дәрәҗәле гусар булачаксың...

* * *

Усак, чаган агачлары яфракларына урманны матурлатып сары, кызыл төсләр төшә башлаганда, Бөгелмә каласы ягыннан Каратай авылы аша Зәй-Каратайга пар ат җигелгән, өсте ябык җинел генә кибитка килеп керде. Соңгы атна-ун көн эчендә яңгырлар булмаганлыктан, юллар такыр, тузанлы һәм тыныч иде. Кибитка эчендә гусарларча киенеп утырган Мәүлетдин Төхфәтуллин байтак көннәр буена, озын-озак юллар үтеп, үз авылына кайтып житте. Байтак урыс калаларын, аларның чиксез хәерче, яртылаш җимерек авылларын үтеп, Аустерлиц янындагы үлемнән котылып, исән калып кайтты ул туган авылына.

Каршы алуда була торган кочаклашу, елау-сыкташтан соң атна-ун көн буена «хәл белергә» килү башланды. Көзге игеннәрне җыю бара иде. Шунлыктан килгән-киткән ерак-якын туган-тумачалар, күрше-күлән һәм дә дус-ишләр бик озаклап утырмадылар. «Иртә таңнан эш бит, урак бит, көлтә ташыйсы бар бит!»—дип, китә тордылар.

Беренче карашка Мәүлетдин төскә-башка таза, әйбәт кенә күренсә дә, исәнлеге бик шәптән түгел иде гусарның. Яңгыр яварга, яисә кар-буран булырга торса, ул ике-өч көн алдан авырый башлый. Кул-аяклары авырая, йөрәге акрын тибә башлый, хәле бетә, һава житми. Кыш буена ишек алдыннан чыкмыйча яши хәзер элекләре гайрәтле игенче, печән чабучы, сабан туйлары батыры һәм дә оста кылыччы гусар Мәүлетдин. Өстәвенә, сул кулы тиешенчә өскә таба күтәрелеп тә бетми...

Кайтып ай чамасы яшәгәч, Мәүлетдин әтисенә генә үзенең «гусар серен» ачты.

—Әти! Әйдә әле минем белән. Сиңа күрсәтә торган бер әйбер бар миндә.

Ишегалдын узып мунчага керделәр. Мәүлетдин кулбашына салган гусар киверенең эчке түш кесәсенә тыгылды да, чүпрәккә төргән кечкенә төен чыгарды. Аны чишеп учына җәйде. Әтисе җәелгән учтагы яткан әйбергә карап дерелдәп куйды. Улының сул кулында көмеш тәре белән көмеш түгәрәк тәнкә ята иде.

—Нәстәләр болар, Мәүлетдин?!—дип сорады ата кеше улыннан.

—Аустерлиц сугышы өчен урыс патшасы урдины белән, тере калган өчен патша мидале.

—Мина нәстәгә күрсәтәсең инде боларны?

—Болар икесе дә минем батырлык өчен ак патша бүләкләре, әти! Нәрсә эшләтик икән?

—Кайчан бирделәр?

—Санкт-Петербургта гуспиталдән чыкканда. Алмаска да иткән идем, «тәреле» дип, гуспитәл нәчәлнигe алдырды: «Сиңа ныклы тәрбия кирәк 2—3 ел буена. Син эшләп ашарлык түгелсең, ал! Ул урдин белән мидәлгә акча түлиләр»,—диде.

Ике айныкын бергә кушсаң, бер сыер алып була, ди. Ак падишаһ өчен кан түктең, акчасы сиңа тиеш, ди. Мин әйтәм: «Крест бит, ә мин мусульманин!» Ул көлә: «Крестны сандык төбенә яшереп куй, ә мидал түгәрәк бит, тагып йөр. Акчасын ал—яшәргә кирәк бит»,—ди. Нишләтәбез инде боларны, әти?

—Акчасын каян алырга?

—Бөгелмәдән, елына ике мәртәбә барып алырга. Април, нуябр айлары уртасына.

Карт, бераз уйлангандай басып торды да, сүзен әйтте:

—Мин, улым, болай дип уйлыйм. Синең госпитал нәчәлнигын дөрес әйткән. Кан түккәнсең ак патшага—түләсеннәр! Дөрес ул. Тәре алганыңны бер кешегә дә әйтмә, сөйләмә. Миңа тапшыр аны. Яшереп куярмын. Кирәге чыкса, үзенә кире бирермен. Ә түгәрәк мидалең тагып бар, акча алырга барсаң. Авылда такма. Түгәрәк мидал булса да, без татарга килешеп бетмәс. Акчалары сиңа бик кирәк—исәнлегеңне ныгыту өчен сиңа сый-тәрбия кирәк бит инде.

Шулай килештеләр дә. Тәреле урдинны Әмәметдин каядыр яшерде. Ә түгәрәк урыс мидалын Мәүлетдин акча алырга барганда Бөгелмәгә тагып йөрде...

Авылга кайтканнан соң Мәүлетдин дүрт елдан артыбрак киткән вакыт эчендә тулысынча савыгып бетә алмады. Шулай да, 1810 елның язынннан алып кара көзенә кадәр әтисенә яхшы гына ярдәмче булып, ялан кыр эшләрендә катнашты. Печән өсте житкәч, Ерак Акланда үзенә куыш ясап алды да, печән өсте узганчы кайтмастан диярлек шунда куна ятып печән чапты. Иртән чык белән, кичке салкында кабаланмыйча, тәмен белеп печән чапты. Кояш күтәрелеп кыздыра башласа, тырма белән печән жыйды, чүмәлә салды. Кигән киң төпле, буйлы киндер ыштан, оек-чабатасы олпат гәүдәсенең матурлыгын бозмыйча, Мәүлетдиннең чибәрлегенә комачауламый иде. Кояшлы, жылы, хәтта эссе көннәрдә дә Мәүлетдин өстенә күлмәк кимәде. Әтисе ашарга китергән көннәрдә дә ул, күлмәген кимичә, иненә гусар мундирын гына сала иде. Әтисе бер көнне өйләдән соң килгән чагында, улы Мәүлетдин тезләнгән хәлендә арты белән куыштан чыгып килә иде. Әтисенең килгәнен сизмәгән Мәүлетдин аягына басты. Шулчак аның аркасын күреп, әтисе тетрәнеп китте. Ирексездән аның күзләреннән яшь агып чыкты. Аркасының яртысын диярлек зәңгәр-кызыл тире, өзгәләнгән яра эзе каплаган. Кеше аркасына охшамаган. Ата кеше акрын гына атлап килеп, улының бетәшкән ярасын зур учы белән сакланып кына каплады. Мәүлетдин акрын гына башын борып карады—әтисе икән!

—Исән-сау килеп життеңме, әти?—диде улы аркасы белән әтисенең учына сыена биреп.—Учың жылы инде.

—И, бала, бала!—дип сыкранды ата кеше.—Ничекләр итеп исән кала алдың син? Ә?!

—Минем исән калганга Петербург табибларының да ышанасылары килмәде инде. Дәвалаган табиб үзе кебек егермеләп табибны алып кереп, минем арканы шуларга күрсәтте. Тотып-тотып карыйлар исләре китеп. Ярты арка өзгәләнгән иде бит. Үземә шуны көзгедән күрсәттеләр Петербургта. Тетрәнеп, куркып киттем үзем дә...

—Син печән чабасың да бит чабуың, малай! Ярыймы икән соң ул чабу сиңа?

Мәүлетдин ышанычлы тавыш белән әйтте:

—Ярый, әти! Чаба башлаганчы ярты төн житкәнче минем арка кызышып сызлый иде. Чаба башлагач та өч көн сызлады. Дүртенче көнне яткан көйгә йоклап киткәнмен, иртән тартай кычкырганга гына уяндым. Ятканмын да, сүнгәнмен дә. Чалгы селтәү арканы яза ахрысы. Кан йөрешен әйбәтләндерәдер дип тә уйлыйм. Инде башның сызлавы да кимегәннән-кими...

Чалгы белән печән чабып, Мәүлетдин тәмам аягына баса алды. Яраланганына биш ел тулып килгәндә, әтисе Әмәметдин сакланып кына сүз кузгатты:

—Улым, синең бу солдат-гусар хезмәтенә тагын барасың бармы, юкмы?

—Белмим, әти! Медальләр акчасына өстәп миңа бит сугышта яраланган өчен азрак тагын акча бирәләр. Сорашкан идем мин, хезмәт турында. Бер әфисәр әйтте: «Ул кадәр каты яраланганнан соң сине башкача алмаслар инде»,—диде. Азрак уйлап торгач, өстәде: «Безнең патша белән Француз императоры бәхәстә яшиләр. Тагын сугышмыйча булдыра алмаслар ахрысы. Сугыш булачак. Шуңа халыкны тагын җыюлары мөмкин»,—диде. Берәр уең бар мәллә?

—Соң, улым, баш булгач, башта ми бар бит инде. Ми булгач, уй да була торгандыр инде...

Бормаланып сөйләгәненә үзенә дә күңелле булып китте ахры. Йөзе яктырды, елмайды:

—Әниең белән көн-төн дигәндәй уйлаштык, киңәштек тә, бер карарга килдек икәү. Синең хакта.

Мәүлетдин сораулы күзләрен әтисенә текәде:

—Ниндиерәк карар икән инде? Тыңлап карыйк. Әйт.

Әмәметдин тамагын кыргандай итте. Кеше юкмы икән дигәндәй, артына борылып карады. Анда Мәүлетдин салган печән чүмәләләреннән башка беркем дә юк иде.

—Менә бит... улым... болай бит. Без, әниең белән... әййе, әниең белән, сине башлы-күзле итәргә уйладык бит әле! Әййе! Башлы-күзле итәргә! Бик уңган, үзе чибәр, сылу кыз бала бар. Нәселе дә уңган, эшчән, калын, бай нәсел. Әшли дә беләләр, аш-суга да байлар, муллар.

—Әни белән икәү уйлашкач, килде-китте нәселдән алмассыз инде.

—Шулай, улым! Яшең дә байтак. Озак җәфаландың бит ак патша хезмәтендә алган яраларың белән. Инде, иншалла! Ходай кушып, таза хәлеңә кайтып барасың. Иншалла!

Улына тиз генә күз сирпеп алды да карт, янә өстәде:

—Килен буласы җан—күрше урамнан. Сыерчык Сәләхетдиннең өченчегә туган кызы. Исеме—Шәрифә. Уналтысы тулып унҗидегә киткән шушы елның язында. Әниең әйтүенчә, бик уңган да, бик сылу да икән. Суга барган җирендә дә атлый-йөгерә генә бара икән.

—Бик яшь бит, әти!

—И-и, ул-лым! Алай димә син. Әнә, әнкәннең энесе Сәлимгәрәй абзаңны гына ал. Үзеннән егерме өч яшькә яшь бичә белән яши. Алты балалары бар. Хатыны күпкә яшь булса да, үзе хуҗа өендә. Яшь, имеш! Булса соң. Рәхәтләнеп яшь хатын белән яшәрсең. Шул сиңа!

Мәүлетдин карар кылды:

—Әйдә, болай итик алайса!—Ул кызны мин дә күрим инде... Югыйсә, чыбылдык эченә кергәч, кәкре аяклы, үзе кылый, үзе шадра булса, мин аннан...

Әтисе, көлемсерәп, аны бүлдерде:

—Йә, йә, уенга әйләндермә! Мин ул балага туры итеп караганым юк каравын. Кеше баласы, кыз бала! Әнкәңә бик ошый инде. Кызның әнкәсе белән яшь чакларында ахирәт тә булганнар. Ул кызны сиңа күрсәтү турында без болай итик. Әнкәң барсын, сөйләшсен. Безнең теләкне белдерсен. «Шулай-шулай, яучы җибәрергә уйлыйбыз. Тик улыбызның, читтән генә булса да, кызны күрәсе килә»,—дисен. Гореф-гадәт шулай инде безнең—каршы килмәсләр дип уйлыйм мин...

Ике көн узгач, чишмәгә төшкән сукмакта Мәүлетдин кызны очратты. Гали чишмәсе тау итәгендә чыгып ята. Кызның яшәгән урамы Зәй елгасына килеп терәлгән. Елга аша матур итеп агач басма салынган. Мәүлетдин урам очындагы

өй эчендә, качып, көянтә-чиләк күтәреп өй янынннан үтеп киткән кызны тәрәзәдән карап калды. Тик жентекләп карап өлгерә алмады. Вак-вак кына һәм тиз атлаган кыз гәүдәсе тәрәзә каршында бар да булды, юкка да чыкты.

Кыз үтеп киткәч, Мәүлетдин ишек алдына чыкты да, капка төбендә үсеп килгән куе шомырт куаклары аша кызны күзәтә башлады. Кыз җәһәт кенә атлап басма янына төште дә, аны кабаланмый гына үтеп, сукмактан чишмә янына күтәрелә башлады. Өстендә эре генә чәчкәле, бала итәкле күлмәк, өстеннән итәкләре, түшләре чиккән алъяпкыч буган (узганда тәрәзәдән күренеп калды), башында, артка тарттырып бәйләгән эре чәчәкле, сарылы-каралы яулык, аякларында Казан чүәкләре. Ике юан чәч толымы, очларына таккан чулпылар авырлыгы белән аркасы буйлап аска таба озын булып салынып төшкәннәр.

Кыз, агач улактан аккан көмеш суны чиләкләренә тутырды да, көянтәсенә элеп, кайтыр юлга, сукмакка керде. Мәүлетдин, кызның басмага килеп житкән чагын туры китерергә тырышып, аның каршысына атлады. Нилектәндер тамагы кипте, теле аңкавына ябышкан кебек булды. Куллары, арттан жилкәсе тирләп чыкты. Ап-ак күлмәге эчендә көчле тәне кызыша иде. Хәтта аяклары халсезләнә һәм азрак калтыраган кебек тә була башлады. Кыз басмага килеп житкәндә, аның икенче ягында Мәүлетдиннең олпат гәүдәсе басып тора иде. Башын азрак ия биреп, көянтә-чиләк күтәреп атлап килгән кыз бала басмага күз салганда сискәнеп китте. Ул басманың теге ягында басып торган баһадир егетне күргән иде. Басмага кермичә тукталды да, инде нәрсә эшләргә дигәндәй, башын игән хәлдә басып тора башлады. Мәүлетдин басмадан ике адым читкә атлады.

—Үт, туганым! Курыкма миннән! Әйбәт кеше мин.

Кыз сакланып кына баса-баса басманы үтте. Күзен сирпеп тиз генә егеткә карап алды. Басынкы, матур тавыш белән дәште:

—Исән-саумы, Мәүлетдин абый?!

—Аллага шөкер, сеңлем! Рәхмәт соравыңа! Терелеп беттем инде дияргә була хәзер. Үзең исәнме?

—Аллага шөкер!

Басманы чыккан уңайга ук китеп тә барды. Йөзе чибәр, алсу, гәүдәсе талчыбык кебек зифа һәм атлаулары да затлы иде кызның. Күз карашымны сизеп уңайсызланмасын тагын, дип уйлады да егет, елга буйлап, су агымы ягына салынган ярдагы сукмак белән төшеп китте...

Тугай, болыннарда озак йөрде үлем белән йөзгә-йөз бәрелешеп, күпне күргән, күпне кичергән гаярь егет Мәүлетдин...

Көтү төшеп, мал-туарны жыйнап, сыерлар савылгач кына өенә кайтты. Мич янында нәрсәдер пешереп мавыккан әнисе ишек ачылганга борылып карады. Улының нурланган йөзен күргәч, ананың йөрәге шатланып тибә башлады.

—Юлың уңдымы, улым?—дип сорады ана.

Мәүлетдин җавап урынына башын гына какты да, түр якка үтте.

Бер ай үтүгә, кызны яучылап алып, ике урамга гөрләтеп туй ясадылар. Килен төшерделәр дә, тырышып дөнья да көтә башладылар...

• • •

1812 елның 28 май иртәсендә, Наполеон гаскәре Неман елгасын кичеп, Россиягә каршы сугыш башлаганда, Мәүлетдин елга суында атын юа иде. Лагерьда дөбердәтеп барабан каккан тавыш тирә-якка «тревога—куркыныч» икәнне хәбәр итте. Мәүлетдин хезмәт иткән гусар эскадроны бер минут эчендә жыйналып, атларын чаптырып лагерьга ашыкты. Өч полктан торган атлы гусар гаскәре гомуми сафта иде инде. Шул сафтагыларга Мәүлетдин эскадроны да килеп кушылды. Дивизия белән командалык иткән генерал Волков сүзне кыска тотты:

—Гусарлар! Французлар Русия җирләренә басып керделәр. Без, Бөек император Александр Беренче гусарлары, бүген үк французларга каршы сугыша башлыйбыз! За Веру, за Царя и Отечество!

Дивизия командиры боерыгы белән походка чыгарга әзерләнә башладылар...

Гусар Мәүлетдин Төхфәтуллинны полк командиры полковник Прошкин чакыртты. Полковник артында ике адъютанты басып торган хәлдә сөйләште гусар белән:

—Менә нәрсә, Төхфәтуллин! Безгә чигенергә дигән боерык килгән. Вә ләкин...

Шатлыктан ялтыраган күзләре белән гусарына яратып та, сокланып та карады.

—... Безнең дивизиягә князь Барклай де Толли тарафыннан бик тә дәрәҗәле вазифа йөкләтелгән. Французлар бездән ике мәртәбә күбрәк. Ачык сугышта әле аларны без җиңә алмыйбыз. Шунлыктан, актив чигенү тактикасы белән чигенәбез. Армиянең бер өлеше чигенә, бер өлеше торып калып, Наполеон гаскәрләренең авангардына ташлана һәм тиз үтә торган бәрелеш ясый. Французлар килеп җитеп көч алганчы, без инде тагын чигенәбез. Бездән алда киткәннәр җайлы урын табып, французларга тагын бәрү өчен көтеп торалар. Ә безнең гусарлар дивизиясе Барклай де Толли галиҗәнапләре армиясенең һәрчак аръергады булып барып, армиянең чигенүен каплап, бертуктаусыз дошман белән терәлеп сугыша. Дошман авангардының һәр адымын белеп тору безгә фарыз.

Син, гусар Төхфәтуллин, үзебезнең полкта гына түгел, бөтен дивизиядә—иң атаклы гусар. Син бит, Төхфәтуллин, француз белән 1805 елны ук, Аустерлицтан ук таныш. Аустерлиц батыры! Французны яхшы беләсең. Сиңа утыз гусардан торган команда бирелә. Һәм син, көн-төн французлардан ерак китмичә, аны күзеңнән югалтмыйча, маневр ясап чигенергә тиешсең. Өч сәгать саен бер атлы гусарны полк штабына француз турында хәбәр белән җибәреп барасың...

—Ваше благородие! Мин бит урысча укый-яза белмим.

—Гарәп хәрефләре белән татарча яз! Иң кирәген! Ә күбесен телдән хәбәр ит. Һәр полкта татар тылмачы бар һәм ул тылмач татарча язуны яхшы белә.

Синең командаң кебек тагын унике команда була. Туры килеп, ялгыш бер-берегезне чапкалап ташламагыз. Форма—гусарларча! Сораулар бармы?

—Бар, Ваше благородие! Берәү генә!

—Нинди?

—Французлар белән йөзгә-йөз очрашканда безнең команданың тактикасы нинди булырга тиеш?

Полковник бик ныклап карады гусарына.

—Син каласың аръергадның иң соңгы өлешендә. Һәр минут, һәр секунд синең хәлең, команданның хәле үзгәреп торачак. Шунлыктан, мин сина урынында карар кылып хәрәкәт итәргә, сугышыргамы, качаргамы дигәндәй, синең үзенә тулы ирек бирәм. Карар кыл, сугыш, кылыч белән чабыш, дошманны үтер, тик үзең генә исән кал һәм команданны исән калдыр. Иң мөһиме—синнән дошман турында безгә җибәрелгән хәбәр! Иң мөһиме!

Июнь азагыннан алып, август беткәнче Мәүлетдин командалык иткән кечкенә отряд көн-төн хәрәкәттә булды. Кунарга авылларга туктамадылар. Йокыга көн яктысын биреп, бүре кебек төнлә хәрәкәт иттеләр. Утыз бер атны, утыз бер гусарны Мәүлетдин баштанаяк үзе карап чыкты. Бер генә тимер дә, икенчесенә бәрелеп, чыкылдап тавыш чыгарырга тиеш түгел! Төнен, «кәсепкә» чыкканда, ат башына, эченә солы тутырылган кечкенә капчык кидереп, колак артына бау белән тарттырып бәйләп куела. Ат пошкырмасын, кешнәмәсен өчен, вакытны әрәм итмәс өчен гусарлар тәүлеккә ике мәртәбә генә ашый. Иртән һәм кояш баерга 2—3 сәгать кала. Көндез берәр урман

эчендә, яисә юллардан ераграк ерым, чокыр эчендә—ял, йокы. Йокларга яткан чакта дүрт якта дүрт гусар каравыл- дозорда тора. Боларга инде йокы юк. Тик алар өч сәгать саен алмашына—йокламыйча ял итә алмаган гусар булырга тиеш түгел.

Мәүлетдинне, аръергадка чыгып китәр алдыннан, тагын унбер гусар белән «француз» теленә «укыттылар».

—Кайсы полк? Кайсы дивизия?

—Командирыннын исеме кичек?

—Ничә пушка?

—Полкта ничә кеше? Дивизиядә ничә кеше?

Ике сәгать чамасы шул сорауларны француз телендә бирергә өйрәттеләр. Җавабын анламасагыз, яздырыгыз, диделәр. «Кай арада анда яздырып торып өлгерәсен инде?»—дип уйлап куйды Мәүлетдин. Һәм французлар белән очрашканда чыннан да язып тору кайгысы беркайчан да булмады.

Икенче көнне кичен,урыс попы чукындырып озатырга килде. Кадиласын күтәргән, карадан киенгән поп гусарлар сафына якынлаша башлагач, Мәүлетдин, сул кулы белән кынлы кылычын ботына кыса биреп, тавышсыз гына сафтан чыкты да, сулгарак тартылып, бик үк ерак китмичә басты. Поп сафның икенче башында басып торган полк командирына дәшеп, башын селкеп, сафтан чыккан гусарга ымлады. Полковник Прошкин кабаланмый гына атлап гусары янына килде:

—Син нигә сафтан чыгасын, Тәхфәтуллин?

—Мин мөселманмын, ваше высокородие! Урыс попынын мине чукындырырга хакы юк. Һәм мин беркайчан да чукынмаячакмын.

—Син бит патшага ант иткән гусар!

—Минем чукынып ант иткәнем юк. Ә патшага мин поптан башка да тугрылыклымын. Мин, Аустерлиц сугышын узып, исән кала алган гусар. Шул сугышта мин исбат иттем инде үземнен кем икәнлекне! Мин—мөселман!

—Ладно!—диде полковник .—Мөселман бул. Яхшы!

Төн карангысына чыгып киттеләр урыс армиясе гусарлары. Үлемгә каршы, француз белән бәрелешләр эзләп, урман куелыкларында, ерым-чокырларда уяу йокыга талып, аз гына булса да йоклагандай итеп, дошманга һөҗүм итү өчен.

Август азагына кадәр Мәүлетдин җитәкчелек иткән кечкенә отряд тоташ агым булып килгән француз армиясенең авангарды алдында үткәрде көннәрентөннәрен. Хәрәкәт итә башлаган көннән үк Мәүлетдин-гусар үзенең гусарлары белән һәрвакыт хәрәкәттә булды. Тан атып килгән чакта, яктыра башлагач, әле кояш чыкмас борын, көндез йоклап ял итәр өчен алдан сайлап, карап куйган урынга урнашалар. Утыз бер гусар—һәркайсынын үз вазифасы.

Якын-тирә акланнан иятгә бәйләнгән урак белән азрак булса да үлән ура бер гусар. Ботка пешерергә урын эзли. Алдан тапкан урынга тан атуга иптәшләрен алып килеп җитә...

Көндез качып ятып, йоклап ял иткән кебек булсалар да, яшеренеп яткан дүрт гусар күпме гаскәр узган, ничә пушка үткән, аларга ничәшәр ат җигелгән, гаскәрнең төрләре нинди—барысын да күреп, исәпләп, санап ята. Караңгы төшүгә, бер гусар полк командирына язу белән, яисә телдән барлык күргәнбелгәнне җиткерергә китә. Көндез качып, йоклап яткан гусар төркеме, французларның хәрәкәт итүеннән инде аларнын тылына әйләнгән урында кала...

Караңгы төшкәч, «кәсепкә» чыгалар. Берәр авылга җитеп бетмичә атларыннан төшәләр дә, 4—5 кешедән торган төркемнәргә бүленеп, авылга кереп китәләр. Бакча, тыкрыклар аша алдан икәү, арттан 2—3 кеше булып, «тел» эзлиләр. 2—3 француз солдаты туры килсә, берсен исән калдырып, калганнарын пычак аша үткәрәләр дә, авылдан юкка чыгалар. Күп вакытта куркуыннан исе чыга башлаган французны ияр алдына аркылыга салып, көндез туктаган урынга алып кайталар. Мәүлетдин французлардан сорау алганнан

сон, аны чәнчеп үтерәләр дә, үзләре ягына юл алалар. Яктырганчы барып, юл күрсәтүче тапкан урынга ялга туктыйлар.

Французлар да йоклап ятмый. Бер мәртәбә, авылга житәрәк, кечкенә калкулыкны узганнар иде, тирә-яктагы чокырлардан француз атлылары пәйда булды. Мәүлетдин кылычын чыгарды да:

—Минем арттан!—дип кычкырды.

Ул атын туп-туры французлар төнгелеккә туктаган авылга каратып, томырылып чабып китте. Гусарлар—аның артыннан! Засадада көткән француз атлылары авылга керә торган якка бер генә француз да куймаганнар. «Курыкмыйча, французлар туп-тулы авылга кереп китмәсләр бит инде урыслар! Аны эшләү өчен башсыз булырга кирәк!»

Атлары шәп иде гусарларның. Шулар коткарды. Ул көнне «кәсеп» итмичә, буш кайттылар. Шулай булса да, кәефләре кырылмады егетләрнең. Исән калдылар бит, үлем элмәгеннән котылып. Төн буе Мәүлетдин уйланып ятты: «Хата нәрсәдә? Нигә безнең килгәнне французлар көтеп торган?» Уйлана торгач, очына чыкты шикелле: «Төнен «кәсепкә» кергәндә, авылның Мәскәү ягына караган очыннан түгел, ә кире ягыннан керергә кирәк. Француз безне шул яктан, Мәскәү ягыннан килгәнне көтә».

Һәм, ике төн беркая да чыкмыйча, «кәсепне» туктатып тордылар. Ял иттеләр, яхшы итеп атларын ашаттылар, аларны тазарттылар, юдылар. Өч көн узгач, Чугуновка исемле 50—60 йорттан торган авылда французларга көпә-көндез һөҗүм иттеләр. Яңа гына авылга килеп кергән французлар төркеме йөз кеше чамасы иде. Французлар килгән юл белән гусарлар жай гына юыртып авылга килеп керделәр дә, Мәүлетдин биргән боерыкка буйсынып, кылычларын чыгарып урамда буталышкан французларга «ура» акырып ташландылар. Унга-сулга кылыч белән селтәнеп, озын бер урамлы авыл буйлап, французларны чаба-чаба атларында жилдереп уздылар да, авылны чыккач, аңа терәлеп үк торган урманга кереп юкка чыктылар. Өч-дүрт чакрым барганнан соң унга кереп киткән урман юлына борылдылар. Берничә кечкенә елганы кичеп чыгып, озын сөзәк тауны менеп житкәч, тагын 15-20 чакрым чамасы юл үтеп, юлны ташлап урман эченә кереп киттеләр.

1812 елның август аенда Барклай де Толли урынына Кутузовны хәрби Баш командующий итеп куйганда, Русия патшасы Александр I аңардан сорый:

—Михаил Илларионович! Син Наполеонны жиңә алырсыңмы?

Кутузов, сынар күзе белән патшасына бераз карап тора да, жаваплый:

—Жиңә алырмынмы-юкмы — анысын төгәл генә әйтә алмыйм. Иллә дә мәгәр, мин аны алдарга тырышачакмын!

Август азагында полкка кайткач, полковник Прошкин Мәүлетдин командасын башкача жибәрмәде. Штабка кергән гусарны кочаклады да, түргәрәк алып барып, урындыкка утыртты:

—Булды, Төхфәтуллин! Безнең белән хәзер фельдмаршал Кутузов житәкчелек итә. Ишеттеңме шул турыда?

—Юк. Сездән ишетәм. Әйбәт бу. Аустерлицта Кутузов командалык итмәгән булса, без тоташ беткән идек. Наполеон байтагыбызны тураклап, күпчелегебезне әсир итеп алган була иде.

—Шулай! Инде дүрт көн ял итегез. Ашагыз-эчегез, йоклагыз, юыныгыз, кырыныгыз. Бетләдегезме?

—Бет юк бездә. Гусарларны көн саен, барысына да боерык биреп, юындырдым. Очраган елга-күлләрдә. Тән чиста, юылган булса, бет чыкмый. Ул пычрак тәнне ярата.

—Нигә алай?

—Чиста тәндә бетнең аягы тая, диләр. Ә пычрак тәндә ана йөрергә түмгәкләр күбәя, диләр. Басып йөрергә.

Икәүләшеп көлделәр.

—Ярар, уен-көлке бетте. Синең белән сугышкан гусарларга медальләр, ә сина Георгий тәресе булыр бүләккә.

Мәүлетдиннең йөзе карала төште.

—Минем бер тәрем бар инде. Такканым юк һәм такмаячакмын.

—Нигә алай?

—Мөселман бит мин.

—Шуннан, мөселман булсаң ни булган?

—Безгә тәре тагып йөрергә Алла кушмый. Сез белмисездер, безне бит поплар тәре үптереп, чукындырырга болашалар. Инде өченче йөз ел китте.

—Сине бит бүләксез калдырырга ярамый.

—Мина түгәрәк медаль бирегез, ә башка гусарларга мина бирергә иткән Георгий тәресен бирегез. Алар бар да урыслар, православныйлар.

Полковник сүзне икенчегә күчерде.

—Без дивизиябез белән бергә гомуми, зур сугышта катнашачакбыз. Бәрелеш Бородино авылы янында булачак. Атларыгызны, аммунициягезне, коралларыгызны карагыз. Киемнәрегезнең ертыгы булмасын. Юыгыз, ямагыз. Бик күпләребез исән кала алмас ахрысы...

—Бар да Алла кулында!

—Шулай. Дөрес.

—Кылычларыгызны яхшылап чарда тотыгыз, үткерләгез! Аларга эш күп булачак.

—Слушаюсь!

—Ярар! Яхшы! Күп күрдегез, күп файда китердегез. Инде зур сугышка әзерләнегез!

—Слушаюсь!

—Бик шәп гусарсың, Төхфәтуллин! Исән калырга тырыш!

—Слушаюсь, вашвысокород!

—Хуш, Төхфәтуллин! Башкача күрешмәсәк, бәхил бул!

—Хуш, вашвысокород!

—Кая, кочаклыйм әле үзеңне!

Ике батыр сугышчы, полковник һәм аның гусары, кочаклашып хушлаштылар. Бу аларның чыннан да соңгы күрешүләре иде.

Полк командирының чатырыннан чыкканда Мәүлетдин эчке бер өзгәләнү сагышы белән сөйгән хатынын исенә төшерде. Бөгелмәдән Мәүлетдин Казан каласына, аннан Мәскәүгә китәргә дип чанага утырырга җыйналганда, хатыны аның киң күкрәгенә сыенып башын яшерде дә, пышылдады:

—Мәүлетдин! Безнең кечкенәбез булачак бит!

Ире эсселе-суыклы булып китте. Зур учы белән сакланып кына хатынының иягеннән тотып, башын өскәрәк каратты:

—Чынлапмы?

—Әййе.

—Кайчаннан бирле инде?

—Шәрифә түтәй әйтә, ике айлык чама белән, ди...

Мәүлетдин хатынын үзенә таба тартып сак кына кочаклады. Ә анысы яшь аркылы өзгәләнде:

—Исән-сау гына кайтырга тырыш инде, бәгърем. Мин синсез саргаеплар үләрмен инде монда.

—Мин кайтырга бик тә тырышырмын. Син мине көт. Үлә торганнардан түгел мин.

Хатынына иелеп, иреннәрен аның маңгаена терәде. Йөрәктән чыккан сүзләрен әйтте:

—Малай туса, исемен Төхфәтулла кушыгыз.Ә инде кыз бала туса, дәү әниемнең исемен бирегез. Бик ярата иде ул мине. Елама, бәгърем. Ходай кушса, исән кайтырмын. Әгәр инде кайтырга язмаса, мине ике ел көт тә, кешесе табылса, икенчегә кияүгә чык. Ә баланы әтиләргә калдырып кит. Үги әтидә яшәтәсем дә, үстерәсем дә килми аны. Кайтмасам, бәхил бул. Рәхмәт сиңа, асыл хатын булдың. Хуш!

Хөкүмәт толыбын киеп, хөкүмәт чанасына утырды да, көчле татар егете Мәүлетдин тагын урыс гусарлыгына дип карлы, озын юлга чыгып китте. Авырлы хатынын калдырып. Мәңгелеккә...

Әмәметдин улы гусар Мәүлетдин Төхфәтуллин 1812 елның 7 сентябрендә Бородино сугышында французларга каршы ясаган атлы контратакада һәлак була. Французлар үзләренең сул флангысы белән каршы торган урыс гаскәрләрен туздырып ташлап, тар-мар итәләр дә, Бородино кырында үзләре белән алышкан барлык урыс гаскәрен чолгап алу исәбе белән, кырны уратып ала башлыйлар. Кутузов уртада сугышкан ике гусар полкын тагын атакага әзерләнгән жиреннән туктата. Аларны арткарак чыгарып, көчле агым белән урыс тылына ыргытылган французларның атлы корпусына каршы юнәлтә. Ике агым булып, атлы гусарлар французлар белән килеп бәрелешә. Атлар ачыргаланып кешнәгән, үлем эләктереп алган урыс һәм французларның җан биреп акырулары, корычка корыч бәрелгән кылыч тавышлары, ат тоягы тавышлары атлы сугыш барган кырны каплап ала... Урталай өзелеп аскы өлеше иярдә калган гәүдәле атлар, муены кылыч белән чапканнан жиргә тәгәрәгән башлар, аягы өзәнгедән чыга алмыйча жирдән өстерәлгән гәүдәләр, иярендә кылыч белән алышкан сугышчылар утырган атлар—бар да бергә буталып бетә...

Ярты сәгать үтүгә, урысларның ике полк гусары француз кылычы астында тоташы белән юк ителә. Тик французларның атлы корпусы да Бородино кырын уратып алырлык көч- гайрәтен югалта.

Атларыннан төшмичә генә, французлар жирдә аунап яткан яралы урыс гусарларын чапкалап чыгалар. Өч француз сугышчысы кулларын җәеп яткан олпат гәүдәле гусар янында тукталалар. Муенының уң ягыннан, арттан кылыч белән күкрәгенең яртысына кадәр аерып чапканнар. Атыннан егылып төшкәч җан биргән. Таза гәүдәле француз иптәшләренә мактана:

—Безнең өчәүгә каршы бер үзе алышканда, мин чабып килеп, атымны арткы аякларына күтәрдем дә, шул алгы аякларын җиргә төшергәндә, өстән аска чаптым. Бер ялгызы калган иде инде бу гусар...

Атыннан төште.

—Трофей итеп кылычын алыйм әле.

Тик йомарланган бармакларны ачып кылычны ала алмады. Кул бармакларын чабарга дип кыныннан кылычын чыгара башлаган иде, ат өстендәгеләрнең берсе аны туктатты:

—Пьер! Чыгарма кылычынны! Тимә бу гусарга! Чын сугышчы бит бу! Кабергә кылычын тотып ятсын. Әйдә, киттек. Әнә быргы уйный—безне җыялар.

Арттан, муеныннан алып күкрәгенең яртысына кадәр кылыч белән чабылган, сынар кулы белән сугышып һәлак булган урыс гусары исәпләнгән бу сугышчы—гайрәтле татар егете Мәүлетдин иде. Ак патша өчен, «Бөек, Бүленмәс» Русия өчен һәм Урыс Тәресе өчен мөселман егете Мәүлетдин Бородино сугышында җанын бирде...

* * *

1812 елның 23 сентябрь иртәсендә Зәй-Каратай авылында бер сабый дөньяга килде. Бала малай иде. Җан-фәрманга акырып бөтен урамга сөрән салды яна дөньяга килгән гусар Мәүлетдин малае. Ана кешенең тирләп чыккан битен сөртә-сөртә, кендек әбисе Шәрифә карчык ананы сөендерде:

—Менә дигән, олпат кебек малай таптың. Тач әтисе Мәүлетдин инде менә. Хәзер юалар анда. Бирермен, кочакларсың, имезерсең. Аллага шөкер! Бик әйбәт итеп котылдың! Ходай ташламас, иншалла, ике-өч көндә аякка басарсың. Сугышлар беткән француз белән, әтисе Мәүлетдин кайтыр җинеп...

Ак биләүләргә биләнгән, беренче мәртәбә анасының сөтен туйганчы имгән, әтисез калган ятим сабый Төхфәтулла алсу иреннәрен кымтып-кымтып тәмле йокыга талган. Сабый йоклый. Ул әле, урыс басып алып үзенеке иткән җирдә үсәсен дә, үсеп җиткәч ач урысны туендырыр өчен ат урынына

эшләячәген дә, һәм урыс патшаларына яна җирләр яулап, кулына, әтисе Мәүлет кебек корал тотып сугышасын да белми иде. Шулай ук, хәрби тормышта хәерче Русиядә яшәп, көн-төн эшләсә дә, ярым хәерчелектә дөнья көтәсен дә белми иде.

Сигезенче сентябь иртәсендә, Наполеон, иртән гаскәрен торгызып, сугышка хәзерләнә башлаган гына иде, ана хәбәр итәләр: урыс армиясе лагерын ташлап юк булган. Учаклары гына яна!

Кутузов Филя авылында уздырган хәрби киңәшмәдә барысын да тыңлап бетерә дә, тарихи күрсәтмә бирә. Кыска гына:

—Мәскәүне французга калдырып чигенәбез!

1812 елның 13 сентябрь иртәсендә французлар Мәскәү янына килеп, анарга кермичә туктыйлар. Наполеон көне буе чатырында утырып чыга. Кечкенә тау башында басып торып, җинелгән урысларның Мәскәү капкасы ачкычларын ана, император Наполеонга китереп, баш иеп тапшырганны көтә. Тик ачкыч китерүче булмый...

Татар морзасы Котдус нәселеннән чыккан урыс фельдмаршалы Кутузовның армиясе Мәскәүне ташлап калдырып, Тарутино каласы янында лагерь булып урнаша. Кутузов французларның Мәскәү эчендә кышлауга калмасын белә. Чөнки 100 меңнән артык французны ашатырга Наполеонның азыгы юк. Кутузов, Тарутино каласы янында гаскәре белән урнашып, Наполеонның бай Украина аша чигенергә мөмкин булган юлын ябып куя. Наполеонга чигенергә Мәскәүгә килгәндәге таланган юлы гына кала.

14 сентябрьдә Мәскәү каласында ут чыгып, каланың дүрттән өч өлеше янып бетә.

18 октябрьдә француз маршалы Мюрат, Наполеонның чигенү маршрутын тәгаенләп, Украина ягына, көньякка корпусы белән хәрәкәт итә башлый. Шул көнне аның корпусын Кутузов гаскәре тар-мар итә. Наполеон килгән юлы белән чигенергә мәҗбүр була. Зур бәрелешләргә кермичә, аның чигенеп ясаган маршрутка көньяктанрак параллель рәвештә Кутузов гаскәре хәрәкәт итә. Көньякка борылып кереп китеп, икмәкле, җылырак җирләр аша чигенергә форсат бирми.

Зәмһәрир декабрь ае суыкларында Наполеон армиясе Неман елгасын кичеп чыга. Наполеон армиясеннән шул чакта нибары 20 мең кешесе калган була.

Вильно каласы янындагы сугышта французлар тулысынча тар-мар ителә. Һәм аларның тар-мар ителгәннән тере калган, аерым-аерым тәртибен югалткан төркемнәре, юлда туры килгән җирле халыкларны талап, тамак туйдырып, үзләренең Франциияләре ягына кайтып китәләр. Вильно сугышыннан соң Кутузов катгый нәтиҗә ясый: « Сугыш бетте!».

Карт төлке Кутузов, Наполеонның җиңелмәс бөек армиясенә каршы төп көч итеп кышкы суыкларны кулланып, аны юк итә. Бородино кырларында француз җинеп, урыс армиясен чигенергә һәм Мәскәүне ташлап качарга мәҗбүр итсә дә, җиңүдән файдалана алмый.

• • •

Мәскәү Кремленең хәрби җиңүләргә багышланган Георгий залында, диварга алтын хәрефләр белән язылган Беренче Ватан сугышы батырларының исемлеге булган. Шул исемлектә урыс исем-фамилияләре арасында бер татар да булган: гусар Тухфатуллин Мавлютдин Амаметович. Тик, большевиклар хакимияткә килгәч, ул дивардагы исемлекне тоташ юк итәләр. Икенче Бөтендөнья сугышы җиңү белән тәмамлангач, шул ук залда исемлек тагын торгызыла. Тик анда инде татар егете гусар Төхфәтуллин фамилиясе юк. Татар батырының урыс данына катнашын яшерү... Русия бөеклеге өчен тик урыс кешесе генә сугышкан һәм җиңгән. Причем монда гололобый татарин?!

*2005 ел*



# Фәйрүзә Исмәгыйлова

## Бизмән

Бер ягында — Фәрештәм бар,
Бер ягында — Шайтаным...
Таганнарда атынган күк
Утыралар чайкалып —
Бизмәнемдә...

Язып алам: — Пышылдарга
Йә, кайсыгызда чират?!
Син, Шайтаным, әрсез дә соң,
Син, Фәрештәм, бик тыйнак.

Холкыгыздан таныйм сезне.
Аерамын ерактан.
Син, Шайтаным, ышандырып,
Пышылдыйсың, колакка.

Син, Фәрештәм, бик сак кына
Орынасың йөрәккә.
Тотып алсаң шул мизгелне,
Туа изге теләкләр.

Рәхәтләнеп атынасыз —
Шуны гел тоя йөрәк.
Үземне раслар өченме
Бу бизмән — миңа кирәк?!

## Халәт

Бу җырым — илче ул;
Яныңа
Җанны илтә торган
Сукмак ул:
Күзләреҥ нурында коенып,
Бусагаңа җитеп
Туктар ул.

Тыелгысыз рәхәт тойгыдан
Күкләрем каршында тезләнер.
Хәрефләрмени бу? —
Йөрәкнең
Атлап килгән
Вак-вак
Эзләре.

*Фәйрүзә* ИСМӘГЫЙЛОВА *— шагыйрә; «Җанымда яз рәсеме» исемле китап авторы. Азнакай районында яши.*

Суырылып кереп китте җан —
Хисләр дулкынына ымсынды.
Алыштырмас идем бернигә
Шушы газап, шушы тылсымны.

Әсир төшкән чакта сөюдә,
Илчем аша кат-кат киленер.
Иң ләззәтле кичерештер бу,
Күңел —
Иң моңлы Моң Иледер.

* * *

Ышанычны югалту — тиз...
Сакла, Тәңрем! —
Бер көн җитә.
Ә кабат аклау өченгә.
Еллар... бәлки, гомер китә...

* * *

## Шайтанмы өметсез?

Булыр сиңа шайтан өметсез!
Өмет итә кешелектән — күптән:
Адәмнең гел түбән тәгәрәвен
Һәм чыгуын — тәмам кешелектән!

* * *

Килешәсеңме син дә:
Хушлашу җиңел түгел...
Ефәк тукыма кебек
Сыпылып китте күңел.

Көрәшүләр булган көк,
Саубуллашу— табигый.

Теләсәк тә үзгәртеп
Булмый тормыш агымын.

Тик, белсәң, сыкрый күңел —
Бу халәт сиңә таныш:
Көндәй өмет балкыса,
Төн булып ойый сагыш...

## Чүп үлән

Кайчак салкын караштан
Бер тереләм, бер үләм...
Ә син кыраудан соң да
Яшәрәсең, чүп үлән!

Тәпиең тисә җиргә,
Яфрагың, гүя, канат.
Тамырдан йолкыгач та
Яңарасың син кабат.

Һич сер түгел: рухымда
Кабыну бар, сүнүләр.



Әлфия
Ситдыйкова

# ҖИР ӨСТЕНӘ МИНЕМ ХИСЛӘР СИБЕЛӘ...

* * *

**Җаның ачты күзен минем алда,
Тетрәп куйдым утлы караштан.
Әйтерсең лә яшен камчылары
Оча миңа бөтен тарафтан.**

**Гомер буе сусап арган җаным
Керсә әгәр кайнар кочакка,
Күбәләктәй, канатлары көеп,
Төшәр төсле ялкын-учакка.**

* * *

**Сине сагынудан күкләр елый,
Елый күксел болыт.
Әллә синме тамдың чәчләремә
Көмеш тамчы булып?!**

**Күрәсеңме таң пәрдәсен ачып
Кояш карый күктән?!
Тургай булып, безнең күңелләрдә
Сөю сайрый күптән.**

**Аңламаган булып кыланмачы,
Яратасың, беләм.
Синең хисләр булып, юлларымда
Кышын үсә үлән...**

* * *

**Чүл кызы да түгел мин югыйсә,
Бетмәс сусау тулы күңелем...
Ничә тапкыр җиһан йөрәгенә
Утлы сагыш булып түгелдем.**

**Күзләр җитте диеп уйлыйсыңдыр,
Юлларыңа яфрак коелса.
Җир өстенә минем хисләр сибелә —
Алтын төсендәге муенса.**

Әлфия СИТДЫЙКОВА — *шагыйрә; шигырьләре көндәлек матбугатта даими күренеп килә. Чаллыда яши.*

Син Аллаһ та, Пәйгамбәр дә түгел,
Нигә күңел сиңа табына?!
Бер караштан басылыр бу сусау,
Төбәп кара, иркәм, җаныма!

* * *

Янулардан торган иде бөтен гомер,
Тик беркем дә яндырмады мине болай.
Мәңгелеккә китәрмендер дигән чакта
Өздерепләр сайрый яңа җырчы тургай.

Китеп булмас. Мәңге сусап арган җанга
Тансык наз ул яз җырчысы — тургай моңы.
Бу дөньяда, димәк, әле кирәгем бар,
Тагын Сөю борды — кире китәр юлны.

* * *

Тән нәрсә ул, җанны саклый белик
Тәмугларга салыр гөнаһтан:
Бер эләксәң ычкынуы авыр
Иблис үзе корган тозактан...

Хозыр Ильяс янәшәдә булсын,
Җанны саклыйк олы гөнаһтан:
Табынганың Сөю — Аллаһ икән,
Дога саклар — явыз Иблис корган
Мәкер тулы утлы тозактан.

* * *

Син кирәк миңа, давылда
Ышыклар өчен җилдән.
Сыгылмам, таллар шикелле,
Кочып калалсаң иңнән.

Син кирәк миңа туңганда,
Җылытыр өчен җаным.
Бергә көлеп каршыларга
Гомернең соңгы таңын

Син кирәк, күтәрер өчен,
Ишелеп килсә бәхет:
Ялгыз җанга кирәк түгел
Алтын бизәкле тәхет.

Син кирәк миңа һавадай,
Бер тамчы тере судай.
...Бу дөньяга минем өчен
Яраткан сине Ходай!

* * *

Сөюсез калсам мин —
Табалмам кыйбламны:
Җуярмын шул чакта
Җандагы иманны.

Сусаудан кипшенеп
Ярылыр иреннәр.
Күңелем түрендә
Коелыр сиреньнәр.

Сөюсез калсам мин —
Табалмам үз-үзем.
Дөнья да кочакка
Сыйдырмас үксезен.

Сөюсез калсам мин —
Йотар күк Мәңгелек.
... Яшим мин Сөюдә
Тәм белеп, гамь белеп.

*2006*

*Хикәяләр конкурсына*

Халисә
Ширмән

## МӘХӘББӘТНЕҢ СОҢГЫ КӨНЕ

...Күзге җил якында үсеп утырган барбарис куакларының яфракларын өзә, җимешләрен йолкый да тәүге ап-ак карга ыргыта. Сусыл җимешләр кар өстендә кызыл кан бөртекләренә охшап, Айратның күңелендә ниндидер шом уята, беренче кар эреп килгән ала-кола сукмакка кирәкмәгән киеренкелек, аңлашылмаучылык өстиләр сыман. Айрат көзге җилнең салкыныннан бөрешеп куя. Әнә, әле кайчан гына җәйге шаян кыяфәттәге җил малае ак сакаллы агай дәрәҗәсенә күтәрелгән дә, буй җитмәс каен ботакларына кагылмыйча, паркта үтеп-сүтеп йөргән яшь җилбәзәкләрнең куен кесәсен капшый. Югарырак үрмәләргә әллә теләми, әллә көче җитми. Утыргычта урын алган утыз биш-кырык тирәләрендәге Айрат исемле иратның пәлтәсе дә юка, фырт икәне күренеп тора, шуңа күрә аның куенына үрмәләү берни дә тормый җил агайга...

Айрат сәгатенә күз төшереп алды. Әйе, күренергә тиеш инде Лилия. Айрат көтә, бик көтә Лилияне. Бүген ул аңа күңелендә йөргән, бергә чакта әйтә алмаган сүзләрнең барысын да әйтер. Гафу сорар. Юкка гына ул «Гафу аллея»сына дәшмәде Лилияне. Барысы, барысы өчен дә кичерүен сорар. Ялынып, тезләнеп сорар. Лилия андый каты күңелле түгел, әлбәттә, Айратны кичерер. Ул хәтта шулай буласын алдан ук сиземләп, белеп килде. Алар Лилия белән инде унбиш ел бергә гомер кичерделәр, Лилия һәрвакыт аны гафу итә иде. Бу үпкәләве дә мәңгелек түгел, үтәр... Шулай да кар өстендәге барбарис җимешләре әллә артык уңган күплеге белән (барбарис уңган елны янгыннар, фаҗигаләр күп була, диләр), әллә җете кызыл төсләре белән Айратны ниндидер шомга салган иде.

...Ниһаять, шактый көттереп, аллеяның икенче башында таныш адымнар шәйләнде. Кара пәлтә ханымның зифа гәүдәсенә сыланып тора, һичшиксез, бик килешә һәм аның яшен дә шактый киметә иде. «Җүләр инде мин! — Айратның анында, үзе дә сизмәстән, чын үкенү сызылып үтте. Чыннан да, бу назлы адымнарның ир-ат нәфесеннән читтә кала алмый икәне билгеле. — Ничек элек игътибар итмәгәнмен?!»

Ханым килә-килешкә бер куактан барбарис тәлгәше өзеп алды.

— Айрат. Исәнме. — Ханым янәшәгә утырды. — Карале, быел барбарис бик уңган икән. Кып-кызыл, миләш төсле.

—Әйе шул, бик уңган. Сокланып карарлык.

Бераз дәшмичә утырдылар. Лилия кулындагы ботакка мөкиббән киткәндәй, үзалдына тын гына елмая иде. Нинди сөйкемле икән бит аның хатыны! Барбарис тәлгәшләре Лилиянең йөз алсулыгы белән ярышалар сыман. Кара кашлар, кара күзләр. Кашларына кадәр төшереп кигән кара беретка. Рафаэль бирелә булса, һичшиксез, мондый сылудан сурәт төшерми калмас иде...

—Йә инде, Айрат. Син монда мине юкка гына чакырмагансыңдыр бит?!

Айрат сискәнеп китте. Нәрсәдер җавап бирергә кирәк иде, нәрсәдер әйтергә, сүз башларга, сөйләргә, сөйләшергә... Башкача болай яшәп булмый. Башкача Лилиянең битарафлыгына ул түзә алмый.

—Лилия... Дөрес әйтәсең, юкка гына сине монда чакырмадым. Бу аллея «Гафу аллеясы» дип атала. Күрәсеңме дүрт яклы һәйкәлне?! Анда дүрт телдә «гафу» дип язылган. Әгәр мөмкин булса, мин синнән дөньядагы барлык телләрдә дә гафу сорар идем.

Лилия, күрәсең, бу турыда сизенгән иде, шуңа Айратның сүзләренә бер дә исе китмәде. Бераз тын торганнан соң, шаян гына көлеп куйды.

—Айрат! Син, репертуарыңны үзгәрткәнсең. Элек өйдә генә гафу сорый идең. Бу юлы паркка ук чакыргансың. Берәр нинди юбилей түгелдер бит?!

—Көлмә, зинһар, Лилия. Мин чын күңелдән синнән гафу үтенәм.

Лилиянең тавышы моңсуланып китте.

—Ә элек юри генә идеме?!

...Алар Лилия белән инде унбиш ел бергә. Унбиш ел ирле-хатынлы булып гомер кичерәләр. Яратып өйләнештеләр. Берничә ел яратышып гомер иттеләр... Аннан соң бер-бер артлы балалары туды. Йокысыз төннәр, аллергияле балалар, эш. Бәхетле гаилә тормышын, ике яшьнең арасын боза торган тагы нинди дә булса зуррак мәсьәләләр була, дисәләр, Айрат ышанмас иде. Ана балалары туганнан соңгы ике-өч ел чәчләрне агартырлык унбиш елга тиңләште. Арыды ул, гаиләдән гарык булды, вакытсыз өйләнгәнлегенә терсәген тешләрдәй дәрәҗәгә килде. Юк, ул бала чүпрәкләрен юуга катышмады, Лилия кебек, авыру баласын күтәреп, хастаханә юлында йөрмәде, кайтуына ашарга әзер, киемнәре юып үтүкләнгән, чиста иде. Ләкин Лилиянең талчыккан йөзен, бөгәрләнгән халатын, буялмаган тырнакларын күреп, булган гайрәте кире кайта башлады. Житмәсә, янда берсеннән-берсе чибәр кызлар кайный иде... Ул үзе дә ут кебек кайнар, үгездәй таза иде... Беренче мәртәбә хатынына хыянәттән соң күзләрен күтәреп карый алмады. Лилия, аптырап: «Авырыйсыңмы әллә?!» дип, шифалы үлән чәе ясады, караватка йомшаграк түшәк җәеп, сабый баладай сөеп яткырды... Ә ул ана кычкырды да әле хәтта. «Туйдырдыгыз! Күрәсем килми беркемне дә!» дип кычкырды. Күңелендә торган ташны алып атасы килә иде. Икенче юлы да шактый авыр булды. Ә аннан соң... Лилия үзе гаепле. Үз-үзен карамады, матур итеп киенмәде, тырнакларын, иреннәрен буямады. Ә үз-үзен карамаган хатынга кем карасын?! Нишләп әле ана Айрат карарга тиеш?! Әнә, телевизордан да шулай сөйлиләр, газета-журналлар да гел шуның турында акыл сата. Хатын-кыз гел үзен карап, матурланып торырга тиеш, югыйсә, ир-атның башкалар янында чуалуы гадәти күренеш икән. Әйе, алар ир белән хатын, ләкин бу төзәтерлек хата. Әгәр кирәк булса, Айрат бүген үк ирекле була ала. Бигрәк тә хәзер — Лилия эшләми, өйгә акча алып кайтмый. Ә ул, әзме-күпме, хезмәт хакы ала. Әгәр акчалы ир белән яшисе килә икән, иренең капризына түзсен. Шуңа күрә соңга калып кайтулар ешайды, көндәлек хәлгә әйләнделәр. Күрәсең, Лилиягә дә яхшы кешеләр житкерә торганнардыр, бер вакытны Лилия әсәрләнеп бәргәләнә башлады. Төн уртасы узганчы фатирның эчке бусагасы төбендә лифт тавышын тыңлап, «Кайтмыймы икән?!» дип, елап төн үткәрә иде дә, иртәнге якта шул ук бусага төбендә йокыга китә торган булды, бичара. Кайчакта Айрат чын күңелдән гафу үтенә иде. Лилия дә таш бәгырьле түгел, ул да аны кичерә иде. Нишлисең, чыннан да балалар кечкенә, еш авырыйлар, авыру бала янында ата кеше утырмый инде, әлбәттә. Лилия — хатын-кыз, ул — учак терелтүче, йорт-хуҗалыкка җан өрүче. Димәк, йортның тынычлыгы анардан тора. Ә ул соңга калып, арып-талып кайткан ирен сөеп каршы аласы урынга,

гауга куптара. Ачудан кыйшайган йөзен әллә Айратның бик күрәсе килә дип уйлыймы икән?!

—Син дә йөр, — дип кычкырды Айрат бервакыт. — Үзенә баерак ир-ат тап та, рәхәтләнегез шунда! Ичмаса, тынычланыр иден, мина да тынычлык бирер иден!

Учакка су сиптеләрмени, Лилия тынып калды. Әле генә ярсудан дингездәй кайнаган күзләрендә башта аптырау, анламау, аннан рәнжү чагылды.

—Син мина башка ир белән йөр дип әйтәсенме?!

Айрат дәшмәде. Күнелендәге ачу басылмаган иде әле.

—Син мина башка ир-ат белән йокла дип әйтәсенме?! Син мине яратмыйсынмыни?!

—Ә син бутама!!! Мин сине яратам, ләкин синен бу җәнҗалларынны башка ишетә алмыйм! Әгәр мин йөрим икән, нигә сина да әзрәк күнел ачмаска!

Айрат башына килгән бу уйдан бик канәгать иде. Әлбәттә, әгәр ул хатынына ирекле мәхәббәткә рөхсәт бирә икән, димәк, үзе дә рәхәтләнеп мажараларын дәвам итә ала. Ә хатынына кем карар—анысы билгесез, хатынынын әле ирләр каратырлык өс киемнәре дә юк, ирләр белән йөрерлек вакыты да юк. Шуна Айрат бик аптырамады. Тик Лилиянен басып торган жиреннән хәлсезләнеп китүен күреп, йөрәгендә бераз кызгану хисе уйнап алды.

—Йә инде, ул кадәр кайгырган булма. Барлык ир-ат та хатыннарына хыянәт итә, ләкин барысы да, минем кебек, башкалар белән күнел ач дип әйтеп тормый. Кадеремне белмисен.

Лилия тәрәзә янына барып сөялде. Күзләреннән ике бөртек яшь агып төште.

—Айрат, без ник өйләнештек икән?! Нигә балалар үстерәбез?! Күнелләрдән сөю киткәч, кешеләр нишләргә тиеш?! Читкә йөри башлыйлармы?!

Айрат юкка гына хатыннар янында күп чуалмый шул. Бу минутта Лилиягә нәрсә кирәген ул бик яхшы анлады.

—Син нәрсә инде, кадерлем. Мин сине бик яратам, ишетәсенме?! Мин бит бу сүзләрне көнгә йөз кабатлый алам, бөтен туганнарын, дусларын, әти-әниен алдында кабатлыйм! Телисенме, тәрәзәне ачам да, бөтен дөньяга: «Мин Лилияне яратам!» дип кычкырам! Ләкин син секс белән мәхәббәтне бутыйсын. Ирләр секс ярата, ә мәхәббәтләре барыбер бер генә була.

—Хатыннар да шулаймы?!

Айрат сүз агышынын әкрен генә үз жаена керә баруын сиземләде.

—Әлбәттә, шулай, кадерлем. Яшьлек бит һәркемгә дә бер генә килә. Әйдә, бер-беребезгә трагедия ясамыйк, иртәгәдән башка тормыш белән яши башлыйк. Сина да әйбәт, мина да кулай.

Лилия, тәрәзә карангылыгына кереп югалырга теләгәндәй, мангаен пыялага терәде, бераз тынып торгач, янадан Айратка борылды. Хатынынын талчыккан йөзендә бу кадәр сүнгән, бу кадәр өметсез, рәнҗүле карашны күргәне юк иде әле Айратнын. Бер минутка кыен булып китте, башында «каты бәрелдем инде әллә» дигәнрәк уй чагылып китте.

—Ярар, Айрат. Син дигәнчә булыр. Мин сина башка бер үпкә сүзе дә әйтмәм. Тик өйгә чир алып кайтма.

...Лилия сүзендә торды. Шул төннән башлап, Бариевларнын өендә тынычлык урнашты. Айрат элеккеге гадәтләрен ташламады, әлбәттә. Ләкин ире кунарга кайтмаганда да Лилия күзендә яшь күренмәде. Айрат та ялгышмады: Лилиянен читкә чыгып йөрергә вакыты да, мөмкинлеге дә, күрәсен, теләге дә юк иде.

Тормыш үз жае белән акты да акты. Менә балалар да исәйделәр, зурысы

мәктәпкә укырга керде, кечкенәсе дә абыйсы артыннан артык калышмады. Өйгә үзләре кайтып-китеп йөри башладылар. Айратнын дөньясы түгәрәк иде. Ул хәтта Лилиянен тавыш куптармавына беркадәр гаҗәпкә калып, үзенчә «экспериментлар» да оештырып карады.

«Эксперимент» дигәне Лилияне үзенен сөяркәсе белән күзгә-күз очраштыру иде. Очраштылар. Лилия эшкә урнашканнан сон, ул төшке ашка кerә торган кафега Айрат ике мәртәбә сөяркәсе белән килде. Лилия көндәшенә «исәнмесез» диюдән ары китә алмады, әлбәттә, ләкин бу да Айрат өчен көтелмәгән яналык иде. Кара, хатын-кызны да ничек бөгеп була икән! Ничек сындырып була икән! Югыйсә, хатын-кыз дуамал, дәҗҗал дигән булалар! Шуннан сон Айрат Лилияне хәтта ниндидер бер аерым хис белән хөрмәт итә башлады. Кайчакта чираттагы сөяркәсе белән ачуланышса да, салган баштан монзарларын Лилиягә сөйли иде, кинәш тә сораганы булды. Гаҗәп, Лилия бер сүз каршы әйтми тынларга өйрәнде, күзләрен күтәреп карарга теләмәсә дә, кайчакта кинәш тә биргәләде. Айрат шундый заманча гаиләсе булуга искиткеч шат иде, дус-ишләренә сөйләп, бөтенесе гаҗәпкә калган иде.

...Көннәрдән бер көнне Лилия өйгә сонга калып кайтты. Хәтта Айрат та бу вакытта инде өйдә иде, хатынына берәр хәл булмады микән, авырып китмәде микән дип, йөрәгенә шом йөгергән иде. Сау-сәламәт, күтәренке күнел белән кайткан Лилиягә сораулы карашын төбәде.

—Кинога бардык. Роза белән. Бөтен Казан үлеп-бетеп «Йолдыз сугышлары»н карый икән, без дә әйләнеп кайттык әле.—Лилиянен җинелчә шарфыннан алгы бүлмәгә затлы сигарет исе анкыды.—Арыдым.

Кинәт Айратнын күнел түрендә ниндидер ят хис кымшанып куйды. Нәрсә икәнен ул үзе дә анлый алмады, һич көтмәгәндә ниндидер ачу кузгалгандай булды, ана шикләнү өстәлде.

—Кем белән дисен?! Роза беләнме?! Ул тәмәке тарта башладымы әллә?!

Лилия өстен алышып тора иде, җинел, шома, кара төстәге затлы ефәктән эшләнгән эчке күлмәген ялангач тәненә киеп куйды да, Айратка борылды. Күзләрендә ниндидер көлемсерәү чагылып китте.

—Юк, Роза тәмәке тартмый, син бигрәк инде. Безне машинада озатып куйдылар, подъезд алдында сөйләшеп утырдык бераз. Ир-атлар тәмәке тартты шул. Шунда сенгәндер инде ул ис. Син нишләп ятмадын сон әле?!

Айратнын «Сине көттем» дип әйтәсе килмәде. Үзалдына «Кино карадым» диебрәк мыгырдады да, йокы бүлмәсенә кереп ятты. Бераздан, юынып, Лилия дә йомшак юрганга төренде, иренә аркасы белән борылды да яту белән йокыга чумды, ә менә Айратнын күзенә йокы эленмәде. Кин караватта әле унга борылды, әле сулга авышты, юка юрган астында әле тирләп-пеште, әле салкыннан калтырады. Бу ана таныш түгел хис, шул хис ана тынгылык бирми иде. Күпмедер вакыт хатынынын тигез сулышын тынлап ятканнан сон, анын ягынарак авышты, кулын юрган ачылып киткән урынга куйды. Нәзберек ефәк астында тыгыз күкрәкләр шәйләнделәр. Тәрәзәдән төшкән тулган ай яктысында кинәт үз кулы ниндидер бер йонлач чит кеше кулы булып күренде, чит ир хатынынын йомры күкрәкләрен әвәли сыман тоела башлады. Айрат, корт чаккандай, кулын тизрәк тартып алды. Йә, Хода, элек мондый җүләрлек уена да кереп чыкмый иде, бүген нәрсә булды сон ана?! Хатыны чит ирләр белән машинада утырдым, диде. Утырса сон, ул бит ана үзе рөхсәт итте. Машинада утырырга гына түгел, теләсә, кемнендер сөяркәсе булып йөрергә дә мөмкин, диде. Шулай булгач, ни кимерә сон әле анын күнелен?!. Нишләп әле ашказанына таш тутыргандай, күкрәгә кысыла да сулышы йотыла?!.

...Шуннан сон Лилиянен сонга калып кайтулары ешайды. Айрат исә, киресенчә, нәкъ сәгать алтыда өйдә булырга тырыша, балалары да мондый

үзгәрешкә беркадәр гаҗәпсенәләр иде. Беркөнне Лилия таң сызылганда гына кайтып керде. Әкрен генә тышкы йозакны ачты, ишекне этеп, эчкә үтте, ут кабызмый гына аш бүлмәсендә плитәгә чәйнекне кайнарга утыртты. Айрат әле йокламаган иде. Баштарак «чыкмыйм» дип кыбырсып ятса да түзә алмады, тавышсыз гына басып, хатыны янына чыкты. Лилия таң нурлары яктысында кулларындагы ялтыравык төймәләргә карап мөкиббән киткән. Айрат ут яндырды. Хатынының кулларындагы кыйммәтле асылташлар җемелдәп куйдылар, ут яктысыннан күзләрен кысып, Лилия Айратка елмайды.

—Айрат. Уяттыммы? Гафу ит.

Айрат Лилиянең кулындагы муенсага текәлгән иде.

—Нәрсә ул анда синен?!

— Муенса. Матурмы?! Килешәме?!

Килешкәнен Лилия үзе дә белә. Айрат, җавап бирмичә, теш арасыннан диярлек сытып чыгарды.

—Нәрсә, чын асылташлармы?! Бүләк иттеләрме әллә?!

Лилия, беркадәр сынап, Айратның чытылган йөзенә карады да көлемсерәде.

—Кем бүләк итсен инде миңа. Әлбәттә, чын түгел, ясалма. Сатып алдым. Барыбер, матур бит, әйеме?!

Айрат Лилиянең тавышындагы ялганны шунда ук тотып алды. Бүләк ителгән муенса инде, күренеп тора. Айрат үзе дә сөяркәләре янына бүләксез бармый иде. Хәзер генә ир бүләккә тоткан акчаларының гаилә кесәсеннән чыкканын аңлагандай булды. Ә Лилия, киресенчә, гаиләгә алып кайта икән...

Айратның күңелендә әйтеп бетергесез ачу кабарды. Хатыны ачыктан-ачык аңа хыянәт итә иде. Эчтәге ярсуы тавышына бәреп чыкты.

—Алдашмасаң да була! Ниндидер бер ухажерың биргән муенсаны күз алдымда селкемә, яме?!

Лилия каршында күзләреннән утлар чәчрәткән ир-атка бер дә курыкмыйча карады.

—Тынычлан, Айрат,—диде ул әкрен генә.—Балаларны уятырсың.

Айратның эчендә ачу гына түгел, көнчелек кайный иде. Кара син аны, аның сөекле хатыны кемнеңдер түшәге булсын инде! Гарьлеген кая куярсың! Лилиянең бер дә исе китмәде.

—Әйе, Айрат, бу — чын асылташлар. Тик син миңа кычкырма, яме! Әллә безнең килешү барлыгын оныттыңмы?! Кем миңа «баерак ир-ат тап та, шуның белән уйна» дигән иде?! Син түгелме икән?

Лилия бер минут тын торды. Айрат кул бармакларының йодрыкка җыелуын чамалады.

—Кайчандыр миңа да бик авыр иде. Мин бит түздем, телемне тешләп, яшемне сөртеп булса да, түздем. Син дә түз, Айрат. Бу әле уенның башы гына.

...Әйе, чыннан да, бу әле уенның башы гына булган икән. Соңга таба Лилия җиңелчә салган килеш тә кайта башлады, кайчакта бөтенләй кайтмый да калгалады. Эшеннән китте. Хәер, аңа хәзер эш кирәк тә түгел иде — хатынның алтын-көмеш муенсалардан, алкалардан, беләзек-йөзекләрдән торган тулы бер хәзинәсе барлыкка килде, Айрат гомердә дә бүләк итә алмый торган кеш туннан йөри башлады, бераздан машина йөртергә укый башлады. Хәзер Лилия иренең эш хакына мохтаҗ түгел иде.

Айрат беренче вакытта җәнҗал куптарды, көн саен диярлек Лилиягә кычкырды, хәтта бер тапкыр кул күтәрүгә кадәр барып җитте. Лилия сүзне кыска тотты, «тагы бер шулай эшләсәң, балаларны алам да, китәм», диде. Әйе, Лилия китәчәк, һичшиксез, китәчәк иде. Айрат, аптырап, хатынына ялынды, «кичер» диде... «Башка бер тапкыр да сиңа хыянәт итмәмен» диде... «Әйдә, яңадан яши башлыйк» диде... Лилия ул көнне йомшарган сыман

булган иде, ул да иренә башка хыянәт итмәскә вәгъдәләр бирде. Тик икенче көнне үк кунарга кайтмады. Айрат үзе дә нәкъ шулай эшли иде ләбаса... Лилия һич кенә дә Айраттан уздырмады да, кимен дә куймады. Ире Лилияне нинди газапларга салган булса, хатын да Айратны шул ук утларда янарга мәҗбүр итте.

Сыер дуласа, аттан яман, диләр. Су алган коена төкермә, үзен эчәрсең, диләр... Айрат моны бераздан соң гына аңлады. Эчендә янган утлар аны акылдан язар дәрәҗәгә житкерделәр. Лилияне ярата иде ул, үлеп ярата иде. Күзенә бернинди башка хатын-кыз күренмәс булды. Тик Лилия генә янадан аныкы, бары аныкы гына булсын иде. Тик Лилия генә аны яратып елмайсын иде...

...Кар сарган барбарис ботаклары, юеш карның авырлыгын күтәрә алмый, сыгылып килгәннәр. Хәер, ботаклардан инде тып-тып итеп, тамчылар тама.

— Көзге һава бигрәк тотнаксыз инде, әйеме. Кичә яңгыр яуды, бүген — кар.

Кайдадыр укыган шигырь юллары Айратның хәтеренә килде, күңелендә ургылган ташкынга буйсынып, Лилиянең сүзләренә җавап рәвешендә шигырьне яттан әйтә башлады:

Син башкамы бүген, минме бүтән,
Сүзләр—монсу, йөзләр—ямансу...
Күзләренә карыйм. Ирененндә
Яшеренгән төксе елмаю...
Йә, әйт инде, сузма, әйт дөресен,
Күзем күрде—йөрәк ишетсен!
Хәер, әйтмә. Мин аңладым сине.
Тоткарламыйм ...кеше кешесен!
Йөрәгең бит ауга чыккан икән.
Котлыйм, котлыйм... Димәк, киек бар.
...Әллә нишләп көннәр болай чуар.
Кичә яңгыр яуды...
Бүген—кар...

...Барбарис җимешләренең кызыл ялкыны Лилиянең күзләренә күчкән дә, яшь тамчыларын кайнатып тора. Кайнар тамчылар ханымның күз алмасын яндыралар да яндыралар... Агып төшсеннәр иде алар, битен, янакларын чылатып, боздай салкын кулларына тамсыннар иде... Лилиягә җиңелрәк булыр иде... Юк, хәзер инде күзләре шул ике яшь бөртеген дә сыгып чыгара алмый. Иреннәре генә пышылдый:

—Айрат... Син бу шигырьне хәтерлисеңмени?!

Юк, Айрат хәтерләми. Нинди шигырь икәнен дә, нишләп әле аның үзенең хәтерендә сакланганын да, нишләп бу шигырьнең Лилияне шулкадәр тетрәткәнен дә аңламый...

—Дәшмисең, Айрат... Мин бит аны сиңа атап язган идем. Хәтерлисеңме, син дус кызым белән чуала башлагач?! Без әле ул вакытта өйләнешмәгән идек.

Юк, Айрат барыбер хәтерләми. Нинди дус кызы булгандыр Лилиянең, нигә Айрат аның белән чуала башлагандыр—белми. Ә менә ни өчен шигырь шулкадәр озак еллар хәтерендә сакланды икән?!

—Әй, Айрат. Миннән дә бәхетле кеше юк иде бит кияүгә чыкканда. Ап-ак туй күлмәге, ак чәчәкләр, биргән вәгъдәләр... Хәтерлисеңме ЗАГСта вәгъдә биргәнне?! «Шатлыкта да, кайгыда да бергә булырбыз, беркайчан да бер-беребезгә хыянәт итмәбез, кайгы күрсәтмәбез...» Нәкъ армиядәгечә. Присяга

кабул иткән кебек. Ант эчкән кебек. Тик армиядә Ватанга хыянәт иткән өчен үлем җәзасы бирәләр, ә тыныч тормышта хыянәт иткән кешене ирекле мәхәббәт белән яши, диләр...

Айрат сискәнеп китте. Әйе, ул армиядә булды, присяга кабул итте. Ватанга хыянәт итсәм, үлем җәзасына әзермен, диде... Ә хатынына, яисә иренә хыянәт итү ул Ватанга хыянәт иткән кебек түгелмени?! Барыбер вәгъдәсен бозган кеше хыянәтче дип атала ләбаса. Хыянәтче дип. Ягъни, предатель... Нигә ул элек бу турыда уйламаган?!

—Гафу ит мине, Лилия. Соңгы тапкыр. Мин элек җүләр булганмын. Мин сиңа башка беркайчан да хыянәт итмәмен. Беркайчан да. Мин бит сине бик яратам. Балалар хакына, әйдә, янадан яши башлыйк, Лилия?!

Лилия дәшмәде. Бу сүзләрне ул инде яттан белә иде. Бу сүзләрне ул күп мәртәбәләр ишетте. Ышанды һәм алданды. Тагы ышанды, тагы алданды...

—Беләсеңме, Айрат, вакытында май салырга онытkансың икән, сүнгән лампаны гаепләмә. Мин синнән күп еллар буе наз көттем, мәхәббәт көттем. Син элек тә мине яратам ди идең. Мин дә сине яратам. Безгә нәрсә комачаулый соң?! Син мине яратасың, мин—сине. Бер түбә астында яшибез, балалар үстерәбез. Мин—синеке, син—минеке. Бездә ирекле мәхәббәт. Шулай түгелмени?!

Айрат ни әйтергә белмәде. Барысы да шулай иде, барысы да Лилия сөйләгәнчә, дөрес иде. Шул ук вакытта берсе дә дөрес түгел...

—Лилия, мин ялгышканмын. Ирекле мәхәббәт дигәнем—ул азгынлык кына бит. Мин моны аңламаганмын. Кичер мине. Әйдә, ирекле мәхәббәт турында онытыйк. Ата-бабалардан килгән гореф-гадәтләребезне кайтарыйк.

Лилия ачы көлемсерәде, тавышы күтәрелде.

—Менә ничек сайрый башлады безнең сандугачыбыз... Ә минем күз яшьләрем кая түгелгән?! Ә йокысыз төннәр?! Ә «син акча таба алмыйсың» дигән сүзләрең?! Син үзең дә миннән ким кайгырмыйсың бит, нигә алай тиз генә гафу сорыйсың да, нишләп болай тиз кичерергә әзер әле син?! Тагы ялганларгамы исәбең?! Нигә мине монда чакырдың?! Кеше күрсен дигәнсеңдер, бәлкем?! Публикага уйныйсыңмы?!

Айрат беренче мәртәбә халык зирәклегенә таң калды—хәтерендә балачактан ялганчы көтүче турындагы әкият яңарды. Көтүче бер ялганлый, ике ялганлый, өч ялганлый, дүртенче тапкыр үзен коткарырга бер кеше дә килми... Ул үзе шул көтүчегә охшап калды лабаса.

—Лилия, ни сөйлисең инде син. Мин бит чын күңелдән әйтәм...

—Ә менә мин синең сүзләреңә ышана алмыйм. Беләсеңме, мин ничек яшәдем синең белән?! Синең кулларны күрә идем дә, «менә бу куллар башкаларны коча, бу иреннәр башкаларны үбә, бу чәчләрне башкалар назлый» дип тилмерә идем. Шикләнә идем, һәрбер сүзеңнән шикләнә идем. Соңыннан хыянәтең турында аерым-ачык әйткәч, акылдан шашардай булдым. Балаларны алып китәрдәй булдым. Көнләшүдән тәрәзәдән сикерердәй булдым. Ә син минем тилелегемне күреп, рәхәтләнеп газапладың. Хәтерлисеңме, көндәшем белән очраштырдың?! Утларда янганда, хәтеремне югалтырдай булып көнләшкәндә син мине үзеңнең сөяркәң белән очраштырдың. Беләсеңме, мине кем коткарды?! Көндәшемнең ире. Минем иң беренче хыянәтем ул көндәшемнең ире белән булды. Авырмы?! Миңа да авыр иде. Ә нәрсә?! Бу бит ирекле мәхәббәт!..

...Айрат ни өчен монда Лилияне чакырганын онытты. Чынлап та, нигә соң әле?! Алар хатыны белән бергә яшиләр, бергә йоклыйлар, балалар үстерәләр, бар яклары җитешкән, нишләп болай яраларны актарып йөри соң әле Айрат?! Нәрсә кирәк аңа?!

...Җилнең әчкелтем-тозлы тәме бар икән. Битенә энә белән чәнчиләрмени,

Айрат, әрнешүгә түзә алмый, янакларын кул аркасы белән ышкый. Юеш. Күрәсең, агачтан тамчы тама...

—Син дә мине гафу ит, Айрат. Авыр сүзләремнең авырлыгы өчен кичер. Мин инде ул сүзләрнең авырлыгын тоймыйм. Минем күнелем каткан. Ә синең күнелең йомшак әле, шуна елыйсын. Мин менә елый да алмыйм. ...Бераздан синең дә күнелең катар. Шунда гына тынычлык табарсын. Ирекле мәхәббәт ул — каткан күнелләр мәхәббәте. Каткан күнелләр генә мәхәббәттән ирекле була ала.

...Барбарис куаклары артына ялтырап торган кап-кара машина шуышып килеп туктады, тавыш бирде.

...Барбарис куаклары артына яшеренгән кара машина Лилияне дә үз эченә йомды. Салоннан күнелле музыка тавышы ишетелә иде. Кара жирлектә ялтыраган кызыл жимешләр, ак кар кунган ботакларда коелмыйча калган соңгы соргылт яфраклар төсе белән аралашып, ниндидер чуарлык барлыкка китерә. Айратның әллә колагында, әллә күнелендә шигырь юллары янгырый:

Әллә нишләп көннәр болай чуар.
Кичә янгыр яуды...
Бүген—кар...

---

## КОНКУРС ДӘВАМ ИТӘ

### «Яңа дәвер кешесе»

Мең яшьлек башкаласы булган татар дөньясына журналыбызның мең санын бүләк итү һич очраклы хәл түгел, чөнки «Казан утлары» Илебез тарихына, халык язмышына турыдан-туры бәйле.

Үткәнебез меңнәр белән язылды. Яңа меңьеллыкка—яңа дәвергә аяк басуыбызга да әле кайчан гына. Кем ул Яңа дәвер кешесе? Кальбе, яшәеше, кылган гамәлләре нинди? Яңа дәвердә кешелекне нинди могҗизалар көтә? Гел хөрриятә, үзгәрешкә, муллыкка, үсешкә омтылганда инсаният, әхлак, гаилә, мәхәббәт исән калырмы? Мөхтәрәм язучыларыбызны әлеге проблемалар борчыймы?

Яңа хикәяләргә ачык конкурс дәвам итә. «Яңа дәвер кешесе» бәйгесенә килгән хикәяләрнең күләме бер табактан артмаска тиеш.

Жиңүчеләрне акчалата бүләкләр көтә:

**I урынга**—25 мең сум
**II урынга**—15 мең сум (ике бүләк)
**III урынга**—10 мең (өч бүләк)

Хикәяләр 2007 елның декабренә кадәр кабул ителәчәк.

**«Казан утлары» журналы редакциясе**



Лилия
Гыйбадуллина

## ХӘТЕРЛӘРНЕҢ ХӘТӘР ЧИГЕШЕНДӘ

***

**Күкнең күкрәгенә хәнҗәр кадап,**
**Җиргә кояш кояр көннәрем.**
**Иләс җилнең тыны туздырмасын**
**Үткәннәрнең үксез көлләрен...**

**Ташуларга ташланырга әзер**
**Челтер-челтәр болыт—Күкләрем...**
**Мин талчыккан тозлы тамчы булып,**
**Мең гасырлар моңын күтәрдем.**

**Сынмаска дип Сабырлыкмы сыкрый**
**Вакыт ярларына уралып?..**
**Өмет булып чынга аша Яшәү,**
**Язгы саташудан юралып...**

***

**Син мине очарга өйрәт тә,**
**Юл күрсәт болытлар эзеннән..**
**Офыклар күкрәве — әрнү ул,**
**Күңелем түреннән өзелгән.**

**Ә күкләр хозуры мәңгелек.**
**Бу дөнья яралган болыттан...**
**Томанлы чиксезлек ярында**
**Мин сине онытмам, онытмам...**

**Талпыныр үрләрем көтәдер,**
**Китәмен йөрәгем канатып...**
**Яшенле яңгырлар, үчегеп,**
**Чылатыр минем ак канатым.**

**Күзләре әрнетер җанымны,**
**Төшермә җирләргә кабаттан.**
**Тик тыңла офыклар авазын:**
**«Мин сине яратам, яратам...»**

---

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА—*яшь шагыйрә; «Мин Бәхетне күрәм!» исемле китап авторы. Казанда яши.*

***

Бәхетем тузаны томан күк
Һавага тарала таңнарда...
Мең таулар кичәргә кирәктер
Күңелем күкрәвен аңларга...

...Ак яулык очырдым кичләрен
Ак кыя башыннан упкынга.
Ажаган эзләре йөрәктә —
Тоташтан ут кына, ут кына...

Төннәргә күмелгән чиксезлек
Офыктан кул сузым арада...
Йолдызлар атылыр чагында
Ымсынып күкләргә карама!..

Тик синең күзләрдән эзләдем
Яшәүнең ялкынлы үзәген...
Бу тормыш—мәңгелек тораташ,
Мин генә нигәдер үзгәрдем...

Язларны узгач та юллар бар,
Һәм ерып чыккысыз кар анда...
...Күкләрдән мең йолдыз атыла
Тауларны ак томан сарганда...

***

Шартлап Вакыт өзелерлек Тынлык...
Онытылып килә отыласы...
Мең үрләрдән күкрәр кайтавазга
Бер йотым тын булып йотыласы...

Мең ярадан яралырлык итеп
Юраласы килә, югаласы...
Үзәкләргә үтәр үкенечтәй
Вакыт ярларына ураласы...

Чиксезлекнең чикләренә җитеп,
Чигеш булып килә уеласы...
Тын төннәрдә ачык тәрәзләргә
Йолдыз булып килә коеласы...

...Шартлап Вакыт өзелерлек Тынлык—
Йөрәкләрнең тигез тибешендә...
...Онытылыр өчен отылдыкмы
Хәтерләрнең хәтәр чигешендә!..

***

Томан түгел, төсләр төенләнгән...
Тояр-тоймас тәме алмаларның...
Давыл булып дулап, дөнья өнен
Тыңлаганчы ук гүя аңлаганмын...

Ефәк ятьмәләрдә ята йөрәк...
Күккә карыйм. Аягүрә дөнья.
...Хыяллар да җитмәс биеклектән
Кемдер тоя мине, кемдер тоя...

Яшеннәрдә—дуамал бер күкрәү.
Сискәнәсе килә сизгерлектән...
Ә Вакытлар ватык. Үлчәмнәр юк...
Курка кыргый җаным Синсезлектән...

Юк, нелеп алмыйм алмаларны...
Томан түгел, төсләр төене бу.
Иректәге сәгать укларының
Ятьмәләргә яткан коедер бу...



Эльвира
Һадиева

# ЗӘҢГӘР ТАҢ КАНАТЫ

* * *

Күк җилләр канаты очында
Зәңгәрсу таңнарны күтәбез.
Түбәндә ак хыял бәйләнми:
Офыклар куйнында, өстә без!

Омтылдык яралы йөрәктән
Төннәрнең сафланган чагына.
...Зәп-зәңгәр күзләрең ашамы
Гасырдан багасың җаныма?

Мәңгелек учына тезләнеп,
Сөюең туганын күзәтик...
Ике җан һәм тынлык кавышкан,
Нигәдер сулкылдый үзәк бик...

Ул курка: бу төше өчен дә
Ай нуры сарылыр моң сорап,
Ике җан һәм өмет серләшә—
Зәңгәр таң елады аптырап!..

* * *

Нигә мине җылытмыйсың?
Туңа учларым...
Моң җаныңа канат идем,
ә син... очмадың!

Карлар әллә түгеләме?
Күкләр тын алмый.

Күзләр күптән сүрелсә дә,
Йөрәк тына алмый.

Бәсләр сара керфекләргә—
Кемнең сулышы?
Юк, җылытма!
...Качып янә
Төнгә елыштым!

* * *

Пәрдәләрең әле дә йоклый икән.
Керфегеңнән үбеп уятам...
Бер таң җылы караш,
Тоясыңмы?
Бу — йөрәгем, сине яраткан!

Икеләнеп оялчан таң туганда,
Сыйпап уздым ап-ак битеңнән...
... Илаһи нур сирпер күзләреңә,
Җаннан өзеп, җылы китерәм!

Юләр...
Юләр күңел!
Тылсым көтә...
Әрнет аны, эрет, калтырат!

Канат очын манып тулган айга,
Учларыңда сөю калдырам...

Эльвира ҺАДИЕВА—*КДУ студенты. Казанда яши.*

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

Габдулла Тукай, Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Риза Фәхретдиннәр замандашы, татар әдәбиятының горурлыгы булган Галимҗан Ибраһимовның тууына 120 ел тулды. Үткән гасырның беренче чирегендәге, дөресрәге репрессияләр чорына кадәрге татар иҗтимагый тормышын бу исемсез күз алдына китерү кыен. Ул—зур язучы, олуг галим, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе.



Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 елның 12 мартында элекке Уфа губернасы Эстәрлетамак өязенең (хәзерге Башкортстанның Авыргазы районы) Солтанморат авылында мөгаллим мулла гаиләсендә туа. Башта авыл мәдрәсәсендә укый, бер үк вакытта өч класслы земство мәктәбендә беркадәр русча белем дә ала. 1898—1905 елларда, ягъни 11 яшьтән 17 гә кадәр, Оренбургның Вәли мулла мәдрәсәсендә укый. 1905 елгы революция тәэсирендә мәдрәсәләрдә иске тәртипләргә каршы хәрәкәт кузгалгач, Г. Ибраһимов та, башка шәкертләр белән бергә, уку программаларына яналык кертүне таләп иткән демонстрацияләрдә катнаша һәм шуның өчен мәдрәсәдән куыла да. 1906 елның көзендә ул Уфага килә һәм әле янарак кына ачылган «Галия» мәдрәсәсенә укырга керә һәм анда 3 ел укый. «Галия» мәдрәсәсе Г. Ибраһимовның тормышында тирән эз калдыра, аның рухи офыгы киңәюгә, әдәбият дөньясына тартылуына унай йогынты ясый. Нәкъ менә шушы чорда аның беренче әдәби әсәрләре—Оренбург мәдрәсәсендә үз башыннан кичкән вакыйгаларга нигезләнгән «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907) «Гыйшык корбаннары» (1908), «Татар хатыны ниләр күрми» (беренче варианты, 1909), исемле хикәяләре һәм «Борынгы ислам мәдәнияте» (1908—1909) дигән хезмәте языла.

«Галия» мәдрәсәсеннән киткәч, Г. Ибраһимов берникадәр вакыт казакъ далаларында, Уралда төрле эшләрдә эшләп йөри. Әстерханның нугай татарлары арасында мөгаллимлек итә һәм 1909 елның ахырларында Казанга килә.

Казанда яшәгән бу беренче чорында (1909—1912) Г. Ибраһимовның иҗат активлыгы аеруча көчәя. Ул үзенең революциягә кадәрге иҗатында күренекле урын тоткан романтик хикәяләрен («Яз башы», «Дингездә», «Йөз ел элек», «Сөю—сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла» һ. б.) һәм «Яшь йөрәкләр» (1912) исемле романын яза. Бу әсәрләрендә композиция һәм сюжет төзү осталыгы, образлар тудырудагы психологик тирәнлек, тел һәм сурәтләү чараларының байлыгы Г. Ибраһимовны шул заманда ук татар прозаикларының алгы сафында баручы художник итеп таныта.

Бу чорда Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть һәм публицистика өлкәсендәге эшчәнлеген дә киң җәелдереп җибәрә. Мәкаләләрендә ул татар әдәбиятының

барышына, аерым жанрларның үсешенә, гомумән татар матбугатына, сәнгатькә, милли театрга, әдәби телгә, тарихка бәйләнешле күп төрле актуаль мәсьәләләрне күтәреп чыга һәм аларны заманның алдынгы идея-эстетик карашлары нигезендә хәл итәргә омтыла.

Әдип 1912 елны Киевка китә, мөселман студентлары җәмгыятендә эшли, аларның Бөтенроссия съездын оештыруда катнаша. 1913 елның апрелендә сәяси эшчәнлек алып барган өчен кулга алына. Шул ук елны азат ителә һәм Казанга кайтып «Аң» журналында җаваплы сәркатип булып эшли башлый. 1914 елны кабат Киевка китә, аннан Уфага кайта һәм 1915—17 елларда кайчандыр үзе укыган «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Бу чорда әдипнең эстетик һәм иҗтимагый карашлары тагы да ачыклана төшә, әдәби иҗатында җитди үзгәрешләр, яңа сыйфатлар барлыкка килә: ул үз әсәрләрендә иҗтимагый проблемаларны кыюрак күтәрә башлый, хезмәт кешеләренең реалистик образларын сурәтләүгә таба кискен борылыш ясый. «Көтүчеләр» (1913), «Табигать балалары» (1914), «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) кебек хикәяләр һәм, аеруча беренче рус революциясендә татар халкы вәкилләренең катнашуын сурәтләгән «Безнең көннәр» исемле романы (беренче редакциясе, 1914) язучы иҗатындагы әнә шул уңай үзгәрешләрнең ачык мисаллары булып тора. Әдәби әсәрләр, тәнкыйди һәм публицистик мәкаләләреннән тыш, Г. Ибраһимов бу чорда гыйльми-педагогик хезмәтләр язуга да зур игътибар бирә. Аның «Татар сарыфы» (1911), «Татар нәхүе» (1911), «Татар имлясы» (1914), «Яңа әдәбият» (1914), «Әдәбият дәресләре» (1914), «Татар телен ничек укытырга» (1916) исемле китаплары, татар теле һәм әдәбияты буенча беренче җитди теоретик һәм методик хезмәтләр буларак, озак еллар буе мәктәпләрдә дәреслек-кулланма рәвешендә укыла.

1917 елгы Февраль революциясеннән соң актив рәвештә иҗтимагый-сәяси тормышта катнаша башлый. 1917 елны язучы Ф. Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш. Сүнчәләй белән бергә «Ирек» газетасын чыгара. Ул—татар-башкорт мөселман сул эсерләр партиясенең оештыручылары һәм җитәкчеләренең берсе. 1917—18 елларда Милләт Мәҗлесе һәм Учредительное собрание депутаты. 1918 елда М. Вахитов һәм Ш. Манатов белән берлектә РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комиссариаты карамагындагы Үзәк мөселман комиссариатын оештыруда катнаша, комиссар урынбасары була. 1919—20 елларда Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, бер үк вакытта РКП (б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе, «Кызыл Шәрекъ» журналы хезмәткәре. 1920 елдан ТАССР Мәгариф халык комиссариатында. «Безнең юл», «Мәгариф» журналларының оештыручысы һәм мөхәррире, 1925—27 елларда Гыйльми Үзәк җитәкчесе, бер үк вакытта Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе. Бөтенроссия ҮБК һәм ТАССР ҮБК Президиумы әгъзасы.

Татарстан республикасы төзелүнең беренче көннәреннән алып утызынчы елларга кадәр ул республикадагы иҗтимагый тормышның һәм әдәби хәрәкәтнең алгы сызыгында торып эшли, татар совет матбугатын нигезләүдә һәм оештыруда, мәгариф системасын яңа фәнни нигездә коруда, яңа милли кадрларны тәрбияләп үстерүдә һәм башка бик күп иҗтимагый һәм культура төзелеше мәсьәләләрен яңача хәл итүдә иң якыннан катнашкан шәхесләрнең берсе була.

Язучы-художник буларак, ул татар әдәбиятында беренчеләрдән, революция, гражданнар сугышы вакыйгаларын («Яңа кешеләр» драмасы, 1920, «Кызыл чәчәкләр» повесте, 1921), егерменче еллар башын авылда һәм шәһәрдә җәелгән кискен сыйнфый көрәш картиналарын («Тирән тамырлар» романы, 1926) калку итеп сурәтли. Г. Ибраһимовның иҗат колачы милли кысаларда гына чикләнеп калмый, ул революциягә кадәрге чор казакъ тормышының социаль һәм ыруглык каршылыкларын искиткеч тирән һәм тәэсирле итеп ачкан «Казакъ кызы» (1923) романын иҗат итә, әүвәлрәк язылган «Татар хатыны ниләр күрми» повесте белән «Безнең көннәр» романының яңа вариантларын эшли. «Адәмнәр» (1923) повестенда Идел буендагы коточкыч ачлыкның реаль вакыйгаларын тасвирлый.

Әдәби әсәрләреннән тыш Галимҗан Ибраһимов бай публицистик һәм әдәби-

тәнкыйди мирас калдырды. 1910 еллар мәкаләләрендә ул милли әдәбият үсешенең принципиаль мәсьәләрен күтәрә, аны милли рухның һәм холык-фигыльнең көзгесе дип саный. Әдәбиятның эчтәлеген һәм сәнгати формасын баетуда халык авыз иҗатының әһәмиятен күрсәтә, татар зыялыларын, халык массаларын рус, Шәрекъ һәм Европа классик әдәбиятлары байлыкларына тартуның кирәклеге турында яза.

Г. Ибраһимовның революциягә кадәрге романтик эстетикасы С. Рәмиев, Дәрдмәнд, Г. Тукай иҗатларын анализлауга багышланган «Татар шагыйрьләре» (Оренбург, 1913) исемле тәнкыйди мәкаләсендә ачык чагыла.

Әдипнең Октябрь революциясеннән соң язылган байтак хезмәтләренең үзәгендә үткән чорларның мәдәни мирасына мөнәсәбәт, яңа чор татар әдәбияты үсеше мәсьәләләре тора. Алар аның «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» (1924) «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (1927) исемле китапларында чагылыш таба.

Аерым хезмәтләрендә Г. Ибраһимов татар халкы тарихының этапларын, революцион хәрәкәтен һәм татар мәгърифәтчелеген өйрәнә. Алар арасында «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» (1925, рус телендә 1926) билгеле бер урын алып тора. Ул Ш. Мәрҗани, К. Насыйри турында, «Шәрекънең бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» (1919), «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1922), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» (1922), «Урал һәм уралчылар» (1927) һ. б. тарихи һәм тарихи-публицистик хезмәтләр яза.

1927 елдан башлап Г. Ибраһимов, көчәеп киткән үпкә авыруы аркасында, даими рәвештә Кырымда яши. Авыруының торган саен җитди төс ала баруына карамастан, ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр әдәби һәм фәнни иҗат эшен дәвам иттерә.

Г. Ибраһимов—гаҗәеп бай әдәби һәм фәнни мирас калдырган шәхесләрнең берсе. Утыз еллык иҗат гомерендә ул егермеләп хикәя, өч повесть, дүрт роман, бер пьеса, аерым китап булып чыккан унике фәнни хезмәт, биш йөзгә якын тәнкыйди һәм публицистик мәкалә, тел һәм әдәбият буенча уннан артык дәреслек бастырып чыгара.

Фән, культура өлкәсендәге күренекле хезмәтләре өчен Г. Ибраһимов 1928 елда Дәүләт Сәнгать фәннәре академиясенең хакыйкый әгъзасы итеп сайлана һәм шулай ук Көнчыгышны өйрәнү буенча Бөтенроссия гыйльми ассоциациясенең оештыручы әгъзасы була. 1932 елда аңа Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты карары белән Хезмәт Батыры дигән мактаулы исем бирелә.

1937 елда Г. Ибраһимовны «Уң троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы» эшендә катнашуда гаепләп кулга алалар. Авыру хәлендәге әдипне Казанга алып кайталар. Ул 1938 елны төрмә хастаханәсендә үлә. Вафатыннан соң аклана.

Г. Ибраһимов әсәрләре СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителде. Аның иҗаты казакъ, үзбәк, әзербайҗан, төрекмән, башкорт һ. б. әдәбиятлар үсешенә зур йогынты ясады.

ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты Г. Ибраһимов исемен йөртә (1967 елдан). 1987 елда туган авылы Солтанморатта язучының музее ачылды.

*(Бу биобиблиографик язмада «Совет Татарстаны язучылары» исемле белешмә китаптагы (төзүчеләре Р. Даутов, Н. Нуруллина) һәм «Татар энциклопедия»сендәге (том 2; М. Хәсәнов мәкаләсе) материаллары файдаланылды).*

---

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ТУРЫНДА КҮРЕНЕКЛЕ ӘДИПЛӘР

*Татар халкының бөек улы, атаклы язучы Г. Ибраһимовның шәхесе, иҗаты, гыйльми һәм иҗтимагый эшчәнлеге хакында татар-башкорт, рус һәм башка халыкларның күренекле вәкилләре тарафыннан бик күп фикерләр әйтелгән. Арада бик гыйбрәтле һәм кызыклылары да байтак. Алар төрле газета-журналларда, аерым җыентыкларда, фәнни хезмәтләрдә урын алган. Шулай ук хәйран материаллар Татарстан радиосы фондында да бар. Алар, нигездә, Г. Ибраһимовның Казанда һәм Мәскәүдә уздырылган юбилей кичәләренең язмалары, әдипкә багышланган махсус тапшырулар һәм аерым чыгышлар.*

*Бөек әдибебез турында төрле чыганакларда чәчелеп яткан фикерләрнең кайберләрен (фәкать кайберләрен генә!) туплап, укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдык. (Моңа безне радио фондындагы язмаларны тиешле саклау чаралары күрелмәгәнгә, аларның тиздән бөтенләй юкка чыгу ихтималы да этәрде). Бу фикерләрнең байтагы беренче тапкыр дөнья күрә.*

***Рөстәм Акъегет***

* * *

Мин өлкән буын татар әдипләре иҗаты белән танышмын, алар фәкать үзләренең сәяси биографияләренә бәйле рәвештә генә басылмыйлар. Мәсәлән, Ибраһимов. Мин әйтергә телим: татар классикларына үз хезмәтләренә карата тәнкыйтьчел мөнәсәбәт хас. Алар художестволы әсәр өстендәге хезмәтнең нәрсә икәнлеген яхшы төшенеп эш итәләр.

***

...язучыларны берсен икенчесенә каршы куеп тикшерергә ярамый. Бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов шикелле, зур-зур романнарның һәм бик күп хикәяләрнең авторы булган кешене, башка язучыларның иҗатларына каршы куеп бәяләү дөрес эш түгел. Шуның белән бергә, язучының бер әсәрен уку үзе генә аңа тулы бәя бирергә җитәрлек булмаска мөмкин. Күренеп тора, Галимҗан Ибраһимов—киң колачлы, тормышка үтеп керә торган сизгер һәм үткер күзле язучы.

**Александр ФАДЕЕВ**,
*рус язучысы*

* * *

Төрки язучы-реалистлар арасында Галимҗан Ибраһимов гаять күренекле урын тота. Аның йөзендә татар прозасы хәзерге заман совет әдәбиятына сизелерлек өлеш кертте. Г. Ибраһимовтан житди тормышны житди өйрәнергә мөмкин.

**Чыңгыз АЙТМАТОВ**,
*кыргыз язучысы*

* * *

Сулар ага, ә кыялар какшамас булып кала. Аларга вакытның көче дә житми. Үз эшләренең көче һәм рухы белән мәгърур кыялардай күтәрелгән кешеләр дә шулай. Аларның исемнәрен вакыт та, очраклылык та кешеләрнең ихтирамлы хәтереннән тартып ала алмый. Татар әдәбияты классигы, әдәбиятның зур һәм катлаулы юлында минем беренче остазым Галимҗан Ибраһимов әнә шундыйларның берсе иде.

Вакыйгаларның барышы унае белән дә, аларга бернинди бәйләнешсез дә, мин күп еллар буе Галимҗанны хәтеремдә тотып килдем. Аның куе кара чәчләрен, фикер иясенең киң һәм биек маңгаен, дөньяны сизгер күзәтүче акыллы күзләрен мин үзем күргән кеше бит. Күкрәк тавышы белән ышандырырлык итеп сөйли иде ул. Аның зур әһәмиятле сүзләре дә үзеннән-үзе хәтердә кала һәм эшкә өнди.

Ул миннән җиде яшькә генә олы иде. Ләкин мин әдәбиятка әле беренче адымнарымны гына атлаганда, ул инде әдәбият юлыннан ышанычлы адымнар белән бара һәм башкаларны үзенә ияртә иде.

Әйе, Галимҗан минем беренче укытучым булды. Өстәп әйтә алам: ихтимал, бердәнбер укытучым булгандыр.

Совет хакимияте урнаштырылган беренче елларда, Урта Азия халыклары әдәбиятлары белән чагыштырганда, татар әдәбияты аеруча алга киткән иде. Анда Галимҗан Ибраһимов күренекле урын алып торды. Аның әсәрләрендә барлык совет милли әдәбиятлары нигезләнгән принципиаль яңалык бар иде. Һәм бу яңалык минем өчен, башка язучылардагыга караганда, көчлерәк, аңлаешлырак һәм гүзәлрәк яңгырады, һәм мин Ибраһимовның бер генә әсәрен дә укымый калмадым. Аның һәр сәхифәсе минем өчен бер ачыштай була иде.

Икърар итә алам һәм моны шатланып әшлим: минем әсәрләрем, Галимҗанның зур йогынтысы белән иҗат ителделәр.

Мин аның «Казакъ кызы» романын сокланып укыдым һәм Казакъстанның сарык һәм ат көтүләре белән тулы киң далалары күз алдыма килде. Мин кабиләләр арасындагы ызгышларны, хакимият өчен көрәшне, тормыш өчен көрәшне күрдем. Болар барсы да инкыйлабка кадәрге Төркмәнстандагы чынбарлык белән җанлы образлар аркылы якыннан бәйләнгән иде.

Татар зыялыларының сәяси уянуына багышланган «Безнең көннәр» романы уйлану өчен бик күп азык бирде. Мин «тормыш хуҗалары» белән матди байлыкларны тудыручылар арасындагы бәрелешләрне яңадан үз күзем белән күрдем, реакционерлар белән демократлар арасындагы аяусыз бәхәсләрне яңадан ишеттем. Рухи көчсезләрнең ренегатлыгын күзәттем. Тормышта да нәкъ шундыйлар белән якыннан торып бәрелешергә туры килде.

Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов турында бик күп сөйләргә мөмкин. Мин аны тере итеп, бетмәс-төкәнмәс көч ташып торган кеше итеп, зирәк, даһи акыллы итеп, яктылык, гаделлек өчен какшамас көрәшче итеп күрәм.

**Берды КЕРБАБАЕВ**,
*төрекмән язучысы*

• • •

Зур язучының әсәрләрен үз халкының укучылары гына түгел, башка милләтләрнең укучылары да яратып, сөеп укыйлар, аны үз укучылары итеп саныйлар. Гәрчә Галимҗан Ибраһимов тумышы белән татар булса да, әсәрләрен татар телендә язса да, казакълар аны үз язучылары итеп исәплиләр. Әгәр без аның яшь чагында казакъ җәйләүләрендә яшәгәнлеген, балаларны укытканлыгын искә алсак, казакъларның аны үз язучылары итеп санаулары бигрәк тә аңлашылса кирәк. Ул елларда ана «Казакъ кызы» кебек нәфис романны иҗат итү өчен гаять күп материал биргән казакъ халкы тормышындагы вакыйгаларны бик зур мәхәббәт белән тасвирлавы өчен казакълар аны беркайчан да онытмаслар.

**Сабит МУКАНОВ**,
*казакъ язучысы*

• • •

Галимҗан Ибраһимов—татар әдибе генә түгел, ул безнең әдип тә. Аның иҗаты уртак. Казакъ халкы Галимҗан Ибраһимовны аеруча якын, үз итә. Бер фактны гына искәртеп үтик. Казакъ әдәбиятының классигы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Сәкен Сәйфуллин Галимҗан Ибраһимов турында «ул минем иң якын дустым» дигән. Бу чынлап та шулай булган. Әдипләр дуслыгы, ул—әдәбиятлар дуслыгы. Ә әдәбиятлар дуслыгы, ул—инде халыклар дуслыгына тоташа. Казакъ халкының Га-

лимҗан Ибраһимовка булган хөрмәте—ул бөтен татар халкына хөрмәт. Татар әдәбияты, татар мәдәнияте безнең казакъ халкына үрнәк, өлге иде. Татар халкының төрки халыклар тарихында тоткан урыны турында аксакал язучыларыбыз гел зурлап сөйләде. Күренекле акын Солтан Мәхмәт:

*«Анау алда татар торыр,*
*башкаларга өлге торыр»,—*

дип тикмәгә генә язмагандыр.

Без, казакъ язучылары, бүгенге татар әдәбиятының уңышларын күреп сөенәбез. Галимҗан Ибраһимовка лаеклы буын үсеп килә. Казакъ әдәбиятында да шундый хәл. Бу куанычлы күренештә Галимҗан Ибраһимовның шифалы йогынтысы бар. Рәхмәт аңа.

**Сагынгали СӘЕТОВ**,
*казакъ язучысы*

* * *

Зур татар прозаигы, романист Галимҗан Ибраһимовның әсәрләре 1925—30 елларда әзәрбайҗан теленә тәрҗемә ителә иде. Аның хикәяләре, повестьлары һәм романнары җөмһүриятебездәге киң катлау укучылар арасында зур уңыш казанды. Күпләр хәтта аны әзәрбайҗан язучысы дип санадылар.

Яшьлек елларымда, беренче хикәяләремне яза башлаган вакытта, мин соклану белән Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен кат-кат укый идем. Безнең буынның башка вәкилләре турында да шуны ук әйтергә мөмкин.

Бу зур язучының фаҗигале үлеме безнең йөрәкләрне тетрәтте. Ниһаять, ул арабызга кире кайтты, һәм без аның гүзәл әсәрләрен яңадан укый алабыз.

**Мәһди ХӨСӘЕНОВ**,
*әзәрбайҗан язучысы*

* * *

Сезнең Галимҗаныгыз—бер татар халкының гына булмыйча, барлык шәрык халыкларының да зур язучысы.

**Сәмәд ВУРГУН**,
*әзәрбайҗан язучысы*

* * *

Галимҗан Ибраһимов үзенең сокландыргыч әсәрләре белән Кырым татарлары укучылары арасында Октябрь инкыйлабына чаклы ук мәгълүм иде. Без, яшьләр, аның китапларын кулдан-кулга йөртеп, бик яратып укый идек. Шуның белән бергә, ул Кырым яшьләренең бер төркем алдынгы өлешенә мөгаллим буларак та билгеле иде. Чөнки Уфада «Галия» мәдрәсәсендә Кырым яшьләреннән кайберәүләр аңардан укыганнар, дәрес алганнар. Октябрь инкыйлабыннан соң Г. Ибраһимов безнең мәдәниятебезгә һәм иҗтимагый-сәяси тормышыбызга тагын да якынайды. 1918 елда Үзәк мөселман комиссариатында эшләгәндә, үзеннән-үзе билгеле, аңа Кырым ярыматавында яшь Совет хакимиятен ныгыту мәсьәләләре белән шөгыльләнергә туры килде. Шуның белән бергә, аның тарафыннан редакцияләнгән «Чулпан» газетасы бездә дә тарала һәм аны Кырым халкы да кызыксынып укый.

**Бекир УМЕРОВ**,
*Кырым татары язучысы*

* * *

Бер тел галименең миңа язган хатында шундый юллар бар: «Г. Тукай, Г. Ибраһимов чын мәгънәсендә тел чирәме күтәрделәр. Г. Ибраһимов прозада телнең җәүһәрләрен, энҗе-мәрҗәннәрен искиткеч урынлы куллана белде». Г. Ибраһимовның әнә шул кабатланмас маһирлегенә мин гомер буена сокланып яшәдем. Монда сүз аның әсәрләренең сүзлек хәзинәсе, фразеологик һәм сурәтләү

чараларының гаҗәп бай булуы хакында гына да бармый. Бердән, бу әдип элек әдәбияттан читтә калып килгән бик күп гади сөйләм сүзләрен кыю рәвештә әдәбиятка кертте, икенчедән, шуның өстенә, анда сүзнең эмоциягә тәэсир итү хасиятен, аның эстетик функциясен сиземләү сәләте ифрат дәрәҗәдә көчле иде. Шул сәләтенә таянып, Г. Ибраһимов әдәби әсәрләрендә сүзне мәгънә аңлату белән бер үк вакытта эстетик ләззәт бирерлек итеп тә кулланды. Ул әйтсә, бергәйле итеп, тәмам җиренә җиткереп әйтте. Аның җөмләләре философлар телендәгечә тирән мәгънәле, шул ук вакытта образлы, музыкаль яңгырашлы, халыкчан булалар («Без түбәннән күтәрелдек», «Фәхрине үтереп ташладылар» һ. б. бик күпләр). Минемчә, композитор күңеленә килеп төшкән җанга якын, дәртле хушавазлар белән рухланып, шуның белән канатланып яңа музыкаль әсәр тудыргандагы кебек, Г. Ибраһимов та үзенең иң һәйбәт әсәрләрен телебезнең байлыгына, матурлыгына, чын күңелдән бирелеп, күз алдында ачыла барган мөмкинлекләре белән рухланып, шуннан тәм табып, аерыла алмыйча язгандыр. Шул сәбәпле, без дә аның әдәби әсәрләренең эчтәлеген аңлау максаты белән генә түгел, бәлки теленең нәфислеге, тапкырлыгы белән дә мавыгып укыйбыз.

Галимҗан Ибраһимов кыйммәте беркайчан да югалмый торган бай, кадерле әдәби мирас, әдәби осталык үрнәкләре калдырды. Аның иҗат алымнары, ул баетып калдырган әдәби тел әле хәзер дә, яңа заманда да үрнәк булып хезмәт итә. Аның әсәрләре безнең заман кешесенә дә Туган илгә, туган туфракка тирән мәхәббәт тәрбияли, рухи ярлылыктан азат булырга, күңел хәзинәсен гуманистик кешелек сыйфатлары белән баетырга ярдәм итә.

**Гомәр БӘШИРОВ**

• • •

Телебезнең саф татарчага әйләнә баруы, сүз сәнгате буларак аның нәфисләшүе, образлашуы, бизәкләргә баюы Фатихлар, Галимҗаннар заманына туры килә. Бигрәк тә Галимҗан Ибраһимов иҗатында бу ачык чагыла. Сез аның 1911—14 еллар арасында язган хикәя, повестьлары белән мәкаләләрен генә чагыштырып карасагыз да тел җәһәтеннән болар арасында ярылып яткан аерма күрерсез... Әдәби телебезне сафландыру һәм камилләштерүдә Галимҗан Ибраһимовның тоткан роле гаять зур.

Сыйфат ягыннан үсүнең икенче мисалы итеп, мин прозада жанрларның төрләнүен һәм ачык билгеләнүен әйтер идем. Озак та үтми, романны озын хикәядән (повестьтан), озын хикәяне кыскасыннан аерып була башлый (билгеле, күләм җәһәтеннән генә түгел). Болар жанр буларак формалашу белән бергә, һәркайсының зур осталары да мәйданга чыга. Һәр өч жанрның, бигрәк тә повесть белән хикәяләрнең, гүзәл үрнәкләрен Фатих Әмирхан белән Шәриф Камал бирәләр. Мәгәр шулай да бу өлкәдә дә Галимҗан Ибраһимов иҗаты ныграк аерылып тора. Киң колачлы, социаль эчтәлекле романнарны, төгәл, камил язылган хикәя, повестьларны безнең әдәбиятта башлыча ул тудыра.

Фатихлар, Галимҗаннардан соң әдәбиятка килгән язучыларга алардан өйрәнмичә, үрнәк алмыйча иҗат итү мөмкин түгел иде инде. Алар «мәктәбен» узмаган берәр язучы булды микән?!. Тик моны сукыр ияру, кабатлау дип кенә аңламаска кирәк... Һәрбер чын язучы, нинди генә «мәктәп» узмасын, ахыр чиктә бары үзенчә, үзе аңлаганча иҗат итә.

Икенчедән, безнең яңа реалистик әдәбиятыбыз инкыйлабка кадәр тугандаш төрки халыклар өчен дә күпмедер дәрәҗәдә үрнәк иде. Безне укыдылар, бездән өйрәнергә тырыштылар... 1957 елны Алма-Атада Мохтар әкә Әуэзов белән очрашып сөйләшкән чакта ул миңа:

—Тукай белән Галимҗан Ибраһимов сезнең генә түгел, безнең дә осталарыбыз!—дип әйткән иде.

Әдәбиятыбызга әнә шундый дан-абруй китерде безнең классикларыбыз!

**Әмирхан ЕНИКИ**

## Шәриф Байчура

# БЕРГӘ УЗГАН ЕЛЛАР[1]

Бу—1911 елнын жәй башында булды. Мин ул вакытта бер хосусый типографиядә корректор булып эшлим һәм шул ук вакытта рус теленнән укытучы булырга әзерләнә идем.

Бу елны мин хәзерге Спартак (элекке Әрмәнский) урамының 16 нчы йортында Казан хәрби интендантствосы чиновнигы Спасский квартирасында бер гимназист һәм сәнгать мәктәбенең укучысы белән берлектә аерым бүлмә алып тора идем. Бер көнне кич минем эштән кайткан төшемә хуҗаның өй хезмәткәре:

—Сезгә ниндидер бер төргәк калдырып киттеләр,—дип каршылады.



*«Яшь йөрәкләр» романын бастырганнан соң. 1913 ел.*

Мин моңа гаҗәпләнеп, кайдан, нинди төргәк китергәннәр дип, бер кәгазь төргәген ачып карасам, ул кайсыдыр типографиядән җибәрелгән корректура булып чыкты. Яхшылап карагач, аның шул елларда әдәбият мәйданына чыккан һәм таныла барган язучы Галимҗан Ибраһимовның беренче әсәре—«Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» дигән хикәясенең корректурасы икәне беленде. Аның бу әсәре 1907—1908 елларда «Әл-Ислах» газетасында Фатих Әмирханның турыдан-туры булышлыгы белән газетаның күп саннарында басылып килгән иде. Хәзер исә аның аерым китап итеп басылуы икән. Сораша торгач, ул корректураның миңа килеп эләгүенең сәбәбе дә аңлашылды. Галимҗан Ибраһимов шул ук Әрмәнский урамында 5 нче йортта тора икән. Типографиядән җибәрелгән кыз аны таба алмыйча урамда саташып йөргәндә кемдер бирәү:

— Менә бу йортта типографиядә эшләүче бер татар егете тора,—дигәч, төргәкне миңа калдырып киткәнлеге беленде. Мәсьәлә ачыклангач, мин икенче көнне кич белән Г. Ибраһимовны эзләп таптым.

Ишек шакып керсәм, миңе уртача буйлы, озын кара чәчен артка таба шомартып тараган, кара мыеклы, коңгырт кара күзле, өстенә кара сатин күлмәк киеп, биленә киң каеш бәйләгән, чалбар балакларын күн итек кунычына кертеп кигән, мөлаем кыяфәтле егерме биш яшьләр тирәсендәге егет каршылады. Бу—Галимҗан Ибраһимов иде.

Аның бу елларда үзенең тышкы кыяфәтен Максим Горькийга охшатырга тырышканлыгы күпләргә мәгълүм. Минем башыма кылт итеп шул фикер килеп китте.

Г. Ибраһимовның ул вакытларда ук инде демократ табигатьле, кунакчыл кеше икәнлеген аны белгән күп кешеләр хәтерли булса кирәк. Ул тиз генә чәй әзерләп

[1] 1966 елны Татарстан китап нәшриятында «Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр» дигән җыентык дөнья күрде. Аның төзүчесе — язучы Афзал Шамов. Биредә Афзал ага тарафыннан шул җыентык өчен әзерләнеп, төрле сәбәпләр буенча керми калган истәлекләр файдаланылды. Аларны безгә әдипнең кызы Әлфия Шамова китерде. Г. Ибраһимовка багышланган бу сәхифәдә Әлфия ханым биргән фоторәсемнәр дә файдаланыла. *Редакция.*

алды һәм без—беренче очрашкан кешеләр—шактый вакыт төрле темаларга сөйләшеп утырдык. Күбрәк ул сөйләде, мин сораулар гына биргәләп утырдым. Бу вакытларда инде анын башлыча «Йолдыз» газетасында байтак кына мәкаләләре чыгып өлгергән, татар әдәбиятынын барышы турында еллык отчетлары басыла башлаган, татар сарыфы (морфология), татар нәхүе (синтаксис) һәм дәреслекләре чыккан, шуна күрә анын фикер ягыннан шактый үскән, мәгълүматы да байтак кин икәнлеге һәр сүзеннән аңлашыла иде. Минем Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан иҗатлары турында биргән сорауларыма да ул кыскачарак кына, ләкин унай җавап бирде, чөнки бу чакта әле бу язучыларга карата унай позициядә тора иде.

Менә шушы күрешүдән соң мина Г. Ибраһимов белән тагын да очрашкаларга туры килде. Кайчакларда урамда очрашып сөйләшеп йөрүләр дә булгалады. Бу елны ул һәрвакытта башына котелок (каты кара эшләпә), өстенә соры калын чикмән киеп йөрде. Моннан сонгы елларда инде материаль ягы яхшыра бару белән кием дә үзгәрә барды: жәен, кубесенчә, эшләпә, өстенә накидка (жинсез пальто), кышын—гади пальто һәм бүрек кия, аякта һәрвакытта кун итек була, йөргәндә ул вак-вак атлап тиз йөри, гәүдәсен төз тота иде.



*Уңда—Шәһит Әхмәдиев (1924–1927) елларда ТАССР Мәгариф министры). 1928 ел, Ялта.*

Революциягә кадәр анын белән тагын бер озаклап сөйләшеп утыруым исемдә калган. 1913 елда, анын «Ан» журналында секретарь чагында булды. Бу чакта ул хәзерге Куйбышев мәйданы ягыннан килеп, Щапов урамына кергәннән сон тау уртасына кадәр менгәч, ун кул якта урамнан ук агач баскыч белән менеп керелә торган өч катлы 4 нче номерлы йортнын икенче катында, дүрт тәрәзәле якты бүлмәдә тора иде. Бу юлы без ана язучы М. Гали белән барып чыктык. Татар әдәбиятынын үсеше, яшь көчләрнен туып күтәрелеп килүе, «Ан» журналынын бу өлкәдә зур эшчәнлек күрсәтүе турында шактый озакка сузылган сөйләшү алып барылды. Без китәргә җыенгач кына Г. Ибраһимовнын якын дусларыннан берсе булган Шәһит Әхмәдиев килеп калды.

Әлеге күрешүдән сон Г. Ибраһимов озак та тормыйча, Казаннан китте. Колчак тылында йөреп кайтканнан сон, ул янадан Казанга килә.

Бу вакытта мин «Кызыл Армия» газетасында секретарь булып эшлим. Без тагын очрашабыз. Ул редакциягә еш кына килгәли. Бу чорда ул әдәби әсәрләр тудырудан бигрәк публицистика белән шөгыльләнә, революциянен барышына, совет шартларында милли культуранын үсешенә карата «Кызыл Армия», «Эшче», һәм «Эш» газеталарында әһәмиятле мәкаләләр бастырып килә. Шунын белән бергә, әдәби әсәрләр язуны да бөтенләй читтә калдырмый. Беркадәр вакыт үткәч, Г. Ибраһимов белән бер очрашуыбызда ул гостиница тормышыннан туйганлыгын (бу вакытта ул «Бристоль»да тора иде), кая булса да квартирага чыгарга теләвен белдерде һәм миннән шул хакта сорашкалап каравымны үтенде. Мин ул чакта хәзерге Зәйни Солтанов урамы, 12 нче йортта профессор Газиз Гобәйдуллин әтисе квартирасында тора идем, шул ук өйдә торак мәйданнарына ордер бирүче район оешмасы да урнашкан иде. Шуннан сорап карарга булдым. Бер-ике көннән Г. Ибраһимов исеменә ордер алдым, һәм ул элекке Шиһап Мәрҗани йортындагы (Каюм Насыйри урамы, 10) бер квартирага күчте. Хәзер без тагын якын күршеләр булдык. Атна-ун көн үткәч, мин авылдан хат алдым. Хәзерге Буа районы, Аксу авылында укытучы сенелем авырый икән, кайтып килергә кирәк. Галимҗан авылга

кайтасымны белгәч:

—Көннәр салкын тора, юл ерак, өстең юка, әнә минем доханы киеп кайт,— диде. Аның Уфадан алып килгән бу дохасы эче-тышы мехтан, киң, иркен һәм гаять җылы иде. Аны кигәч, салкынның нәрсә икәнен дә белмичә, авылдан бик әйбәт йөреп кайттым.

Г. Ибраһимов әдип тә, тәнкыйтьче дә, тарихчы да, педагог та, тел галиме дә иде. Шулай ук орфография мәсьәләсе белән дә җитди шөгыльләнде. Шундый бер вакыйга хәтеремдә калган: 1920 елның көзендә (сентябрьдә булса кирәк), Татарстан республикасы Совнаркомы рәисе Сәетгалиев җитәкчелегендә хәзерге Щапов урамы 41 йортта (Машкин йорты) татар теле орфографиясе буенча киңәшмә үткәрелде. Бу чорда татар әдәби телендә сузык авазларны алты яки ун итеп санап, бу ике агым вәкилләре арасында көрәш бара иде. Республика күләмендә шул агымнарның кайсын рәсмиләштереп, эшкә ашыру мәсьәләсен хәл итү өчен барган бу киңәшмәдә алты сузык ягындагылар белән ун сузык ягындагыларның докладлары тыңланды. Алты сузыкны яклап, доклад белән Г. Ибраһимов чыкты һәм киңәшмәдән соң алты сузыклы орфографияне кабул итү турында Татарстан хөкүмәтенең декреты чыгарылды.

Бу киңәшмәдә тагын бер эпизод исемдә калган: мәсьәләне коммунистлар һәм партиясезләр катнашы белән гомуми утырышта озак тикшергәннән соң, мәсьәлә аерым рәвештә комфракциягә куелачак булды. Г. Ибраһимов төп докладчыларның берсе буларак комфракциядә калырга теләвен белдергәч, ТатЦИКның беренче рәисе карт коммунист Борһан Мансуров иптәш:

—Юк инде, Галимҗан ага, комфракциягә коммунистлар гына катнаша ала, менә Коммунистлар партиясенә кергәч, фракциягә катнаша алырсыз, диде.

Шуннан ике ай чамасы үткәч, шул ук 1920 елның декабрендә, Г. Ибраһимов иптәш Коммунистлар партиясенә керде. Татарстан Өлкә Комитеты һәм партия Үзәк Комитеты аның революция башыннан бирле болшевикларга теләктәш булып һәм Компартия линиясен үткәреп килүен искә алып, аның партия стажын 1917 елдан исәпләргә карар бирделәр.

1925—1927 елларда Г. Ибраһимов Татарстан мәгариф комиссариаты янындагы гыйльми үзәк рәисе булып эшләве белән бергә В. И. Ленин әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү эшенә дә җитәкчелек итте. Бу вакытта (1923-24 еллар) ул хәзерге Ленин урамы, 21 нче йортта тора иде. Шул чорда Ленин әсәрләрен тәрҗемә итү комиссиясенең бер утырышында булган эпизод исемдә калган. Сүз мәкаль һәм әйтемнәрне тәрҗемә итү турында барды. Утырышны алып баручы Галимҗан Ибраһимов:

—Мин үзем, егетләр, мәкальләрне тәрҗемә итү ягында тормыйм. Мәкальләр ул, күбесенчә, һәр телнең үзенчәлегенә бәйләнешле була. Шуңа күрә тәрҗемә уңышлы чыкмый. Сирәк очракта гына әйбәт килеп чыгуы мөмкин. Ә менә бу «львиная доля» сүзләрен—«арслан өлеше» дип тәрҗемә итүгә килгәндә (сүз шул турыда бара иде), минемчә, болай ярамый. Чөнки татарчада бу мәгънәне бирә торган мәкаль юк,—диде.

Менә шул рәвешле Г. Ибраһимов тәрҗемә өлкәсендә һәрбер үзенчәлекле мәсьәләгә зур игътибар бирә иде.

1926 ел башында, мин нәшрият һәм матбугат комбинатының редколлегиясе секретаре эшенә күчкәч, Г. Ибраһимов белән тагын да ешрак аралаша башладык, чөнки бу редколлегиянең рәисе Сафа Борһан булса да, мәгариф комиссариаты вәкиле буларак, әлеге коллегиядә член саналган Г. Ибраһимов бу өлкәдәге зур тәҗрибәсе һәм авторитеты белән нәшрият планнарын төзүдә һәм башка төп мәсьәләләрне хәл итүдә үзәк рольне уйнап килде. Бу вакытларда аның мина телефон шалтыратмаган көне аз булгандыр. Шулай ук ара-тирә аның өенә дә барып чыккаларга туры килгәләде. Мәгълүм булганча, бу елларда (1925—1927) ул хәзерге Комлев урамы, 33 нче йортта гаиләсе белән яшәде һәм исәнлеге начарлана башлагач, шул квартирасыннан Кырымга күчеп китте. Аны озак вакытка Казаннан аерган ерак сәфәргә озатучылар арасында бу юлларны язучы да бар иде.

*Галимҗан Ибраһимовның соңгы көннәре турында истәлекләр*

# «МИН ПАРТИЯГА ЫШАНАМ»

1937 ел. Көз. Плātән төрмәсе больницасы.

Без ята торган тар, озынча камераның гадәттәге көннәреннән берсе. Аның бер башыннан икенче башына хәтле, мөмкин кадәр тыгызлап, ике яктан тимер караватлар тезелгән. Үтеп йөрер өчен ике арада тар гына юл калдырылган. Әгәр караватларындагы кеше аягы сыярлык кына урыннарны искә алмасаң, камерада шуннан башка буш урын юк.

Һәр караватта бер авыру. Хәер, бөтен караватларда да түгел. Ике-өч карават буш. Аларның салам тутырган, каралып, керләнеп беткән сыек матраслары, мендәрләре яна килүчеләрне көтәләр... Килүчеләр булыр, караватлар буш тормас. Чөнки төрмәдә авырулар күп. Өзлексез кереп-чыгып торалар. Терелеп тә житмиләр, чыгып китәләр. Дөресе, алып чыгып китәләр. Алар урынына яналар килә. Яна хәбәр, яна вакыйга, яна кайгы алып киләләр.

Килүчеләр дә, «терелеп» чыгып китүчеләр дә шәхес культы нәтиҗәсендә кулга алынган кешеләр: партия, совет, профсоюз хезмәткәрләре, әле күптән түгел генә, әле моннан берничә айлар элек кенә җаваплы урыннарда эшләгән иптәшләр. Барысы да диярлек партия членнары. Партиябездә ленинчыл нормаларның бозылуы аркасында кемнәр тарафыннандыр партиядән чыгарылып, халык дошманы дигән гаять авыр исем тагылуга карамастан, һәркайсы үзен бөек партиянең члены итеп саный, горур тота, бөгелми, төрле ялаларга, гайбәтләргә бирелми, вөжданына, намусына хыянәт итми.

Арабызда хәрби кешеләр дә бар. Шуларның берсе мин.

Барыбыз да каты авырулар. Шуна карамастан, камерабызга врачлар сирәк керә. Алар кергәндә калын тимер ишек ачыла, алар чыккач яңадан бикләнә.

Һава тынчу, авыр. Төрмә больницаларында гына була торган авыр ис аңкый.

Менә шундый көннәрнең берсендә, кичкә каршы, энгер-менгер вакытта калын тимер ишек шалтырап ачылды һәм аннан өстенә күе-күк плащ, башына шундый ук төсле фетр эшләпә кигән, кулына таяк тоткан, ябык, саргайган йөзле бер кеше, хәлсез генә атлап килеп керде дә, башын бераз ия төшеп бөтен авырулар белән исәнләште:

—Исәнмесез, иптәшләр!—диде.

Сәламен алдык.

Аны алып керүче ике кешенең берсе сул стена кырыендагы буш караватка күрсәтте:

—Менә шунда ятарсыз.

Алып керүчеләр башка бер сүз дә әйтмичә чыгып киттеләр. Ишек яңадан шалтырап ябылды, яңадан бикләнде. Керүче кеше бер кадәр вакыт баскан хәлдә калды, урыныннан кузгалмыйча, зур карасу күзләре белән камераны, андагы кешеләрне сөзеп карап чыкты, аннары билгеләнгән караватка таба китте һәм өстен салмыйча, кулындагы таягын да куймыйча, ана авыр гына утырды. Аның арыганлыгы, хәлсезлеге күренеп тора иде.

Авыруларның кайберләре аның һәр хәрәкәтен, утырышын һәм утырганнан соң, күзләрен бер ноктага текәп, тынып калуын читтән күзәтеп торалар иде. Бу хәрәкәт—төрмәгә эләгүнең беренче минутларындагы күнел кичереше—таныш иде безгә. Шуңа күрә булса кирәк, иптәшләр ана бераз тын утырырга, уйланырга, булып үткән гадәттән тыш вакыйганы бөтен күләме белән төшенергә, аңларга мөмкинлек бирделәр. Ләкин бу кеше монда кергәнчә үк инде үз-үзен кулга алган, көтелмәгән

дәһшәтне аңлаган, төшенгән шикелле иде. Анда ниндидер салкын канлылык, рухи ныклык бар иде.

Бераздан, бер-ике минуттан соң, иптәшләрнең берсе аңардан сорады:

—Иптәш, сезне каян китерделәр! Кем буласыз?

Яңа кеше аңа борылып карады:

—Ялтадан,—диде. Ләкин фамилиясен әйтергә ашыкмады.

Миннән берничә караватат аша, озын буйлы, ябык гәүдәле, бик аз сүзле, ярым сукыр бер кеше ята иде. Күзләрен ул күп вакыт ут яктысыннан сөлге белән каплап утыра иде. Бик аз сүзле. Әмма жор, шаян сүз әйтә белүче, үзенең хәленнән зарланмаучы, ыңгырашмаучы бу кешенең кем икәнен мин белми идем. Баштарак авыруым көчле иде. Аннары, ул кешеләр белән аралашмый иде. Хәер, аның да сәламәтлеге начар иде. Менә шул кеше, яңа керүченең тавышын ишетеп, урыныннан кинәт торды да:

—Кара әле, иптәш Галимжан түгелме син?—дип сорады һәм аның җавабын ишетеп, кулындагы сөлгесен ташлады да аңа таба китте. Алар кочаклашып күрештеләр һәм шактый вакыт шул хәлдә калдылар.

Бу ике кешенең икесен дә мин күңелләрне тетрәткеч шушы минутта гына таныдым. Әле генә безнең камерага кергәне, торышы, күз карашы миңа ничектер таныш шикелле тоелганы Галимҗан Ибраһимов, ә икенчесе—язучы Садрый Җәлал иде.

Яңа керүченең кем икәнен белүчеләр кинәт тынып калдылар, күзләрен аңардан алмадылар. Өзлексез ыңгырашып ятучы бер каты авыру бар иде. Хәтта ул да бу минутларда ыңгырашуыннан туктады.

Бу кич, Г. Ибраһимов белән С. Җәлал, янәшә утырып, ярым кочаклашкан хәлдә пышылдашып кына озак сөйләштеләр. Бераздан Галимҗан ага, өстен салып, караватка сузылып ятты. Ул яткач та, С. Җәлал аның яныннан китмәде.

Галимҗан ага белән минем дә бик сөйләшәсем килә иде. Мин аны сокландыргыч әсәрләре белән үземнең укытучым, хәлфәм, миңа тормышта тугры юл күрсәтүче дип саный идем. Аңа күңелемдәге борчулы уйларымны гына түгел, ә бөтен биографиямны, тормышымны, узган эшләремне инәсеннән җебенә кадәр, берсен дә калдырмыйча, иң яшерен серләремне дә яшермичә сөйләп бирәсем һәм аңардан күп нәрсәләр турында сорашасым, күңелемне әрнеткән мәсьәләләргә ачык җавап аласым килде.

Иртәгесен иртә белән врачлар обходына кадәр аның янына барып утырдым, күрештем һәм үземнең кем икәнемне кыска гына сөйләп бирдем:

—Мин 1920 елдан ВЛКСМ, 1926 елдан партия члены, кулга алынганда I нче укчы татар полкының политругы идем,—дип тәгәлләдем дә хәрбиләрчә әйттем:—Галимҗан ага, менә бу минем сезгә кыскача рапортым,—дидем.

Сөйләвемне бик житди төс белән тыңлап утырган әдип, соңгы сүзләремне ишеткәч елмайды да һәм һич тә көтелмәгәндә аркамнан сыйпады.

—Димәк, Зариф туган, син монда да үзенне укчы полкының политругы итеп саныйсың?—диде.

—Шулай саныйм, Галимҗан ага!

Җавабым ошады булса кирәк. Күзләре җылынып, яктырып китте, тормышымны, кайда укуымны, моңарчы хезмәт иткән урыннарымны, гаиләви хәлемне җентекләбрәк сораштырды.

Ахырда мине (юк, мине генә түгел ә меңнәрчә, меңнәрчә кешеләрне) борчыган, төн йокыларыбызны калдырган, йөрәгебезне гаҗәп дәрәҗәдә әрнеткән соравымны бирдем:

—Галимҗан ага, әйтегез әле, зинһар, бүгенге бу хәлләрне ничек аңларга?—дидем.

Әдип карасу күзләре белән мине башымнан алып аягыма хәтле сөзеп карап чыкты да бераз уйланып торды. Тик шуннан соң гына ашыкмыйча, тавышын мөмкин кадәр әкренәйтеп, үзен тыныч тотарга тырышып, сөйләргә кереште:

—Зариф туган, сиңа мәгълүм, безнең коммунистлар партиясе—бөек Ленин тарафыннан оештырылган, аның тарафыннан тәрбияләнеп үстерелгән партия. Ул һәрвакыт, мәңгегә Ленин партиясе, аның тарафыннан урнаштырылган нормалар

белән яшәүче партия булып калачак. Бүгенге хәлне, бу урынсыз репрессияләрне мин вакытлы бер тайпылу дип саныйм. Озакламас, партия үзенең сүзен әйтер, ленинчыл нормалар сакланыр, моны бозуда гаепле кешеләр каты җавапка тартылырлар дип уйлыйм. Исән калган иптәшләр моны күрерләр. Мин партиябезнең ленинчыл сыйфатларын югалтуына ышанмыйм. Ышана алмыйм... Шулай да хәзерге коточкыч хәл кин колач алды. Күрәсең, мине дә читтә калдырмадылар, Ялтадан барып алдылар,—диде һәм бу сүзне әйткәндә ачы елмайды,—шуңа карамастан... шуңа карамастан мин партиябезгә ышанам! Ул үз сүзен әйтер! Аның ленинчыл сыйфаты югалмас!..

Шул арада тимер ишек шалтырап ачыла башлады. Мин тиз генә үз урыныма киттем. Шулай итеп, безнең сүзебез өзелде.

Шул көннән башлап, Галимҗан аганың: «мин партиягә ышанам!»—дигән сүзләре бер минутка да башымнан чыкмады һәм ул миңа тел белән әйтеп, аңлатып бирергә мөмкин булмаган зур, рухи көч бирде.

**Зариф ИДРИСОВ.**

*Язып алучы һәм әдәби эшкәртүче—*
***Афзал Шамов**, 1965 ел.*

# ЯЗУЛЫ ТАКТА

...Мин төрмәдә, ябылуда идем.

Каты салкын тидереп, үпкәм шешкәч мине дәвалар өчен Плэтән төрмәсе больницасына күчерделәр. Температурам бик югары булганлыктан, берничә көн бик каты яттым, тирә-ягымдагы бер нәрсәне дә күрмәдем, бер нәрсә дә аңламадым. Тик бераз хәл ала башлагач кына камерадагы авырулар белән таныштым. Алар арасында мине күргән, белгән кешеләр дә бар икән. Алар мине больница хәлләре белән таныштырдылар. Күрше камераларда таныш-белешләрдән яисә исемнәре республика күләмендә билгеле булган кешеләрдән кемнәрнең ятуын сөйләделәр.

—Галимҗан Ибраһимов та монда,—диде иптәшләремнең берсе.

Колакларыма ышанасым килмәде, кайтарып сорадым:

—Кем дисең?

—Язучы Галимҗан Ибраһимов.

—Булмас!—дидем мин, аның сүзләренә ышанырга теләмичә,—ялгыша торгансыңдыр. Бәлки икенче кешедер. Бәлки исем-фамилиясе генә туры килә торгандыр. Беткәнмени дөньяда бер үк исемле, бер үк фамилияле кешеләр!

Иптәшем ялгышмый булса кирәк, аның төсен-битен, кыяфәтен бик дөрес тәфсыйллады.

—Кайсы камерада ул?—дидем мин.

—Беренчедә. Бездән берничә камера аркылы гына. Бәдрәфкә барганда мин аны һәркөнне күреп узам.

Аның бу сүзе миңа бик сәер тоелды:

—Ничек күрәсең? Камера ишеге бикледер бит?—дидем мин аның сүзенә ышанмаска теләп, һәм бу ышанмауда «ялгыша торгандыр бәлки»—дигән ниндидер бер өмет бар иде.

—Бикле түгел шул менә,—диде иптәшем,—һәрвакыт ачык. Хәер, бикләүнең кирәге дә юк. Чөнки ул каты авыру. Караватында гына ята.

—Камерада үзе генәме әллә?

—Үзе генә.

Шушы сөйләшүдән соң Галимҗан аганы күрәсем, хәлен белешәсем бик килде. Аның белән очрашу турында күңелемнән төрле планнар кордым һәм ул планнар берничә көн башымнан чыкмады.

Әдип белән таныш идем мин. 1936 елда берничә укытучы белән бергә аның

янында булган идем. Ул безне бик җылы каршы алып, озак сөйләшеп утырган һәм күңелләребездә бик яхшы тәэсир калдырган иде. Безгә, барыннан да бигрәк, аның шундый зур язучы, күренекле галим булуына карамастан, үзен бик гади тотуы, кунакчыллыгы ошаган иде.

Бу—узган ел иде... Ә быел, 1937 елда, монда—төрмә больницасында...

Ниһаять, миңа аның белән очрашырга мөмкин булды. Миңа иптәшләрем ярдәм иттеләр.

Торып, йөри башлагач, мине дә, камерадагы иптәшләрем белән бергә һәр көнне бәдрәфкә алып бара башладылар. Юлыбыз беренче камера яныннан уза иде. Чыннан да, ишеге ачык икән. Узганда Галимҗан аганың караваты һәм үзе күренеп кала. Теләсәң, сакчым күрмәгәндә-фәләндә, батырчылык итеп, аның янына кереп калырга һәм узган-барганнар күрмәсен өчен ишекне бераз яба төшәргә мөмкин. Көннәрнең берендә мин шулай иттем дә.

Ул караватында чалкан ята иде. Бик ябыккан, саргайган. Янына бардым, исәнләштем. Төбәп карап торды. Танымады. Моннан бер ел элек Ялтада, аның янында булганымны әйттем. Алай да хәтерләмәде. Шулай да минем кем икәнемне, кайларда эшләгәнемне сорашты.

Мин аңа Садри Җәлалның да монда, дүртенче палатада ятканын әйттем. Аның монда икәнен белә икән. Аңа сәлам әйтергә кушты. Янына керүемнән максатым, бердән хәлен белешү, аңа бер-ике җылы сүз әйтү, ихтирамымны белдерү булса, икенчедән, күңелемдәге кайбер сорауларга анардан җавап аласым да килә иде. Минемәч, ул, карт коммунист, зур галим, күп нәрсәләрне алдан күреп белүче, фикер яисә күңелемне борчыган, төннәр буе йокларга ирек бирмәгән сорауларыма ачык җавап бирер шикелле иде. Ләкин беренче керүемдә аның белән бу турыда сөйләшеп булмады. Вакыт сыйдырмады. Камерага кире кайтучы иптәшләргә кушылып китәргә кирәк булды. Хәер, икенче кергән чакларда да мин сорауларыма җавап ала алмадым. Ул миңа бары киңәш кенә бирде:

—Кайда гына булсаң да, Ленин партиясенең члены булганыңны хәтереңнән чыгарма!—диде.

Шулай итеп, мин аның янында берничә мәртәбә булдым, берничә мәртәбә кыска-кыска гына сөйләшкәләп, караваты янында тын гына басып тордым, урын-җирен рәтләдем, кирәк икән, су алып биргәләдем. Күңелем белән моңа да канәгать идем мин.

Янына керә алмаган көннәрдә аның хәле турында коридорда дежур итүче санитаркадан сорашкалый идем. Авыруларга көченнән, мөмкинлегеннән килгәнчә ярдәм итүче, йомшак сүзле, ягымлы мөнәсәбәтле, 25-26 яшьләрдәге татар кызы иде ул. Кызганычка каршы, хәзер аның исемен дә, фамилиясен дә хәтерләмим.

Бер көнне, гыйнварьнең икенче яртысында, иптәшләрем белән коридор буйлап узганда, мин тагын аның камерасына яшеренеп кереп калдым. Ләкин бу юлы Г. Ибраһимов урынында юк иде. Идәнне яңа гына юып чыгарганнар, караватны урыныннан кузгатканнар. Тумбочка ящигын чыгарып, ни өчендер аны тумбочка өстенә каплап куйганнар. Аңа кемдер зур-зур гарәп хәрефләре белән нәрсәдер язган. Язучы кешенең куллары калтыраган булса кирәк, диагональ юллар шактый тигезсез. Мин, кызыксынып, язуга күзләремне төшердем. «Утыз еллар әдәбият юлында эшләгән эшләремнең соңгы көннәре болай бетәр дип уйламаган идем. Нишлисең! Тарих үзе тикшерер, дөрес бәһа бирер»—Галимҗан Ибраһимов»,—дип язылган иде анда.

Нәкъ шул сүзләр идеме, әллә бераз башкачарак идеме анысын хәзер ачык хәтерли алмыйм. Әмма шунысын беләм: язуның эчтәлеге шул мәгънәдә иде.

Камерадан бик борчылып, шомлы уйлар белән чыктым: «Галимҗан ага нигә урынында юк?»

Шул ук көнне җаен китереп, әлеге санитаркадан, сакланып кына сорадым:

—Беренче палатадагы авыру кайда?

—Ул бүген иртә белән үлгән,—диде кыз,—без кергәндә идәндә ята иде.

—Үлгән??..

Биш хәрефтән генә торган бу сүзнең татар әдәбияты, татар мәдәнияты өчен,

гомумән, бөтен совет мәдәнияты өчен нинди зур югалту, нинди зур трагедия икәнен ул минутларда аңларлык, аңлап бетерерлек хәлем юк иде. Аны башыма сыйдыра алмый идем.

Көн һәм төн авыр узды. Камерадагы иптәшләрем—бөек әдипнең иҗатын белүчеләр дә, белмәүчеләр дә—моны халык кайгысы, мәдәниятыбызның зур югалтуы дип кабул иттеләр. Ул көнне бу хәбәр, стенага шакылдату юлы белән бөтен төрмәгә таралды.

Иртәгесен санитарканы янадан күрдем:

—Ул кешенең кем икәнен белә идегезме?—дидем.

—Белә идем,—диде кыз.—Әсәрләрен дә укыган идем.

Аның күзләре дә мина кайгылы тоелды.

—Алайса, сеңелем, син ул фанера тактаны сакларга тырыш. Төрмәдән алып чык. Аның кайчан да булса бер кирәге булыр.

Кыз җавап бирмәде. Ул аны төрмәдән алып чыктымы, юкмы? Тарих өчен саклангканмы, ул авыр көннәрдә моның әһәмиятен белгәнме? Бу турыда бернәрсә дә әйтә алмыйм. Кем белә, бәлки бу китап басылып чыккач, кайчандыр төрмә больницасында хезмәт иткән, үзенең йомшак мөгамәләсе, кулыннан килгәнчә эшләгән ярдәмнәре белән безнең авыр хәлебезне аз гына булса да җиңеләйтергә булышкан әлеге санитарка минем бу юлларымны укыр да, Татарстан Язучылар союзы идарәсенә килер һәм вакыйганың ничек тәмамланганын сөйләп бирер. Әгәр ул моны эшләсә, гаҗәп яхшы булыр иде.

**Хайбик СИБГАТУЛЛИН.**

*Язып алучы һәм әдәби эшкәртүче—*

***Афзал Шамов**. 1962 ел.*

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясенә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



**—Былтыргы ел «Әдәбият һәм сәнгать елы» байрагы астында узды. Президентыбыз М. Шәймиев Указы белән 2007 ел исә Хәйрия елы дип игълан ителде. Шушы җәһәттән сез җитәкләгән оешманиләр эшләде һәм ниләр эшләргә җыена?**

**Ислам ӘХМӘТҖАНОВ, *«ИДЕЛ-ПРЕСС» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры:***

—XX гасырның азагыннан бирле хәйриячелек, химаячелек, иганәчелек белән шөгыльләнәбез дисәк, бу бер дә арттыру булмастыр. Эшебез, язмышыбыз безне шушы игелекләр белән бәйләп тора. Еллар нинди генә авыр булмасын, без әлеге юнәлештә кулдан килгәнчә кешеләр файдасына, җәмгыять һәм милләт файдасына эшләп торабыз, шөкер.

Минем уйлавымча, дөньяда китаптан да кадерле һәм олы бүләк була алмый. Матбугаттан ишетеп-укып белдек ич: олуг юбилее уңаеннан Президентыбыз Минтимер Шәймиевкә Россия Президенты Владимир Путин китап бүләк иткән. Әле нинди китап диген: татар телендә язылган 1775 елгы борынгы китап! Мин бу хәлгә шатландым, ихластан куандым.

Өстәп шунысын да әйтәсе килә: берничә еллар элек ул чактагы премьер-министр Михаил Касьянов үзенең кул астындагы министрларына Яңа ел бүләге рәвешендә бер кочак китап бүләк итүен дә укыган бар. Әйе, китаптан да олы бүләк булуы мөмкин түгел.

Әле күптән түгел хезмәтләрен игътибарга алып, хөрмәтләп үзебезнең байтак кына хезмәттәшләргә, якыннарга, туганнарга бүләк төсендә китаплар таратып бирдек. Авыл һәм район китапханәләре фондын тулыландыру хакында да онытмыйбыз. Милләттәшләребез күпләп яши торган төбәкләргә, татар китабына кытлык булган өлкәләргә дә хәлдән килгәнчә бүләк ясыйбыз. Узган елгы Мәскәү сабан туенда Мәскәү татар җәмгыятенә 1000 данә китап тапшырдык. Шулай ук бушлай, бүләк сыйфатында.

Узган ел шулай ук республикабызның Екатеринбургтагы Вәкиллегенә газиз ана телебездә чыккан 700 китап-журналлар юлладык. Укысыннар, шатлансыннар диеп. Туган телебездә телләре ачылсын дип, Арча районының Апаз мәктәбенә, шулай ук Буа районының Норлат авыл китапханәсенә шагыйрьләр Равил Фәйзуллин, Әхмәт Рәшитов катнашында үземнең шәхси китапханәмнән 1000нән артык китап бүләк иттек. Чын китап бәйрәменә әйләнде бу, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә халык китапка мәдхия укыды. Ни әйтсәң дә авылда әле китап сүзенең кадерен беләләр, шуңа инанып кайттык.

Хәзерендә исә Буа үзәк китапханәсенә күпсанлы яңа китаплар туплаган көнебез. Казакъстандагы татар Вәкиллегенә вәгъдәбез бар иде, истән чыгарган юк, монысын да онытмабыз. Казанның балалар бакчасына, мәктәпләргә, колониядәге тоткыннарга, хәрби хезмәттәге якташларга тапшырылган дистәләгән китапларны саный китсәм, саллы гына бер исемлек килеп чыгар иде. Әле болар белән генә чикләнергә уйламыйбыз.

Инде килеп, сезнең «Казан утлары» журналы белән берлектә, безнең

комлекснын матди ярдәме белән Гөлзадә Бәйрәмованын «Әле кайчан гына...» дигән шигырьләр җыентыгын нәшер иттек. Мин моны яшьләр һәм башлап язучыларнын иҗатын халыкка җиткерүдәге игелекле бер башлангыч дип саныйм.

Бу җәһәттән шундый бер вакыйга да искә төшә. Моннан бер-ике ел элек бүлмәбезгә олпат гәүдәле, гөрелдәп чыккан тавышлы бер агай килеп керде дә:

—Зинһар, ярдәм итә күрегез!—дип сүз башлады. Гозере шул икән: үнсигез яшьлек кызы шигырьләр яза, байтак кына конкурсларда җинеп тә чыккан, күпме генә ишекләрне шакып карасалар да китабын бастыруда ярдәм итүче юк икән.

Шулай итеп, безнен шәфкатебез ярдәмендә, Александра Кашина дигән кызнын «Кочевница сердца...» (рус телендә) дигән беренче шигъри җыентыгы дөньяга аваз салды.

Мондый игелекле эшләрне 1999 елларда ук башлавыбызны әйтер идем. Ул чакларда әле хәйрия-иганәчелек дигән хәрәкәт бөтенләй диярлек күренми иде. Мохтаҗларга ярдәм дигәндә иркенләп сөйләшеп булмый иде. 2000 елда, Уфада яшәгән күренекле шагыйрь Әнгам Атнабаевнын саллы китабын 15 мен тираж белән дөньяга чыгардык, бу беренче карлыгач иде. Аны тарату, тәкъдир итүдә дә көчебезне кызганмадык.

Хәзер үтенеч белән килүчеләр күп, үҗәтләр дә байтак. Хәйрия булгач, олырак гамәлләр, зуррак эшләр башкарасы иде, әлбәттә. Безнен тарафтан гына түгел, бу юнәлештә башкалар да кул кушырып утырмасын иде, дип әйтәсе килә. Уйлап карасак, республикабызда күп нәрсәләр эшләнә. Байларыбыз, хәлле кешеләр халык, җәмгыять тормышына йөз белән борыла башлады. Куанып сөйләр мисаллар байтак. Шул ук вакытта заманында Шамов салып калдырган шифаханә яисә Апанаев, Юнысов, Рәмиев һәм Хөсәеневләрнен данлы мәдрәсәләр тотуы искә төшә. Дәрдемәнднен татар типографиясе ачып, Оренбургта китап бастыруы, ин абруйлы саналган «Шура» журналын һәм «Вакыт» газетасын нәшер итүе дә тарихта мәгълүм ич. Менә шундый саллы гамәл кылучылар бүген дә күбрәк табылса иде ул. Әйтик, «Бәхетле» компаниясенен аз керемле кешеләр өчен башкалабызда өч социаль ашханә ачканнарына ничек инде сокланмыйсын!

Туфан Миннуллиннын бер әйткәне һич исемнән чыкмый: «Бай гына бер кешегә, әйдәле, сәләтле татар балалары өчен махсус бер мәктәп, татар лицее ачыйк әле, дигән идем, тәкъдимем һавада эленеп калды»,—ди. Гыйбрәтле мисал!

Бервакыт мина Уссури юлбарысларын саклау фонды төзибез дип тә килделәр. Андый юлбарысларга ярдәм итәргә кирәкме сон безгә? Бигрәк тә *Татарстаннын* үзенен киек һәм кош-кортларына экологик афәт янап торганда. Туган телебезнен язмышы, киләчәге зур сорау астында торганда... Минемчә, безгә хәзер менә шуларны яклый белү кыйммәтрәк.

Быелтыр безнен комбинатка 35 яшь тулды!

Без базар шартларында югалып калмадык, дәрәҗәбезне төшермәдек. Киресенчә, колачыбыз кинәя бара, инде бөтенроссия базарына ныклап үтеп кердек. «ИДЕЛ-ПРЕСС» нәшриятынын машинасы көн саен менләгән китаплар, газета һәм журналлар бастырып чыгара. Узган ел 322 миллион сумлык товар җитештердек.

Шушында тукталыйк. Экономика-икътисат, кемдер әйтмешли, инде бүтән тема, бүтән тарих.

Тәлгат
Галиуллин

# ДӘВАМЧАНЛЫК

«Без гаять киеренке, кискен еллар кичердек һәм кичерүдә дәвам итәбез. Җәмгыять җил-давылда актарылган диңгез кебек шаулап, гүләп, дулап алды. Татар халкының һәрвакыт йөрәк төпкелендә йөрткән олы хыялы куәтле аваз булып мәйданнарга бәреп чыкты, парламент залларын тетрәтте, дәүләт карарларына күчте, дөнья халыкларының теленә керде. Без үзебезнең яшәү ихтыяры тыелгысыз милләт икәнлегебезне раслыйбыз, дәгъваларыбызның гадел, юлларыбызның өметле булуына иманыбызны ныгыта барабыз». Ашкынулы дәрте, киләчәккә якты карашы, халыкның омтылыш көченә ышанычы белән бу юллар азатлык өчен көрәш елларында мөнбәр тоткан, ачлык мәйданында утырган милләтпәрвәр көрәшчеләр авазын хәтерләтә.



Әмма юк шул! Чорыбызга мондый төгәл һәм кырыс бәя карап торуга ифрат тыныч, хәтта тышкы дөнья матавыкларына битараф күренгән, үз фәненнән башканы (ягъни Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ыннан бүтәнне) белергә дә теләмәгән, филология фәннәре докторы профессор Нурмөхәммәт Хисамов каләменнән чыккан «Җан авазы» мәкаләсендә бирелгән икән. Ни кызганыч, каләмдәшләребезнең рухи дөньясы, йөрәк тибеше, тормыш юлы, үткәне, холкы, киләчәге турында аларның юбилейлары якынлашкан көннәрдә генә искә төшерә, уйлана башлыйбыз шул.

Пөхтә киенеп, атлаган адымының, мәҗбүри рәвештә «әййе» дип башлап җибәрелгән һәр җөмләсенең кадерен, тәмен белеп, «ак кар бөртекләре» кунса да, бөдрәлеген югалтмаган чәчләре як-якка таралмасын дигәндәй гәүдәсен уктай туры тотарга тырышкан Нурмөхәммәт Хисамов та «җитмешчеләр» сафына кереп бара икән.

Татарстанның бер читенә урнашкан гап-гади, ишле татар гаиләсендә дөньяга килгән Нурмөхәммәт, бәлки, башкалардан атаклы умартачы улы, тумыштан шигъри җанлы булуы өстенә, рәсем ясауга маһирлеге, белем бирердәй мәдрәсә эзләп берсеннән икенчесенә күченеп йөргән элеккеге зыялыларыбыз мисле, төрле мәктәпләрдә укуы (әүвәл туган авылы Мунчәли, аннан Яшел Үзән, ниһаять, Чүпрәле мәктәпләре) белән аерылып торгандыр, һәр адәми затка теге яки бу юнәлештә үсү өчен табигатьтән орлык салына, диләр. Табигый талант ачылып китсен өчен дөрес юнәлешеңне, күңеленә, рухыңа якын өлкәне табу һ. б. алшартлар булуы лязим. Шулар өстенә яшь кеше туктаусыз белем эстәргә, ялкаулык шаукымына бирелмичә, үзен кызганмыйча эшләргә тиеш.

Урта мәктәпне ифрат унышлы тәмамлаганнан соң, шагыйрьлек хыялы Нурмөхәммәтне шөһрәтле Казан дәүләт дарелфөнүненең татар теле һәм әдәбияты бүлегенә алып килә. Мәктәп партасыннан студент эскәмиясенә күчеп утыргач,

анын өметләренә Пегас канатлары куелгандай була. Житмәсә якташы—лирик шигырьләр, поэмалар авторы, бигрәк тә татар поэзиясенә сонетлар бәйләме алып килгән Ш. Мөдәррис—аны ижатка дәртләндереп тора. «Дуслык» күмәк җыентыгында, хиссиятенә өмет нуры индереп, бер көлтә шигырьләре басылып чыга. Тәнкыйть өлкәсендә үзен сынау нияте исә эзләнүчән егетне киләчәкнең җитди галиме Хуҗи Мәхмүтов һәм гайяр тәнкыйтьчесе Фәрваз Миннуллиннар җитәкләгән әдәби түгәрәккә алып килә, аудиторияләрдән тулай торак бүлмәләренә күчкән, кан басымы күтәрелгәнче дәвам иткән бәхәсләр анын рухани һәм гамәли язмышын билгеләүдә хәлиткеч булып китәләр.

Тиздән анын шигырьләр мәҗмугасы дөнья күрә, вакытлы матбугатта да Хисамов имзасы еш очрый. Кыска лирик шигырьләрдән, дүртьюллыклардан торган әсәрләрендә яшь шагыйрь замандашынын дөньядагы урыны, әдәп-әхлак кагыйдәләре, кешеләрне якынайткан дуслык җепләре турында ихластан уйлана. Ә чын шигырь исә ихласлык чишмәсеннән генә ургылып чыга ала.

Әдәбият фәне белгеченә ул көннәрдә генә ихтыяҗ табылмагач, янәдән журналист тәҗрибәсе ярдәмгә килә. 1965—1969 елларда Н. Хисамов—Казанда «Җину байрагы» исемле күп тиражлы завод газетасы мөхәррире. 1969 елда аны «искә төшерәләр» һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать (ул заманда тарих) институтына эшкә чакыралар: әлеге фәнни оешмада ул кече фәнни хезмәткәрдән башлап директор дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Яшь галимнең бөтен барлыгын, рухи куәсен, дәртен татар-болгар шигъриятенең безгә килеп җиткән тәүге үрләреннән берсе, татар халкынын фал китабы, изге дәфтәр дәрәҗәсендә йөрткән Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы били. Бу даһи әсәр анын икенче мәхәббәтенә, юлдашына, күнел юанычына, шатлыгы-кайгысына әверелә. Галимнең XIII гасыр дастанына тугрылыгы, сабитлыгы, Кол Галинең шигъри һәм инсани ачышларына мөкиббәнлеге сонрак башка шагыйрьләр иҗатын бәяләүдә дә символ -бизмән, ачкыч булып китә.

Иҗади гомерләрен бер автор мирасын өйрәнүгә багышлаган ике фән докторын гына беләм. Нурмөхәммәт Хисамов шуларнын берсе. Хәзерге фән дөньясында Хисамов дигәч, Кол Галинең даһи әсәре күз алдына килеп баса, «Кыйссаи Йосыф» поэмасы телгә алынуга Нурмөхәммәтнең олпат гәүдәсе шәйләнә. Зиһенләп карагыз: 1979 елда Мәскәүнең абруйлы «Наука» нәшрияты аша анын «Кыйсса-и Иусуф» Кул Али: «Анализ источников сюжета и авторского творчества» исемле күләмле (254 б.) монографиясе җәмәгатьчелеккә ирешә һәм ул гомумсоюз матбугатында унай бәя ала. Хезмәт турында «Советская тюркология», «Общественные науки в СССР. Литературоведение», «Вопросы литературы», «Казан утлары» журналларында Ә. Нәҗип, А. Кичиков, Н. Шкарлат, И. Нуруллин, М. Госманов кебек олы галимнәрнең сөенеп, беришесенең хәтта исләре китеп язылган мәкаләләре урын ала.

1980 елнын апрелендә Мәскәүдә, Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты каршындагы гыйльми советта Н. Хисамов Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәренә багышланган хезмәте нигезендә кандидатлык диссертациясе яклый. Таләпчән башкала галимнәренең фәнни эшне хуплавынын вәкаләтле нигезләмәсе әлеграк дөнья күргән китабы була.

Фәннәр кандидаты булып, өлкән фәнни хезмәткәр дәрәҗәсен алгач та, Н. Хисамов Кол Гали ядкяренә игътибарын киметми. «Кыйссаи Йосыф» нын тирән серләрен, илаһи матурлыгын җәһәт кенә ачып бирү мөмкин булмаган иксез-чиксез фикер вә хис дәрьясы икәнлеген галим анлый, шигъри йөрәге белән сиземли. Эзләнүләрнең саллы нәтиҗәсе буларак, 1984 елда Н. Хисамов «Бөек язмышлы әсәр» китабын (336 б.) татар укучысына тәкъдим итә. Анын бу хезмәтенә иң төгәл фәнни бәяне Татарстаннын Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, филология фәннәре докторы Н. Юзиев биреп калдырган: «Н. Хисамовнын теоретик фикерләве киң колачлы, кыю, тәвәккәл диясе килә. Анын үзәккә бер сюжетнын, конкрет Йосыф сюжетынын эшкәртелү тарихын алуы гаять уңышлы нәтиҗәләргә китергән».

2001 елда галимнең «Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII-XV вв. (Проблема версий)» исемле монографиясе дөнья күрә. Н. Хисамовнын бу юнәлештәге фәнни эзләнүләренә язучы Г. Ахунов, профессор Ф. Галимуллин,

фольклорчы галимнәр Х. Мәхмүтов, И. Надиров, шагыйрь Ә. Рәшитовлар унай бәя бирә. Рәссам Нәҗип Нәккаш-Исмәгыйль үзенең мәкаләсенә «Галимнең уңышы, укучының куанычы» дип мәгънәле исем бирә.

Н. Хисамов урта гасыр төрки-татар шигърияте үсешенә багышланган докторлык диссертациясен шул ук Дөнья әдәбияты институтында 1996 елда яклый. Иң югары фәнни дәрәҗәгә ирешкәч тә, галим дастанны өйрәнүдән һәм пропагандалаудан туктамый. Кол Гали әсәренең әхлакый-фәлсәфи тирәнлегенә, рухани дөньясына үтеп керү юлларын эзли, ишарә-кинаяләрдә татар халкына хас милли сыйфатларны күреп, шигъри энҗеләрне күтәреп ала. Алдагы елларда Йосыф китабын ул хәзерге әдәби телгә тәрҗемә итә. Аны Татарстан китап нәшрияты да, «Раннур» да (берсе—100 мең, икенчесе 50 мең тираж белән) бастырып чыгаралар. Бу китап халыкның азатлыкка омтылышы уянган, үзен аңлау өчен үткәнен, нигезләрен барлавы дәвам иткән 1989-2000 елларга туры килә. Рухи сусауны канәгатьләндерү ихтыяҗы вакытына туры килгән әлеге әсәрне хәзер инде көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Иҗади эзләнүләр яңа нәтиҗәсе дә озак көттерми: 1991 елда «Мирас», журналында (№ 6-7) Н. Хисамовның «Йосыф-Зөләйха» исемле драмасы басыла.

Кол Гали поэмасы турында чит ил, Мәскәү, Петербург галимнәре дә күп яздылар. Аның сюжет һәм мотивларына таянып, шагыйрь Р. Харис иҗат иткән либреттога нигезләнгән балет 2006 елда Рәсәйнең иң олы премиясенә лаек булгач, бу әсәрне беразга читтәрәк калдырып торырлар дип уйласак, бик нык ялгышырбыз. Бу көннәрдә генә Татарстан китап нәшрияты Н. Хисамовның «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» (XIII-XV йөзләр)» исемле бик нәзакәтле бизәлгән милли орнаментлы китабын (207 б.) бастырып чыгарды. Махсус сөйләшүгә лаеклы бу хезмәт бөтен төрки дөньяның әдәбият белемендә яңа сүз буларак кабул ителер дип уйлыйм.

Борынгы дәвердә, хәтта аннан соңрак туган әсәрләрнең күбесе безгә килеп җитмәгән, ә халык «Йосыфнамә»не зилзилә-давылларга, җимергеч сугышларга бирмичә, буыннан-буынга, авыздан-авызга тапшыра. Тәүге фәнни тикшеренүләрендә үк Н. Хисамов шундый нәтиҗәгә килә: тумыштан даһи Кол Гали гарәп-фарсы классик поэзиясен, ислам фәлсәфәсен, аның гаделлеккә, яхшылык кылуга өндәвен күңеленә сеңдереп, үз чорының дөнья, яшәеш моделен, төрле катлау кешеләренең рухына муафыйкъ әсәр тудыра алган. Читтән ингән традицияләргә таянып кына һәр тарафтан камил, шигъри өслүбе нәфис әсәр язылa алмый. Димәк, фольклор әсәрләре, халыкның җыр, мәкаль-әйтем байлыгы белән беррәттән, Кол Галигә чаклы ук, татар язма поэзиясе шактый озын үсеш чорын узып, профессиональ дәрәҗәгә ирешкән булырга тиеш. Табигый ки, Кол Гали кебек бөек затны биргән халык үзе дә шактый югары иҗтимагый, сәяси, икътисади үсеш баскычында торган дип фараз кылырга нигез бар. Үзенә лаеклы тирәлектә генә бөек шәхесләр туа һәм туган халкының дәртен, көчен, ихтыярын, яшәүгә, киләчәккә омтылышын гәүдәләндергән әсәрен иҗат итә ала. Н. Хисамов фикеренчә, Кол Гали төрки әдәбиятлар арасында Йосыф темасына таянып, беренче булып мөстәкыйль әсәр иҗат итә һәм хәзергәчә аның дастаны алдынгылыкны ычкындырмый. Бу поэма үзәгендә яткан инсани фикерләр, самими хисләр төрле чор һәм буын татар кешесенең зәвегын һәм рухын канәгатьләндерә килә. Икенче яктан, Кол Гали дастаны халкыбызның үткәнен, әхлакый эзләнүләрен аңлауда ышанычлы юлдаш дәрәҗәсендә тора. Ягъни татар-болгарның холкы, дөньяга карашы, яшәешне бәяләү үзенчәлекләре, гаделлеккә, сафлыкка омтылышы, балаларның аталарына тугрылыгы (Йосыф—Йагъкуб) хәзергәчә актуальлеген югалтмаган.

Кол Галине сүз сәнгатебезнең алтын баганасы, җаннарга һәрдаим яктылык нуры сирпеп торган якты йолдызы дип санаса да, галим—борынгы һәм урта гасыр татар әдәбиятын бер бөтен һәм олуг мирас итеп өйрәнү, бәяләү тарафдары, шул ерак еллар мәдәниятенең аңа җаны-тәне белән бирелгән ялкынлы яклаучысы. «Татар әдәбияты тарихын бәян итүдәге кимчелекләргә килгәндә исә, барыннан да элек, сәнгатьчә үсешнең дәверләренә фәнни игътибарның гадел булмаган нисбәте ризасызлык уята,—дип әрнеп-рәнҗеп яза ул «Яңача фикерләү һәм татар әдәбияты тарихы концепциясе» исемле мәкаләсендә.—Мәсәлән, ун гасырлык (VIII-XVIII йөзләр) үсешкә бер том бирелсә, 70 еллык совет дәверенә өч том багышланган».

Әлбәттә, совет чоры таләпләренә буйсынып, әдәби мирас нигездә сыйнфыйлык, дус-дошман күзлегеннән бәяләнгән хезмәттә башкача буленеш була да алмаган. XX гасыр әдәбиятыбыз бай һәм мул, ә борынгының бик күп ядкярләре безгә килеп житмәгән дип, галим белән сүз көрәштереп булыр иде. Хикмәт анда түгел. Борынгы һәм урта гасыр әдәбиятыбызда татар халкының хәтер һәм рух чагылышын, һәрберебезгә якын, кадерле балачак һәм үсмерлек дәверләрен күргән Н. Хисамов беренчеләрдән патриот кына түгел, ул ун гасырлык татар әдәбиятын фәнни, гамәли өйрәнүнең методологиясен тәкъдим итә. «Шигърият ижтимагый-инсани мәсьәләләрнең куелышы җәһәтеннән дә, сәнгатьчә үсеш ягыннан да Кол Гали ирешкән биеклектән кузгалып китә»,—ди автор «XIV йөз татар шигъриятендә кеше идеалы» мәкаләсендә һәм шул фикерен Котб, Хәрәзми, Кятиб һәм Сәйф Сарай кебек шагыйрьләр иҗатында ижтимагый-фәлсәфи мотивлар үсешендә раслый. Берсен икенчесе тулыландыра килгән «Двенадцать столетий татарской литературы», «Борынгы әдәбиятыбыз», «Урта гасыр татар әдәбиятын өйрәнүнең принципиаль мәсьәләләре», «Урта гасыр татар әдәбиятында үзара бәйләнешләр», «Урта гасыр төрки шигърияте үсешендә болгар-татар һәм госманлы төрек әдәбиятлары (Сәнгатьчә фикерләүнең уртак нәтиҗәләре)», «Әдәби мирас һәм милләт бердәмлеге» кебек мәкаләләрендә галимнең борынгы һәм урта гасыр татар сүз сәнгатен өйрәнүнең фәнни концепциясе тирәнрәк ачыла, һәр җөмләсендә автор татар шигъриятенең милли җирлектә, үз сурәтле фикерләү байлыгына таянып үсүенә басым ясый.

Кол Галидән соң сүз сәнгатенә төрки-татар поэзиясе биргән яналык, халкыбызның шигъри юлдашы—Г. Тукай булды. Бөек шагыйребез иҗатын өйрәнүгә, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлекләрен, рухани бөеклеген ачуга Н. Хисамов унга якын мәкаләсен багышлый. Аның «Тукай—яңа гасыр шигъриятенә нигез салучы», «Некоторые трудности в постижении лирики Тукая», «Тукайның шигъри фикерләвендә шәркый сурәтләр», «Тукай һәм Аурупа шигърияте», «Тукай шигъриятендә һөҗү», «Тукайга якынаю» кебек шагыйрь мирасына чиксез ихтирам, даһилеге каршында баш иеп, бер тын белән язылган мәкалә-чыгышлары шул хакта сөйли. Тукай иҗатына югары бәя шагыйрь үзе исән чакта ук башлана һәм төрле буын галимнәре, язучылары тарафыннан дәвам иттерелә. «Н. Хисамов бу өлкәдә нинди яңа сүз әйтә алды соң?» дигән сорауның тууы табигый. Галимнең Тукай шигъриятен бәяләүдә үз концепцияләре бар. Беренчедән, бөек шагыйребез татар поэзиясенең Кол Галиләр кабызган шигъри ут-эстафетасын кабул итә һәм чор таләпләреннән чыгып, поэзиянең ижтимагый аһәңен күтәрә, фәлсәфи-әхлакый нигезен тирәнәйтә. Икенчедән, Тукай татар поэзиясен милли мәнфәгатьләргә, халык яшәешенә, тормышына якынайта. Өченчедән, нәфис аһәңле, нечкә, сизгер тоемлы шагыйрь татар теленең бай һәм сыгылмалы көченә, ритмик байлыгына таянып, шигырь төзелешенә реформа ясый, шәкел калыпларының төрле һәм сыйфатлы булырга тиешлеген раслый. Татар поэзиясе тарихында «иң көчле шигъри мәктәп, һичшиксез, Тукай мәктәбе ул. Унлаган һәм унлаган яшь шагыйрьләрнең төрле басмаларда дөнья күргән шигырьләренә күз салсак, Тукай ритмнары, аңа хас мотив һәм аһәңнәр ярылып ятканын тоемларга мөмкин»,—ди галим «Тукай—яңа гасыр шигъриятенә нигез салучы» мәкаләсендә, һәм бу фикерен Тукай шигъри мәктәбеннән күтәрелгән күп санлы мисаллар белән дәлилли.

Кол Гали «оныклары»Тукай, Дәрдемәнд, Туфан, Г. Афзал, Ш. Галиев, Ә. Баян, бигрәк тә Р. Фәйзуллин белән Р. Харис шигъриятләре турында нечкә зәвыклы, энә күзеннән чыккан күзәтүләргә бай мәкаләләрендә Н. Хисамов мәңгелек хакыйкатьләр һәм кыйммәтләр дәвамлылыгы турында уйлана. Аерым алганда, вакыт ягыннан иң соңгы «Хәтер сагында» дип аталган күләмле, күп еллык иҗади эзләнүләрен эченә алган (2004 ел, 556 б.) җыентыгына да югарыда аталган шагыйрьләр иҗаты турында этрафлы мәкаләләрен урнаштыра. Хосусан, «Тирән хакыйкатьләр дөньясы» мәкаләсендә ул түбәндәгечә яза: «Равил Фәйзуллин ... аның бәгърен милләтенең тетелеп, чәрдәкләнеп, чәчелеп бетүе өзгәли. Ул кавемендәге аңлы, намуслы замандашына Морзе әлифбасы аша борчылу хәбәре җиткерә. Гадәттән тыш гомумиләштерелгән серле гыйбарәләр. Мәгәр сорауларның хәвефле куелышында, сыйдырышлы серле төшенчәләрдә ил, милләт язмышы абайлана.

Дәрдемәндчә колачлы иңләү, күренеш төгәллеге һәм тирән борчылу... Тик шулай да, Р. Фәйзуллин—«фәлән мәктәп» шагыйре түгел. Дөресрәге, хәзер ул үзе мәктәп».

«Ренат Харис исемен телгә алуга, күп гасырлык традицияләргә тоташкан татар шигъриятенең иҗтимагый, әхлакый, рухани йөген иннәренә нык салган буын күз алдына килеп баса»,—дип яза Н. Хисамов «Янам, яктыртам, жылытам» исемле мәкаләсендә.

Берәүләр әдәбиятта искене, үткәнне кире кагу аша гына яңаны раслап була дип ялгышсалар, икенчеләре яңаны бары тик элгәрләрнең вакыт басымына бирешмәгән, матурлыгы уңмаган йолаларына таянып, шуларны үстереп кенә алга этәреп була, дип саныйлар. Изгелек кылу, милләтеңне, туган телеңне ярату, кемгәдер ярдәм кулын сузуны яшәү мәгънәсе, табигый ихтыяҗ дәрәҗәсенә күтәрү һәр заман сүз сәнгатенең үзәгендә яткан. Шундый бөек идеалларга омтылып яшәгән кеше генә Раббыга якыная бара, инсани яшәү рәвешенә, мәңгелек мөкәммәл әхлак тәртипләренә буйсына, рәхимле яшәеш ярларына килеп чыга. Мәңгелек әхлакый-иҗтимагый кыйммәтләр, Кол Гали каһарманнарына хас Аллаһ Тәгаләдән ингән нур (нур фәлсәфәсе Көнчыгыш шигъриятенең алтын баганасы), гасырлар катламы караңгылыгын үтеп, безнең көннәр поэзиясенә эзләнүләр рухы, халык, табигать белән бердәмлек тойгысы иңдерә, дәвамлылыкны үсеш чыганагы дәрәҗәсенә күтәрә (Кол Гали—Тукай—хәзерге татар шигърияте). «Әдәбият—милләтнең хәтерен уяту чарасы» дигән фикер Н. Хисамовның иҗаты буйлап чаң кагып уза. «Әдәбиятта,—ди ул «Хәтер сагы» мәкаләсендә,—хәтернең эчтәлеген мирас тәшкил итә. Безнең бөек әдәби мирасыбыз халкыбызның Ауразия киңлекләрендә, Шәрекъ белән Гареб арасында лаеклы урын биләгәнлеген, кешелек дөньясы өчен гаять кыйммәтле һәм гыйбрәтле фикри проблемалар күтәргәнен искә төшереп тора. Аңардагы югалмас гамәл һәм гакыл формулалары бүгенге яшәү көрәше өчен дә әһәмиятле».

Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры булып эшләгән дәвердә Н. Хисамов Тукай, Дәрдемәнд, Такташ, Туфан кебек бөекләребезнең юбилейларына багышланган фәнни конференцияләрне оештыруга, уздыруга үз өлешен кертте, еш кына әтрафлы кереш сүзләре белән тиешле фәнни дәрәҗәне билгеләде.

Минемчә, Нурмөхәммәт барыннан канәгать булып яши торган киң күңелле кеше, башкаларның уңышы, бәхете өчен шатлана белә. Директор булып эшләгән елларда хезмәткәрләренең китапларын бастырып чыгару, яшәү шартларын яхшырту турында чын күңелдән кайгыртып, хуҗаларның бусагаларын шактый шомартты. Фольклорчы Хуҗи Мәхмүтовны, буйдак егет З. Мөхәммәтшинне шәһәр үзәгенә, олы сәнгаткярләр генә яши торган йортка күчерүгә ирешкәч, балаларча куанып йөргәне хәтердә. Әйтерсең лә, үзе яңа фатир алган! Бәлки, аның бу җаваплы эшендә, җитәкчелек тәҗрибәсе азрак булу сәбәпле, җитешсезлекләре, һәр гамәлне ашыкмыйча, җиренә җиткереп башкарырга омтылуы аркасында хаталары да булгандыр. Әмма аның үз вазифаларын яратып, теләп башкаруы бәхәссез иде.

Н. Хисамовлар гаиләсен бизи торган янә бер сыйфатка тукталмыйча булдыра алмыйм. Нурмөхәммәт әфәнде белән Фәһимә ханым, фәннәренә, иҗтимагый эшләренә хилафлык китермичә, берсеннән-берсе талантлы өч ир-егет тәрбияләп үстерәләр. (Сүз уңаенда: татар язучыларыннан милләт горурлыгы булырлык өчәр малай тәрбияләгән ике язучыны гына беләм: Аяз Гыйләҗев һәм Нурмөхәммәт Хисамов, кызлар үстерү җәһәтеннән Әмир Мәхмүдов беренчелекне бирми кебек.) Күрәсең, ун гасырга якын элегрәк язылган (бәлки, әйтелгәндер) әсәр авторы Кол Гали шәхесе, иҗаты, анда тәкъдим ителгән әдәп-әхлак кануннары, яшәеш кагыйдәләре белән якыннан танышып, «аралашып» яшәү Хисамовларның үз гаилә тормышының да итагатьле, мәгънәле, нәтиҗәле булуын тәэмин иткәндер дип уйларга нигез бар. Тулаем алганда, Н. Хисамовның фәнни һәм тәнкыйди хезмәтләре туган халкының мирасын саклау, тарихын дөрес бәяләү, поэзиябезнең эчке җегәрен, матурлыгын, сурәтләү чаралары байлыгын ачуга багышланган. Ул яшь фәнни алмаш әзерләүгә җитди игътибар бирә (аның җитәкчелегендә унга якын фән кандидатлары һәм докторлары пәйда булды), шул ук вакытта үзе дә яшьләрчә дәрт, илһам белән иҗади һәм гыйльми эзләнүләрен дәвам итә. Ана исәнлек, рухи хөрлек телик!

# УРАЛ-ТАУНЫҢ БЕР КЫЙТГАСЫ

*Урал кыяларыннан төшеп, Сакмар суларын эчеп, аның бормалы уйсулыкларында уйланып, хыялга чумып, биниһая гүзәл күренешләрне җанына-күңеленә сеңдереп, җыр-моңнар һәм бихисап сурәтләрне туплап безгә җиткерер өчен, алар белән халкыбызның рухын баетып, янып-көеп яши бүгенге көндә рәссам Абрек Абызгилдин.*



*Ул—республикабызда абруйлы, билгеле шәхесләрнең берсе. Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге дәүләт бүләге һәм Бакый Урманче премиясе лауреаты, Татарстанның халык, Россиянең атказанган рәссамы. Унбиш ел дәвамында Татарстанның Рәссамнар берлеге рәисе.*

*Абызгилдин—үзе генә дә бер дәвер, үзгә бер катлаулы шәхес. Ул илебез өчен куркыныч, шомлы 1937 елда—Сталин режимының эзәрлекләү һәм атып үтерүләрнең иң дәһшәтле чорында туган. Аның тормышы илебез яшәешеннән аерылгысыз: сугыштан соңгы авыр еллар, Хрущев заманындагы «епшеклек» еллары, заманалар алышынуы һәм торгынлык еллары, үзгәртеп кору, матбугат һәм сүз ирекле, тамырдан үзгәрту еллары. Әлеге һәрбер чор үзгәрешләре кешенең холкына йогынты ясый, бигрәк тә иҗат кешеләренә. Әлбәттә, бу үзгәрешләр Абрек Әмир улы характерына һәм иҗатына да үз йогынтысын ясамый калмый. Шуңа күрә мин бу интервьюда аны рәссам яки җәмәгать эшлеклесе буларак түгел, ә бәлки шәхес буларак күрсәтергә теләр идем.*

**—Абрек әфәнде, күп еллык иҗат дәверендә сезнең, әлбәттә, күренекле хезмәтләрегез байтак: монументаль сәнгатьтә—интерьер һәм мозаик паннолар Чаллы, Казан, Әлмәт һәм башка зур шәһәрләрнең йорт һәм интерьерларын бизи. Балчыктан эшләнгән әйберләр дә бик кызыклы, майлы буяу белән рәсем ясаган картиналарны исә әйткән дә юк. Соңгысында Сез үз стилегезне тапкансыз. Ә шулай да нәрсәләр эшләнеп бетмәгән, җаныгыз нәрсәгә сызлана?**

—Сүзне аз гына ерактан башларга кирәк дип уйлыйм. Үзган елнын ноябрь аенда Рәссамнар берлегенең оешуына 70 ел тулды. Миңа да шулай ук 70 яшь. Бу җитди, уйланырлык саннар. Казан сынлы сәнгать мәктәбе, моннан бер гасыр элек, 1895 елны оешкан, һәм мин, шәхсән үзем, Казан рәсем сәнгате училищесын тәмамлаган шәкерт булуыма чиксез горурланам. Әлеге училищены күренекле рәссам-оештыручылар К. Мюфке, Н. Белькович, Г. Медведев, Ю. Тиссен ачып җибәргән. Алар Бакый Урманче, Николай Фешин, Петр Сперанскийларга белем-тәрбия биргәннәр. Үз чиратында алар да байтак рәссам-мөгаллимнәрне тәрбияләгәннәр.

Казан художество училищесын (КХУ) тәмамлаганнар Бөтенроссия һәм чит илләрдә булып узган күргәзмаләрдә дә билгеле, сәнгать сөючеләр дә, сәнгать белгечләре дә

аларны таный. Ләкин, тагы бер бик мөһим эшләнәсе эш бар әле. Татар милли рәсем сәнгате мәктәбен оештыру. Моның өчен бездә бөтен шартлар, мөмкинлекләр бар.

Шәрык, милли стильдә рәссамнар Илдар Зарипов, Рифкать Вахитов, Канәфи Нәфыйков, Рабис Сәлахов, Әлфия Ильясовалар иҗат итә. Безнең борынгы шамаил сәнгатен дәвам итүче һәм үстерүче рәссамнар Нәҗип Нәккаш, Фирдәүс Гыйрфанов, Владимир Попов эшләп киләләр.

Бик тә зәвыклы, искиткеч гүзәл әйберләр зәркәнчелектә Шамил Хәялиев, Рәфкать Мөхәммәтшин, Илгиз Фазылҗанов кул астыннан чыга. Сәнгати тимерчелекне Игорь Башмаков шәкертләре дәвам итә. Күн мозаика осталарының һөнәрен Софья Кузьминых һәм аның кызы Светлана Гарбузова үстерә. Борынгы болгар һәм Казан ханлыгы чорындагы балчыктан чүлмәк, савыт-саба чыгаруны рәссам Зөфәр Низаметдин төп максаты итеп куйды. Безнең көннәргә кадәр сакланган татар милли декоратив-гамәли сәнгатебез буш урында барлыкка килмәгән. Ул нигездә болгар дәүләте, Казан ханлыгы чорында оешкан. Әлбәттә, аңарга башка шәрык халыкларының йогынтысы кагылмый калмаган. Болгар халкының халык кул сәнгате алымнары сизелерлек дәрәҗәдә. Ул заманда халыклар бик тыгыз аралашкан, сәүдә иткән. Шул аралашу нәтиҗәсендә матур сынлы сәнгать һәм халык кул иҗаты сәнгате җәүһәрләре барлыкка килгән.

Өс киемнәре һәм баш киеме тегә торган берничә шәхси фирма турында да әйтеп үтәргә кирәк. «Туран» һәм «Эбиваль»—Казанныкылар, «Карина» исемендәгесе Чаллыдан. Алар искиткеч матур киемнәр тегәләр.

Халык сынлы сәнгать һөнәрләре чит илләрдә дә сакланып кала. Чөнки халыклар үзләре үк, һәм шулай ук рәссамнар да үзләренең милли-мәдәни тамырларының үзенчәлеген сакларга тырышалар.

Бездә сын ясау йомшак, сынчылар аз иде. Соңгы елларда бу өлкәдә җанлану сизелә. Гаиләләре белән Нигъмәтуллина-Рогожиналар, Габдрәшитовлар, Кәдим Җәмит, Мәхмүт Гасыймов, Асия Миңнуллиналарның хезмәт җимешләре шәһәр һәм бистә урамнарын бизи. Алтын җепләр белән чигү ысулын үз иткән, бик күп конкурс-күргәзмәләрдә бүләкләр алган Луиза Фәсхетдинова турында да әйтмичә булдыра алмыйм. Шуңа күрә янә басым ясап әйтәм: татар милли рәсем сәнгате мәктәбен булдырырга кирәк.

**—Абрек әфәнде, Сез, уйлавымча, гаять дәрәҗәдә кызыклы һәм (поучительный) тормыш тәҗрибәсе туплагансыз. Шуларның иң якты мизгелләрен сөйләп үтмәссез микән?**

—Сугыштан соңгы еллар. Ачлык, ялангачлык. Әни тормышны тартып бара торган хатын иде. Җиденче классны тәмамлауга, ул тау техникумына укырга керергә киңәш бирде. Чөнки студентларны форма—өс киеме белән тәэмин итәләр иде. Техникум һөнәр, урта мәктәпне тәмамлау турында таныклык һәм тормыш тәҗрибәсе бирә иде. Ә соңгысы һәр иҗат кешесенә бик кирәк, мөһим нәрсәләрнең берсе. Дүрт ел уку дәверендә Уралның барлык шахталарында эшләргә туры килде. Ул чакта укуны практика белән аралаштырып алып бара иделәр: алты ай теория, өч-дүрт ай забойда боксит (алюминий) рудасын кәйлә белән чокыйсың. Җир асты катламында, 360 метр тирәнлектә алтышар сәгать эшли идек. Эт булып арыйсың. Аллаһы Тәгалә язмасын андый эшне. Аяныч, авыр булса да, тормышның ямьле яклары да бар. Уралның табигате, тарихы искиткеч матур һәм бай. Әлбәттә, алар миңа бик нык тәэсир иттеләр. Төньяк балкышының матурлыгы әйтеп бетергесез, әле дә күз алдымда. Минем хезмәт кенәгәмдә беренче язу итеп «6 разрядлы забойщик» дип теркәлгән.

Техникумны тәмамлаганнан соң Төньяк Уралга җибәрделәр. Атаклы Семёнов рудникларында эшләргә туры килде—ул минем туган шәһәрем Баймактан биш чакрым ераклыкта. Биредә Урал таулары бетә, халык җырларында җырлана торган Сакмар елгасының башланып киткән урыны. Шуның янәшәсендә риваятьләргә кергән, изге, уйчан Аркаим. Биредә инкыйлабка кадәр атаклы татар эшмәкәрләре абыйлы-энеле Рәмиевләрнең алтын приискалары булган. Мөхәммәтзакир—танылган шагыйрь Дәрдеменд, аның энесе Мөхәммәтшакир Оренбургта газета-журнал нәшер иткән.

Ниһаять, миңа 18 яшь тулды, армиядә хезмәт итәргә вакыт җитте дигән сүз. Ул заманда бит армиядә хезмәт итмәгән егетләрне чүткә да санамыйлар иде. Ләкин шахтада эшләүчеләрне армиягә алмыйлар, бронь биреп калдыралар иде. Минем исә армиядә хезмәт итеп, дөнья күрәсе, авыр хезмәттән арынасы килә иде. Уңайлы мөмкинлек

озак күтәрмәде.

Якшәмбе көннәрендә мин дуслар белән танцыга йөри идем. Шунда бер чибәр кыз белән таныштым, ул да миңа гашыйк булды. Шәфкать туташы булып эшләгәнлектән, аның ярдәме тиде. Ярдәм итүен итте дә, соңыннан әйтеп салмасынмы: «Менә нишләдем инде мин? Синең белән мәңгегә аерылабыз бит»,—дип елады. Ул мине армиягә озатты. Биш дус малайдан өчебезне алдылар. Байкал аръягында хезмәт иттем. Горный институтка керергә әзерләнә идем. Андагы табигать мине сихерләде, шунда беренче тапкыр кулыма төсле карандаш, буяулар алып рәсем ясый башладым. Армиянең соңгы елында Казанда хезмәт итәргә туры килде. Биредә рәссамнар белән таныштым, алар рәсем училищесында укырга үгетләделәр.

**—Абрек әфәнде, Сезнең бик сәер, гаҗәеп фәлсәфи, Тукайның һәм татар халкының уй-фигыленә үтеп кереп аңлавыгызны тасвирлаган картинагыз бар. Ул «Тукай илә Шүрәле» дип исемләнә.**

—Мондый образда Тукай беренче тапкыр тасвирлана иде. Бу картина Мәскәүдә күргәзмәдә булды. Аны караган кешеләр шаккатканнар. Ул картина турында соңыннан күп яздылар, минем, әлбәттә, күңелем булды.

Картина аллегория стилендә иҗат ителгән. Минем әйтәсе килгән фикер: Тукай— татар халкының вөҗданы ул. Һәм аны без бөтенебез дә шулай күзаллыйбыз. Ул сатылмый, бернинди алтынга да алданмый, җәмгыять аны читкә каккан, ул үзе дөньядан ваз кичкән, ләкин ул дөреслек өчен җанын фида кылырга һәрчак әзер, ул гадел, ул— милләт сагында торучы. Шул картинаның идеясен җигеп, Рифкать Вахитов һәм Әхсән Фәтхетдинов иҗат итә башладылар. Шүрәле исә —татар халкының түгелмичә калган күз яшьләре. Шамил Нигъмәтуллинның әле Мәскәүгә күргәзмәгә киткәнче үк: «Мондый картинаны бездә бер рәссам да иҗат иткәне юк иде»,—дип әйткәне бар.

**—Абрек Әмирович, Сез Бакый Урманчены яхшы белгәнсез. Аның турында истәлекләрегезне уртаклашсагыз икән...**

—Бакый абый белән танышкач та, ул минем портретымны киндергә майлы буяу белән төшерергә ниятләде, күрәсең, минем йөземдә, килеш-килбәтемдә нәрсәдер аның күңелен җәлеп иткән. Бер ай чамасы мин аның остаханәсенә килеп йөрдем. Ул ашыкмыйча, каударланмыйча, иҗат итүнең ләззәтен, мәгънәсен белеп эшли иде. Әлеге очрашулар минем үземә, шәхсән, бик күп нәрсә бирде. Үзенең вакыйгаларга бай тормышыннан төрле эпизодлар сөйләде: ул бит патша заманында туган, инкыйлабка кадәрге Россиядәге тормышны бик яхшы белгән, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте булган, берничә революция күргән. Мәскәүдә, рәссам булырга ВХУТЕМАСта укыган, рәсем, скульптура осталыгына атаклы укытучылардан дәресләр алган, җыр сәнгатен өйрәнергә консерваториягә йөргән. Бервакытны ул миңа шундый фикер әйтте: үз тормышында иң кирәкле университетны Соловки утравында узганы хакында. Бер уйласаң, парадоксаль фикер: иң куркыныч тоткынлык урыны, ләкин аның белән янәшә иң зыялы, укымышлы галимнәр бергә булган. Ул алардан гыйлем эстәгән, чит телләр өйрәнгән. Искиткеч бай рухлы зыялыларның күбесе шунда үлеп калган.

Тоткынлыктан азат ителгәч, ил буйлап күченеп йөргән, чөнки туган якка кайту һәм зур шәһәрләрдә яшәү катгый рәвештә тыелган булган. 50 нче еллар азагында гына туган якларга кайтырга рөхсәт бирелгән. Урманче ифрат дәрәҗәдә зыялы, гыйлем кешe иде, энциклопедик белем иясе. Ул фарсы телендә шигырьләр укый, искиткеч матур җырлый иде, сәяси яктан әзерлекле иде. Яңалыкларны чит телләрдә нәшер ителүче гәҗитләрдән укып белә иде.

Һәр атна саен билгеле бер көнне ул дусларын үзендә җыя иде. Шундый мәҗлесләрдә мәдәният, татар теле һәм әдәбиятының киләчәге турында гәп куера иде. Без аның һәр сүзен йотлыгып тыңлый, һәрбер күз карашын отып калырга тырыша идек. Ул һәрберебез өчен әтиебез кебек булды, шул ук вакытта өлкән иптәш, дус шикелле иде. Бу очрашулар, шәхсән, минем үзем өчен бик күп нәрсә бирде. Дөньяга карашны гына түгел, ә бәлки минем язмышымны да үзгәртүгә йогынтысы булгандыр дип уйлыйм. Шул портретымны ясаганнан соң безгә еш очрашырга туры килде. Мин аңа охшарга, аның кебек булырга, аның гадәтләрен үзләштерергә ниятләдем. Мәдәният өлкәсендә хезмәт һәм иҗат итүче күпләр өчен ул бүген дә абруйлы, дәрәҗәле шәхес.

Бервакыт сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның 100 еллыгы уңаеннан Бакый агага шагыйрьнең сынын эшләргә заказ бирелде. И останы партиянең өлкә комитеты чиновниклары интектерделәр дә инде!

Һәр сәгать ярым узуга шылтыратып эш барышы белән кызыксынып тордылар. Сын иң югары бәяне алды, бөтен комиссия әгъзаларына да ошады.

Бакый агага әллә ниткән диплом-исемнәр вәгъдә итә башладылар. Ә ул бу «юмартлык»ка:

—Миңа нәрсәгә алар? Әнә фәләнев (рәссамның фамилиясен әйтеп), аңа бирегез, аның матди хәле бик авыр, дип кенә әйтә иде.—Мин бит акча, исем алыр өчен эшләмәдем, фәкать олугъ шагыйребез хөрмәтенә, аның даһилыгын, аңа ихтирамымны күрсәтер өчен эшләдем.

**—Сез чит ил һәм Россия күләмендә бик күп рәссамнарның иҗатлары белән таныш, аларның иҗади башлангычын һәм иҗатларының чәчәк аткан көннәрен дә яхшы беләсез. Рәссам буларак аларның иҗатлары кайчан, нинди яшьтә җитлегәләр?**

—Бу сорау бик кызык тоелды миңа. Матбугатта да, радио-телевидениедә дә мондый сорауны ишетмәдем шикелле.

Һәрбер рәссам индивидум, шәхес булырга тиеш, мин аны планета яки күктәге йолдыз белән чагыштырыр идем. Әгәр дә безне биләгән тормыш-яшәешкә үз карашың булмаса, син рәссам да, язучы да, журналист та түгел инде, син—гади бер кеше.

Рәссамның иҗаты чәчәк ату чоры 35-40 яшькә һәм 50 яшькә кадәр. Шуннан соң иҗат, күп очракта, шаяру—яхшы мәгънәсендәге хулиганлыкка әйләнә дә куя. Рәссам—үзгә бер иҗатчы, ул индивидуалист булырга тиеш. Мин башкорт рәссамы Әхмәт Лотфуллинны бик хөрмәт итәм. Ул Эстониянең сынлы сәнгать институтының 3 курсын гына тәмамлаган да, «миңа шушысы да җитә» дип, туган якларына кайткан да киткән. Һәм, уйлавымча, дөрес эшләгән. Тагын шунысы да бар: Мәскәү яки Санкт-Петербургта укыган булса, ул бөтенләй икенче рәссам булыр иде. Балтыйк буе аның азатлыкка омтылу рухы, иҗатка да, дөньяга карашны формалаштыруга да йогынты ясый. Башкортстанның Әбҗәлил районына кайтып, 5-6 ел иҗат итү дәверендә, Әхмәт зур сәнгать өлкәсендә, үзенең күркәм, абруйлы урынын ала. Бөтен иҗатын ул туган авылына, аңа мәдхия җырлауга багышлый. Яз башында авылына кайтып китә һәм кара көз көнендә Өфегә әйләнеп кайта. Үзенең туган авылының көндәлек алып баручысына әйләнә ул—авылын иң югары фәлсәфи биеклеккә күтәргән рәссам.

Шигърияттә дә андый мисаллар бар. Рәсүл Гамзат «Минем Дагыстаным» дигән китабында үз бабасы турында болай дип яза. Цадаса Гамзат үз гомерендә авылыннан аерылмаган, ул аннан бер генә тапкыр чыгып киткән—Мәскәүгә, Сталин бүләген алыр өчен. Ләкин, шагыйрь буларак, ул планетар фикер йөртүче шәхес булган. Шундый сорау туа: нишләп? Чөнки ул үзенең тауларын, ватанын, авылын, кардәшләрен, әти-әни телен, туган телен, туганнарын бик нык яраткан. Бүген әлеге төшенчәләрнең барысы да диярлек көн кадагына әйләнде. Тик аларга без тамга сугып саклау сүзен кертергә мәҗбүрбез: табигатьне саклау, кеше хокукларын, сәламәтлек саклау, телне, мәдәниятне саклау. Тагын бер мөһим мәсьәлә: Гамзат җанының сафлыгын, пакьлыгын саклап калган, кеше белән аралашу сафлыгын, фикер сафлыгын югалтмаган.

Миңа калса, рәссамга күп гыйлем кирәкми дә шикелле, чөнки ул фикерне чуалтырга, таркаулыкка китерергә һәм иҗат өчен зыянлы булырга мөмкин. Рәссамның төп вазыйфасы—рәсем ясау.

**—Ә Бакый Урманченың күп өлкәдә гыйлемдар булуы?**

—Менә шунда шул бөтен хикмәт тә. Бакый абый—уникаль шәхес, генийлар, даһилар рәтендә. Әлбәттә, белем дә кирәк. Мәсәлән, Ренуар Вазари сәнгать осталыгына төшенер өчен итальян телен өйрәнгән. Ә Леонардо да Винчи, гомумән алганда, китап укымаган, чөнки ул үзенең даһилыгын аңлаган.

**—Сынлы сәнгатьтә, әдәбиятта һәм мәдәнияттә Сезнең күңелегезне җәлеп иткән авторларны беләсе иде.**

—Испан һәм француз рәссамнарын яратам. Ә менә Италия рәссамнарының сәнгатен аңлау дәрәҗәсенә үсеп җитмәдем. Гомумән алганда, иҗат нәрсәдән килгәнен уйласаң, ул табигатьнең һава торышына үтә дә буйсына. Минем туган як Урал тауларының көньяк ноктасы, аны Йөрындык таулары дип атыйлар, янәшәсендә—уйчан, изге Аркаим. Биредәге климат тискәре—континенталь, кыш көне 40 градус салкын, җәй—40 градус эссе. Бу Башкортстанның Учалы районы. Монда туган кешеләрдән ике төрле шәхес чыга—иң шәп, атаклы артистлар, мәсәлән, Лима Кустабаева, хезмәт каһарманнары, биючеләр, яки зимагур, кесә караклары, угры—төрмәдән башлары чыкмый торган башкисәрләр. Минем алдымда да нәкъ менә шул ике юл бар иде: башкисәр яки иҗат юлы. Мин иҗатны сайладым.

Әдәбиятка килгәндә япон язучысы Акутагаваның әсәрләре мина бик якын, рус әдәбиятында иң яраткан язучыларым Чехов һәм Достоевский. Гарсиа Маркесны укыгач, композиция хакында үземнең карашны төптән үзгәртергә туры килде. Кино сәнгатендә иң көчле тәэсир калдырган режиссерлар Андрей Тарковский һәм Сергей Параджанов.

**—Абрек абый, үзегезнең чыгышыгыз турында сөйләгез әле, әти-әниегез кемнәр булган? Сезнең фамилиягез дә кызык яңгырый.**

—Абзый сүзе бик күп төрки телләрдә очрый. Ул югары дини руханилар билгесе. Фамилия бик борынгы заманнан бабайның бабасыннан килә. Әтинең бабасы Морза Абызгилдин тирә-якта билгеле мулла булган. Әнинең бабасы да Зөлкафил шулай ук мулла булган. Тумышы белән ул Оренбург якларыннан. Ике гаилә дә Сталин режимыннан җәбер-золым татыган. Әтием Әмирне, Морза малае һәм әниемне дә, Зөлкафил кызы Җәмиләне 34-35 елларда, халык дошманнары балалары буларак, ФЗУ мәктәпләренә җибәрәләр. Әти механик, әни токарь-фрезеровщик һөнәрләрен үзләштерә. Шуннан соң Өфедә театр техникумын тәмамлыйлар һәм Баймак күчмә театрында артист булып эшлиләр. Әни бик сәләтле була. Яшь чагында Фәридә Кудашева белән дуслаша. Соңыннан ул җырчы «Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисткасы» була. Мин туган елны әниемне «Салават Юлаев» фильмында мәшһүр артист Арслан Мөбарәков белән бергә катнашырга чакыралар. Минем дөньяга килүем әнинең бу фильмда катнашмавына сәбәп булган.

Әти белән әни гастрольләргә чыкканда мине Рәмиевләрнең чыбык очы туганнарына калдыра иделәр. Әлеге гаилә хөрмәтенә рәхмәт йөзеннән үземнең кайбер картиналарымда Дәрдемәндне тасвирлыйм. Әти, театрда эшләп, Ленинградның театр институты югары режиссерлар курсларында укыган. Өченче курстан аны фин сугышына алалар. Ватан сугышы башлангач, ул сугышка китә, офицер була. 1943 елны Орел тирәсендә бик каты сугышлар барганда 28 яшендә һәлак була. Мин туган елны әтинең ике абыйсын да халык дошманы дип атып үтерәләр. Сталин режимының кабахәтлеген безнең гаиләгә муллан татырга туры килде.

*Дөресен әйткәндә, Абрек Абызгилдин иҗатында беркайчан да вакланмаган, ул һәрчак зур, мөһим темаларга тартылган. Шуңа күрә аның картиналарында күренекле шәхесләр арасында кешелек җәмгыятендә зур, күркәм эшләр башкарган даһилар—Микеланджело, Коперник, Параджанов, Тукай, Сәйдәш, Урманче тасвирлана. Әлеге темага рәссам бүген дә тугъры калган.*

**—Абрек Әмирович, Казан рәссамнар училищесын тамамлагач, Сез белемегезне Суриков исемендәге Мәскәү рәссамнар институтында дәвам иткәнсез икән. Кемнәр укытты Сезне?**

—Әйе, мин 1965 елда укырга Мәскәүгә киттем һәм алты ел урынына биш елда институтны тәмамладым. Иртәрәк бетерүемнең сәбәбе—гаиләмне, балаларымны карарга акча кирәк иде. Мин Мәскәүдә укыганда Хрущевның «епшек» елларының соңгы аккордлары яңгырый иде. Әле халык демократия, сүз ирегенә ышануыннан арынмаган иде.

Мин атаклы профессор Клавдия Александровна Тутывольдан (Александр Дейнека остаханәсе) тәҗрибә тупладым. Рәсем һәм композиция дәресләрендә бу остаханәдәге укытучылар Александр Мызин, Дмитрий Жилинский искиткеч биеклекләрне яулаган

иделәр. Андый рәсем мәктәбе бүгенге көндә юк дәрәҗәсендә. Күңелемә, җаныма Михаил Алпатов сөйләгән лекцияләр үтеп керде. Үз гомеремдә укытучыларымны олы ихтирам белән искә алам һәм аларга башымны иям.

**— Абрек әфәнде, дөньялар бик үзгәрде, яшәү дәрәҗәсе дә төрләнде. Бу үзгәрешләрне рәссамнар ничек кичерә, алар ничек көн күрә?**

—Рәссам җәмгыять сулышын тоеп яшәргә тиеш, аңа киләчәк заманны сиземләү, үзенә күрә күрәзәчелек сыйфаты хас булырга тиеш. Шулай булмаса, ул читтән торып күзәтүчегә әйләнә. Хәзер кешегә мөмкинлекләрнең төрлесен сайлап алу заманы килеп җитте. Базар мөнәсәбәтләре рәссамнарны да читләтеп узмый. Кайберләрен ул үз кулына алды да инде, алар иҗатларын сату юлына бастылар. Андыйларны акча, байлыктан башка берни дә кызыксындырмый һәм алар ихлас иҗат турында уйлап та бирмиләр, осталыкларын югалталар. Ләкин иҗатның, сәнгатьнең үз кануннары бар, алардан тайпылсаң, син көнлекче рәссамга әйләнәсең, иртәгә исә сине онытачаклар.

Рәссамнар берлегендә бүгенге көндә 300 дән артык рәссам әгъза булып тора. Шуларның һәрберсенең гаиләсе, бала-чагасы бар. Аларга матди яктан ярдәм итәргә, көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерергә, проблемаларны чишәргә кирәк. Берлекнең бурычы хәлдән килгәнчә ярдәм итү дип саныйм. Безнең өлкәннәр иң авыр хәлдә. Яшьләр бит алар сыгылмалы, тиз җайлаша алалар. Ә минә традицион, классик ысулда иҗат итүче рәссамнарга килгәндә, аларның тормышы авыррак. Шуларның картиналарын сатып алуны оештыру да Рәссамнар берлеге рәисенең уставта язылмаган бурычы.

**—Безнең Татарстан сынлы сәнгатендә нинди яңалык, үзгәрешләр булуы ихтимал, яшь рәссамнарга нинди теләкләрегез бар?**

— Күп еллар буена безне, рәссамнарны дип әйтүем, төньяк мәдәниятенә, Европа сынлы сәнгатенә йөз тотарга әйдәделәр, аңа гына табынырга чакырдылар. Көнчыгыш мәдәниятеннән читләшә килдек, аны өйрәнмәдек, игътибар итмәдек. Имеш, алар артта калганнар. Бактың исә, без күп нәрсәне белмәгәнбез. Чынлыкта борынгы һәм урта гасырда иҗат ителгән чәчмә әсәрләр, шигърият, Япония һәм Кытай халык гамәли сәнгате бөтендөнья җәүһәрләре исемлегенә кертелгән. Безнең өчен ул гел ак тап булып кала бирде. Ихтимал, моның сәбәбе бездән ерак урнашкан булуы да, чикләрнең ябыклыгы да булгандыр. Ләкин, нәкъ көнчыгыш илләр мәдәнияте һәм сәнгатендә безнең татарларның да тамырларын абайларга була, шунда безнең төсләрне, форма-сурәтне дә табарга була. Шуңа күрә дә яшь рәссамнарның мин игътибарларын Көньяк, шәрык сынлы сәнгатенә юнәлтүләрен, өйрәнүләрен теләр идем. Минә хәзерге көнне шул Көньяк илләре яңа технологияләр, сәнәгать өлкәсендә, гомумән, икътисадта бик нык алга киткәннәр, һәм әлеге күренеш очраклы түгел дип саныйм. Уйлап карагыз әле, бу илләрдә милли мәдәният, милли сәнгать онытылмаган гына түгел, ә бәлки чәчәк ата.

Мәсәлән, безнең эраның башындагы Кытай сынлы сәнгате искиткеч югары дәрәҗәдәге әсәрләре белән дан казанган. Альбомда табигать күренешләре мөкәммәл-камил: бирелә перспектива да, һава перспективасы да, төс һәм күләгә чагылышы да—барысы да бар. Соңрак бөтен галәмдә бернинди яңалык уйлап табылмаган. Ул чордагы табигать күренешләрен рәсемгә төшерүне төрле ил рәссамнары төрле вариантларда кабатлыйлар гына. Кытай рәссамнары перспективаны тоеп кына, интуициягә нигезләнеп кенә кулланганнар һәм күргән тәэсирләрен рәсемдә бирә алганнар. Шуның белән берләттән, күңел кичерешләрен дә тасвирлый алганнар.

Петр I дән соң бездә Азиядәге бөтен нәрсәне дә начар дип кабул итә башлыйлар. Көнчыгыш—Русия өчен «азиатчинага» әйләнә дә куя, артта калган караңгы як исәбендә. Бактың исә, Азия Европага караганда өстенрәк һәм соңгы вакытта ул моны исбатлап килә.

**—Әңгәмәгез өчен рәхмәт. Иҗатыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телим.**

*Яшүсмер чагында Абрекны Суворов училищесына алырга «разнарядка» белән килгәннәр, ул чакта 6 нчы класста уку сәбәпле, алмыйча калдырганнар. Икенче*

*елны Нахимов училищесыннан килгәннәр—бүе тәбәнәк булганга күрә кичектергәннәр. Менә язмыш диген. Абрек Абызгилдин үзен бәхетле дип саный.*

*—Әгәр мин диңгез офицеры булсам, ихтимал, күптән инде берәр океан яки диңгез төбендә балыклар азыгы булыр идем. Әгәренки коры җир армиясе яки очучы офицер булсам, күптән картаеп беткән, чак кына аякларын шуышытырып йөри торган отставник булыр идем,—дип шаярта.—Әлегә мин өлгергәнлек чорына гына кердем,—дип елмая аксакал-оста,—һәм тирә-юньдәгеләргә акыл сатам әле.*

*Мин бу сүзләрдән соң мондый фикергә килдем: Абрек абый адмирал яки генерал булса да, кырыс, гадел һәм уен-көлкене кирәк вакытта куллана торган хәрби белгеч булыр иде. Юмор исә, билгеле булганча, тормышның иң авыр вакытларында да ярдәмгә килә.*

*Әгәренки А. Абызгилдин үз тормышы турында роман язган булса—үтә дә кызыклы, мавыктыргыч һәм маҗаралы әдәби әсәр туган булыр иде. Һәм әлеге китапта шатлык һәм кайгы, мәхәббәт һәм нәфрәт тә, әлбәттә, иҗатка багышланган хиссиятле чын рәссам, олпат шәхескә тиң язмалар урын алыр иде.*

*Урал тауларының бөтен көч-кодрәтен, аның зирәклеген һәм кырыслыгын, иксез-чиксез башкорт далаларының азатлык тойгысын үзенә сеңдергән, башкорт кураеның җаны—йөрәк төпкелләреннән сыкранып-ургылып чыккан, борынгы мәҗүсилек заманыннан килгән моңын, җырларын үзенә сеңдергән ул.*

*Менделеев таблицасындагы барлык матдәләрнең энергиясен үзенә алган Абрек Абызгилдин—татар мохитенә, мәдәниятенә, сынлы сәнгатенә ирек алып килгән һәм яңа эз салган шәхес.*

*Татар милли сынлы сәнгать казанышларын үзләштереп, аның кыйбласын аңлап, ул гомумкешелектән галәмгә омтыла—бүгенге көндә кешелек җәмгыятенә үтә дә кирәкле өлкәгә, чөнки анда яшәүне дәвам итәргә кирәклеге көн кадагына әйләнде. Әлеге фикерне кабатлап, Абрек абый болай диде: «Барысы да рәссамның җаныннан, вөҗданыннан тора. Юлны ул бары тик үзе генә сайлый алачак: галәмгә китәргәме яисә хаҗ кылыргамы». Күрәсең, бу ике юл да бүген дәреслеккә туры киләдер.*

*Абрек абыйның тагын берничә күркәм сыйфатына тукталып узыйк әле. Ул сынлы сәнгатьнең бөтен нечкәлекләрен, тарихын һәм бүгенгесен белә һәм аңлый торган рәссам. Мәскәү, Санкт-Петербург, Идел буе төбәкләрендә яки чит илләрдә зур дәрәҗәле күргәзмәләрне ачу тантаналарындагы чыгышларында ул төгәл, объектив фикерне ярып сала. Һәрбер рәссамның уңышына шатлана, гади кеше күрмәгән үзенчәлеген табып, аны үстереп җибәрә, яки җитешсез якларын күрсәтеп, йомшаклыкларны бетерү өстендә үзенең киңәшләрен бирә. Әлеге очракта ул чын тәрбияче-мөгаллим вазыйфасын да үти.*

*Күптән түгел «Казан» милли мәдәният үзәгендә әлеге оешманың 15 еллыгына багышланган күргәзмә булып узды. Анда Абрек Абызгилдинның бер картинасы игътибарны аеруча үзенә җәлеп итте. Ул «Соңгы солдат» дип атала. Картина өч өлешкә бүленгән шикелле. Як-ягында 12 персонаж: күренекле шәхесләр—Аллалар, дин әһелләре, пәйгамбәрләр, язучылар һәм философлар, кешелекне яклаучылар. Шулар арасында—Будда, Йосыф пәйгамбәр, Кришна, Иоанн Павел IV, Алексий атакай, Равил хәзрәт Гайнетдин, Достоевский, Тереза анакай һәм башкалар. Картинаның урта бер җирендә 13нче персонаж—машина да, танк та уза алмаслык очлы тимердән эшләнгән тоткарлау җайланмасы аша ялан тәпиле, киемсез, ябыгып беткән, күзендә яшәү нуры калмаган, үлү дәрәҗәсендә алҗыган солдат килә. Кием урынына, тәнендә ике иңбашыннан кендеге турысында кисешкән автомат лентасы. Нәзек хәлсез бармак очларында Калашников автоматы чак кына эленеп тора.*

*Рәссам 12 пәйгамбәр белән бергә әйтерсең лә кешелек җәмгыятенә сорау белән ялвара: «Әй, сез, кешеләр, ни эшлисез? Сез бит ахыр чиккә килеп җиттегез! Акылга килегез!» Менә шулай рәссам, борчылып, бөтен дөньяга чаң кага.*

**Расим МӘҺДИЕВ**

Әзһәр
Шакиров

# ЯЗМЫШ ҺӘМ УЗМЫШ

(АРТИСТ ЯЗМАЛАРЫ)

*Җаным татар,*
*Илем урыс—кем соң мин???*
И.Гыйләҗев.

Менә хәзер радиодан Гаяз Исхакыйның "Ул әле өйләнмәгән иде" дигән әсәрен тыңлап утырам. Үзем укыганга күрә түгел. Гаяз Исхакыйның бөеклегенә сокланам. Без әле аңа тиешле бәябезне биргәнебез юк! Ул исемә төшкән саен күңелемне, җанымны борчып торган уйлар, фикерләр йөрәгемә тынгы бирми. Ничә еллар инде урамнарда, мәйданнарда кышкы салкын, көзге яңгыр дими "Азатлык, Азатлык!" дип, тамагым беткәнче җан ачысы белән кычкырып, татар халкын уятырга тырышып йөрдем. Шулай эшләргә мине бәлки заман этәргәндер? Юк, алай гына түгел: Гаяз Исхакый фикерләре минем ошбу дөньяга, үзебезнең тормышыбызга күземне ачты; татар милләтенең язмышын, фаҗигасен, киләчәген бөтен җаным, күңелем, йөрәгем белән шунда аңладым. Нишләп шушындый зур, гайрәтле, көчле, бай булган халык үзенең милли горурлыгын, милли аңын, милли рухын югалткан? Үз язмышы белән көрәшергә көч тапмаган. Ул милләт хакына көрәшергә, җанын, тормышын бирергә әзер торучы ирләр тәрбияләмәгән. Ни кызганыч! "Үз дәүләтең булса иде!"–дигән бөек фикерне әкрен-әкрен генә безнең аңыбызга ана сөте белән каныбызга сеңдермәгәннәр.

Татар баласын:

–Синең бабаларың заманында дөньяны үз кулында тотканнар. Аларның борынгы тамырлары көчле, гайрәтле, дәүләтләре иксез-чиксез булган. Син шуларның баласы. Син халкың өчен, үзеңнең хаклыгың өчен көрәшергә тиешсең дип тәрбияләмәгәннәр.

Бу дөньяда үзеңдә яшәргә, көрәшергә көче барлыгын бүтән халыклар алдында исбат итә алган милләтләр генә яши ала. Халкыбызның, милләтебезнең "Сез болай яшәргә тиеш түгел!" дип күзен ачмаганнар, якты киләчәккә өметен уятмаганнар. Минем өчен татар кешесенең кыйммәте: язучымы, композитормы, артистмы, гомумән, нинди генә эштә эшләмәсен, милләте хакына, аның киләчәге өчен, мин-минлеген җиңеп, иң авыр, иң кадерле, иң бөек эшкә тотынырга кирәк. Без милләтебезне саклап калып, үзебезнең дәүләтебезне торгызырга тиешбез. Менә шул эшкә гомерләрен, язмышларын багышлаган кешеләрне генә мин үземнең идеалым итеп күрәм. Халкыбыз тарих алдында иң зур имтихан тота! Без милләт булып, дәүләт булып яши алабызмы? Әллә безне тарих чүплегеннән генә эзләргә калыр микәнни инде?

*Күпме сүгәм: "куркак", "сатлык", "аумакай",—дип,—*
*Үз кадерен белмәс җебегән.*
*И татарым,*
*татар,*
*татаркаем,*
*Үз кулыңда түгел дилбегәң.*

*Ахыры. Башы журналыбызның 2006 ел, 11 санында.*

*Уф, арыдым инде сине тирги-тирги,*
*Ирек күрмәсмени бу тараф?*
*Яратканга сүгәм...*
*Яратмасам,*
*Яшәр идем мин дә битараф.*

И. Гыйләҗев.

–Сез һаман эшлисезме?—дип сорыйлар миннән

–Әйе, эшлим. Хәзер инде үләргә кирәк,—дип җавап бирәм кайчак.

Фәкать тормышнын гына бәһасе юк. Житәкченен акылы турында аны урап алган ярдәмчеләренә карап хөкем йөртәләр. Йөрәк бүгенге белән яши, акыл исә—киләчәк белән. Шуна күрә "Йөрәк белән акыл тартыша", дип әйтәләр дә бит инде.

Мин дә нәкъ шул хәлдәрәк; акылым әйтә: тукта, барысын да язып бетермә, соныннан үзенә унайсыз булыр, ди.

Шулай да... нишләп безнен татар әдәбиятында Рәсул Гамзатов кебек шагыйрьләр, Чынгыз Айтматов кебек язучылар сугыштан сон үсеп чыкмады? Мин бу сорауны бирә алам, җавабын гына таба алмыйм. Әллә, мин әйтәм, без–татарлар, дип әйтергә шул кадәр дә курыкканбызмы? Безнен жаннарыбызны суырып алганнар, күрәсен. Шәүләбез генә калган. Җансыз шагыйрь бөек була алмый, язучы турында әйткән дә юк. Милли аннын түбән булуы, кешенен кол хәлендә яшәргә шул хәтле күнегүе минем жанымны тетрәндерә. Нәкъ шушы нәрсә йөрәгемне ашый. Әгәр милләт болай яшәсә, татар халкына кадерле, чын талантлар туарга жирлек калмый.

*Туу дөрес җирдә, үлем дөрес,*
*Ә калганы тоташ сафсата.*

И.Гыйләҗев.

Татар музыкасы турында шуны гына әйтә алам: безнен музыканы, безнен бөек монны урыслар: "Сезнен музыкагыз юк, сезнен музыканы без дә, Европа да кабул итми, анламый. Шуна күрә сез руслардан үрнәк алып эшләгез",–дип, безнен композиторларыбызны бик нык "өйрәттеләр". Безнекеләр хәтта милли моннарны кулланырга ояла башладылар. Чөнки урысларга ияреп, бөек буласылары килде. Урыслар өчен Япон, Кытай, Һиндстан халыкларынын да бөек музыкасы юк! Юк инде, урыслар, Европа кабул итмәгән өчен генә, бу бөек халыкнын музыкасы юк, дип әйтеп булмый. Музыкаль аннары, белемнәре үсәр, акренләп күнегерләр, анлый башларлар. Үзләре безне шулай күнектерделәр бит. Әле урыс дәүләте булмаганда, Кытайда опера һәм балет театры моннан мен еллар элек үк булган, 800 еллар әүвәл японнар үз музыкаль театры белән хозурланган. Без надан булганга ул халыклар гаепле түгел. Американын бөек музыкасы каян килеп чыккан дисез? Африкадан коллар, нигерлар алып килгән. Үзләренен ирекле яшәргә теләвен алар музыкалары, җырлары, биюләре белән расларга тырышканнар. Татарнын бөтен дөньяны тетрәндергеч моны әле үз ачышын көтә. Салих Сәйдәшев башлаган юл авыррак, ләкин милләтнен бөеклеген ачарга фәкать шул юллан гына барырга тырышу кирәк. Татар музыкасын, урысларга ошарга тырышып язып, барыбер яһүди халкын уза алмыйсын. Алар урыс музыкасын аларнын үзләренә караганда да яхшырак яза. Безгә халкыбызнын урыс коллыгын жинеп чыккан, рухи көчен күрсәтерлек татар моны, татар музыкасы кирәк. Без әле генә күзебезне ачып, тирә-ягыбызга карый башладык. Дөньяга танылган композиторлар, үз милләтләренен даһилары—алар үз халкынын милли көйләрен язган, шуна күрә кадерле дә. Мин дөнья музыкасын белмәгез, өйрәнмәгез дип әйтмим. Сүз дә юк, әгәр үзенне дөньяга танытасын килсә, барсын да белергә, өйрәнергә кирәк. Әмма үзеннен бөек татар монын югалтмыйча. Милләтнен йөзен әдәбият, сәнгать билгели. Әгәр урыснын әдәбияты, сәнгате булмаса, ул бөек милләт булып калыр илеме?

*Эчем тулы каргыш, үпкә белән*
*Китам инде җирнен өстеннән.*

*Мескен әни юкка гына мине*
*Күз нурларын түгеп үстергән.*
*Юкка гына күкрәк сөтен имезеп,*
*Бишек җыры җырлап тибрәткән.*
*Дөньясына нәфрәт, каргыш булып*
*Чыкты ул җыр минем йөрәктән.*

М. Җәлил.

Көнелемдә калган бер хатирәне искә төшерәсем килә. Ул–минем хажга баруым. Нәрсә дип әйтсәм дә, хаж минем тормышымда иң кадерле вакыйгаларның берсе булды. Мин Мөхәммәд галәйһе-әс-сәлам пәйгамбәрнең бөеклегенә ышандым. Дөньяның 125 иленнән Мәккә шәһәренә килеп, миллионлаган адәм балаларының хаж кылуы—бу бит үзе әйтеп бетергесез бер могҗиза. Әгәр Мөхәммәд галәйһе-әс-сәлам исән булып, шушы халне күрсә, үзе дә шаккатыр иде. Кирәк бит, моннан мең дүрт йөз еллар элек нинди бөек, мәңгелек фикерләрне, Ходай Тәгаләнең бар һәм бер булуын ачкан. Син нинди халыктан, милләттән булуыңа карамастан, Аллаһы Тәгалә каршында бөтенең дә бертигез. Бу ни дигән сүз? Дөньядагы барча милләтләр бертуганнар, чөнки Аллаһы Тәгалә барыбыз өчен дә фәкать бер генә. Моның мисалы Мәккә шәһәренә хаж кылырга килгәч, аермачык күренә. Кешеләргә шул кадәр хөрмәт, итагатьлек белән бертуганың итеп карыйсың. Монда һәммә адәмиләр–ярлымы син, баймы—бертигез. Мона ирешү—кешелек дөньясының мәңгелек хыялы. Хажга баргач, шушы хыял тормышка аша. Мөхәммәд галәйһе-әс-сәлам шундый ачышлар ясый ки, мең еллар узгач кына аның дөреслеген исбат итәләр. Әйтик, Җир шары тузан бөртеге хәтле генә, Галәм иксез-чиксез, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте кин. Ул нәрсә теләсә–шул булыр. Нинди бөек фикер. Моның шулай икәнлеген XX гасырда гына раслый, дәлилли башладылар. Чыннан да, Галәмнең очы-кырые юк икән. Раббыбызның кодрәте дә тинсез икәне үзеннән-үзе аңлашыла. Һәммәбезне Аллаһы Тәгалә яраткан. Телибезме-теләмибезме, Мөхәммәд галәйһе-әс-сәлам соңгы пәйгамбәр булгач, шул замандагы диннәр тәгълиматын ул нык үзләштергән, барчасының мәгънәсен, тирәнлеген аңлаган. Шуңа күрә үзеннән алда килгән пәйгамбәрләргә бик зур хөрмәт белән карап, кадерләп, һәрберсенең үз урынын билгеләгән. Безгә якын булган һәммә пәйгамбәрләрнең бөеклеген аңлатып, Ислам диненең кешелек дөньясына күзен ачарга ярдәм итүче Коръән-Кәримнән без кешелекнең яшәешенә, яктылыкка юл табарбыз. Мин үзем, Ислам динен яхшы белмәгәнемә күрә, бәлки ялгышамдыр да. Ләкин Ислам дине һәрбер дәвердә бөек ачышлар ясарга ярдәм иткән. Гарәби халыкларны юкка чыгудан саклап калган. Алай гына да түгел, нинди бөек, көчле дәүләт төзергә ярдәм иткән.

Хәер, безнең татар милләтебезне дә Ислам дине үз вакытында саклап килгән. Ул булмаса, без күптән урыска әйләнеп, үз телебезне, гореф-гадәтләребезне, яшәү рәвешебезне юкка чыгарып бетереп, татар дигән бөек милләтнең исеме дә калмас иде. Болай да татар халкының яртысыннан күбесе урыслашып беткән инде. Чөнки XX гасырда безнең динебезне дә, телебезне дә юк итәргә тырыштылар. Үз динен тоткан милләт тиз генә юкка чыкмый, аның әле киләчәге бар. Әнә яһүдиләр ике мең еллан соң XX гасырда дәүләтләрен төзеделәр, ә без исә юкка чыгу алдында торып калдык.

Миннән гел сорыйлар: "Нишләп Ислам динендәге дәүләтләр үзләренең үсешендә христиан динендәге дәүләтләрдән артта калганнар?"–дип. Монда сүз тәрәккыять турында гына барырга мөмкин. Аның сәбәпләре бик күп. Шуңа күрә һәммә мәсьәләне Ислам диненә генә кайтарып калдырырга кирәкми. Шулай да, вакытлар узу белән, Ислам диненең үсешендә бераз тоткарлану сизелә. Шуны аңлаган кешеләр җәдитчеләр булып китәләр, ягъни Ислам дине бүгенге көн таләпләренә җавап бирергә тиеш. Дөнья үсешенә, дәвамына, Адәмнең яшәешенә без Ислам динендә ачык, дөрес, тирән мәгънәле җаваплар табарга бурычлыбыздыр. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте чиксез дип әйтәбез икән, без бит адәм баласына Ходай Тәгалә биргән бөек акылның, көчнең, кодрәтнең дә чиксезлеген раслыйбыз. Бер сүз белән әйткәндә, Аллаһы Тәгалә адәм баласына

даһилык биргән, монын ин бөек мисалы—Мөхәммәд пәйгамбәр. Безнен татарларда заманында музыканың, рәсем сәнгатенен, жырның, театрның үсеп чыкмавы, тоткарлануы күп очракта дин аркасында. Хәзрәтебез Шиһабетдин Мәржани беренче мәртәбә фотосурәткә төшә, беренче мәртәбә, музыканы тынлау Аллаһы Тәгаләгә каршы килми дип, безнен күзләребезне ача. Бу ни дигән сүз? Дөньядагы бөтен ачышлар да Аллаһы Тәгалә ризалыгы белән адәмнәр тарафыннан эшләнә. Шулай булгач, без үзебезгә ин кирәген, ин файдалысын, яхшылыкка өндәгәнен сайлап ала белергә тиешбез. Әйткәнемчә, мөселманнар заманабызнын ин укымышлы, ин тәрбияле, үзләренен яшәү рәвешен бөтен дөньяга оялмыйча тәкъдим итәрлек дәрәҗәдә булырга тиешләр. Бер сүз белән әйткәндә, менә ислам динендәге кешеләр ничек яшиләр бит дип, дөнья халыклары горурлансын, үрнәк алсын. Аеруча без татарларга бүгенге көндә ислам дине милләтебезне берләштерергә, телебезне, гореф-гадәтләребезне саклап калырга ярдәм итүче бөек көч булсын. Казан ханлыгы җимерелгәч, Аллаһы Тәгалә вә Сөбханә халкыбызга үзен сакларга көч биргән. Иншалла, без бүген дә үзебезгә төшкән авырлыкны сабырлык, бердәмлек белән җинәргә тырышырбыз.

*Кергән чакта гомерләрнең көзләренә,*
*Көзге җилләр үткән чакта үзәгенә,*
*Колак салып газиз әткәй сүзләренә,*
*Бер багасы килә әнкәй күзләренә.*

*Г. Мөхәммәтшин.*

Мин тормышта көнче, хөсетле кеше булмадым. Бәлки мин үземне артык югары куеп, эшкә бик житди караганмындыр. Күнелемдә, йөрәгемдә иптәшләремнен эшләренә яктылыгым, риясызлыгым бар иде. Мин хәзерге әдәбиятыбызда, шигърияттә, драмада Ислам динен кабул иткән кешенен дөньяны үзгәртүен, халкы, милләте, азатлык өчен үзенен тормышын корбан итү дәрәҗәсенә күтәрелгән, күнелебездә яшәргә, көрәшергә өмет нуры уяткан чын татар улларын күрмәдем. Сүз йөз меннәрчә татар балаларынын тиндәшсез батырлыгы, үзләренен жанын, канын урыс дәүләтен саклап калу өчен бирүләре турында бармый. Сүз үз милләте, үз дәүләте хакына корбан булган, шәһит киткән татар балалары турында бара. Кая сон ул дәүләтебезнен, Казаннын җимерелүе, менләгән милләттәшләребезнен тере килеш яндырылуы турында жанны тетрәндергеч бөек драма? Халык шундый спектакльне карап, үзенә гомерлек сабак алсын иде. Яисә татарларнын оятсызлыгы—балалы хатын-кызны, дәүләтнен ханбикәсе Сөембикәне Явыз Иванга коллыкка бирү. Мондый хәлнен бер халыкта да булганы юктыр, булса да,–бик сирәк. Сез: ул үз иле, дәүләте, халкы хакына үзен-үзе корбан иткән, дип әйтерсез. Чын ирләр хатын-кызны андый хәлгә калдырмый, шундый дәрәжәгә төшерми. Мондый гамәлнен фәкать бездә генә булуы мөмкин. Монын өчен безгә Ходай Тәгаләнен каргышы төшкән дә инде. Сөембикә турында бар дөньяны елатырлык искиткеч бөек трагедия язып булыр иде. Хәзер бит язарга мөмкинлекләр бар, ирек бирделәр—яз гына. Яки бүген татар кешесендә милли анның уянуы турында татарларны тетрәндерерлек, йокысыннан уятырлык публицистик драма кайда? Кайда сон алар? Әле мин берничәсен генә санадым. Бөек тарихыбызга күз салсак, гаҗәеп язмышлар бар бит. Шуларны күрсәтә алсак, халкыбыз гомерлек сабак алыр иде. Юк бит, юк талантлы драматург! Шуларны язарга акыл да, көч тә житми. Бик кызганыч!

*Табарлар безнең эзләрне,*
*Әйтерләр хәйран калып:*
*—Үзе үстергән еланнан*
*Чагылып үлгән халык...*

*М. Галиев.*

Минем бик күп шагыйрьләр, язучылар, галимнәр авызыннан шуны ишеткәнем бар: аларнын күбесе артист булырга хыялланган. Күрәсен, һәрбер сәләтле

кешедә артистлык "жене" утыра торгандыр. Ягъни кешеләрне үзенә җәлеп итеп, сәләтен күрсәтү теләге. Тормышта моңа бик сирәк кеше генә ирешә шул. Артист ул йә бар, йә юк. Без–сәхнәдә чакта гына тамашачының иң яраткан, хөрмәт иткән, горурланган кешесе. Әгәр сәхнәдә күренмәсәк, безне бик тиз оныталар, без югалабыз. Без әллә бар, әллә юк. Гомеребез ахырында безне шундый фаҗига көтә. Кайвакыт сорыйлар: "Әле ул һаман исәнмени?" Шагыйрь, язучы турында андый сорау бирү мөмкин түгел, чөнки алар үзләреннән гүзәл әсәрләре белән һәрвакыт безнең күңелебездә торалар, яшиләр. Әгәр телисең икән, рәхәтләнеп укый да аласың. Артистның сәхнә гомере алай озын булмый шул.

Шулай да безнең эшебезнең бер яхшы ягы бар: тамашачы сине карый, үз бәясен бирә. Әгәр ошатса, рәхмәт хисләрен җәлләми инде. Артист өчен моннан да зур бәхет юк. Чөнки сине талантлы кеше дип кабул итәләр. Әлеге дә баягы "талантлы" дигән сүзне ишетү өчен шигырьләр, музыка, романнар языла, рәсемнәр ясала. Кеше бит бер-берсеннән шул таланты белән генә аерыла, калганы барысы да—уртак. Безгә чын күңелдән:

–Афәрин, булдырдыгыз!–дип, рәхмәт әйтеп кул чапсалар, шул җиткән, без шуннан артыгына мохтаҗ түгелбез. Артист сәхнәдә яхшы уйнап чыкса, үзе дә зур ләззәт ала. Моны бернәрсә белән дә алыштырырлык түгел. Синең җаның, күңелең тынычлана, тагын да яхшырак итеп уйныйсың килә. Бу тойгыны сүз белән аңлатуы кыен.

Шуңа күрә мескен артистларның сәхнәдән бер дә китәселәре килми (гомер буе уйнарлар иде). Ләкин язмыштан узмыш юк бит ул.

Инде ошбу язмаларымны шушының белән төгәллисем килә:

*Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә,*
*Дәшми калмам Газраилне күргәндә дә:*
*"Без китәбез, сез каласыз" дип җырлармын*
*Җәсәдемне туфрак берлә күмгәндә дә.*

Г. Тукай.

Тормыш барыбер кире кайтмый: үкен, үл син, ела. Ходай сиңа нинди язмыш биргән булса, шуның белән тормышыңны тәмамлыйсың инде.

Чыннан да, дөньяда талантлы кешеләр сирәк туа. Шуңа күрә аларны күреп алу, вакытында үсеп китәргә ярдәм итү—бу безнең иң изге бурычыбыздыр.

Мине күрмәделәр, үстермәделәр, ярдәм итмәделәр, дип әйтә алмыйм. Алай әйтсәм, мине Аллаһы Тәгалә каргар. Миңа бөтен кеше ярдәм кулын сузды. Шуңа күрә үз көчемә ышандым да инде. Безнең эштә бу—иң кирәк нәрсә. Тамашачылар минем җанымны, йөрәгемне тынычландырырга тырышып, дистәләгән хатлар, шигырьләр язып, язмышымны бәхетсезлектән саклап калган өчен аларга мәңге рәхмәтлемен. Шуларны төннәр буе җылый-җылый укып, эшләргә, ничек булса да эшләргә дип үз-үземә сүз бирә идем. Минем бит исемем дә–Җылак артист! Адәмнәрнең бәхетсез язмышын уйнарга, безне елатырга тугансың син дип, күңелемә якты нурлар сибәләр иде. Гомерем буе үз-үземә җан тынычлыгы таба алмыйча, үз-үземне кая куярга белмичә, яраланган кош кебек җәфаландым. Чөнки минем характерым шундый катлаулы, каршылыклы, эчемдә гел үз-үзем белән көрәш бара. Мине җәфалаган, гомеремне кыскарта торган уйлар, хыяллар, сәхнәдә беразга онытылып торалар иде. Әлбәттә, минем хыялларым тормышка ашмады, ә миңа кайбер теләкләрем кабул булды. Монысы өчен үзем белән бергә эшләгән иптәшләремә, хатыным Сажидәгә, Ходай Тәгаләгә рәхмәтлемен.

*Юк, коявым, мин беләм: син батмагансың мәңгегә,*
*Син, вөҗдан, бер торырсың: ятмагансың мәңгегә.*

Г. Тукай.

**P.S.** Аллага шөкер, барысын да язып бетермәдем, Ходай Тәгалә "җитте" дип туктатты.

Адлер
Тимергалин

# МИЛЛИЯТ СҮЗЛЕГЕ

***ТҮГӘРӘК ӨЙ*** – Борынгы киез тирмә турында шулай дигәннәр. "Түгәрәк өйнең түре юк" дигән мәкаль дә булган. Нәкый Исәнбәт: "Бүген дә кунак кабул иткәндә, өй кечкенә булса, кунак кайсы яктан утырса да түр урын була, дигән мәгънәдә һәркайда әйтелә" дип өсти. Бүгенге "түгәрәк өстәлләр"дә катнашучыларның тигез хокуклы булуын күрсәтү өчен оештырыла.

***ТЫЛМАЧ*** – Гомумтөрки сүз. Мәгънәсе–тәрҗемәче, тәрҗеман. Угыз телендә–*дилмәч*, башкортта–*телмәр*. "Тылмач" сүзенең килеп чыгышын "аңлаткан" бер версияне халык этимологиясенә үрнәк итеп китерергә була. "Татар ханлыклары чорында рус, Литва, Польша шикелле кенәзлекләрдә татар илчеләре белән аңлашу өчен тәрҗемәчеләр тотканнар. Ханнан килгән илче кенәзгә сүзен әйткәч, янындагы тәрҗемәчегә "телем ач!" дип, үз әйткәнен тәрҗемә итеп бирергә кушуыннан тылмач сүзе ясалган." (Нәкый Исәнбәттән.)

Әйе, "тылмач" сүзе "толмач" формасында рус теленә дә кергән. Ләкин XVIII гасыр юридик документларында "тәрҗемәче" ("переводчик") һәм "тылмач" ("толмач") терминнары мәгънә ягыннан аерыла. Мәс., 1770 елда Уфа провинциясе канцеляриясенә коллежский регистратор дәрәҗәсендә елына 80 сум хезмәт хакы белән бер тәрҗемәче (переводчик) һәм елга 25 сум хезмәт хакы белән өч тылмач билгеләнгән. Тылмачлар сөйләшүләр вакытында телдән тәрҗемә итсәләр, тәрҗемәчеләр исә язма текстларны тәрҗемә кылганнар. "Тылмач" сүзе шушы мәгънәсендә немец теленә дә кергән, венгр теленә дә алынган.

Рус патшаларының грамоталарын татар теленә Мәскәүдәге Илчелек приказында эшләүче татарлар тәрҗемә иткән. Алар гадәттә Касыйм, Темников (Төмән) һәм Романов өязе татарлары булган. 1689 елда илчелек приказы штатында исәпләнгән татарчадан тәрҗемә итүче тылмачлардан Кочекәй Сакаевны, Сөләйман Толкачиевны, Петр Татариновны, Рәҗәп Байцынны, Тахтарали Багининны күрсәтергә мөмкин (Ф.М.Хисамованың "XVII-XVIII гасырларда татар телендәге грамоталар" дигән мәкаләсе буенча). Аларның күбесенең аталары, хәтта бабалары да тәрҗемәче-тылмач булып эшләгәннәр. Мәс., Рәҗәп Абдул улы Байцынның бабасы Билал Бөзәргәнов та рус патшаларына тылмач булып хезмәт иткән, өч тапкыр Кырымга илчелек белән җибәрелгән, Кырым ханы Сәлимгәрәй белән шартнамә төзегән, аннары Персиядә ("Персида"да) булып кайткан. Рәҗәп Байцынның әтисе Абдул да илчелек приказында исәпләнгән, Кырымда 5 тапкыр булган, Кырым ханы Нурадинга грамоталар белән барган. Ә Сөләйман морза Сәгый улы Тонкачиевның Касыйм, Кадом һәм Зөя (Свияжск) өязләрендә бабасы һәм атасы хезмәт итеп тапкан борынгы биләмәләре булган. Кадерали Сакаев та агасы Кочекәй Сакаев белән бергә Персидага барып кайткан, илчелектәге кошчы Игнат Большой юлда үлеп калгач, аның урынына кошчы итеп Кадералины билгеләгәннәр. 1723 елда Петр патша әмере буенча Казан татарларыннан 23 кешене Иранга (хәзерге Әзәрбайҗанга) тылмач итеп җибәргәннәр (Татар әдәбияты тарихы, I том, 1984).

Тылмач булып эшләүчеләр арасында тарихыбызда эз калдырган шәхесләр дә аз түгел. Мәс., күренекле галим һәм педагог Хәлфин Сәгыйть Хәсән улы Казанда алмиралтия конторасында тылмач булган. Болгар кабер ташларындагы язуларны русчага

*Дәвамы. Сүзлек журналыбызның 2004 елның 1нче саныннан басылып килә.*

тылмач Йосыф Ишбулатов һәм Сүнчәләев Кадермөхәммәд тәрҗемә иткәннәр (1722). Шәрыкка сәяхәт итүе белән мәшһүр Гобәйдулла Әмиров та Оренбург чик буе комиссиясендә тылмач булган. Мәхмүтов Идеркәй–Емельян Пугачевның тылмачы. Мәгърифәтче, рәссам һәм нашир Әмирханов Рәхмәтулла Казанның татар ратушасында тылмач булып торган. Бикчурин Мирсалих Мирсәлим улы 1865-73 елларда рус армиясенең Урта Азиягә походларында тылмач сыйфатында катнаша. Тылмач Бикчурин Миндиярның (1740-1821) коллежский советник дәрәҗәсенә тикле күтәрелгәнлеге мәгълүм. Бу исемлекне әле тагын дәвам итеп булыр иде.

Татар телендә тылмачлык мәгънәсендә *аударлык* сүзе дә кулланылган.

Тагын кара: ***ТЕЛМӘРЧЕ.***

***ТУФӘК*** *тар.* – Утлы корал, кечкенә туп. Төрекләр исә мылтыкны түфәк диләр. Көпшәсе 1 м чамасы озынлыкта булган, таш ядрәләр белән аткан. 1376 елда болгарлар Болгар шәһәрен саклаганда рус гаскәренә каршы түфәк кулланганнар. Атама *тюфяк* формасында рус теленә дә кергән.

Чаг.: ***ТУФӘНГ.***

***ТҮШӘКЧЕ*** *бор.төр.* – Хан, патша сарайларында хакимгә ятак хәзерләүче, урын-җир, ястык түшәүче кеше. Рус телендә–*постельничий* (бу сүзнең дә тамырында "түшәү" мәгънәсе бар.)

***ТЫЛСЫМ*** *г.* – Сихер. "Тылсым" сүзе уңай мәгънәгә ия. Русча *талисман* сүзе дә шушы сүздән килеп чыккан (хәер, кайбер чыганакларда бу сүз рус теленә грекча *telesma*– "багышлау", "сихер" сүзеннән алынган дигән фикер дә очрый). Күплек саны шәкеле–*тәләсим*.

***ТЫЛТЫК*** – Себер татарлары *л, р* авазларын әйтә алмый торган сакау кешене *тылтык* диләр. Аларда бу сүзнең төп мәгънәсе–*бүдәнә, бытбылдык*.

***ТЫН*** – "Инҗил"нең татарчага тәрҗемәсендә "рух" ("дух", "пневма") мәгънәсендә алына. //*Әйтүчеләр сез булмассыз, әмма Атагызның Тыны сезнең эчегездә әйтеп торыр* (Матфей, 10:20). *Исус җавап биргән: "Чын, чын сиңа әйтәмен: кем дә кем судан, Тыннан тумаса, Алла Патшалыгына керә алмас. Тәннән туган үзе дә тән, әмма Тыннан туган үзе дә тын"* (Иоанн, 3:5-7).

***УБАЛ*** *иск.* – Гөнаһ, язык. //*Убалын кая куярсың?* ("Идегәй" дастаны.)

***УВЫК*** *бор.* – Киез өйнең сырт кабыргаларын һәм түбәсен күтәргән агачлар.

***УГЫЛ*** – Ата-ананың ир затындагы баласы, ул, вәләд. *Олан / оглан / углан* сүзе дә шул тамырдан. *Увыл* (әле канатланмаган умарта корты) һәм *уылдык* сүзләре дә "угыл"га кардәш тиешле. "Улан" сүзе рус теленә дә кергән ("атлы гаскәри", "атлы гвардин" мәгънәсендә). Ләкин Р.Әхмәтьянов бу сүз рус теленә төрек теленнән француз һәм немец телләре аркылы гына кергән дип исәпли.

***УК*** *тар.* – Җәядән атылып чыга торган кечкенә "сөңгечек", сугыш һәм ау коралы. Төркиләр кул белән ыргытыла торган укларны *җыба* (*чыда, чида, җида*–дротик, кыска сөңге) дип атаганнар. Ук йомры һәм төз агач сабактан, корыч очлыктан яки башактан (борынгы чорда аны чакматаштан (ихтимал, *каш* дигән каты таштан–нефриттан) яки сөяктән ясаганнар, соңрак тимердән ясалганнары, М.Кашгарыйда теркәлгәнчә, *тимеркән* дип аталган) һәм туры очсын өчен койрык итеп куелган каурыйлардан гыйбарәт. Сабакның нәкъ төбендә җәя керешенә кую өчен уем эшләнгән була. Укның койрыгы *куз* дип аталган. Электә укларның *сызгыра торганнары*, семәксез яки башаксызлары (*калва*), тупак башаклылары (*тумар, томар*–җәнлек тиресен бозмас өчен тупыйк сөяк *томарчыклы* мондый уклардан руслар да файдалана башлаган, алар аны, татардан күчереп, *томар* яки *томарка* дип атаганнар), төз колаклылары (*аткы, аткыйоч, сәрпи ук*–тигез колаклы, ерактан ала торган уклар), еракка ату өчен озын һәм җиңел ук-

*чурам угы, утлы ук (шәрәшир), агулы ук* (Ибне Фазлан болгарларның шундый ук белән ниндидер "борынмөгезләрне" аулавы турында яза) һ.б. төрләре булган. Сугышчылар укларын махсус савытларда–*калчаннарда, сагайдакларда* йөрткәннәр яки күнитек кунычына кыстыра торган булганнар. Монгол сугышчысының ике яки өч җәясе һәм уклар тутырылган өч зур калчаны булган. Ук очларын ике яктан да үткенләп тору өчен алар калчаннарында һәрвакыт игәү йөрткәннәр.

Борынгы Кытай язма истәлекләрендә төньяктагы ниндидер Илэу иле халкының кара тузлы каен агачыннан озын уклар ясарга оста булуы, бу укларга куелган таш очлыкның тимерне дә тишүе турында әйтелә. Бик ихтимал, бу таш нефрит (каш) булгандыр.

Укка нисбәтле бер табышмак аның турында шактый мәгълүмат бирә. Түбәндә шул табышмакны Нәкый Исәнбәт аңлатмасы белән китерәбез.

"Яртысының яртысы–каен агач яртысы; Яртысының яртысы–Туң тимернең яртысы; Яртысының яртысы–Очкан кошның яртысы." Каенның яртысының яртысы-юнып ясалган агачы, очар кошның яртысы–укның койрыгына куелган кош каурые (юнәлткече). *Туң тимер* дигәне, ихтимал, каты тимер, ягъни чыныктырылган (туңдырылган) корыч булыр (соңгы фикер минеке-*А.Т.*). Плано Карпини монголларның ук очларын утта кыздырганнан соң тозлы суга тыгып чыныктырулары турында яза.

"Ул нидеркем, өч канат белән очар, Томшыгы корыч икәндер, таш печәр" дигән табышмакның да җавабы–ук. Өч канатлы дигәнне өч каурыйлы дип аңларга кирәк. Бу каурыйлар ук сабагының арткы өлешенә бер-берсенә карата 120 градуслы почмак ясап урнашкан булганнар.

Каюм Насыйри туплап бастырган табышмакларның берсендә ук түбәндәгечә тасвирлана: "Ул нидеркем башы айырык, төге бар, башы өстендә ак тимердән бүрке бар, Хак Тәгаләдән фәрман килсә, җан алырга ирке бар."

Борынгы төркиләр ук-җәя ясаучы осталарны *ук-җаяче* дип атаганнар. Ук ясау осталары борынгы Гарәбстанда да булган. Мәс., сөнни юнәлешендәге маликиләр мәзһәбен нигезләүче, *"нәҗмел-эиммә"*, ягъни имамнарның йолдызы ләкабен алган Малик бине Әнәс (713/92-795/179) Мәдинә шәһәрендә ук ясаучы оста гаиләсендә туган.

*//Ук ату һөнәре.*

***УК АТЫМЫ*** *тар.* – Җәядән аткан ук очып уза торган ара–0,6 чакрым. Электә үзенә бер төрле ераклык үлчәү берәмлеге булып хезмәт иткән. Тажетдин Ялчыголның "Рисаләи Газизә" китабында *"ике йәйә откасы микъдары"* төшенчәсе ике ук атымы кадәр ара мәгънәсендә кулланыла. *Җәя буе* (җир, ара) сүзе дә ук атымы кадәр араны белдерә. Әдәбиятта *ике очым ук* гыйбарәсе дә очрый.

***УКАЗЛЫ МУЛЛА*** – Имамлыкка имтихан тотып, мөфтиаттә шәһадәтнамә алган зат–*мәнширле мулла*. *"Указлы мөәззин"* төшенчәсе дә булган.

***УКУЛЬКА*** *тар.* – Сугышка керер алдыннан яугирләргә өләшенә торган бүләк. Мәс., 1395 елда Аксак Тимер Туктамыш ханга каршы яу белән чыгу турында әмер бирә һәм яубашларына зур бүләкләр өләшә.

Бу термин өчен уңайлы татарча язылыш табарга кирәк.

***УЛУС, ОЛЫС/ОЛУС*** *тар.* – Бу сүзне Р.Фәхреддин *өлеш* мәгънәсендә дип аңлата. Р.Әхмәтьянов аның борынгы *ус*-кабилә сүзе нигезендә ясалганлыгын әйтеп, *улу ус-олы ус-улус* чылбырын күрсәтә. Аныңча, улус–кабиләләр союзы, федерация.

Монгол ханнарының нәсел биләмәләрен дә "улус" дигәннәр. Мәгънәсе ягыннан бу сүз мәгълүм дәрәҗәдә рус телендәге *волость* сүзенә дә туры килә.

Тагын кара: ***ОЛЫС.***

***УНИКЕ БӘХЕТ*** – Бирмалыларда *"уникe бәдәни ләззәт"*–яшь һәм таза организмга хас булган физиологик рәхәтлек тойгылары: 1) аппетит, 2) ризыкның тәмен белеп ашау, 3) сусынны басып ләззәт алу, 4) хуш истән ләззәтләнү, 5) ләззәтләнеп

тыңлау, 6) гүзәллек күреп соклану, 7) капшап-тотып караганда шатлану, 8) хәрәкәт иткәндә шатлану, 9) мускулларның сыгылмалылыгы, 10) аяк-кулларның көчен тою, 11) ирлек куәтен тою, 12) мәхәббәт дәртеннән ләззәт табу.

***УНЧЫЛАР*** – XX гасыр башларында татар телендә сузык авазлар барысы унау һәм аларның һәркайсы аерым хәреф белән билгеләнергә тиеш дип санаган юнәлеш. Бу фикерне беренче тапкыр Каюм Насыйри үзенең "Әнмүзәҗ" исемле хезмәтендә күтәрә, ләкин татар фонетикасында бу ачышын куллана алмый. Совет хакимияте елларында бу фикер кабат ныклап күтәрелә һәм нигездә тормышка ашырыла. Күренекле унчылардан Әхмәтһади Максудины, Гыймад Нугайбәкне, Гыйбад Алпаровны, Хуҗа Бәдигыйны, Мөхетдин Корбангалиевләрне күрсәтергә мөмкин. Унчыларга "алтычылар", ягъни татар телендә мөстәкыйль сузыклар саны алтау гына дип баручы юнәлеш (Әхмәтҗан Мостафа һәм аның тарафдарлары) белән көрәшергә туры килгән, хәтта баштарак соңгылары өстен дә чыкканнар. Тагы шунысы кызык, галимнәрдән Г.Шәрәф башта ун мәд (сузык) тарафдары булса да, соңыннан бу фикереннән чигенә, алтычылар сафына баса, әмма ахырда барыбер ун сузык аваз булуын танырга мәҗбүр була.

***УҢ һӘМ СУЛ*** – Уң як, уң кул халыкта уңай мәгънәгә ия. Гомумән, сулагайларга сәерсенеп карыйлар һәм монда ниндидер эчкәрге биологик һәм психологик сәбәпләр дә бар сыман. Күп кенә эш-гамәлләрдә уң якка өстенлек бирелә.

Тәваф кылу өчен хаҗи әл-Мәсҗид әл-Хәрамгә "Тынычлык капкасы" аша уң аяктан керергә тиеш. Тәһарәтханәгә кергәндә сул аяк белән атлап керергә, чыкканда исә уң аяк белән атлап чыгарга кирәк дигән кагыйдә бар. "Хаккат" сүрәсенә (69) караганда, Кыямәт көнендә гамәл дәфтәре уң кулына бирелгән кеше: "Ий, җәмагать, килегез минем гамәл дәфтәремне укыгыз, мин, әлбәттә, дөньяда белдем бүген хисабка юлыгачагымны"-дияр, ягъни куаныр. "Әмма гамәл дәфтәре сул кулына бирелгән кеше әйтер: "Ий, кашки миңа гамәл дәфтәрем бирелмәгән булсачы! Хисабымның нинди икәнен белмәгән булсамчы!"-ди, ягъни җәһәннәм утыннан куркып кайгыга кала." Гомумән, адәмнәр уң кулларын биреп күрешәләр, кәефсез яки усал кыланган кеше турында "сул аягы белән торган" диләр.

***УР*** *тар.* – Электә шәһәрләрне саклау өчен аның тирәли казылган чокырларны яки, киресенчә, балчык өемнәрен "ур" дип атаганнар. Гарәпчәсе–*әсвар*. Русчада очрый торган *Перекоп* атамасы да төрки *ор (ур)* терминының тәрҗемәсеннән гыйбарәт. Р.Фәхреддиннең Кирилл хуруфатына күчерелгән бер хезмәтендә "үр" язылышы алынган. //*Мин үзем "Бөгелмә" берлә "Чистай" шәһәрләре арасында булган "үр"ләр берлә шәех Шамил рәсемене күргән вакытларымда әсәрләнәм, фикер дәрьясына гарык булам.* Р.Фәхреддин.

Тагын кара: ***ӨЕК.***

***УРА КЫЧКЫРУ*** – Бу сүз рус теленә төрки телләрдән (татарлардан) кергән дигән фикер яшь ("*уран*–ярсулы кычкыру, һөҗүмгә чакыру"). Р.Әхмәтьянов: "*Ура!* сүзе татарча ура (окружай) сүзеннән дигән фикер дә игътибарга лаек (төркиләрнең төп тактикасы–дошманны урау була)",–дип яза. Ләкин аны монгол-татарларның "хура"– "алга!" сүзе белән аңлату акылга муафикъ. Шуны да әйтергә кирәк, М.Фасмер үзенең "Этимологический словарь русского языка" сүзлегендә "ура!" сүзен немец телендәге "hurra"дан чыгара. Һәрхәлдә "русское ура!" дип, аерым сүзгә хуҗа булуны берничек тә аклап булмый.

***УРАМ*** – Шәһәр-авылларда гадәттә ике яклап тезелеп киткән йортлар арасындагы ачыклык, юл. "*Урау*" сүзеннән килеп чыккан дип уйланыла, ягъни "урам" сүзенең мәгънәсенә караганда, электә урамнар ниндидер бер үзәк тирәсен әйләндереп алган бөҗра рәвешендә булганнар дип уйларга мөмкин. Ихтимал, бу шәһәрне саклау максатларын күздә тоткандыр. Мондый түгәрәк урамнар борынгы Мәскәүгә дә хас булган (мәс., Мәскәүнең мәркәзен ураган "Садовое кольцо"). Р.Әхмәтьянов "урам" сүзен *ор* "канау, окоп" сүзе белән дә бәйли.

***УРТАК*** *тар.* – Башка сәүдәгәрләр белән бер компаниядә (ширкәттә) сәүдә итүче;

компаньон, "иптәш"; ханның сәүдә агенты. Кайчагында "аренда хакы" мәгънәсендә дә очрый.

***УРТАКЧЫ*** *тар.* – Арендатор. Электә, мәсәлән, морза җирен арендага алып чәчүчене *уртакчы* дигәннәр.

***УТЛЫ ТУП*** *тар.* – Казан ханлыгы чорында Мәскәү гаскәре Казан каласын тупка тоту өчен кулланган ату коралы. Кол Шәрифнең "Зафәрнамәи вилаяте Казан" дигән әсәренә караганда, 1550 елның февралендә Казанны камалыштa тоткан рус гаскәре кулында шундый унбер туп булган. Туплар ата торган утлы ядрә бер батман кадәр авырлыкта булып, аның эченә төрле янучан матдәләр ("ак нефть"? һәм күкерт атап күрсәтелә) һәм дүрт-биш кургашын ядрә салынган була. Бу утлы ядрәләр" шәһәр эчендә һәр җиргә" төшкән, "һичкемнең ул утлы ядрәне барып сүндерергә дәрманы булмаган". "Ләкин кайбер яшьләр һәм гайрәтле егетләр ул утка үзләрен чаяннар кебек атарлар, аны сүндерерләр һәм аның әсәре вә эзе дә калмас иде." (Телгә алынган әсәрдән бүгенге тәрҗемә.) Туп үзе дары белән корылганмы, әллә катапульта (мәнҗәникъ) булганмы–анык кына аңлашылмый. Шулай да безгә башка чыганаклардан руслар көнчыгыш осталарыннан ясарга өйрәнгән *шерешир* (шәрәшир) дигән утлы корал билгеле. Казанны камалышта тотканда, утлы туплардан башка, руслар кулында 4-5 "*һавалы туп*" та булган.

Тагын кара: **УТЧАГЫР.**

***УТЧАГЫР*** *иск.* – Артиллерия тубы, пушка. Электә, дары белән корыла торган тупларга кадәр, утлы чүлмәк ыргыта торган җайланманы (мәнҗәникъны, ягъни катапультаны) утчагыр дип атаганнар булса кирәк. //*Гавер аткан утчагыр*–кяфир аткан туп. "Идегәй" дастаныннан.

***УЧАК*** – **1**.Гомумтөркидә *мич, таган* (русча–*костер*). Электә *казан асу*–учак ягып, ашарга пешерү мәгънәсенә ия булган. Хәзерге авыл мичләрендә мич белән янәшә казан астына ягыла торган урынны учак диләр. Бу сүз рус теленә *очаг* рәвешендә кергән. **2**.Иске татар әдәбиятында–*шахта, рудник, мәгъдән чыганагы; мәркәз.* //*Сугыш учагы. Гаилә учагы. Мәдәният учагы.* 3.Электә җинаятьче муенына кыздырылган хәлдә кидерелә торган коршау, суынгач аны баш аркылы салып ташлый алмаганнар (Р.Әхмәтьянов буенча).

***УЧАН*** *тар.* – Зур көймә. Мәхмүд Кашгарый сүзлегендә–"ике җилкәнле көймә. Ихтимал, русларның *ушкуй* терминына туры килә торгандыр?

***Ү*** *бор. төр.* – Өй. Бу сүз турында Шакир Абилов түбәндәгеләрне әйтә: "Өй"нең борынгы әйтелешен хәзерге татар теле графикасы белән бирү кыен: эв, ив, өв. Аның якынча дөрес әйтелеше мишәр телендә сакланган: ү; тагын да дөресрәге-өү, эү. Татар язуында латиндагы кебек кыска "ү" булмаганлыктан, "өү"не "эү" дип язу кулайрак тоела". //*Карьянең икенче бер очына бер ү салып, аерып чыкармыш иде.* Ризаэддин Фәхреддин.

***ҮЗӘРЕ, ҮЗРӘ*** – Борынгы төрки сүз, бәйлек хезмәтен үтәгән: өсте, өстендә; эчендә. //*Үзрендә*–өстендә, *үзренә*–өстенә. *Төрле лисан үзәрендә*–төрле телләрдә. *Аяк үзрендә*–аяк өстендә. *Баг үзрә*–бакча эчендә. *Баш үзрә*–башта, баш өстендә. *Дөнья үзрә*–бөтен дөньяга. *Шәһәр үзрә*–шәһәр өстендә. *Кабер үзрендә. Су үзрена. Тәхет үзрендә.*

***ҮКӘК*** *бор.төр.* – **1**.Манара (почмак манарасы), маш; ныгытма. **2**.Зодиак тамгасы, зодиак йолдызлыгы. //*Он икки үкәк*–унике зодиак тамгасы, йолдызлыгы. "Древнетюркский словарь". 3.Сандык; җеназа агачы. Бу мәгънәсе Мәхмүт Кашгарыйда очрый.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Кушлавыч

Кушлавыч авылы Арча районында, Арча эшчеләр бистәсеннән 24 чакрым ераклыкта утырган.

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай Кушлавыч авылында 1886 елның 14 (26) апрелендә дөньяга килә. Аның әтисе, указлы мулла—Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгали улы Тукаев (1824—1886) Кышкар мәдрәсәсен тәмамлый. 1886 елның август ахырында вафат була. 1890 елда шагыйрьнең әнисе Мәмдүдә Балтач районы Сасна пүчинкәсе авылы мулласына яңадан кияүгә чыга һәм улын үзе белән ала.

1955 елда Кушлавычта шагыйрьнең бронзадан эшләнгән бюсты куела (скульптор И. А .Новоселов). 1976 елда Тукайга багышланган музей ачылды.

Флера Гыйззәтуллина Кушлавыч турындагы шигырен Габдулла Тукай белән бәйләп язган. Аңа Луиза Батыр-Болгари көй иҗат иткән. Бу шигырь юллары йөрәк кылларын тибрәтә:

*Кушкаеннар шаулый Кушлавычта,*
*Йөрәкләрне ялгый сагыш-моң.*
*И, Кушлавыч, тәүге бишеге син*
*Тукай моңы иңгән язмышның.*

Кушымта:
*И, Кушлавыч, җырга юл ярганда*
*Каеннарның чугын тарама.*
*Халык кичерешләре, тирән үкенечләре*
*Сызлый йөрәктәге ярада.*

*Юлчыларның, якты хәтер фалы*
*Кушкаенга кунар кошлар ич!*
*Җырлап сулган ятим шагыйреңне*
*Сагынасың, изге Кушлавыч.*

*Тукай җаны төсле үрсәләнеп*
*Уза еллар көрәш гамендә.*
*Гасырлардан әрнү саркып тора*
*Каеннарның күз яшьләрендә.*

Авыл атамасы тарихи-географик, географик-статистик чыганакларда еш очрый.

Алат юлы өстендәге бу авыл Казан ханлыгы чоры авыллары исемлегендә искә алына. Авыл атамасы И. П. Ермолаев хезмәтендә 1676 елның 24 июль датасы белән теркәлгән.

Д. А. Корсаков (1908) җыентыгында Кушлавыч авылы чишмә янына утырган дип телгә алына. Анда 89 йомышлы татар яшәгән. Шунда ук—Кушлавыч пүчинкәсе дә искә алына, анда 18 йомышлы татар теркәлгән. 1761—1866 елларда үткәрелгән

*Дәвамы. Башы журналның 2006 елгы 6 санында.*

Генераль ызанлау мәгълүматларыннан күренгәнчә, Кушлавыч авылында һәм Кушлавыч пүчинкәсендә йомышлы татарлар яшәгән. А. Артемьев китабыннан (1866) күренгәнчә, Кушлавычның 86 хуҗалыгында 384 ир-ат һәм 356 хатын-кыз исәпкә алынган, авылда мәчет эшләгән. Кушлавыч авылы турында Н. Н. Вечеслав (1878) мондый мәгълүмат бирә: Чишмә суы һәм коры чокыр янына утырган Кушлавыч авылындагы 121 йортта 368 ир-ат һәм 342 хатын-кыз көн күргән. Анда бер агач мәчет, кибет һәм тимерче алачыгы булган. Кушлавыч авылы И. А. Износков китабында (1895) телгә алына. Анда 120 хуҗалык булып, ислам динендәге 411 ир-ат, 383 хатын-кыз яшәгән. Халык бик тырышып умартачылык белән шөгыльләнгән. 1898 елгы исемлектә Кушлавыч авылында татарлар яши дип искә алына. К.П.Берстель мәгълүматларына (1908) караганда, авылда барлыгы 798 татар кешесе яшәгән.

Нажия Борһанова язуына караганда, Кушлавыч, Югары Сәрдә һәм Урта Сәрдә авыллары июнь аеның 17-20 көннәрендә Сәрдә җыены бәйрәм иткәннәр. Җыенны икенче төрле Кушлавыч дип тә атаганнар.

Олы буын вәкилләре сөйләвенә караганда, борын заманнарда авыл урынына ике кеше килеп утырган. Аларның берсе елганың бер як ярына, икенчесе икенче як ярына йорт торгызган. Тора-бара бер-берсенә бик нык ошаган ике урам барлыкка килгән һәм шуннан чыгып авылны Кушлавыч дип атаганнар. Шуны да әйтеп китик, «Үзбәк энциклопедиясе»ндә «Кушлавыч» атамасы Кышлавыч рәвешендә бирелгән (Кышлак мәгънәсендә).

Бу тирәләрдә элек урман булганлыгын елга-инеш атамаларыннан күрәбез. Каенлы елга тирәсендә, билгеле инде, каеннар үскән. Ылыс елгасы исеме елга буенда чыршы, нарат агачлары күп үскәнгә бирелгән. Баланлы елга атамасының да килеп чыгышы бик аңлаешлы.

Кушлавыч авылы табигатьнең матур урынына, Габдулла Тукай язганча, тау башына салынган. Ул Красна суының ике ярына урнашкан һәм хәзер ике туры урамнан тора. Исемнәре: Аргы як һәм Бирге як. Элек авыл бик зур булган, урамнарын Эш урамы, Тегәрҗеп урамы, Түбән оч, Югары оч, Чүлмәк атавы дип йөрткәннәр. Хәзерге вакытта шулардан Чүлмәк атавы гына сакланып калган. Ул авыл читендә, тау башында. Элек бу атауда яшәгән халык чүлмәк ясаган, кызыл балчык ала торган урыннары әле дә билгеле. Бу атауда сугышка кадәр 25 хуҗалык яшәгән, ә хәзер 4 хуҗалык калган. Авылның Бирге як урамын сусыл коры елга кисә, ул Тимерче елгасы дип атала, чөнки елга башланган урында тимерче алачыгы булган. Авыл эчендә Питрән чишмәсе һәм коесы бар. Чардуган елгасының исеме бу елга янына бер юлчының күмелгән булуына бәйле. Кабергә чардуган корылган һәм коры килгән елларда әбиләр, шул кабер янына барып, сәдака куялар, дога кылалар һәм Ходайдан яңгыр сорыйлар. Җырлы елга ташларга бәрелеп моңлы авазлар чыгарып акканга шулай йөртелә. Кишет елгасы—шул исемдәге авыл ягыннан агып килгән өчен шулай аталган. Баткак елганың бу исеме тирәсе сазламык, юеш булып торган өчен бирелгән. Чукрак елгасы чукракланган Зиннәтулла абзый өе янәшәсеннән үткән. Авыл басуыннан Сыер, Үгез, Кече су елгалары һ.б. ага.

Авылда, тау астында Тукай чишмәсе дип аталган чишмә бар. Кунакка килүчеләр бу чишмәгә күз салмыйча китмиләр. Авылда тагын Котый чишмәсе бар. Аны Хөснетдин исемле кеше карап һәм чистартып торган. Халык Хөснетдин исемен кыскартып Котый дип атап йөртә икән. Авыл кырыендагы болынлыкны Яшелчә бакчасы дип йөртәләр, элек анда бакча булган. Казан арты районнарының төньяктарак урнашкан һәр авылында диярлек чирмеш, әкәйләр белән бәйләнешле атамалар бар. Кушлавыч авылында да чирмеш каберләре дип аталган урыннар халык хәтерендә саклана. Авыл эчендәге зиратта Габдулла Тукай әтисенең кабере бар. Авыл халкы кабергә таш куйган һәм чардуган корган, аны даими карап торалар.

Кушлавычта мәдәният йорты, медпункт, элемтә үзәге, балалар бакчасы, китапханә бар, күптән түгел генә башлангыч мәктәп төзелгән, хәзер унбер еллык мәктәп салынып беткән. Мәктәп элек мәчет бинасына урнашкан булган. Хәзер авылда яңа мәчет җиткерелгән.

Казанның Насыйри урамында (19а йорт) М.Вәлишин йорты бар. Мәрҗани мәчете диварлары белән әйләндереп алынган ике катлы агач йорт XIX гасыр уртасында М. Вәлишин тарафыннан төзелгән. 1872 елда йорт хуҗасы Захарьев урамы сызыгында (архитектор Шмаков проекты буенча) беренче катында кибет урнашкан ике катлы кирпеч флигель төзеткән.

Мифтахетдин Вәлишин (1811—1904) чыгышы белән Казан өязенең Кушлавыч авылыннан (Татарстанның хәзерге Арча районына керә) булган, икмәк һәм бакалея товарлары белән сату иткән. 1870 елда ул һәм сәүдәгәр Г. Абдуллин яна татар бистәсендә кирпечтән мәчетләр төзелешенә матди ярдәм күрсәткән. Сәүдәгәрнең улы Мөхәммәт Вәлишин (туган елы—16.09.1881) 1915 елда Г.Кариев чакыруы буенча «Сәйяр» труппасында актер булып эшли башлаган. Әтисе вафатыннан соң мирас булып йорт аның милкенә күчкән.

Кушлавыч авылы халкы үзәкләштерелгән газ яга, юлларга асфальт түшәлгән.

Халык әби-баба, ата-ана ята торган зиратны карап тора. Аның тирә-юне койма белән тотып алынган, каберләр тазартыла, чардуганнар буяла.

Карауcontainedы булмаган олылар халыкның игътибар үзәгендә торалар. Ялгыз олыларны махсус хезмәт хакы түләп карауchылар да бар. Хезмәт хакын авыл хакимияте түли.

Авыл халкы тырыш һәм унган. Тормышлары әйбәт, киләчәккә алар ышаныч белән карыйлар.

Шагыйрь һәм прозаик Әнәс Касыйм улы Галиев Кушлавыч авылында туып үскән.

## Күәм

Авыл атамаларының һәрберсе диярлек чал тарихка барып тоташуы турында без әйттек инде. Әгәр ономастика, топонимия мәгълүматлары тарих, этнография, археология, мифология, фольклор хезмәтләрендәге документаль информация һәм тел җәүһәрләре белән ныгытылып барылса, топонимның мәгънәсен ачу халыкның килеп чыгышын ачыклау өчен өстәмә материаллар бирә. Күәм атамасы да шактый серле һәм катлаулы бер дөнья тәшкил итә.

Күәм авылы Әтнә районында, район үзәгеннән 7 чакрымда, тимер юл станциясе Коркачыктан—37, Казан шәһәреннән 78 чакрым ераклыкта урнашкан. Күәм—жирле үзидарә советы үзәге. Аның даирәсенә Әйшияз, Дусым, Җилгелде, Каенсар, Казак Үртәме авыллары керә.

Атама тарихи чыганакларда, халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм башка хезмәтләрдә телгә алына.

Алат юлы өстендәге Күәм авылы Казан ханлыгы чорында ук булган. Казан өязенең теркәү кенәгәләрендә (1602-03 еллар) Күәм авылы искә алына, анда йомышлы һәм ясаклы татарлар яшәгәнлеге күрсәтелә. 1648 елның май ае белән Күәм атамасы И. П. Ермолаев хезмәтендә теркәлгән.

Д. А. Корсаков (XVIII йөз) авыл турында түбәндәге мәгълүматларны бирә. Иске Йомышлы Күәмдә 39 йомышлы татар, Яңа Йомышлы Күәмдә 255 йомышлы татар, Күәм авылында 48 йомышлы татар яшәгән. А. Артемьев җыентыгында (1866) да Күәм искә алына. Пүчинкәдән башланган Күәм (Кубян с починка) авылындагы 274 хуҗалыкта 901 ир-ат һәм 886 хатын-кыз көн иткән, бер мәчет булган. Күәм авылындагы 38 йортта 146 ир-ат һәм 132 хатын-кыз исәпләнгән, авылда бер мәчет эшләгән. Күәм Пүчинкәсенең 9 йортында 21 ир-ат һәм 14 хатын-кыз яшәгән. Иске Күәмдә 12 йорт булып, анда 43 ир-ат, 39 хатын-кыз гомер кичергән, бер мәчет булган. 1898 елгы хезмәттә Кубәндә (шулай язылган) татарлар яшәгәнлеге әйтелә. К. П. Берстель җыентыгындагы (1908) мәгълүматларга караганда, Күәм Пүчинкәсендә 566, Иске Күәмдә 67, Пүчинкәдән башланган Күәм (Кубян с починка) авылында 4128 татар кешесе яшәгән.

Н. Борһанова мәгълүматларына караганда, элекке заманнарда Күәм, Әйшияз (Әшиасты), Үртәм, Казак Үртәме, Күлле Киме, Җилгелде, Бактачы, Каенсар авыллары халкы бергә җыелып июнь аенның беренче декадасында Калатау исемле җыен бәйрәме үткәргән.

Күәм атамасы нәрсә аңлата соң? Исемендә нинди сер саклый бу авыл?

Ике теллелек, ягъни татар һәм рус телләренең үзара бәйләнеше һәм бер-берсенә йогынтысы көчәйгән чорларда атамалар еш кына ике төрле итеп әйтеләләр һәм язылалар. Кайбер очракларда атаманың рус теле формасы борынгылыкны күбрәк саклаган булып чыга. Бу очракта русча Кубян атамасы борынгы формага якынрак. Вакытлар үтү белән бу топонимның төзелеш калыбы бераз үзгәргән. Куман—кубан,

коман—кобан сүзләренең, ягъни этнонимнарының параллель төрдәшләре булып кулланылуы академик Мирфатыйх Зәкиев хезмәтләрендә карала. «...Урта Идел буйларына команнар болгарлар килеп утырганга кадәрге чорларда ук саркып кергәннәрдер һәм бу тирәләргә әле кыпчаклар килгәнче үк коман—кобан—кабан атамасы алган ойконимнар һәм гидронимнар барлыкка килүгә сәбәпче булганнардыр»,—дип яза ул.

Кыпчаклар—һуннар яшәгән чорларга кадәр үк билгеле булган борынгы кабилә-кавемнәр. Европада аларны команнар дип атап йөрткәннәр. Европалылар бу кабилә-кавемнәр турында һуннар, торклар һәм бәҗәнәкләр чорыннан ук хәбәрдар булса кирәк. Бу хәбәрдарлык Венгриядә Коман исемендә ике өлкә һәм Македониядә Коман атамасы алган шәһәр булуы белән дәлилләнә. Гарәп галиме Идриси географиясендә (XII йөз) кыпчаклар жирендә Ак, Кара, Тышкы Кумания өлкаләре кара-каршы куела. Б. А. Рыбаков фикере буенча, Ак (Көнбатыш) Кумания Днепр һәм Днестр елгалары ярындагы күчмә кыпчак кавем-кабиләләр жирен берләштергән. Кара Куманиянең үзәге Төньяк Донец елгасы булган. Әхмәт Булатов язуына караганда, кыпчакларның бер варисы булган нугайларны мордва-эрзәләр кубан, губин, губан (коман) дип атаганнар. Мирфатыйх Зәкиев аларны кыпчак культурасын дәвам итүчеләр, гадәти төрки телдә сөйләшүчеләр һәм татар-мишәрләр арасына кушылып эрегәннәр (ассимиляцияләнгәннәр) дип карый. Куман—кобан этнонимнары төркиләр элек һәм хәзер яшәгән урыннарда шактый күп очрый. Элекке Казан өязендәге Кубан—Чур дигән авыл хәзер Плаксиха дип атала. Бу өязга тагын Зөя суының сул кушылдыгы Гөбенә (Кубня) атамасы да керә. Самара өлкәсендә татар авылы Губан-күл (Кубань куль), Ука суы бассейнында Коман күле, Кобан чокыры, Ульян өлкәсендә Губань авылы, Россиянең көнчыгышында һәм Төньяк Кавказда Кубань елгалары, Осетия һәм Аджария республикасында Кобан авылы, Әзәрбәйҗанның Җәлилабад районында Команлы авылы бар. Төньяк Осетиянең Кобан тарлавыгында Кобан исемле авыл билгеле. Бу авылда Бикмурзаев, Татаров, Кантимеров, Апаев һ. б. фамилияләр күп очрый. Осетия топонимиясен җентекләп өйрәнгән А. Цагаева бу атамаларның коман этнонимы белән бәйләнгән булуын бик күп мәгълүматлар белән дәлилли. «Тарихтан билгеле булганча,—дип яза А. Цагаева,—Кубанда, Зеленчук районында хәзерге осетиннарның бабалары төрки кавем-кабиләләр белән бергә күрше булып яшәгәннәр һәм бу этнонимны алардан кабул иткәннәр». Куманда һәм Олы Куманда атамалары Таулы Алтайның төньяк-көнбатыш районнарында, Украинада, Молдованың төрки гагауз халыклары яши торган җирләрендә очрый. Джованьолиның «Спартак» романында «Коман юлы» дигән атама телгә алына.

Димәк, Әтнә районындагы авыл атамасы Күәмнең тарихы тирәнгә китә.

Авыл утырган урын бик матур. Аны икегә бүлеп Күәм суы ага. Аның ярларын бөдрә таллар бизи. Җәй көне ул каз-үрдәк белән тула, балаларның шат тавышына күмелә. Кояш чыгышында Танатыр исемле агачлык күренеп тора. Бу урынны гөмбә җыючылар бик ярата.

Авыл тирәсендә, ямь өстенә ямь өстәп, Чупай, Шәриф, Шомыртлы яки Үртәм, Дусым, Аргы күпер, Бирге күпер, Усаклы күпер, Күсәкәй, Танатыр, Кала асты, Казаклар, Татлы бай, Каенлык, Җәлбәк, Балчык базы, Ишчүрә, Коры елга, Күәм Казаклары, Шәриф һ.б. исемле елгалар ага. Тирә-юнендә печәнлек, җиләклек. Табигатьнең бу матур почмакларына килсәң, моннан кайтып китәсе дә килми. Авыл читендә Кала асты дигән урын бар. Анда изге кешеләр күмелгән дип сөйлиләр. Янындан Изгеләр чишмәсе ага. Һәр җәйне бу урынга әби-бабалар килә, изгеләргә дога кылып, сәдака калдыра, чишмәсеннән су алып эчә. Элек монда кала булгандыр дигән фикер яши. Авыл читендә Казаклар дип йөртелгән елга һәм зират бар. Бу тирәдә үз җирләре, үзәннәре, болыннары булган кечерәк кенә Казаклар авылы урнашкан булган. Аңа казак хезмәте итеп кайткан татар кешесе нигез салган дип сөйлиләр. Авылда Моталлап исемле дан тоткан бай булуы да билгеле. Колхозлашу елларында алар берничә урам булып Күәмгә кушылганнар. Хәзер бу урамнар юк, ул урында ферма калкып чыккан. Елганы һәм зиратны Казаклар исеме белән атап йөртәләр. Авылда тагын бер истәлекле урын—Кәҗә тау башы. Аның үзенә күрә тарихы бар. Сугыш елларында барлык ирләр дә сугышта була. Газизә исемле хатынның берсеннән-берсе кечкенә алты баласы һәм бер кәҗәсе була. Яз җитә. Кәҗәгә ашатырга иске печән күптән беткән, ә янасы үсмәгән. Газизә үлән чыга башлаган калкулыкка кәҗәсен арканлый да, арба тартып район үзәгенә китә, ә

балаларына кәҗәгә күз-колак булырга кушып калдыра. Балаларының өлкәненә дә 9 яшь кенә була. Алар уен белән мавыгып кәҗәне бөтенләй онытсалар. Ә әниләре районнан төнлә генә кайта. Бу вакытта кәҗәдән жилләр искән—бер явызы урлап киткән була. Ятимнәр көн саен тауга менеп кәҗә эзләгәннәр...

Хәзер бу тирәләрне сөргәннәр. Олылар аны әле дә Кәҗә тау башы дип атап йөртәләр.

Авылдан ерак түгел генә, яңа ай туган төнне көзге кичләрдә, кышкы бураннарда кешеләрнең башын әйләндереп, адаштырып йөртә торган тау итәге бар. Аны Айтуган тау итәге дип атаганнар. Бу тирәләрдә таза хәлле бик тату гаилә яшәгән. Аларның татулыгына күпләр көнләшеп караган. Тавышлы гаиләләргә һәрчак аларны мисал итеп китергәннәр. Көннәрдән бер көнне, яңа ай туган көнне бу гаиләне үтереп чыгып киткәннәр. Моңа күпләр шикләнеп караган һәм халык моннан күчеп киткән. Яңа ай туган вакытларда бу тирәдән үтеп китәргә курыкканнар. Юлы төшеп үткән юлчыларны гөнаһсыз үтерелгән кешеләрнең рухы һәрчак яңа ай туган төнне адаштырып йөртә икән.

Авыл тирәсендә Жәмилә, Гарәфи, Чеберди, Чупай, Таңатыр, Ишчүрә һ. б. чишмәкизләүләр ага. Каенсар авылы белән ике арада Чирмеш тау башы дигән урын бар. Чупай тау башы дип аталган жиргә Чупай исемле кеше килеп утырган. Имәнсәр, Каенсар дигән жирләрдә элек имән һәм каен агачлары күп үскән. Туң ышна, Имәнсәр һәм Каенсар атамалары бу тирәләрдә элек калын урманнар булуын күрсәтеп тора.

Олылар сөйләвенә караганда, элек өч туган үзләренә йорт төзү өчен жир урыны сайлаганнар. Туганнарның берсе: «Әнә мин теге ялтырап торган жирдә урнашам»,— дигән дә, кояш нурларында ялтырап торган тау башына күрсәткән. Шуннан бу тауны Жылтырый тау башы дип йөртә башлаганнар. Авылда жылтырыйлар нәселе әле дә бар.

Ике калкулык арасында Жаббар атлы кешенең имана жире булган, һәр яз саен ике тау арасында ястык кадәр жирдә генә кар калгач, ул кеше жир сукаларга керешкән. Бу басу шуннан Жаббар ястыгы исеме алган. Элеккедән калган гадәт буенча, колхоз хәзер дә Жаббар ястыгында ястык кадәр генә кар калгач, жир сукаларга тотына һәм язгы чәчүгә керешә.

Авылдан читтәрәк Хәсән күле дигән жир бар. Бу жирләр элек куе кара урман булган. Шушы урман арасында кечкенә генә алан һәм анда бер бик матур күл жәелеп яткан. Күлгә яз саен үрдәкләр һәм кошлар кайтканнар. Аның тирә-юнендә таң атканда сандугачлар сайраган. Шушы күл янына ике бертуган Хәсән белән Хөсни килеп чыкканнар һәм шушында төпләнеп калырга уйлаганнар. Бу урынны икесе дә бик яратканнар. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, алар мин урнашам да, мин монда урнашам дип, ызгышып киткәннәр. Нәтиҗәдә, Хөсни Хәсәнне үтерә һәм күлгә ташлый, үзе бу жирдә яши башлый. Ләкин никадәр генә тырышса да, ул монда мантый алмый. Үлгән туганы аның гел исенә төшеп торган. Ахырда ул түзми, бу жирне ташлап еракларга китеп бара. Күп сулар аккан, буыннар алмашынган. Әлеге матур күл көннән-көн кечерәйгән һәм кипкән. Янындагы агачлар да корыган. Хәзер ул жирдә берничә агач кына үсә, ә Хәсән күле дигән исеме һаман халык хәтерендә саклана. Төнлә белән бер авылдан икенчесенә барганда, Хәсән күле яныннан үткән кешеләр адашып та йөри дип сөйлиләр.

Олылар хәтерендә тагын бер истәлек сакланган. Авылдан ерак түгел генә урынга бер урыс кешесе гаиләсе белән килеп урнашкан. Халык аны Иван дәдәй дип йөрткән. Ул тегермән корып жибәргән. Уңган тегерменченең даны еракларга таралган. Тирәяктагы авыллардан аның тегерменнә он һәм ярма тарттырырга күп килгәннәр. Иван дәдәйдән көнләшүчеләр дә булган. Иванның Ибраһим исемле дусты һәм ярдәмчесе була. Бервакыт Иванның тегерменнә кайсыдыр явызы көнчелектән ут төртә. Ибраһимның сизгерлеге белән тегерменгә әллә ни зыян килми. Төзәткәч, тегермән тагын көйләнеп китә. Язның матур бер көнендә Ибраһим дусты Иван янына килә. Ишегалдына килеп кергәч, ул тынлыкка гажәпләнеп тора. Ишек кага, ачучы булмый. Ишекне төртеп караса, ул ачылып китә. Ибраһим өйгә керсә, үз күзләренә үзе ышанмый. Иванны, хатынын һәм алты баласын суеп чыгып киткәннәр. Ибраһим барып бишектәге имчәк баласын карый, ләкин бала булмый. Ул ишегалдына чыга. Тегермән ташы астында сабый биләнгән ак биләүне күреп ала. Нарасыйның өстенә тегермән ташы бастырып киткән булалар... Иванның гаиләсен жирләгәннән сон, Ибраһим дусты истәлегенә һәм гөнаһсыз сабыйлар

төсе итеп шушы урынга шомырт агачлары утырта. Шомырт агачлары күп еллар буе ап-ак чәчәк атып утырганнар... Хәзер бу урында тегермән дә, шомырт агачлары да юк. Ә халык хәтерендә тетрәндергеч шушы вакыйга һәм Шомыртлы тегермәне дигән атама сакланып калган. Бу урын хәзер басу уртасындагы яшел чирәмле үзән. Аны сукаламыйлар, иген чәчмиләр. Көрәк белән казысалар, көрәк сына, сука керми, имеш, дип сөйли авыл халкы бу урын турында.

Күәм авылы зур, бер башыннан икенче башына кадәр өч чакрымга сузыла. Революциягә кадәр авылда дүрт мәчет һәм дүрт мәхәллә булган. Мәчетләр каршында мәдрәсәләр эшләгән. 1930 елларда мәчет манаралары киселгән. Бер мәчетне мәдәният сарае итеп калдырганнар. Башкалары юкка чыгарылган.

Авыл халкы чыпта суккан, чабата үргән, мунчала ясаган, такта ярган, чана, ат дирбияләре һәм кисмәкләр ясаган. Бу кирәк-яракны халык базарга чыгарып саткан. Моннан тыш акча эшләү өчен читкә—Казанга, Әстерханга һәм шахталарга киткәннәр.

Күәмдә базар эшләгән. Анда утын, ит, май, мал-туар, чана, чабата, себерке кебек кирәк-яраклар сатылган.

Авылда алты җил тегермәне һәм ике су тегермәне булган.

Күәм авылы Иске авыл, Югары оя, Яңа урам, Тәтлек урамы, Баш-аяк, Аргы як, Түбән оч дигән өлешләргә бүленә.

Күәмдә 300 хуҗалык исәпләнә.

Авылда китапханә, зур мәдәният йорты, унъллык мәктәп, медпункт һәм балалар бакчасы бар. Хәзерге вакытта авылга газ кертелгән, асфальт салынган, яңа кибетләр эшли, пекарня һәм мәчет төзелгән. Авыл яңара, яшәрә һәм үсә.

Күәм күп кенә югары белемле укытучылары, җир белгечләре, инженерлар, хәрби белгечләре һ.б. белән дан тота. Язучы Самат Шакир, биюче Габдрахман Сәлимов—республика күләмендә билгеле шәхесләр.

Мәктәптә авыл тарихына багышланган музей бар. Анда укучылар тарафыннан җыйналган борынгы әйберләр урнаштырылган. Авыл тарихына багышланган альбомнар тутырылган, күренекле авылдашларның рәсемнәре куелган. Музей яңа экспонатлар белән тулылануын дәвам итә.

Мәдәният йорты бик матур итеп төзелгән булган. Кызганыч, игътибарсызлык аркасында, кышка җылысыз калып торбалары шартлаган һәм, ягылмаганга күрә, стеналары чатнап аерылган, түбәләреннән су үтеп ул хәрабә хәленә килгән дип ишеттек.

Авылда биш зират бар: Казаклар зираты, Иске зират, Изгеләр зираты, Башаяк зираты һәм Яңа зират. Халык зиратларны карап һәм чистартып тора.

Күәм халкы ачык йөзле, кунакчыл. Гадел дә, шул ук вакытта кырыс та була белә. Яшьләр хәзер авылда кала. Авылның киләчәге өметле.

Күәм авылына багышлап шагыйрь Самат Шакир сүзләренә Сара Садыйкова көй язган.

Прозаик һәм шагыйрь Самат Шакир (Самат Фәтхерахман улы Шакиров) шушы Күәмдә туып үскән.

Авыл халкы ялгыз яшәүче олыларны хөрмәтли, һәрдаим ярдәм итеп тора. Аларга колхоз идарәсе һәм авыл хакимияте матди ярдәм күрсәтә.

Авыл халкы бер-берсенә күбесенчә гадәти кушаматлар кушкан: аю, бүре, куян, чокыр, мунча, каеш, үти, бака, сандугач, сыерчык, чәүкә, шекә, муллый, сары сакал, сары май, метри, өч колак, тана колак, әләү, әхли, чулак, бәби, апрак, карсак һ. б.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# МӘРҖАНИ—ФӘЕЗХАНОВ ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ: ЯҢА ФАКТЛАР

Татар тарихчысы, Шәрык белгече, тел галиме, педагог һәм каллиграф Хөсәен Фәезханов (1828—1866)—милли тарихыбызның чиксез галәме күгендә иң якты йолдызларның берсе. Фани дөньядан яшьли киткән зирәк акыл иясенең фәнни эшчәнлеге даими игътибар үзәгендә булган. Фәезхановның тормышы һәм эшчәнлеге Шиһабетдин Мәрҗани, Владимир Вельяминов-Зернов, Ризаэтдин Фәхретдин, Әхмәтзәки Вәлиди, Галимҗан Ибраһимов, Габдрахман Сәгъди, Флера Сафиуллина, Миркасыйм Госманов кебек мәшһүр галимнәр тарафыннан өйрәнелеп югары бәяләнгән.

Фәезхановның фәнни мирасы шактый тикшерелгән булса да, хезмәтләре бергә тупланып монарчы матбугатта басылып чыкканы юк иде. Ә соңгы елларда гына табылган, татар тарихына багышланган хезмәтләре галимнәр өчен дә бөтенләй билгесез иде. Ниһаять, Фәезхановның гыйльми әсәрләрен һәм хатларын, шулай ук аңа бәйле башка материалларны бергә туплаган 700 битле җыентыгы дөнья күрде («Җыен» нәшрияты, 2006). Галимнең мирасын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә милли тарихыбыз һәм тарих фәне өчен кызыклы яңалыклар ачылды. Мәкаләбездә шуларга кыскача тукталып үтәбез.

Хөсәен Фәезхановның татар милли мәгарифе тарихы һәм мәдрәсәләрне реформалаштыру турындагы «Ислахы мәдарис» һәм «Рисалә», татар тарихын өйрәнүгә багышланган «Казан тарихы» һәм «Касимский ханлыгы», Болгар чоры эпиграфик истәлекләреннән 25 эпитафияне тасвирлаган хезмәтләре фәнгә билгеле. Фәезханов кулъязмалары барысы да үз вакытында Шиһабетдин Мәрҗанинең шәхси китапханәсендә саклanганнар.

Мәрҗанинең вафатыннан соң, васыяте буенча балаларына мирас итеп калдырылган китапханәсенең язмышы катлаулы булган. Шиһабетдин хәзрәтнең гаять бай китапханәсе 1920 нче елда янгында юкка чыккан дигән хәбәрләр дә бар, авыр елларда күпмедер читкә дә киткәнлеге мәгълүм. Мәсәлән, Ш.Мәрҗанинең улы Борһанетдин гаиләсе 1931—1932 елларда Сәмәркандкә киткән вакытында китапханәнең бер өлешен үзләре белән алган. Борһанетдиннең кызы Разия ул язмалардан кайберләрен 1969—1970 елларда Казанга кире кайтарткан. Бу хәзинәдәге ике кулъязманы, ягъни Хөсәен Фәезхановның «Ислахы мәдарис» һәм «Рисалә» исемле хезмәтләрен Мәрҗани оныклары Даниял Әмирханов белән Нажия Ильясова 1986 елда тарихчы галим Миркасыйм Госмановка тапшыралар. Хәзерге вакытта Казан дәүләт университетының Фәнни китапханәсендә саклана торган бу кулъязмалар фән өчен аеруча мөһим табышлардан булды. Чөнки алар Мәрҗани китапханәсе белән бергә янгында юкка чыкканнар дип исәпләнәләр иде.

Мәрҗани оныклары белән аралашуыбыз нәтиҗәсендә Хөсәен Фәезхановның башка кыйммәтле истәлекләрен дә табарга насыйп булды. Даниял Әмирхановларда саклanган, монарчы фән даирәсендә билгесез кулъязмалар белән беренче мәртәбә 1997 елның декабрендә таныштым. Болар—Разия Әмирханова Сәмәркандтәге туганнарыннан кайтарткан, Мәрҗани китапханәсенә нисбәтле кулъязмалар иде. Д.Әмирханов үзләренең гаилә архивларында саклanган әлеге кыйммәтле мирасны 1998 елда Татарстан Милли китапханәсенә тапшырды. Бу тупламда Шиһабетдин Мәрҗанинең үз кулъязмалары, хатлар, китапханәсендәге китаплар исемлегенең бер өлеше, Хөсәен Фәезхановның үз кулы белән язылган тарихи хезмәтләре, башка мөһим документлар бар иде. Алар хакында монарчы тәфсилләбрәк язган идек (*Мәрҗани китапханәсе: фәнни-библиографик җыентык / Төз. Р. Мәрданов.—Казан: Милли китап, 2004.—122 б.*).

Фәезханов әсәрләренең остазы китапханәсенә килеп эләгүләре очраклы түгел.

Чөнки Фәезхановның вафатыннан соң ук Шиһабетдин хәзрәт уртак танышларыннан берсенә–Кәлимулла исемле затка бу мәсьәләдә махсус хат белән мөрәҗәгать иткән. Хатта мондый юллар бар: «...аның һәртөрле җыентыклары һәм китаплары булса кирәк иде. Безгә кулай китаплары булган хәлдә, әгәр сатарга ихтыяр кылсалар, без, бәлки, алыр идек. Хосусан, кешеләр тормышына, тарихлар һәм дөнья хәлләренә мөнәсәбәтле җыентыклары булса, безгә зарур иде... Мөмкин булса, тизлек белән мәрхүмнән калган китапларның исемнәрен язып, тәфсилле исемлек ясап, баягы китапны һәм шуна мөнәсәбәтле аерым кәгазьләрдә булган язмаларны да безгә җибәрерсез».

Фәезхановның Казан һәм Касыйм ханлыкларына багышлап язылган, шулай ук Болгар дәверендәге 25 таш турындагы хезмәтләренең Д.Әмирхановларда сакланган текстлары фән өчен билгесез иде. Әлеге мөһим табыш хакында беренче хәбәрне 2002 елда бирдек *(Казан утлары.–№ 3.–Б. 125-137).* Чордаш галимнәребездән тарих фәннәре кандидаты Фәрит Шәкүров шул ук елда чыккан тарихи хезмәтендә бу фәнни яңалыкны беренче булып җитди бәяләде.

Гомумән, Фәезхановның мондый эчтәлектәге аерым тарихи хезмәтләр язганлыгы турында фәнни җәмәгатьчелек бик аз хәбәрдар иде. Мәсәлән, 1863 елда Чокан Вәлихановка язган хатында ул «Бу җәй көнендә гомумән төрек вә татар тарихын, хосусан «Казан тарихы»н бик кыска (около 10 листов) итеп җыеп бастырырга телӛм. Бу хосуста һәм Сезнең ярдәменезне сорарга кирәк булыр» дигән. Остазы Шиһабетдин Мәрҗанигә 1864 елның март аенда юллаган бер хатында да гомуми генә бер ишарә белән бу турыда белдереп үткән. Кәлимуллага язган хатында Ш.Мәрҗани бу уңайдан «...Болгар вә Казан хакында мәкаләсе булса кирәк...» дигән бер җөмлә язганлыгы мәгълүм иде. Тарихчы Газиз Гобәйдуллин «Мәрҗанинең китапханәсендә материаллар арасында Хөсәен Фәезханов каләме белән язылган, тарихка даир *(караган)* байтак язулар бар» дип искәрткән. Ризаэтдин Фәхретдин исә Хөсәен Фәезхановның «тарих хакында һәм Русия мәдрәсәләре турысында язган әсәрләре үзенең вафатыннан соң юкка чыгуы сөйләнә» дип язган. Галим Миркасыйм Госманов та Фәезхановның Болгар һәм Казан ханлыкларына багышланган хезмәтләре безнең көннәргәчә сакланып калмаганнар дип язган иде. Фәезхановның тарихи әсәрләре хакында болардан башка мәгълүмат булмады. Археограф Сәет Вахидинең «Безнең юл» журналында 1929 елда чыккан «Мәрҗани китапханәсе һәм аның соңгы язмышы» мәкаләсендә китапханәнең янгында юкка чыгуы турындагы хәбәр дә фән әһелләренең эзләнүләрен күпмедер чикләгән булса кирәк. Алай да кызыксынучылар булган. Укытучы, тарихчы Шамил Сафин Мәрҗани китапханәсен совет хакимлеге елларында максатчан эзләгән һәм бер өлешен тапкан. Бу хакта аның үзе язганнарыннан *(Казан утлары.–1982.–№ 4.–Б. 171)* һәм Д.Әмирханов безгә сөйләгәннәрдән ачык билгеле. Дөрес, Фәезханов кулъязмаларын Мәрҗанинеке дип бутап, Сафин ялгыш нәтиҗәләр ясаган *(Сов. Татария.–1986.–10 сент).*

Фәезхановның Казан һәм Касыйм ханлыклары тарихына, Болгар чоры эпиграфикасына караган аерым өч дәфтәре бергә тегелгән җыентык рәвешендә сакланганнар. Бу кулъязмаларда төзәтмәләр һәм өстәмәләр булуы галим тарафыннан аларның ахыргача эшкәртелеп бетмичә, каралама хәлендәрәк калганлыкларын күрсәтә. Ә текстларның бөтен түгеллегенә килгәндә, аларның соңгы битләре Фәезхановның вафатыннан соң җуелганнардыр һәм өч дәфтәрнең кушылып тегелүе дә соңрак булганга охшый.

Автор бу хезмәтләрендә тарихи чыганакларның төрләренә һәм әһәмиятләренә кин тукталган. Хөсәен Фәезханов Казан тарихы буенча үзе туплаган мәгълүматларны язып, «газиз карендәшләремә... тәкъдим кылырга кыючылык иттем һәм бу мәсьәләнең ишеген ачтым. Заманыбыз галимнәреннән бу китапчыкта булган ялгышларымны төзәтеп, минем хезмәтемнең кадерен белүләрен вә хакны исбат итеп, халыкны хатадан коткаруларын өмет итәм. Әгәр бу китапчыгым, үзе күп хаталы булса да, хакыйкать ачылуга сәбәп булса һәм кемнән булса да дөреслек беленсә, мин шуны гына да бәхеткә санармын» дип яза. Фәезхановның бу юлларыннан аңлашылганча, ул үзен татар тарихын фәнни нигездә өйрәнергә керешүче татар галимнәренең беренчесе дип исәпләгән. Кызганыч ки, вакытсыз

үлеме һ.б. сәбәпләр аркасында хезмәтләре дөнья күрмичә һәм заманында үз исеме белән фәнни әйләнешкә кермичә калган.

Әлбәттә, башлангыч чорда Х.Фәезхановның тарихи карашлары формалашуга остазы Ш.Мәрҗанинең зур йогынтысы булган. Ләкин Петербургка киткәч Фәезхановның тарихи мәсьәләләрдә остазына үзе күбрәк тәэсир иткәнлеге мәгълүм. Фәезхановның Мәрҗанигә язган, «Шура» журналында 1916 елда басылып чыккан хатларыннан да әлеге тәэсир ачык күренә. Х.Фәезханов Мәрҗанинең тарихчы булуына зур йогынты ясавы турында чордаш ике галимнең: Ризаэтдин Фәхретдин һәм Газиз Гобәйдуллинның язып калдырган фикерләре бик әһәмиятле һәм гаҗәп дәрәҗәдә охшаш. Күрәсең, Мәрҗани белән Фәезханов мөгамәләләре һәм хезмәттәшлеге хакында XX гасыр башы тарихчылары арасында уртак бер фикер урнашкан булган. Совет дәвере галимнәреннән М.Госманов, М.Йосыпов һ.б. да бу фикерне куәтләделәр.

Мәрҗани белән шәкерте Хөсәен тарих мәсьәләләрендә үзара даими фикерләшеп һәм ярдәмләшеп торганнар. Фәезхановның «Казан тарихы» хезмәтендәге кайбер карашлары 1860 һәм 1863 елларда остазына язган хатларында да чагылыш тапкан.

Иң мөһиме шунда ки, Фәезхановның соңгы табылган тарихи хезмәтләре җәмәгатьчелек өчен бөтенләй үк билгесез калмаганнар икән. Ул язган «Казан тарихы», «Касимский ханлыгы», «Борынгы Болгар ташлары»[1] хезмәтләренең текстлары һәм алардагы фикерләр күренекле татар тарихчысы Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәре аша татар халкына тулаем диярлек ирешкән булган. Мәрҗани һәм Фәезханов хезмәттәшлегенә бәйле, фәнни яңалык дип алдарак әйткән сүзебез дә шушы.

Шәкертенең үлеменнән соң, аның татар тарихы буенча язган әсәрләре бөтенләй югалып калмасын дигән изге нияттән, Мәрҗани үзенең «Мөстәфадел-әхбар...» китабына Фәезхановның текстларын керткән. Бу мәсьәлә—ике галимнең хезмәтләрен чагыштырып тикшергәч ачыкланды. Х.Фәезхановның тарихи әсәрләре Мәрҗани китабының төрле өлешләрендә аерым-аерым өзекләр хәлендә дә, тоташ текст буларак та уңышлы һәм урынлы файдаланылган. Кайбер җөмләләрдәге сүзләр үзгәртелгән булса да (күпчелек очракта гади төрки-татар сүзләре гарәп һәм фарсы гыйбарәләре белән алыштырылган), Фәезханов кульязмасындагыча калган җөмләләр дә аз түгел. Әлбәттә, моңа карап төп фикерләр үзгәрмәгән. Фәезхановның кайбер җөмләләре «Мөстәфадел-әхбар...»да берничәшәр урында кабатланган очраклар да бар. Мәсьәлә аңлаешлырак һәм дәлилле булсын өчен киңрәк шәрехләп, кайбер мисалларга тукталыйк. Фәезханов хезмәтләрен Шиһабетдин Мәрҗанинең беренче кыйсем «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» китабы (1885 елгы басмасы) белән чагыштырып, кыскача күзәтү ясап үтик.

Хөсәен Фәезхановның «Казан тарихы» хезмәтендәге *«Бу хосуста кяфи вә кяфил булган вә шул гасырларда шул ук җирнең голәмасы тасниф кыйлган сахих вә мөфассаль тарих табылмасмы дип көтеп торсак, Аллаһу әгъләм, көтеп алмамыз шикле»* җөмләсендәге төп мәгънә сакланып «Мөстәфадел-әхбар...»ның 7 битендә үзгәртелебрәк һәм баетылып *«Имди тәварихе биляд вә вәкаигы әсляфымыз хосусында голәмаи мөтәкаддимин әсәреннән сахих вә мөфассаль вә шамил вә мөхассаль бәйане вафи вә максудка кяфи булган тарих китабын көтеп торсак, валлаһы әгъләм, мөяссәр улмас»* рәвешендә басылган. Ә шул ук «Мөстәфадел-әхбар...» китабында Казан ханлыгы тарихы тасвирланган урында (119 биттә) бу җөмлә *«Бу хосуста шул гасыр голәмасы тасниф кылган сахих вә мөфассаль, максудка кяфи булган тарих китабын көтеп торсак, валлаһы әгъләм, ул мөяссәр булмас»* дип бирелгән һәм бу очракта аерма тагын да азрак икәнлеге күренә. Фәезханов хезмәтеннән алынган өзек Мәрҗани китабының 7 битендә башланып 8 битнең яртысына кадәр, тел җәһәтеннән берникадәр үзгәртелеп дәвам иткән. Сүзебезне раслау өчен текстның бу өлешеннән мисалга тагын бер җөмләне алыйк. Фәезхановтагы *«Фаразан, андай тарих бер вакыт язылган булса да, ул заманда басма сәнагате булмаганнан нөсхәләре таралмай калып, Казан мәмләкәтенең башына килгән бәлаләр вә бөлеклекләр*

[1] Автор кульязмасында бу хезмәтнең исеме күрсәтелмәгән. «Борынгы Болгар ташлары» дигән шартлы атама безнең тарафтан куелды.

*арасында югалган булса кирәк»* жөмләсе «Мөстәфадел-әхбар...»да *«Вә бил-фараз... андаен эшләр садир улса да, ул заманда сәнагате табагатьләре улмадыгыннан нөсхәләре тәкәссер тапмай вә мөнтәшир улмай, Болгар вә Казан мәмләкәтемез өстенә килгән бәла вә фетнәләр арасында тәләф вә заигъ улдымы»* рәвешендә язылган. Шул ук жөмлә китапның 120 битендә Казан ханлыгын тасвирлаганда да кабатланган. Ләкин анда «...Болгар вә Казан мәмләкәтемез» диелмичә, бары тик «Казан мәмләкәтемез» дип кенә бирелгән.

«Мөстәфадел-әхбар...»ның 23 битендә чирмешләрнең «чуаш» сүзен «мөселман» мәгънәсендә кулланулары—татарларның «урыс» сүзен «христиан» сүзе белән тәнгәлләштерүләре кебек үк күренеш булганлыгы турындагы жөмләләр Фәезхановның «Борынгы Болгар ташлары» хезмәтендә бар. Аның борынгы ташъязмалар турындагы шул ук хезмәтенең бер өлеше «Мөстәфадел-әхбар...» китабында (27 битнең астан дүртенче юлыннан алып 29 битнең башына—5 юлга кадәр) урын алган. Фәезханов текстындагы *«...Хужасан дигән чуаш авылы бар, имеш. (Минем зыныма күрә, Хужасан Хужахәсән булмак кирәк). Шул авылның телләре хәзергәчә татарча, имеш. Әмма кием вә гадәтләре чуашча, хәтта риваять кыйлалар, моннан 80 сәнә кадәр мокаддәм анларның авылларында иске мәсжед тә бар икән. Имеш, хәзер христиан булмышлар»* өзеге «Мөстәфадел-әхбар...»да *«Хужахәсәннән тәхрифдер Хужасан дигән бер чуаш карьясе вар, лисаннары ару төрки*[2], *имеш. Әмма либас вә гадәтләре чуашча. Хәзердә исмән тәнассыр иткәннәр. Шул әтрафта улан татарларның әкъваленә бинаән, сиксән-туксан сәнә мокаддәм шул карьянең ташланган иске мәсжеде бар икән»* рәвешендә басылган. Бу өзектәге борынгы ташлар тасвирламалары, Шонгаты Өсте дигән урындагы болгар кабер ташларын рус авылына алып китеп чиркәү нигезенә салулары турында карт мөәзин сөйләгән хатирәләр дә Фәезханов кульязмасыннан алынганнар.

Болгар чоры ташларында очрый торган «алышу ире» һәм «яу ире» гыйбарәләренә бәйле «Мөстәфадел-әхбар...»ның 65 битендә язылган фикерләр дә Х.Фәезхановның 1863 елда рус телендә чыккан «Три надгробных Булгарских надписи» мәкаләсендә әйтелгән була.

Х.Фәезхановның «Казан тарихы» хезмәте «Мөстәфадел-әхбар...»ның 119–128 битләренә тулаем кереп урнашкан. Фәезхановның *«Казан ханлыгы моннан өч-дүрт йөз ел элгәре бик мәшһүр вилаятләрдән булса да, вә бу заманнарда Русия мәмләкәтендәге татар таифәсенең ма биһил-ифтихары вә мәркәзе гыйлем вә тәмәддене исә дә, аның әхвале кадимәсе гомумән, вә анда падишаһлык иткән ханнарның тарихы хосусан, безнең таифәмезгә бу замангача мәҗһүлият пәрдәсе астындадыр»* жөмләләре «Мөстәфадел-әхбар...» әсәрендә *«Казан мәмләкәте бу тарихтан дүрт йөз сәнә мокаддәмдә бик мәшһүр мәмләкәтләрдән улыб, хәзерге заманымызда безнең татар таифәсенең ма биһил-ифтихары вә мәркәзе гыйлем вә дәүләте тәмәддене исә дә, гыйльме тарих вә әййамен-наска галәме рәгъбәтләреннән һич вакыт әхваль вә вәкаигъләры бәйан вә забыт ителмәй, әхбаре кадимәсе гомумән, вә анда улан мөлүк вә голәма вә әкябире хаким вә саир әхвале кәнди таифәмезгә вә гайреләргә бер дә мәгълүм улмай, бил-көллиятән мәҗһүлият ситрәсе тәхтендә калган»* рәвешендә бирелгән. Бу мисал да әйтелгән фикерләребезне куәтли.

Иске Казанның кайсы урында булганлыгы хакында, Әтнә, Куәм, Киме һ.б. авылларның исемнәре килеп чыгышы турындагы фикерләр дә «Мөстәфадел-әхбар...»да Фәезханов кульязмасындагы жөмләләр белән бирелгән. Хөсәен Фәезхановның «Казан тарихы» әсәренең соңгы битләре сакланмаганлыктан, «Мөстәфадел-әхбар...» китабында 129–135 битләрдәге Казан ханлыгы тарихының ахыргы өлеше белән аның ни дәрәҗәдә тәңгәл килү-килмәве турында кистереп берни дә әйтеп булмый.

Х.Фәезхановның «Касимский ханлыгы» хезмәте дә «Мөстәфадел-әхбар...»ның 140–148 битләрендә тулысы белән урын алган. Ике текстны чагыштыру өчен бер жөмләгә

[2] Китапның 1989 елгы басмасында бу сүзләр «ар һәм төрки» дип ялгыш бирелгән. Чөнки, «ару төрки», ягъни тулаем, саф татар-төркичә дигән мәгънә дөресрәк. Текстта сүз барган төбәккә – Тау ягына ар (удмурт) халкының бернинди мөнәсәбәте булмаган. Шулай ук Мәрҗани кулланган төп чыганакта, ягъни Фәезханов текстындагы жөмләләрдә «ар» сүзе бөтенләй юк.

генә игътибар итик. Фәезхановтагы *«...рус чарлары Казанны алырга карар бирсәләр, ул сурәттә әгәр Казанны аламыз дип рус гаскәре белән вә рус чарынын исеменнән йөрсәләр, татарлар никадәр аз булсалар да, шөҗагате затияләре вә хәмияте динияләре сәбәпле, каннарынын бер тамчысы калгынча вә ахыр сулышка чаклы гайрәт итеп сугышсалар кирәк. Ул сурәттә Казанны алмак мөшкел булыр»* җөмләсе «Мөстәфадел-әхбар...» китабының 144 битендә *«Русия гаскәре үз падишаһлары исеменнән йөрсәләр иде, ул тәкъдирдә Казан татарлары никадәр аз булсалар да, шөҗагате затия вә хәмияте динияләре сәбәпле каннарының бер катрәсе калганча вә ахры нәфескә чаклы сугышсалар кирәк иде. Ул сурәттә Казанны алмак гаять мөшкел улыр иде»* рәвешендә урын алган. Фәезхановның бу хезмәтенең Нурдәүләт хан чорын тасвирлаганнан соңгы ахыргы битләре сакланмаган. Шуна күрә «Мөстәфадел-әхбар...»ның 148–150 битләрендә Касыйм ханлыгы турындагы бүлекнең ахыргы өлеше Фәезханов текстына мөнәсәбәте турында ни дә булса әйтергә читен.

Сүзебезне дәлилләү өчен монда тагын да күпләп мисаллар язу һәм өлешләп текстларын күчерүгә артык ихтыяҗ юк дип, шушылар белән чикләнәбез.

Фәезхановның «Казан тарихы» хезмәтенең «Казанның әхвале кадимәсенә даир берничә сүз» бүлегендә болгар халкының килеп чыгуы мәсьәләсе уңаеннан «Бу хосуста Болгар хакындагы мөхәрраратымызда *(язмабызда)* тәфсил иткәнмез, теләгән кеше анда карасын» дип язган. Бу сүзләрдән Х.Фәезхановның Болгар дәүләте турында да хезмәт язганлыгы ачыклана. Кызганычка каршы, аның тексты хәзергә табылмады. «Хәзергә» дибез, чөнки бер заман табылу ихтималын да кире кагып булмый. Х.Фәезхановның башка тарихи хезмәтләре, югарыда язылганча, «Мөстәфадел-әхбар...»да урын алганнар икән, Болгар турындагы хезмәте дә Ш.Мәрҗани тарафыннан кулланылган булуы мөмкин дип уйлыйбыз.

Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабына Фәезхановның тарихи хезмәтләре кертелгәнлеге мәсьәләсен хәзерге көн карашларынча гына бәяләп, сәерсенергә кирәкми. Әлеге очракта бер галимнең икенче галим иҗатына кул сузуы турында һич тә сүз була алмый. Безнең уебызча, бу турыда артык сүз куерту бөтенләй урынсыз һәм кирәксез. Чөнки Мәрҗани һәм Фәезхановның остаз-шәкерт буларак мөнәсәбәтләре гаять дәрәҗәдә эчкерсез, шулай ук тарих мәсьәләсендәге карашлары уртак, бер-берсенә йогынтылары һәм мөгамәләләре дә ихласлы булган. Фәезхановның Мәрҗанигә язган күп санлы хатларыннан күренүенчә һәм галимнәр язуынча да, алар арасында уртак максатка хезмәт итү өчен үзенчәлекле мөнәсәбәтләр урнашкан. Ягъни, остазы Шиһабетдин хәзрәтнең фәнни эшчәнлегенә шәкерте Хөсәен даими рәвештә тугрылыклы ярдәм иткән. Кульязма һәм сирәк басма китапларның аерым урыннарыннан өземтәләр күчереп җибәреп тә, сирәк хезмәтләрне табышуда да һәрчак остазының ышанычы, таянычы булган. Бу уңайдан Мәрҗанинең тормыш юлын җентекләп өйрәнгән Ш.Шәрәф сүзләре дә әһәмиятле: «Хөсәен әфәнденең Мәрҗани хәзрәтләренә дә күп хезмәтләре булган. Петербургта тордыгында *(яшәгәндә)* Казан вә Болгар тарихына даир байтак нәрсәләр һәм дә Шәрык телләренә махсус көтепханәдән бик күп нәрсәләр күчереп җибәргән. Күргән, ишеткән китаплары хакында мәгълүмат биреп торган. «Вафиятел-әсляф»ка дәреҗ өчен интихаб итеп *(сайлап)* язып җибәргән кәгазьләреннән без күргәне генә ике йөз бит микъдарында булыр[3]». Ш.Шәрәфнең «без күргәне» дию Мәрҗани биографиясен язу өчен галимнең китапханәсен өйрәнгән чагында күргән язмалар күздә тотыла. Бу да, шәкерте булышлыгыннан Ш.Мәрҗанинең киң файдаланганлыгын һәм үз хезмәтләрендә кулланып барганлыгын раслый. Шуңа күрә, Фәезханов вафат булганнан соң аның әсәрләрен остазы үзенә алдырып, «Мөстәфадел-әхбар...» китабына керткән икән, моны бары тик икесе арасында электән урнашкан гыйльми хезмәттәшлекнең дәвамы дип кабул итәргә кирәк.

**Раиф МӘРДАНОВ**

---

[3] Шәһәр Шәрәф. Мәрҗанинең халыкка хезмәт иткән мәшһүр шәкертләре // Мәрҗани: Виладәтенә йөз ел тулу мөнәсәбәтилә. – Казан: Мәгариф, 1915. – Б. 114.

# МӘҢГЕЛЕКТЕР СӘЙДӘШ МОҢНАРЫ

Без татарның атаклы композиторы Салих Сәйдәшев турында яхшы беләбезме?

Шактый гына нәрсәләрне укып-ишетеп беләбез дә кебек, ләкин аның тормыш юлындагы катлаулы, сикәлтәле юлларны бик күпләребез белми. Менә шушы «бушлык»ны тулыландыру өчен, ниһаять, дөньяга яна бер китап пәйда булды: Салих Шамов, «Мелодии судьбы народа», Казан дәүләт университеты нәшрияты, 2004 ел. Бу–авторның шәхси заказы белән чыгарылган китап, тиражы зур түгел, шуңа күрә ул әдәбият-сәнгатьне яратучыларның һәм барыннан да бигрәк укытучыларның барсының да кулына эләкмәскә дә мөмкин.




Менә шуны истә тотып, безнең журнал әлеге китаптан кайбер өзекләрне укучыларыбызга тәрҗемәи тәкъдим итәргә булды. Язманы укырга керешкәнче, әз генә булса да сүз башы әйтәсе килә. Композиторның исеме ничек горур һәм саф татарча яңгырый: Сәйдәш! 1990 елның декабрендә туып, 1954 елның декабрендә үлүе дә гаҗәп бер хәл. Кыскасы, ул–карлы-буранлы декабрь егете, «декабрист». Мин үзем йолдызнамәләргә бик ышанып бетмим, теләүчеләр булса, моны тикшереп-бәяләп карасыннар.

Ниһаять, татар дөньясы өчен, бик күп көрәшләрдән соң, соклангыч бер вакыйга: мәркәзебез Казан уртасында Салих Сәйдәшевкә һәйкәл куелды! Үзе әйткәнчә, ана бернинди дә исем-дәрәҗәләр кирәкми. Ләкин ул барыбер элек тә, хәзер дә–халык мәхәббәте лауреаты.

Мәгълүм булганча, Салих Сәйдәшев ике ут арасында яшәгән һәм иҗат иткән. Әлеге утның бер ягы аны халык мәхәббәте рәвешендә жылытып, янадан-яна көйләргә рухландырып торса, икенче ягы исә кайбер түрәләр тырышлыгы нәтиҗәсендә салкынлык, битарафлык, талантны күрмәмешкә салышу шаукымы белән дә уратылган иде. Нишләтәсен бит, зур талантлардан берсенең дә тормышы һәм иҗаты жинел юлдан бармаган.

Салих Сәйдәшев бәхетле булганмы?

Заманында язучыбыз Әмирхан ага Еники «Азат хатын» журналы аша бу сорауга азмы-күпме ачыклык кертkән иде. Яна китап авторы Салих ага Шамов та нәкъ менә шушы сорауга җавап эзли шикелле. Тулаем дип әйтергә тел әйләнми, әмма да ләкин композитор үзенчә бәхетле булган. Галел Кутуйның: «Сәйдәш–музыкадагы Тукаебыз ул!»–дип әйтүе генә дә ни тора... Бу канатлы сүзләр хәзер дә теллә рдән төшми. Композиторның якты-сагышлырак йөзеннән саркып чыккан тылсымлы-нурлы елмаюы да аның бәхетсез булмавы турында сөйли.

Сәйдәшев моннары язылган кайбер радиотасмаларны заманында Казансу елгасы буенда яндырсалар да, аның әле бик күп моннары исән калды һәм алар халык күнелендә мәнге яши. Үлмәс моннар тудырганы өчен халкыбыз рәхмәтле аңа.

Хәзер инде композиторның замандашы, аны якыннан белгән китап авторына сүз бирәбез.

**Рашат НИЗАМИ**

Салих
Шамов

# ЯШЬЛЕКНЕҢ ЕРАК ТАҢНАРЫ

*Бөек бәхет—калсаң кешеләрнең*
*Күңеленә кунган нур булып.*
*Якты хәтер булып, ләйсән булып,*
*чәчәк булып, моңлы җыр булып.*

1935 ел, август аеның гаҗәеп бер иртәсе. Менә шул чакта татар мәдәнияте әһелләреннән журналистлар, әдипләр, артистлар һәм җырчылар шәһәр читендәге матур бер урында сәйранча, бәйрәмчәрәк очрашу табынына җыйналганнар. Моны оештыру эшләре минем абыем, язучы Афзал Шамовка тапшырылган икән. Ул миңа әйтә куйды:

—Тере язучыларны күрәсең киләме?



Мин, 15 яшьлек үсмер, бу тәкъдимгә рәхәтләнеп, шатланып риза булдым, билгеле. Үзенең бер-берсен кабатланмас пассажирлары, андагы ыгы-зыгылары белән каршы алды безне пристань. «Красное знамя» дигән су трамвае үзенә сыендырганнан соң, без Ослан тавы якларына таба йөзеп киттек. Үзенең базарлары һәм казанлыларның ял итәргә яраткан урыны буларак дан тоткан Маркиз утраулары янәшәсеннән дә узып киттек.

Без таллыклар белән уратылган утрауларның берсенә килеп тукталдык. Янәшәдә генә үзенең аксыл-алтын комнары белән җәйрәп яткан пляж тирәсенә табын корып җибәрделәр. Азык-төлеккә илдә карточка системасы кертелгәннән соң табынның муллыгы шактый сизелә иде. Безнең ише яшь-җилкенчәккә читтәрәк шулай ук аерым табын кордылар.

Җитмеш ел элек булып узган бу вакыйгаларның һәммәсен дә еллар томаны аша караганда хәрефкә-хәреф хәтерләү мөмкин түгел, билгеле. Ул еллардагы шагыйрьләрнең ярсып-ярсып шигырь укулары, әдип һәм артистларның кайнар чыгыш ясавы, җыр-музыка агышлары—боларның һәммәсен дә төгәл генә хәтерләү мөмкин түгел, әмма байтак кына нәрсәләр хәтердә калган. Язучы Галимҗан Ибраһимовның Кырымда шифаханәдә яткан чагы, аңа матди ярдәм күрсәтү, 4 томлык сайланма әсәрләрен бастыру һәм башкалар турында сүзләр хәйран күп булды.

Афзал абыем моның өчен җаваплы итеп билгеләнгән икән.

Шәриф ага Камалның сөйләгәне бик нык истә калган: тыныч-салмак тавыш белән сөйләгәндә Г. Ибраһимов иҗатына карата хөрмәте сизелеп тора.

Кәрим Тинчуринның йөзендә һәрчак диярлек елмаю балкый. Ул бик яшь, гайрәтле күренә. Шәриф Камал аңардан 2-3 кенә яшькә зуррак булса да, аңа нигәдер еш кына аксакал дип эндәшәләр иде.

Сәйранда үзенең төс-кыяфәте белән аеруча аерылып торган Фатих Сәйфи-Казанлы, ханымнарның игътибар үзәгендә торган Фәтхи Бурнаш, куак артларына кереп, еш кына затлы шәраблар белән табындашларын шаккатыралар иде.

Ул чакларга хас булган аксыл чалбар һәм калын киндер туфли кигән Хәсән Туфан волейбол кырыннан чыкмас иде. Шунысын да әйтим, аның көләч-ягымлы

елмаюлары Себер сөргеннәрен кичеп кайтканнан соң шактый нык үзгәргән иде.

Тәнкыйтьче Гомәр Галинең гадилеге, күз карашының матурлыгы, терекөмеш кебек житезлеге истә калган.

Менә шул чакларның берсендә без—шахмат тактасы артында көч сынашып утырган үсмерләр—бер нәрсәгә игътибар иттек: өлкәннәр өстәлендәге «оратор»ларның берсе «Сәйдәш ул—музыкабыздагы Тукай!» дигән сүзләрне һавага чөйде... Бу канатлы сүзләр минем хәтеремә мәңгелеккә урнашып калды.

Абыем Афзал ул чакларда көндәлек алып барган икән. Берзаман бик күп дусларын, каләмдәшләрен НКВД Черек күлгә алып китә башлаган. Борчулы төннәрдә «кара козгын» машинасы үз өенә дә килеп керүеннән шикләнеп, ул әлеге язмаларын (ни кызганыч!) яндырган, көлгә әйләндергән...

Сәйдәшкә карата мәхәббәт, соклану сүзләре дистәләрчә еллар буена татар әдәбиятының күренекле әдипләре теленнән төшмәде. Партократия һәм көнчел бәндәләрнең ничә дистә еллар буена дәшми утыруына карамастан, әдипләрнең абруйлы сүзләре әлеге күрмәмешкә салышу киртәләрен барыбер җиңеп чыкты! Мәдәниятебезнең язмышын, киләчәген билгели торган 20-30 елларда (XX гасыр) әдәбият әһелләре халыкыбызның рухи символы һәм байрагы итеп Тукай, Сәйдәшне күтәрделәр, инде килеп 90-95 елларда Гаяз Исхакыйның исемен шулар янәшәсенә бастырдылар—бу бәягә, батырлыкка сокланмый мөмкин түгел.

Мин бу кечкенә генә хезмәтемдә композитор Салих Сәйдәшевнең иҗатын колачлауны максат итеп куймадым. Бары тик хатирә-истәлекләремне уртаклашасым, ярты гасыр узганнан соң да бу якты шәхеснең исеме, иҗаты яшәвен, рухының бөеклеген раслыйсым килә. Үзе исән чагында һәм инде үлгәне соңыннан да күп нәрсәләрнең әйтелмәве, йозак астында бикләнүе хакында әйтеп каласы килә. Хәтта кайбер замандашлары аңа тормышының кыен чагында кул сузмаганын истә тотып, минем бу язмамны безнең буынның бөек композитор алдында тәүбә кылуы, җан әрнеше, дөреслеккә тәрәзә ачуы дип тә аңларга тырышуларын телләр идем. Үз вакытында Сәйдәшне аңламаска, кабул итәргә тырышмаучы чиновниклар бакчасына сәламәт тәнкыйть «ташлары» ыргытыла, икән, моны һәркем дөрес аңласын.

Хәзер, дөреслеккә һәм матбугат ирегенә юл ачылгач, өлкән буыннан бик күпләр җанланып китте, күргән-белгәннәрен ихластан яза башладылар. Чыннан да, әгәр без—Сәйдәш заманының соңгы могиканнары—дәшми калабыз, татар халкының бөек улы-композиторы, аның тормышы һәм иҗаты турындагы драманы сөйләп калмыйбыз икән, мәдәният тарихындагы байтак сәхифәләр килер буыннар өчен күләгәдә торып калачак. Безне тарих гафу итмәс, зыялыларыбыз да, Сәйдәш моңнарына алкыш яудыручы тамашачылар да кичермәс. Дөрес, композитор турында аның байтак кына замандашлары истәлекләр язды анысы. Ләкин боларның барысы да, маэстро язмышындагы авыр, драматик сәхифәләрне әйләнеп узып, бары тик аның тормышындагы якты сәхифәләрне яктыртудан гына гыйбарәт иде. Композиторның иҗаты, халык арасында популярлык казануы хакында язу—бик җиңел юл, моны шәрехләп тору кирәкмидер...

Аның турында дөресен язу тыелган иде. Ә менә үзе исән чагында, вафатыннан соң да аның иҗатын, шәхесен түбәнәйтү өчен «өстәгеләр» тарафыннан барлык куштаннар өчен юл ачылган иде. Хәтта түрәләр каршында дер калтырап торган профессорлар да Сәйдәш турында чын дөреслекне әйтергә, язып чыгарга батырчылык итмәделәр. «Хуш авылым!» җырын җырлап дан казанган артистлар да авызына су каптылар.

Инде ирек җилләре исә башлагач та Сәйдәшнең драмасы тукталмады. «Сәйдәшкә һәйкәл салу» фондына 1990—1992 елларда халыктан, төрле оешмалардан зур акча (165 мең сум) җыйналып та, чиновникларның кул тыгуы нәтиҗәсендә, әлеге сумма серле рәвештә юкка чыкты.

Кульязмалар янмый, дигән канатлы сүзләрне һәркем беләдер. Татар опера һәм балет театры архивында Сәйдәшевнең үз куллары белән язылган «Гөлнара» балеты партитурасы табылды. Без горурлана торган Шаляпин фестивалендә инде дистә еллар буе төрле музыка үрнәкләре яңгырый. Ә менә шәһәребезнең музыка сөючеләре «Гөлнара» балетындагы соклангыч музыканы һәм борынгы болгар биюләрен кайчан күрерләр һәм тыңларлар икән соң?

Композитор Фасил Әхмәтовның 1995 елны Рөстәм Яхинны искә алу кичәсендә: «Әгәр зурлыгы, матурлыгы, музыкаль мирасының әһәмияте ягыннан безнең

композиторларны бер сафка бастырсак, беренчесе—Сәйдәш, икенчесе, һичшиксез, Рөстәм Яхин булыр»,—дигән иде. Кайбер мөтә-профессорлар: татар профессиональ музыкасы бер төркем иҗатчылар эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килде, дигән ялган юраманы музыка белеме сәхнәсенә күтәреп маташкан чагында Ф. Әхмәтовның аларга кискен каршы чыгуы, бу мәсьәләдә Сәйдәшевнең беренчеләрдән юл ячучы икәнлеген раславы бер дә гаҗәп түгел. Һәрхәлдә, кыю фикер, дөреслекнең күзенә карап әйтсәң генә, кыю яңгырый.

## Кайбер сәхифәләр

1939 елда Татарстан композиторлар союзы оешканнан соң, төрле сәбәпләр аркасында, С. Сәйдәшев иҗатына карата мөнәсәбәт шактый суына. Иҗат коллективларының репертуарында аның әсәрләре һаман саен азрак яңгырый башлый.

Бу җәһәттән ВКП(б) обкомы да үзенең ролен уйный, билгеле. Композиторның гаҗәеп таланты ачылган, ныклап аякка баскан бер вакытта большевизмның җимергеч идеологиясе, тоталитаризм, кешесенә карап бәя бирүдәге тайпылышлары, әшнәлек ысуллары аның иҗатындагы чәчәк ату чорына ясалма киртәләр коруны бер дә кызганып тормый.



*Кәрим Тинчурин һәм Салих Сәйдәшев. Үткән гасырның утызынчы еллары.*

Шөкер, менә шундый шартларда да танылган дирижерлар И. Әүхәдиев, А. Абдуллина һәм Н. Рахлин Сәйдәшнең иҗат мирасына игътибар итәргә кыюлык табалар. Рәхмәт аларга!

Сирәк яңгыраса да, өлкән буын һәм яшь талантлар тарафыннан аның әсәрләре сәхнәләрдә зур осталык белән башкарыла. Атаклы җырчыбыз Фәхри Насретдинов 1956 елны ул чактагы Камал театрында «Наёмщик» спектакленнән Батырҗан ариясен башкара. Сәхнәдә һәм галеркадагы хәлләрне гади сүзләр белән генә аңлатырлык түгел! Халык моңнарына сусаган тамашачы үзенең яраткан артистын алкышларга күмә һәм кабат-кабат сәхнәгә чакыра...

Шушы ук концертта әле сәхнәгә күтәрелеп кенә килүче, үзенең әсир иткеч тавышы белән залны тетрәтүче яшь җырчы Илһам Шакиров тарафыннан «Кандыр буе» дигән җыр да башкарыла. Ә инде соңрак, халкыбызның атаклы җырчысы булып танылгач, Сәйдәшнең «Зәңгәр шәл» мелодраммасыннан «Кара урман» көе яңгырагач, Камал театрының шыгрым тулы залында күз күрмәгән тамаша күзәтелә: озакка сузылга көчле кул чабулар, «афәрин» дип соклану авазлары, кабат-кабат җырны ишетергә теләүләр... Менә шулай итеп, композитор һәм җырчының «гаебе» аркасында, спектакльнең барышы тамырдан үзгәрә!

Бервакытны менә мондыйрак хәлләр дә килеп чыга. 70-нче елларда Ташкент шәһәре Татарстан дәүләт филармониясе артистларын үзенә чакыра һәм аларга өч мең кеше сыйдырышлы залны бирә. Туп-тулы аншлаг. Ярым караңгы залда тынлык. Кинәт вулкандай ташып чыккан көчле кул чабулар: сәхнәдә бик ышанычлы адымнар белән төз гәүдәле Илһам Шакиров пәйда була! Кояшлы елмаю һәм тамашачыларга баш июдән соң яңадан тынлык урнаша. Менә «Наёмщик» драмасыннан беркайчан үзенең көчен, дәртле сагышын югалтмый торган Батырҗан ариясе яңгырый башлый. Беренче куплетның соңгы ноталары залга тарала... Бер мизгеллек тыналыш (пауза), чебен очкан тавыш та ишетелми. Ләкин очраклы рәвештә каяндыр килеп кергән ялгызак шөпшә генә үзенең «бас» тавышы белән залны сискәндерә. Шул мизгелдә «Рәхмәт сезгә, илнең батыр егетләре...» дигән

моннар түгелә. Нәкъ шул чакта түшәмдәге люстраның йөзләгән бәллүр кыңгыраулары, бер-берсенә бәрелеп, ягымлы нәфис авазлар тарата. Һәм бу авазлар баритон тавышлы җырчының:

*«Иртән искән җилдән хәбәрләр көтәм»,–*

дигән сүзләренә кушылып китә... Моны ничек, нәрсә белән аңлатырга?

Җырчы, сәхнә артындагы артистлар, зал тулы тамашачылар концерт беткәннән соң гына бу кыңгыраучыкларның үзара зеңләвен җир тетрәү нәтиҗәсендә килеп чыкканлыгын белеп алалар. Әлеге дә баягы шөпшә, күрәсең, бу хакта алданрак «сизеп» өлгергәндер... Шушы хәлне белгәч, Сәйдәш моңнары белән сихерләнгән тамашачылар тагын бер кат гаҗәпкә калалар. Чын сәнгать әсәренең көчедер бу. Әллә инде Шәрыкның меңъяшәр тау катламнарын Илһамның илаһи тавышы уятты микән ул чакта? Ни генә булмасын, игътибарга лаек серле вакыйга бу!

## Даһига киртәләр бар һәм юк

1948 елның көзе. Камал театры афишаларында Тажи Гыйззәтнең «Наёмщик» мелодрамасы күрсәтеләчәге турында хәбәрләр, ниһаять, күзгә чалына. Хәтердә: утызынчы еллардагы искиткеч уңышлы куелышлардан соң аның инде дистә еллар буе сәхнәгә менгәне юк. Ләкин Батырҗан һәм Гөлйөзем арияләре әле дә булса халыкның хәтерендә саклана. Мелодраманың яңа редакциядәге куелышы шуны раслый: юк, бөек талант сынып-сыгылып төшмәгән, ул яңадан күтәрелеп басты һәм республикабызның музыкаль тормышында үзенең элекке урынын яулады! Сәйдәш талантына баш иючеләр үзләренең кумиры музыка сәнгатенә әйләнеп кайтуын, драманың зур уңыш белән баруын зур сөенеч белән каршылыйлар. Әле бит аның илле яше дә тулмаган.

Сугыштан соңгы авырлыкларны күп кичергән кешеләрнең һәммәсе дә спектакльне карап өлгермиләр, әлбәттә. Билетлар иркенрәк буласын көтеп торучылар да аз булмагандыр. Ләкин, тамашачылар һәм композиторның үзе өчен дә билгесез сәбәпләр аркасында, театр сезонының башында ук мелодрама репертуардан төшерелә һәм 1990 еллар ахырына кадәр алдагы буыннар өчен билгесезлек хәлендә саклана.

Без, педагогия институтының тарих факультеты студентлары, 1948—1950 елларда композиторны авыл хуҗалыгы институты каршындагы бакчада еш күрә идек. Пөхтә киенгән, әмма гел диярлек боек күренә. Күңеленең ул чактагы әнә шундый боек, төшенке чаклары, бәлки, әнә шушы вакыйгалар белән бәйле булгандыр?..

Наёмщик»ның сәхнәгә кабат әйләнеп кайтуын без кырык елдан артык көттек. 1989 елны, композиторның чираттагы юбилеена әзерлек башлангач, мин республиканың мәдәният министрлыгына шушы мәсьәлә буенча махсус мөрәҗәгать иттем. Алардан ямьсез-күңелсез бер җавап алдым: «Наёмщик»ның партитурасы югалган икән... Гаҗәеп хәл! Көнбатышта хәтта Эллада һәм Ренессанс шедеврлары да сакланган, ә партиянең татар обкомы идеологлары Сәйдәшнең шушы бәяләп бетергесез мирасын 50-70 нче елларда чүплеккә чыгарып ташлаганнар.

Тагын шунысы да гаҗәп: искеләренә алмашка яңа чиновниклар аппараты килгәннән соң, алар «Наёмщик»ның югалуына шулай ук тамчы да игътибар бирмәгәннәр. Югалды—бетте-китте... Бервакыт мин Дәүләт филармониясе китапханәсендә эшләүче Фатыйма Вәлиева белән әлеге «югалган хәзинә» турында әңгәмә кузгаттым. Композиторлар союзы китапханәсендә эзләнә торгач, аның зирәклеге ярдәмендә, кыйммәтле партитураны табу бәхетенә ирештек, ниһаять. Бу—Сәйдәшевнең якын дусты, танылган скрипкачы Мөхәммәт Яушев тарафыннан осталарча һәм зур мәхәббәт белән башкарылган нөсхәләрдән берсе булып чыкты. Моңардан чыгып, шуны әйтәсе килә: большевизмның байтак кына «киртәләр» куюына карамастан, әнә шул шартларда да чын сәнгать әсәрен саклау, яшәтү, аны рухи мохиткә якынайту турында ихластан кайгыртучылар табыла торган. Чиновниклар сафыннан ерakта торган Мөхәммәт ага Яушев—шундыйларның берсе.

Хәтерлим: 1950 елның декабрь башында кичке аш табынына утырып, концерт тыңлыйбыз, радиодан исә С. Сәйдәшевнең 20-30 нчы еллар хәзинәсеннән без

яраткан таныш җырларны тапшыралар...

Ләкин алар инде элекке матурлыгын югалткан, икенче бер авторларның чит-ят текстлары да табигый яңгырамый, без бит, ни әйтсәң дә, яшьлектә драматург Кәрим ага Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Ил», «Кандыр буе»ндагы сүзләрен тыңлап үскән буын.

Шулвакыт, ишекне йомшак кына шакып, Афзал абыем эштән кайтып керде. Аяк очларына гына баса-баса табынга утырды һәм дәшми генә музыка авазларына йотылды. Кече сеңлебез Сара апа түзмәде, әйтә куйды: «Безнең буын Тинчуринны гына белә, без аның сүзләрен генә яхшы беләбез!» Музыка тынганнан соң үзенең йомшак-бәрхет тавышы белән Афзал абыем безгә өр-яңа шатлыклы хәбәр җиткерә. Ул безгә 3 декабрьдә 50 яше тулачак Сәйдәшевнең юбилеен үткәрү турында сүзләр барганлыгын әйтә куя. Бер фактны өстәве истә калган. Язучылар союзыннан: «Композиторның юбилее уңаеннан нинди чаралар үткәрергә җыенасыз?»—дигән соравына: «Мондый мәсьәләне ВКП(б) обкомы хәл итә...»,—дигәнрәк җавап ишетәләр. Аңлатма бирү кирәкмидер.

Сәйдәш иҗатына сокланучы, Казандагы 89 нчы татар урта мәктәбе директоры Фатыйма Шамованың түгәрәк өстәл артында әйткән сүзләре бик тә гыйбрәтле. Ул болай дигән иде: «Оятыбызга күрә, без Сәйдәшнең илле еллыгын аның туган көне узып киткәннән соң гына беләбез. 3 декабрьгә кадәр үк инде бөтен җирдә, барлык татарларның бөек композиторы буларак, аның хөрмәтенә тантаналар үткәрелергә тиеш булгандыр. Нишләп моны оныттылар, истән чыгардылар икән!»

Мондый хәлнең килеп чыгуына барыннан да элек хөкүмәт даирәсендә утырган, мәдәният-сәнгать өчен җаваплы булган уртакул түрәләр һәм, әлбәттә, композиторлар союзы гаепле. Афзал абый, безнең алда гаебен йомшартырга теләгән шикеллерәк, соңрак болай диде: «Бу уңайдан Мирсәй Әмир ВКП(б) обкомының икенче секретаре Салих Батыев белән очрашты, ләкин аның мөрәҗәгатенә хәзергә берниндн дә җавап юк».

Безнең «түгәрәк өстәл» артында сөйләшү шактый кискен дәвам итте. Директоршабыз һаман бәхәсләшә бирде: «Батыев—соңгы инстанция түгел. Юбилей мәсьәләсен Мәскәүгә кадәр җиткерергә кирәк. Бу бит илдәге бөтен татар культурасына кагылышлы вакыйга. Аңа Ленин орденын бирергә бик вакыт!..»

Анлашыладыр, Сәйдәшнең юбилеен үткәрү мәсьәләсе безнең түгәрәк өстәлләр артында хәл ителмәде. Бу хакта сөйләшүләр республикабызның рухи тормышына да бик тиз үтеп керә һәм моның авазлары югарыдагы даирәләргә дә барып ирешә. Әмма, «югарыдагылар» дәшмәү аркасында, тынлыкны шагыйрь-фронтовиклар Мәхмүт Хөсәен, Мөхәммәт Садри, Әнвәр Давыдов, Сибгат Хәким боза. Композитор Җәүдәт Фәйзи дә үз сүзен өздереп әйтә. Киң катлам җәмәгатьчелекнең бу теләген Татарстан обкомының ул чактагы беренче секретаре Моратов хуплый. Бераз соңлабрак булса да, 1951 елның гыйнварендa Салих Сәйдәшевнең 50 еллыгын республика күләмендә үткәрү турында карар кабул ителә.

Менә шушы тантаналы кичә бара. Фронтовик-шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә дә сүз бирәләр, ул үзенең чыңлап торган дәртле тавышы белән «Син татарның Чайковские» дигән өр-яңа шигырен укый. Көчле кул чабулар күпне күргән театр диварларын дер селкетә!

Тантананы алып баручы яшь артист Айрат Арсланов шагыйрьнең исемен тамашачыларга тәкъдим итә. Кыска гына тынлык арасында кемнеңдер: «Бу маңка малайны кем сәхнәгә чыгарды икән!..»—дигән сүзләре ишетелеп ала. Баксаң, алар икесе—Мөхәммәт Садри белән бергә, расланган программадан тыш чыгыш ясаганнар икән!

Үзенең юбилеенда көләч елмаюы һәм зәңгәр күзләренең якты балкышы белән тамашачыларны сөендергән Сәйдәш бик бәхетле сәгатьләрен кичерә бу тантанада.

Ләкин, кояшлы бәйрәмнәрдән соң, болытлы көннәр дә озак көттерми. 1952 елның җәендә «Совет әдәбияты» журналында, исеменнән үк күренгәнчә, «Салих Сәйдәшев иҗатына карата» дигән бик тенденциоз мәкалә басылып чыга. Татар профессионал музыкасына нигез салучыны әле музыка дөньясында исемнәре дә «атаклы» булмаган З. Хәйруллина һәм Ч. Бәхтиярова тәнкыйтьләп чыгарга батырчылык итәләр, аның иҗатын күрәлмәтә түбәнәйтергә тырышалар.

Мәкаләне укып чыкканнан соң мин язучы абыем Афзал Шамовтан: «Шундый

житди журналда ничек инде Сәйдәшевкә карата яла ягу мәкаләсе чыгарга мөмкин?»—дип сорадым. Аның әйткәне якынча болайрак иде: «Мәкалә редакция портфелендә бик озак яткан, аны басарга теләмәгәннәр. Ләкин обкомның икенче секретаре С. Батыев редакторны партия өлкә комитеты карарын үтәмәүдә гаепли башлагач, ул аны ирексездән бастырган».

1952 елның азагындарак С. Сәйдәшев белән «Совет әдәбияты» редакторы Гази Кашшаф очрашалар. Әлеге мәкаләгә карата җавап сүзе әйтүен үтенгәч, композитор болай ди: «Рәхмәт тәкъдимегез өчен. Ләкин алар белән көрәшергә минем көчем дә, мөмкинлегем дә, теләгем дә юк».

Шунысын да искә төшерик: Фәтхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин драматургиясенә озак еллар буе тышау салу, аларның рухи дөньябыздагы алтын фондын күрмәмешкә салышуны Салих Сәйдәшев бик авыр кичергән. Мораль-сәяси басымнан тыш, икенче уйласаң, бу бит аның матди хәленә, яшәү рәвешенә дә билгеле бер йогынты ясаган.

Салих Сәйдәшев белән Галия Кайбицкаяның дуслыклары ихлас һәм озын гомерле була. Атаклы җырчы ханымга композиторның триумфаль адымнарын да, иҗатында һәм шәхси тормышындагы драмаларын да якыннан күрергә туры килә.

1953 елның кояшлы җәендә пароход белән «Кызыл Байрак» дачасына барганда миңа С. Сәйдәшев белән очрашырга туры килде. Минем тарих укытучысы икәнлегемне белгәнлектән, ул, яшьләр безнең борынгы бабаларыбыз—Идел буе болгарларының данлы үткәнен беләләрме, диган сорау бирде. «Ул тема уку-укыту программасыннан алып ташланган»,—дигәч, композитор кинәт моңсуланды һәм тетрәнеп калды шикелле.

Мин моның сәбәбен фәкать 1990 елны кө тмәгәндә танылган балетмейстер Гай ага Таһиров белән очрашып сөйләшкәннән соң гына аңладым. Алар, бергәләшеп, Идел буендагы болгарларның героик үткәннәре турындагы легенда сюжетларына нигезләнеп, балет язарга ныклап керешкәннәр икән... Бу хакта нигә бер дә сөйләмиләр, балетның тарихы кайсы юлларда ничегрәк туктап калды икән?..

*Дәвамы бар.*

---

## Авторлар игътибарына

Редакциягә кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълүматлар булу мәҗбүри:

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. ИНН номеры
8. Вертикаль портрет рәвешендәге яхшы сыйфатлы фоторәсемегез
7. Телефоныгыз (шәһәр кодын да күрсәтеп)

*Узган елгы 3 нче санда Рәйсә Юсупованың «Ак сагыш иясе» исеме белән күренекле драматург, «Зөбәйдә—адәм баласы», «Әни килде», «Мәхәббәт сагышы» кебек мәшһүр әсәрләр авторы Шәриф Хөсәенов турында очерк-хатирәсе басылган иде. Без ел дәвамында укучыларыбыздан рәхмәт сүзләре ишеттек. Күпләрне әдипнең тәүге һәм бердәнбер мәхәббәте—Зөлфә язмышы да кызыксындырды. «Исән-саумы икән?..» дигән сораулар еш кабатланды, «тапсын иде аны автор» кебек теләкләр белдерелде.*

*Шул ук авторның «Күкләрдән иңгән мәхәббәт» дип исемләнгән ошбу язмасында әлеге һәм башка күп сорауларга җаваплар бар.*

Рәйсә
Юсупова

# КҮКЛӘРДӘН ИҢГӘН МӘХӘББӘТ

ОЧЕРК-ХАТ

...Ничәнче көн инде, ничәнче ай... мин очрашуларыбызны барлыйм, сөйләшкән сүзләребезне күңелдән кичерәм, һаман сине юатам, Зөлфә! Күз алдымда һаман сагыш-моң белән мөлдерәмә күзләрең—Шәриф атлы унсигез яшьлек үсмерне һушсыз иткән һәм аны ярты гасыр эзәрлекләгән күксел-яшькелт күзләр...

Бу күзләрдәге ул моң җаныңа гына сыеша алмаган сагыш булып сүзләреңә дә түгелде. Һәм аның кайтавазы әле дә тынгы бирми, миңа бүген дә яңадан-яңа сораулар туа, ә күңел... Күңел синең эздән үткәннәргә йөгерә-йөгерә аларга җавап эзли, ярый әле син табылдың дип юана, исән-сау булуыңа сөенә.

...Ә бит табылуына өметем бик аз иде. Минем үтенеч гозерләвемә каршы Шәриф Хөсәеновның җан дусты Суфия Мифтахова болай диде: «Ай-һай, табылыр микән; миндә берәүнең дә адресы юк бит. Институтны тәмамлавыбызга 50 ел тулу уңаеннан 2003 елны җыелышуыбызга да бик аз кеше килде: кемдер дөньядан китеп барган, кемнеңдер—сәламәтлеге юк, кемнеңдер акчасы дигәндәй. Юл чыгымнары гына да әнә нинди—врач пенсиясе күтәрә алырлыкмыни?!»

Өч-дүрт ай мин гел өметсезлектә яшәдем.

Җәйге чиллә көннәреннән берсендә, бөтенләй көтмәгәндә, телефоным аша мин Суфия ханымның көр тавышын ишеттем. «Сөенче! Гозереңне үтәдем,—диде ул. Аннары, әйтәсе хәбәренең түбән-дәрәҗәсен белеп кенә:—Минем бакча күршем ашта Зөлфәләрнең гаилә дусты белән танышкан; каләмең кулыңдамы—телефонын яз»,—дип өстәде.

—Зөлфә телефонымы? Тәгаен генә—Зөлфәнекеме?!..

Минем күгемдә җиде төсе белән салават күпере балкыды.

Мин шул ук җомгада синең белән элемтәгә кердем һәм... һәм сине үземә чакырдым. Шимбә-якшәмбедә кызыңның оныгы белән утырачагыңны әйтеп, син дүшәмбе килергә булдың. («Син» диюемә үпкәли күрмә. Шәриф өчен кадерле булган кеше—миңа да кадерле. Ә кадерле кешемә мин «син» дип эндәшәм.)

...Инде менә... сине көтәм. Газета-журналлар караштырам, телевизорның әле бер, әле икенче каналын кабызам, ә күңел... күңел—тәрәзәдә. Күңел генәме соң, инде үзем дә тәрәзә янында...

Ишегалды манзарасын күз берьюлы колачлый: балалар мәйданчыгында комлыкта кайнашучы сабыйларны да, ике кулына зур-зур ике сумка тоткан ханымны да, житәкләшеп йөгерүче кыз белән егетне дә һәм... Чү! Йортның ә-нә теге башында... таякка таянган әби... аягын көчкә-көчкә өстерәп монда таба килүче... Зөлфә түгелме, Ходаем?!..

Күзәтүемне кыңгырау чыны бүлә, һәм мин, таяклы әбидән аерылып, ишеккә ташланам.

Анда, ишегем янында, үзенә бик тә килешле кызыл блуза белән кара чалбар кигән сөйкемле ханым... таныш чалымнары белән кемнедер хәтерләтеп, мина исемем белән эндәште. Шул мәлдә мин Шәрифнең «Мәхәббәт сагышы» повестенда тасвирланган күзләрне танып алдым: Мәдинә-Зөлфә күзләре! (Бу күзләргә бүген 77 яшьне—жә, кем бирсен!?) Косметика-мазар кагылмаган шоп-шома йөз, артка тарап жыелган озын чәч, сыгылмалы, уртача буй-сын, жыйнак гәүдә һәм... һәм табигый гармония!

Менә нинди икән син —бөек драматург тууга сәбәпче Зөлфә—мәңгелек мәхәббәтнең тере легендасы!

...Бүлмәгә узуның тәүге мизгелендә үк син: «Күкләрдән иңгән язмышым инде ул,—диден дә күкләргә бактың. Ә аннары:—Шәрифем үзе белән иң кадерле кешеләремне дә алды; Казанга кайткач биш ел эчендә биш кешемне югалттым: улымны, апам, абыемны, туганнан туган кардәшләремне. Улымны... бигрәкләр дә ярата идем»,—дип өстәдең. Һәм шундук, аклангандай, болай дип дәвам иттең: «Ә бит мин Самарадан да Шәрифкә якынрак булырмын дип кайткан идем. Квартирыбызны да Ул яшәгән йорт тирәсеннәнрәк эзләттем. Аны ирем белән таныштырырмын да, бергәләп театрларга йөрербез диеп уйлаган идем.

И-и, өмет! Сонарган өмет!..

Юатырдай сүзләр тапмагангамы, мин синең алдына «Шәрифең» архивында сакланган фотосурәтләрне өям.

Менә кулына Шәрифнең яшь-яшь сурәтен аласың да сискәнеп китәсең. Бу аның Мәжнүн кебек сиңа гашыйк булган чагыдыр, мөгаен...

Кайберләренә күз генә сирпеп, кайсыларында озаграк тукталсаң да, фотолар өеме кими бара, кими бара. Менә тагын берсенә үреләсең дә... кинәт корт чаккандай кулларыңны селки-селки, өемне читкә этәрәсең. Ә өем өстенә бармакларың арасыннан бер сурәт оча. Күрәм: Шәриф әфәндененң соңгы елларында төшкән фотосы бу. «Күрсәтмәгез,—дисең син, катгый рәвештә.—Минем Шәрифем түгел бу! Түгел! Түгел!!! Мин мондый Шәрифне белмим.»

Ходаем, кемнәргәдер рәнжисең, кемнәрнедер гаеплисең түгелме соң, дип уйларга да өлгермим, син йомшый төшеп: «Шулай тазардымыни соң ул?»—дип куясың.

Күңелеңне ничек күрергә белми, мин янә «архив капчыгы»на тыгылам. Кулыма Шәрифнең «Зөлфәгә» дип исемләнгән мәхәббәт шигырьләре эләгә. Мин бу «хәзинә»не сиңа сузам.

Кулларында шигырь битләре дереллэп-дереллэп алгаласа да, киеренкелек кими төшә, йөзең жылына бара, яктыра бара, ниндидер бер таныш чалымнарга күмелә бара. Шул мәлдә тел очымнан: «Үзеңне шушындый яратучы барлыгын белә торып ничек башка кешегә кияүгә чыга алдың син?!»—дигән сүзләр ычкына.

Син каушый төшәсең. «Ул яратучы... хыянәтче булсадамы?—дисең дә, үзең әле генә укыган шигырь дәфтәренә текәләсең.—Әни миңа гел «кире бетхән», «тискәре» дия иде. Әнә шул кирелегем хыянәтне кичерә алмады.»

Хыянәтне?!..

Минем бигүк ышанып житмәвем ачуыңны чыгара. Һәм син аңлатып бирүне кирәк табасың. «Аның беренче әсәре—«Профессор кияве»н без бергәләп яздык: соңгы курсларда укыганда, Үзәк китапханәдә. Шәриф яза тора, ә мин укый барам, фикерләремне әйтәм... Ә спектакльгә репетицияләр башланган көннәрдә...—дисең дә, әйтергәме-юкмы дигәндәй, тукталып аласың.—Әйе, әнә шул көннәрдә аның миңа карата суынуын тойдым. Ә бераздан—хыянәте... Моны үз күзләрем белән күрдем!—дисең син, сүзләреңә боз салкынлыгы салып.—Премьера көннәрендә ул

үзе мине аның белән таныштырды. Ул... ул мине аңа (героиняны уйнаучы артистка Рауза Уральскаяга—Р. Ю.) «менә—«Профессор кияве» героинясының прототибы шушы инде» диеп, илтифатсыз гына, алай гына да түгел, ә нииндидер бер пренебрежение белән тәкъдим итте»,—дисең нәфрәт катыш, исемнәр урынына да «ул», «аның», «аңа» алмашлыкларын гына кулланып. Аннары, йөрәгеңне тырнаган шул күренешне куарга теләгәндәй, башыңны күтәрә төшеп: «Бу чакта ул—бөтенләй ят кеше—минем Шәрифем түгел иде инде»,—дип, олы бер сызлану белән нәтиҗә ясыйсың.



*Студент чак.*
*Шәрифкә 19 яшь*

...И-и, Зөлфә, Зөлфә!.. Шәрифеңнең хыянәтен, дөресрәге, аның Камал театры артисткасы Рауза Уральская белән мавыгуын түгел, сөйгән егетеңнең бу актриса алдында үзенә кимсетүле карашын, ягъни «пренебрежительный» мөнәсәбәтне кичерә алмагансың син. Һәм җаның әле һаман (ярты гасыр үтеп тә!) җәрәхәтле синең... Хәер, мондый түбәнсетүне берәү дә гафу итә алмый. Ә «хыянәтне», мавыгуны, ялгышып алуларны хатын-кыз кичерә ул. Кичермәсә... кичермәсә, өйләнешүчеләр сирәгәер, гаиләләрнең дә 90-95 проценты җимерелер, ялгызлар белән җир йөзе тулар иде. Йә, кайсы ир-егет матур хатын-кызга битараф соң?!..

Ә шулай да... егетең чын-чынлап гөнаһлы булгандыр, мөгаен. Синең бер ел эчендә башка кешегә кияүгә чыгуыңны аңламаучыларга Суфия Мифтахова сине яклап, «Шәриф үзе гаепле бит!»—дияр идемени югыйсә?!

...Сизгер җаның уйларымны бүлә. «Мин кияүгә аңа—бер тапкыр хыянәт иткән кешегә —бер ел гына түгел, биш ел, ун ел үтсә дә, барыбер чыкмый идем, чөнки ул тагын һәм тагын хыянәт итәр иде,—дисең горур бер үҗәтлек белән.—Кемгә дә булса бүтән берәүгә чыккан булыр идем. Хатын-кызның ана булу, әтиле бала үстерү миссиясе дә бар бит әле!»—дип янә бер кабатлыйсың да, җиңел сулап куясың. Әйтергә теләгән сүзләреңне әйтеп бетердең, янәсе.



*Зөлфә (уңда) дус кызы Флера белән (Флера—«Мәхәббәт сагышы»нда Фәһимәнең прототибы)*

...Китап шкафымда (архив папкаларының берсендә) Рауза Уральскаяның Шәрифкә язган хаты да саклана. Бәлки Раузаның Шәрифкә «...син мине эткәләп-төрткәләсәң дә...» дигән сүзләре күңелеңне йомшартыр, һәм сөйгән егетеңнең гомере буе сине, бары сине генә яратуына шигең бетәр?..

Шушы өмет белән мин сиңа әлеге хатны укытам. Һәм ялгышмыйм: йөзеңдә канәгатьләнү билгесе—сизелер-сизелмәс кенә елмаю чагыла.

«Беләсеңме,—дисең миңа, «сез» дип сөйләшүдән «син»гә күчеп,—мин бит Шәрифнең аны яратмавын бик соңлап, гомер үткәч кенә аңладым... Бергәләп тәмамлавыбыз турында әле генә әйтеп үткән «Профессор кияве»н Шәриф медицина институтының икенче-өченче курсларында укыганда ук яза башлаган иде. Пьесаны ул миңа булган мәхәббәтенә багышлады, төп героиняга да минем образны салды. Без соңгы курста

укыганда пьеса спектакльгә әйләнеп, сәхнәгә менде һәм... һәм Шәрифнең мина булган мәхәббәте дә минем образ салынган рольгә, шул рольне башкаручы артисткага күчте... Һәрхәлдә мин хәзер шулай дип уйлыйм...»

«Хаклысыңдыр, мөгаен», дим, юаныч табуына сөенеп, ә үзем Шәрифнең Мәдинә образы аша сине тасвирлаган, Хәбир образы аша үз халәтен бәян иткән «Мәхәббәт сагышы» повестеның егерме өченче бүлегеннән бер урынын күңел күзе аша үткәрәм: «Хәбир Мәдинә өчен, бары Мәдинәгә лаек булу өчен генә музыка (пьеса!—Р. Ю.) язарга ашкына иде. Шушы теләк белән рухланып, ул күпме кәгазь буяды, күпме язып карады! Балет (тормышта—«Профессор кияве»н—Р. Ю.) яза башлагач, бу теләк тагын да артты. Үзенең нәрсәгәдер сәләтле булуын тизрәк күрсәтәсе, Мәдинәне сөендерәсе, куандырасы килде. Күз алдында гел Мәдинә торды. Иртәгә һәм соңрак килүе ихтимал уңышларның һәммәсен Мәдинә исеме белән бәйләде. Тора-бара балетның төп каһарманы Сылу ана Мәдинә булып тоела башлады. Тора-бара Хәбирнең хыялында Сылу белән Мәдинә икесе бер җисем, бер тереклек булып кушылды. Еш кына ул Мәдинәгә: «Сылу!» дип эндәшә, ә музыка язып утырганда: «Бу Мәдинә белән безнең дуэт», «Бу Мәдинәнең адажиосы» дип хыялланып китә иде...» Чыннан да, күңел күзе аша үткән менә бу юллар, Хәбир-Шәрифнең ул чактагы менә шундый халәте—синең хаклы булуыңны раслый, Зөлфә.

...Ул чактагы хәлләрне күзаллауны дәвам итеп, мин болайрак фаразлыйм: яшь һәм талантлы артистка Рауза Уральскаяның синең образ салынган рольне тирәнтен аңлап уйнавы—«Профессор кияве» спектакленең уңышын тәэмин итә; театрга—дан, ә япь-яшь драматургка танылу китерә. Марсель Сәлимҗанов әйткәнчә, чибәрдән-чибәр туташлар күтүләре белән Шәрифне сагалый, аның артыннан йөри башлый. Моңарчы беркемгә дә билгеле булмаган самими-саф егетнең башын әйләндерү өчен азмыни бу!? Рауза үзе дә үлеп гашыйк була әле җитмәсә. Шушындый җирлектә Шәрифнең бөтен игътибарын инде син түгел, ә сәхнәдәге синең образ, шул образны искиткеч оста башкаручы артистка җәлеп итүе гаҗәпмени?!



*«Профессор кияве» спектакленнән бер күренеш. Гөлсинә—Рауза Уральская, Рөстәм—Вакил Закиров. Якынча 1955 ел*

Тик... бу күренешне, бу хәлләрне Язмыш үзе координацияли, үзенчә хәл кыла: бүтән егеткә кияүгә чыгып, син Ерак Көнчыгышка китеп барасың, үпкәсенә салкын тидереп Рауза дөнья куя, ә Шәриф... Аны да Вакыт галиҗәнаплары күкләрнең җиденче катыннан җиргә төшерә...

Рауза исән булса... Шәриф аңа өйләнер идеме дигән сорау туа; шулаймы, Зөлфә? Мин бу сорауны Суфия ханымга да бирдем. Ул исә: «Шәрифнең шәхси бәхете Зөлфә белән генә тулы була ала иде»,—диде. Әйе, ялганны, икейөзлелекне яратмаган, яратмыйча өйләнүне, яратмаган кешегә өйләнүне җинаять санаган Шәриф—юк, өйләнмәс, өйләнә алмас иде, минемчә. Ярату һәм өйләнү—Шәриф өчен икесе бер нәрсә, бербөтен, аерым-аерым була алмаучы илаһи хакыйкать.

Ә Раузага хөрмәт-ихтирамы булгандыр, билгеле. «Шул Рауза аркасында Шәриф белән Зөлфә арасындагы мәхәббәт чәлпәрәмә килде бит инде», дисәләр дә, Шәрифкә артистка—синең образны сәхнәдә җанландыручы буларак та, әсәрне һәм аның

авторын (ягъни Шәрифнең үзен) халыкка танытучы буларак та, ә иң мөһиме, театр сәнгатен тирәнтен аңлаучы һәм аңа хезмәт итүче актриса буларак та—якын һәм кадерле булгандыр дип уйлыйм мин. «Профессор кияве» пьесасын нәшриятка тапшырганда: «Талантлы яшь артистка Рауза Уральскаяның якты хатирәсенә» дип багышлама язар идемени югыйсә.

...Тулышкан күңелең бушанды, ахрысы, «төнлә йоклый алмаган идем; үземне әллә ничек хис итәм» дип сөйләнә-сөйләнә, син китәргә җыендың һәм... һәм сумкаңнан таушалган конвертлары саргаеп беткән бер төргәк хат, чит-читләре чуклана башлаган, альбом рәвешендәге бер дәфтәр алып миңа суздың.

Шушы мәлдә киеренкелек йомшаган йөзеңдә мин янә таныш чалымнар шәйләдем.

...Син калдырган хатлар, «Сөю сонетлары» дәфтәре аша менә тагын... мин Шәриф белән очраштым. Ул синең ике хатыңны саклаган кебек, син дә бәһасез бу хәзинәне саклагансың, Зөлфә. Иреннең дингез офицеры икәнен дә искә алсак, аларны саклау җинел генә булмагандыр, мөгаен. Ярты гасыр дәвамында синең белән бергә, китаплар эчендә, төрле-төрле төргәкләрдә, тартма-каплар почмагында «яшеренеп», шәһәрдән-шәһәргә, фатирдан-фатирга «күченеп йөргән» бу хатларның журналист кулына эләгүе һәм... инде менә бүген минем аларны укып утыруым—үзе бер могҗиза түгелмени, Ярабби!?.. Рәссам кулы язган диярсен—дисбедәй вак-вак хәрефләр, алардан тезелгән сүзләр, һәм шул сүзләрдән саркыган гыйшык аһәне, сөю-сәгадәт моңы, мәхәббәт сагышы!..

Биш хат арасыннан берсе—13 июльдә (1951) Шәриф сиңа Буадан... син практика үткән Минзәләгә юллаган сигез битлесе—күңелне хушландыра. (Исеңдәме, «Мәхәббәт сагышы» повестенда да беренче июльдә Мәдинәнең практикага Минзәләгә китүе искәртелә.)

Ә менә бу—илле алтынчы елда русча язылган ун битлесе белән, әйтерсең лә, «Мәхәббәт сагышы»ның дәвамы, ягъни икенче китабы башлана. Аерма шунда: Шәриф хатта Хәбир урынына латин хәрефләре белән Şərif дип, үз исемен куеп яза, сиңа да Мәдинә дип түгел, Зөлфә дип эндәшә. (Повестьның соңгы битләрендәге Хәбир-Шәрифеңнең халәтен хәтерлисеңдер бит, Зөлфә? Оныткан булсаң, исенә төшерәм: йөзенче (юбилей) спектаклендә үзенең беренче мәхәббәте Мәдинәне кабат очраткан, һәм... очрашу-аерылышулардан тетрәнүче; бөтен мал-мөлкәтен, зиннәтен, дан-шөһрәтен, хәтта талантын да шып-шыр өйнең ялангач сәкесендә утыручы Мәдинәгә алыштыруны бәхет санаучы, әмма шуны эшли алырдай тылсымлы көчнең дөньяда булмавыннан гаҗиз калып инрәүче Хәбир сурәтләнә анда. Ә менә хатта шушыннан соң булган хәлләр бәян ителә.)

Хатны повесть белән тиңләгәнмен-тәңгәлләгәнмен икән, аның кайбер урыннарын синең дә исенә төшерәм:

*«Исәнме, минем мәхәббәтем!*

*Менә мин «минем» дип яздым да, нинди минеке инде ул (!) дип уйга калдым. Әмма минем сиңа шулай гына эндәшәсем килә, һәм бу сүз каләмемнән үзеннән-үзе төште дә. Уйларымда гына булса да сине үземнеке итеп тою—миңа чиксез куаныч бирә.*

*Аңлыйсыңдыр, кайчагында мин үземне җир йөзендәге иң бәхетле кеше итеп тоям: яратам һәм яратылам чөнки. Яратылу—ул зур бәхет, шулай бит, минем кадерлем. Гәрчә син башканыкы булсаң да, йөрәгең белән син—минеке. Ә бу минем иң зур бәхетем, зур шатлыгым, олы юанычым, һәм яшәү өчен көч чыганагым да.*

*Үзем язам, үзем сиңа хатны кая җибәрергә белмим. Язмыйча да булдыра алмыйм... Менә тагын бер көн үтте, якшәмбе көне. Ул бик озын булды. Нәрсәдер көткәндә шулай була ул. Әмма мин ни көтәм соң? Берни дә көтәсе юк бит инде. Бөтенесе дә бетте, югалды, күзгә томанлы кояш шикелле юкка чыкты. Башта хат көттем мин синнән, китәр алдыннан бер-ике юл сызгалавыңа өмет тоттым. Бүген инде син киткәнгә дә дүртенче көн. Димәк, юк, димәк–булмаячак хат...*

*Нинди мескен хәлдә идем мин вокзалда сигезендә, син киткәндә. Башта мин бармаска булдым. Эштән кайттым да, арыган булуымны сылтау итеп, йокларга яттым. Йокларга, бөтенесен дә онытырга иде исәбем, ләкин булдыра гына алмадым: аякларым үзеннән-үзе вокзалга атлады. Туганнарыгыз танымаслык итеп киенү уеннан*

*кире кайтып, кара күзлек белән генә чикләнүем, бәхетсезлегемә каршы, ярдәм итмәде. Сез мине күрдегез бит, шулаймы?*

*Ә мин сезнең килүегезне дә, поездга утүегезне дә күреп тордым. Аннары күздән югалттым да алдагы вагоннар тирәсеннән эзли башладым. Әмма монда да мине фортуна аямады: нәкъ сезнең вагон каршысында туктаганмын икән. Шунда мин синең абыеңны күреп алдым һәм читкәрәк киттем. Югыйсә сез вагоннан чыгу белән минем янәшәмә туры килә идегез.*

*Перронда сез хәтсез юандыгыз—мин боларның бөтенесен күреп тордым. Сез дә мине күрәсездер кебек тоелды; һәм бу хәл минем кәефемне кырды.*

*Син бик боек идең. Нилектән бу? Әллә... чынлап та...»*

Шәриф... Әгәр ул вокзалга бармаса, сине читтән генә булса да... тагын бер күреп калмаса, мөлдерәмә тулган күз карасы шушы хатка түгелмәсә—белмим, ничекләр түзәр иде икән аның йөрәге?!..

Хаттан күренгәнчә, сиңа багланган өметнең дә, дөресрәге, мәхәббәт ялкынының да һаман сүнмәве-сүрелмәве—хәйраннар калырлык. Сиңа! Ирен «кочагында» балаң белән китеп баруыңны үз күзләре белән карап калып та!.. Егетләрнең ин-иң асылы гына булдыра алырдай, гасырлардан да бармак белән генә санарлык сирәк күренеш бу. Хәер, хатның дәвамыннан күренгәнчә, моны ул үзе дә белә, кайчак үз-үзен битәрли, язмышка һәм сиңа да әз-мәз генә үпкәләү бар: *«Син һәрвакыт кыюлыгың, тәвәккәл булуың белән аерылып тора идең, ә бу юлы—юк. Йә әйт, зинһар, ник без бу хәлиткеч һәм иң мөһим адымны ясамадык соң? Ышан, хәзер инде без бәхетле булган булыр идек. Ә болай—беләм ич—син дә бәхетле түгелсең... Адресыңны, фотокарточкаңны сорарга да башыма килмәгән. Төгәл хат язып торуыңны, һәм бөтенесен уйлап бетереп, тәвәккәл адым ясавыңны таләп итмәвем дә—мине газаплый, һәм ахмаклыгымны күрсәтә.*

*Нишләп кыюсыз соң мин! Тегe чакта сине өеңә җибәрмәсәм—каршы килмәс идең бит, әйеме? Ярату—ул корбан сорый. Мин яратам һәм яратуым хакына бөтен барлыгымны корбан итәргә әзер. Бел, синең бәхетле икәнеңне күрмичә, «сине күрәсем килми, мин башканы яратам» дигәнеңне ишетмичә—мин өйләнмәячәкмен. Бу минем ныклы ниятем. Шикләнмә, мин үз сүземдә торачакмын!*

*Шулай да мин бәхетле язмышыма ышанам. Әллә миңа гел кайгы-хәсрәтләр генә язганмы? Минем дә икенче—язмыш бүләк иткән бәхетле чорым булырга тиештер ләбаса! Һәм мин көтәм. Көтәм. Көтәм. Көтәм. Онытма шуны!*


*Сөйгәнеңнең (үзең шулай дидең бит!) зарыгып көтүе турындагы уй сине дә үз бәхетең турында уйланырга мәҗбүр итәр һәм, бәхетең хәрабәләре өстенә кемнеңдер нигез коруына түзеп торудан арынып: «Җитте!»—диеп, чик куярсың дип өметләнәм, Зөлфә! Сине яратуымны, синнән беркайчан да баш тартмаячагымны—онытма гына!?..*

*Кадерлем, син ничек уйлыйсың, миндә язу сәләте, ягъни иҗатка сәләт бармы икән? Бик күпләр «сиңа язарга, ешрак, күбрәк һәм активрак язарга кирәк» дип тукысалар да, мин үзем моңа ышанудан ерак торам. Язсам да—синең өчен генә, синең белән, синең мәхәббәтең белән рухланып кына яза алам бит мин. Менә үземнең соңгы эшем—бичара «Чулпан»ымны да сиңа багышладым. Аһ, минем аны сиңа шундый укыйсым килә!—ләкин бу мөмкин түгел. Җибәрү мөмкинлеге дә юк. Хат түгел бит, аны китап эченә яшереп булмый. Аның сиңа күңелсезлек тудыруы бар. Хәер, моның әле яхшыга булуы да—безнең язубыз җитүен тизләтүе дә мөмкин. Шулай да син кая җибәрә алуымны әйтеп яз. Адресыңны җибәр.*

*Зөлфә, кадерлем! Әгәр дә син минем бәхетсез-бичара халкыма нәрсәдер бирә алу сәләтемә өметләнәсең икән—мине яратуыңнан туктама. Синең белән, синең мәхәббәтең белән генә яшим бит мин. Мәхәббәтебез хакына гына мин нәрсәдер эшләргә сәләтле. Мин әле үземдә көч тоям. Минем әле әйтер сүзем бар. Әгәр син мине ташласаң, мин аларны әйтә алмаячакмын. Мине чынлап яратасың икән, минем белән кызыксынасың икән, минем әзме-күпме уңышым да сине шатландыра икән—мин әле нәрсәләрдер эшли алуыма өметләнәм. Әгәр моңа ышансаң, үзебезнең халык өчен минем нидер эшли алуым хакына гына булса да—ташлама?! Бу турыда мин күз яшьләрем аша ялварам...»*

«...Ташлама...»

Мин инде бу хатның дәвамын укый алмыйм, юк! Чыклы керфекләрем аша берни дә күрмәүче күзләрем дә шул сүзләргә берекkән. Дөньяның барлык гашыйкләры ишетерлек итеп шул сүз белән кычкырасым килә: ташлама! Ташлама, ташлама, ташлама!!!


7

Кетмәгәндә минем күңелемдә
Әллә нинди сихри ут яктың.
Керсез йөрәгемнең иң түрендә
Йоклап яткан хисне уяттың.
Берни юктай миңа карадың да,
Күңелең булган кадәр уйнадың да,
Мине кайнар утка син салдың,
Аннан китеп бардың, югалдың —
Йөрәгемне минем алып киттең,
Күрмәгәнгә мине салмыштың;
(Ә мин авыруга салмыштым)
Абау ялгыз соеп яну читен!

Читен, дуслар, ялгыз януы,
Ул януга дәва табасы.

1-май, 1950 ел.

*1949-51 елларда язылган 24 «Сөю сонеты»ның берсе*

Ә син... син—Зөлфә!—бу хатны укыганда нинәрсә кичердең?! Шәрифнең бу сүзләреннән качып ирен куенына ныграк сендеңме? «Мин бит Шәрифнең аны (Рауза Уральскаяны—Р. Ю.) яратмавын (димәк, сине генә яратуын!—Р. Ю.) бик соңлап, гомер үткәч кенә аңладым» диюең дә—аклану өчен генә әйтелгән буш сүзләрме?! «Ташлама?!» дип, күз яшьләре аша ялваручы 26 яшьтәге егетнең сиңа аңлату, сине ышандыру өчен өйләнмичә 70кә житүе һәм... һәм үлеп күрсәтүе... әйе, әйе, үлеп тә күрсәтүе кирәк булдымы?!..

Гафу ит, Зөлфә, жанга сыеша алмаган бу сүзләр кәгазьгә үзләреннән-үзләре төште.

...Өч-дүрт көнем әлеге хат тәэсирендә үтте. Әйе, әйе, сине «тиргәп» узды. Инде менә... тынычлана төшкәч, Шәрифнең шул ук көннәрдә язган, әллә нинди дипломатик юллар узып сиңа ирешкән бүтән хатларын да һәм тегe—чит-читләре чуклана башлаган альбом-дәфтәрдәге Сөю сонетларын да кулыма алам, һәм хәйран кала-кала укый башлыйм. Боларда да «Мәхәббәт сагышы» повесте аша миңа билгеле булган кайбер хәлләр, вакыйга-эпизодлар бар. Укыганда ук йә син, йә Шәрифең күз алдыма килә...

Мине «сезнең дөньядан» әледән-әле шалтыраучы телефоным гына аера. Менә бу юлы да... Теләмичә генә трубканы алам һәм... һәм таныш тавыш—синең тавышыңны ишетеп өнсез калам.

Күңелең минем тиргәвемне сиздеме әллә, Ходаем, бу юлы син мине үзеңә кунакка чакырасың, «ирем поликлиникага барырга җыенды—әле тиз генә кайтмас, иркенләп сөйләшеп утырырбыз»,—дисең...

Иркенләп диюең—ярый үзе: бихисап сорауларыма жавап табасы бар; үзем белгән кадәренчә Шәриф турында сиңа сөйләүне дә—бурычым дип саныйм. (Синең исән-сау булуың, табылуың—юкка түгел бит инде ул!)

Киеренке халәтенне абайлап, бу көрешүебездә сүзне мин башлыйм. «Илле алтынчы елда язган хатыңда» дип әйтүем була, син шундук, «минем аңа хат язганым юк; бер тапкыр да язмадым» дип, мине бүләсең. «Их, әнә шул чакта язмаган, өметен уятмаган булсаң икән кана, бу очракта Шәрифнең тормышы да бөтенләй бүтәнчә юнәлеш алыр иде, бәлки», дип уйлый-уйлый, мин сиңа аны театрда күреп калуыңнан соң күрешергә чакырып язган хатыңны укытам. (Шәриф архивында Рауза Уральская хаты һәм синең ике хатың саклануы хакында әйткән идем шикелле. Ярый әле үзем белән алганмын!) Моны укыгач та әле син (әллә мин-минлегең, горурлыгың комачаулый, әллә әниең әйткән «кире беткәнлегең», «тискәрелегең» бимазалый): «мин спектакльнең йөзенче куелышы, юбилее икәнен белмичә генә, очраклы гына барган идем» дип, аклана башлыйсың. Һәм шундук: «Илле алтынчы елгы очрашулардан соң мин әле Шәрифне тагын ике тапкыр күрдем: берсе—

Ленинградта, ә 1971 елдагысы—Казанда, үзе эшләгән больницасында»,—дип өстисен. «Менә, менә», дим күнелемнән, «мин бит синен нәкъ шушы сүзләренне көтәм дә...» Һәм сөйләшүебез тагаенрәк төс ала.

—Бу очрашуларыгыз да очраклы идеме?

—Ленинградтагысы—әйе, очраклы очрашу иде. Мин аны язмыш очраштыруы дип кабул иттем. Ул чакта Ленинградка катлы-катлы киртәләр үтә-үтә эләгүем, дөресрәге, барыбер эләгүем—шуны искәртте. Безнен округка балалар больницасының баш врачы өчен бер урын бирелгәнен хәбәр итеп, Ленинград Хәрби медицина академиясе үзенен белем күтәрү курсларына чакыру җибәргән иде. Әзерләнеп беткәндә генә, минем урынга ирем дәрәҗәсеннән зуррак чиндагы офицерның хатыны җибәрелүен белдем. Мондый гаделсезлектән ачуым чыгып йөргән көннәрдә, округның өстәмә тагын бер урын соравы, һәм шәһәр түрәсе хатынының юлга җыенуы мәгълүм булды. Моңа карамастан, өлкә хөкүмәтенен медицина бүлеге мөдире мина да юлга чыгарга әмер-фатихасын бирде. Шулай итеп, 1 урынга 3 кеше бардык, һәм беребезне дә кире бормадылар. Әйтәм бит, язмыш бүләге бу.

—Казармада яшәү... Хан сараенда яшәү булып тоелмагандыр бит?!

—Юк, казарма тормышы «тәтемәде» безгә. Килү белән безне академиянен тулай торагына урнаштырдылар. Хәтерлисең микән, ул елларда «Зульфия» дигән фильмның бик шаулаган чагы иде. Исемем Зөлфә булу аркасында мин үземә карата аеруча җылы мөнәсәбәт сиздем. Урнашкан кичтә үк староста кызыбыз егетләр курсы яшәгән «хәрби шәһәрчек»кә барып кайтты. Кайту белән ул бик тә кәефләнеп: «Егетләргә бүген «Зульфия»не күрсәтәләр. Мине дә кинога калырга кыстаганнар иде, риза булмадым, «безнен үз Зөлфиябез бар» диеп мактанып кайттым»,—дип сөйләде. Ә бер-ике көннән, мин дежур чакта постта телефон шалтырады. Исемемне әйткәч, шалтыратучы егет, «сина күнелсез булмасын әле» дия-дия, төне буе мина телефоннан Пушкинның «Евгений Онегин»ын сөйләп чыкты. Яттан, житмәсә. Мин соныннан, курслардан кайткач кына, бәлки Шәриф булгандыр ул дип уйладым.

—Хуш, Шәрифнен дә Ленинградта икәнен кайчан белден инде? Кайда, ничек очраштыгыз диюем...

—Килгән атнада ук безне, хәрби корабльгә «тәяп», Кронштадтка экскурсиягә алып бардылар. Корабльгә утыру сират күпере кичү белән бер булды; һәр документның өтер-ноктасына кадәр кат-кат тикшереп тенкәгә тиделәр. Кергәч нәрсәгәдер сөялүем, корабль янындагы мәхшәрне күзәтә башлавым исемдә. Кемнендер җылы, йомшак карашын тоеп борылуым һәм елмаеп торучы Шәрифне күреп, Ходаем, саташам, ахрысы, диеп уйлавым да хәтердә әле. Шуннан сон минем өчен вакыт туктады. Кая баруыбыз, ни өчен баруыбыз, күпмегә баруыбыз—боларның берсенең дә әһәмияте юк иде инде.

—Шәрифнең архивында «СССРның оборона сәләтен армый-талмый ныгыту белән мәшгуль военкомат мине 1964 елның язында Ленинградтагы Хәрби медицина академиясенә җыемга җибәрәсе итте» дип, шукланып язган «әсәре» бар. Үзен бәхетле сизгәндә шукланырга яратуын белгәнгә күрә, сөйгәне белән күрешү насыйп иткән Ленинградта ул гомеренең тагын бер бәхетле чорын яшәгәндер дип уйлыйсы килә.

—Әкияти төш кебек иде шул безнен ул көннәр. Ленинградның без урамаган урамы, без аяк басмаган бакчасы калмагандыр, мөгаен. Беркөнне безне урамда курс кызлары күргән. Алар соныннан мина: «Синең бәхетенә көнләштек әле. Дөньяда чын ирләрнен дә бетмәвенә инандык. Бөтен курска бер синен ирен килде. О-о, нинди кадерле икәнсен син иренә! Ул сине шулкадәр нык сагынган ки, мәхәббәт тулы күзләрен синнән алалмый, ә үзе... үзе шундый сак атлый, әйтерсен лә дөньяның иң-иң затлы бәллүрен алып бара»,—дип, соклануларын белдерделәр... И-и, бәхетемнән исереп йөргән әнә шул көннәрдә озын толымнарымны кистерергә дип парикмахерга керүем дә истә икән әле. Тагын да матураям, янәсе!.. Урта яшьләрдәге ханым гына, «җүләрләнә күрмә, Аллаһ биргән байлыгың бу; озын килеш тә патша кызлары да көнләшерлек итеп прическа ясап була» дип, чәчемне кисмичә генә матурлап чыгарды.

—Бәхетле көннәр бик тиз үтә диләр. Ул курслар озакка бардымы соң?

—Шәрифнең курслары алты айлык, ә минеке өч кенә айлык иде. Ләкин миңа аны да тәмамлау насыйп булмады. Бер баламның авыруы, үзенең дә чирләп китүе—больницага ятарга җыенуы, икенче баланың караучысыз калуы хакында иремнән телеграмма алдым. Һәм, билгеле инде, китәргә туры килде.

—Ленинградтагы очрашуның дәвамы да бар бит әле. Житмеш беренче елда Казанда очрашуыгыз турында әйтүем.

—Бу соңгысы инде очрашу түгел, тагын бер күрү, күреп калу гына булды. Без—институтны 1953 елда тәмамлаучылар, биш ел саен очраша идек. Аларның берсенә дә Шәриф килмәде. Әни янына бер кайтуымда, аның кайда эшләвен сорашып белдем дә, Соцгородка, ул эшләгән больницага бардым. Күрештек, әмма ул теләр-теләмәс кенә сөйләште. Шәриф миңа карата бик салкын иде... Аннан соң да күрәсем килеп йөдәдем. Кызым кияүгә чыккач, аларның фатирын Шәриф яшәгән Восстание урамыннан юнәттек. Мин оныгымны карарга килеп, кызымда алты ай яшәдем. Көн саен икешәр тапкыр баланы урамга, һава суларга алып чыктым—ник бер мәртәбә Шәриф очрасын! Ул яшәгән йорт тирәсе, ул йөргән сукмаклар бит инде югыйсә.


*Ленинград. 1964 ел*

...Жилле, карлы-бозлы яңгыр астында... күкрәгенә бала кыскан ханымның урамнан үтүче һәркемнең йөзенә текәлүен күз алдына китереп, өшеп китәм. Баш киеме эченә сыешмаган толымнарын сүтүче жил... шул чәч кыллары белән гүя мине дә яңаклый—битем кызыша. Күрәм: синең дә хәсрәтле йөзең тартышып куйды. Һәм мин шундук сөйләшүне янә яшьлегенә, бәхетле көннәренә юнәлтәм.

—Шәрифнең хатларында еш кына Нариман урамы телгә алына. Бу урам ни өчендер аңа бик кадерле сыман.

—Мин туып-үскән урам бит ул. Без үз йортыбыз белән шул урамда яшәдек. Ә Шәриф... Ул башта институтның тулай торагында торды. Соңгы курсларда инде, иҗат эшенә уңайлы дип, Һади Такташ урамына квартирга күчте. Кабан күле дә ул яшәгән йорт янында гына иде. Без шунда, зур тал төбендә киләчәгебез турында хыялланып, сандугачлар сайравын тыңлап, төнге күл өстендә йолдызлар жемелдәвенә хәйран калып таң атуын да сизми утыра идек.

—Дүртенче курсны тәмамлаган илле беренче елда син практикага—Минзәләгә, ә Шәриф Буага китә. Һәм «сагыну» сүзенә бишәр өндәү билгесе куеп, сиңа сигезәр битле сәлам хатлары юллый. Практиканы бергә үтү мөмкинлеге дә булгандыр бит?..

—Безнең чорда әхлак кануннары бик югары иде. Сөйгән егетең белән бергә практикага бару ничектер оят кебек тоелды. «Безнең яклар белән дә таныша тор!»—дип, чакырган иде Шәриф югыйсә.

—Житмеш беренче елдагы очрашу турында бая, «бу соңгысы... күреп калу гына булды», дидең. Ә Казанга бөтенләйгә кайчан кайттыгыз? Шәрифнең әле исән-сау чагы идеме?

—Кайда гына яшәсәм дә, минем күңелем гел Казанда булды. Ирем дингез офицеры булгач, безне гел дингез буендагы шәһәрләргә күчерделәр. Бер урыннан икенче урынга күченеп йөреп, еллар үтүе, еллар белән бергә гомер узуы да сизелмәгән. Ә 1999 елның башыннан ук миңа әллә нәрсә булды: мин Казанга

ашкындым. Квартир алмашу мәсьәләләрен хәл итә торырга дип башта ирем кайтып китте. Безгә яраклы вариант табылганчы хәтсез вакыт үтте. Без июль ахырларында гына күченеп кайта алдык. Шәрифнең бакыйлыкка күчүенә нибары 18 көн үткән булган!.. Бу юлы да сонардым... Соңга калдым! Ә бит күңелем сизенгән булган. Бөтен июнь, июль башы кайтырга ашкынган идем, җанымны кая куярга белми җирсенгән, бәргәләнгән идем.



*«Кисмичә матурланган»* чәч

Ул... ул бит врач. Авырый башлавын алданрак сизмәде микәнни соң?! Больницалар, санаторийлар җитәрлек ләбаса!..

—Сизмәгәндер дип уйлыйм. Сизгән булса, билгеле, сәламәтлеген кайгыртыр, дәвалану чарасына да керешер иде. Бәлки әле чит ил больницаларына да, санаторийларга да барган булыр иде. Аның табиб хезмәт хакы яшәренә җиткәндер, мөгаен, үзенең гонорарларын «картлык көненә» дип долларларга әйләндереп баруы турында әйткәне булды... Минем елмаюымны күреп, Шәриф, көләргә ашыкма, СССРның абруйлы кырыклап театры минем «Әни килде»не дистә еллар дәвамында сәхнәләреннән төшермәде, ә алар түли дә белә, дип мактанды һәм... һәм, хәзер минә пенсиямне дә долларларга әйләндереп барам, дип өстәде.

—Ә квартиры... Хәзер анда кемнәр яши? Шәриф рухы саклана микән?

—Квартиры да апасы кызы Наза Сафинага калды. Сатты бугай ул аны. Әдәбият-сәнгать кешеләренә түгелдер дип уйлыйм... Ә син Шәриф турындагы хәвефле хәбәрне Казанга кайткач кына ишеттеңме?

—Кайту белән әйберләрне урнаштыру мәшәкате дигәндәй... Атна-ун көн үткәндер әле. Шуннан соң гына туганнарга әйтергә, аларны җыеп, кайту шатлыгыбызны уртаклашырга булдык. Үзенә күрә өй туе да инде, янәсе. Шушы табында пышылдап кына колагыма апам әйтте. Ә бит мин, менә шушы табын мәшәкатеннән соң ук, Шәрифне күрергә ниятләгән идем. Бакый йортын күрү генә насыйп булды.

—Бу хәбәрне ирең дә ишеттеме соң?

—Ул минем янымда ни барын белеп өйләнде, белеп яшәде. Табында да кинәт үзгәрүемнән үк бөтенесен дә аңлап алды. Кунаклардан соң җыештыру-юу эшләрен миңа калдырып, өйдән юк булган иде. Бераздан кайтып, үзе белән мине дә әйдәде. Шәрифнең каберен эзләп тапкан икән.

—Күз яшьләрен тыя алмагансыңдыр, билгеле.

—Күз яшьләре!.. Алар әллә кайчан кибеп беткән иде инде.

—Шәрифнең соңгы көннәрендә бер юаныч булып, Аллага шөкер, «Әни килде»нең яңа куелышы Камал театры сәхнәсенә менде. Әсәренең премьерасын күреп, режиссеры Марсель Сәлимҗановка рәхмәт әйтеп, артистлардан һәм спектакльдән канәгать булып китте Шәриф. Ә сиңа, Зөлфә, ошадымы бу спектакль? Нинди тәэсир калдырды?



*Соңгы чәчәкләр...*

—Кызганыч, миңа аны карарга туры килмәде. Аңлыйсыңдыр, бу—иремнең күңелен аямау булыр иде.

...Ирең кайтып керү белән, аның арыган булуын абайлап, мин китәргә кузгалдым.

Озата чыгуын да әйбәт булды. Мин сиңа Шәрифеннең тормышы турында да, миңа васыять итеп калдыргандай, синең исемеңне—гомере буе йөрәгендә саклаган исемне әйтүе турында да, күңеленә хуш килгән дуслары турында да сөйләдем.

Синең дә соравың калган икән әле:

—Теге чакта... Житмеш беренче елны әйтүем, нилектән Шәриф миңа бик салкын булды икән?—дип, йөземә текәләсең.

Мин моның җавабын белмим. Шунлыктан, кыска гына итеп:

—Ул чакта мин Шәриф әфәнде белән таныш түгел идем бит. Мин аны беренче тапкыр житмеш жиденче елда, «Азат хатын» журналында эшли башлагач кына күрдем,—дип җаваплыйм. Һәм синең хафалы йөзеңдә канәгатьсезлек күреп, Ходаем, син бакый дөньядагы Шәрифеннән дә көнләшәсең түгелме соң дип хәйран калам.

Бу уемны раслагандай, син әле:

—Ә ул... ул кайчан китте?—дисең.

—Кем? Шәрифме?

—Аның... аның шул Раузасы!

—Рауза Уральская 1957 елда ук дөнья куя,—дим, һәм ирең кайтып керү сәбәпле өендә калдырырга кыенсынган журналымны—«Казан утлары»ның 2006 елгы март санын кулыңа тоттырам.—Шәриф әфәнде турында бөтен белгәннәрем—шушында инде!


*Ерак Көнчыгышта*

...Очрашу-күрешүләр тоныклана барган бер мәлдә, син мине янә үзеңә дәшәсең. Мин, соң түгелме соң инде дип, жиде тулуын искәрткән арада, син иреннең санаторийгә китүен, миңа күрсәтәсе әйберләрең булуын әйтеп, икеләнүләремне оныттырасың. Күрсәтәсе әйбер булу кебек аргумент—журналист өчен—айның жиргә төшүе белән бер инде ул. Хәер, Шәриф өчен син үзең дә күкнең-жирнең ае да, йолдызы да булган кеше ләбаса! Һәм мин менә... каршыңда утырам.

Сервантыңның аскы тартма төпкеленнән бер кәгазь кап алып, өстәлгә куясың. Кап тулы фотолар: «Шәриф жибәргән иде,—дисең.—Ленинградта үзе төшергәннәре!»

Мин бер фотога, дөресрәге, әнә шул фотодагы купшы чәчәкләргә ымлыйм: Шәриф бүләгеме, янәсе. Шуны да аңламыйсыңмыни дигәндәй, миңа шелтәле караш ташлап: «Аныкы, билгеле!—дисең.—Ленинградтан китеп барган чагым!»

Берөчтан гаилә альбомыгызны да актарам: ирең белән син, балалар, оныклар, һәм инде әнә—кызыңның да оныгы!.. Минем дикъкатемне синең ялгыз гына төшкән бер сурәтең—ирең аның артына «Күчеш чоры! 1961» дип язган фото жәлеп итә. Жиде ел яшәгән иренә кунегә бару чорына ишарәме икән инде бу? Әллә, сине китмәс, минем янда калыр дигән өметенең ныгый барган чагымы?.. Син үзең дә, «Нигә алай язгандыр инде, аңламыйм», дисең...

Ә-һә! Тагын бер сюрпризың бар икән бит әле. Өстәлдә Шәрифнең алтмыш бишенче елда чыккан, бәләкәй форматтагы «Мәхәббәт сагышы» китабы пәйда була. Китап эченнән икегә бөкләнгән бер кәгазь алып миңа сузасың. Күрәм: Шәрифнең язуы! Һәм сөенеп укый башлыйм: «Син минем хатларыма жавап бирмәсәң дә, мин менә тагын китабымны жибәрәм. Кемнәрнеңдер уку ихтималын истә тотып, сиңа бу багышламаны китап битенә түгел, аерым кәгазьгә генә язам. Китап сиңа ошар дип уйлыйм. Чөнки анда безнең яшьлек, безнең мәхәббәтебез! Мәдинә—син! Ә Хәбир... миннән күпкә әйбәтрәк мин. Әсәр таләп иткәнчә, әниләренне генә үзгәртергә туры килде».

...Укып бетерәм генә, син шундук бу багышламаны «Мәхәббәт сагышы» эченә «качырып», стеллажга, катлы-катлы китаплар артына яшерәсең. Һәм бу гамәлеңнән унайсызлангандай, «Шәриф белән безнең мәхәббәтебез турында хәтта кызым да белми. Күкләрдән ингән бу язмышымны үзем белән алып китәрмен дигән идем. Хәер, күкләрдән гасырга бер мәртәбә инә торган, йөзләр, меңнәр арасыннан минем

өлешемә тигән мондый мәхәббәтне яшерергә дә кирәк булмагандыр, бәлки?!»— дип куясың. Ә боек йөзенне сагыш каплый.

Гаиләнә килгән бөтен кайгы-хәсрәт, бәла-казаларны да мәхәббәт әҗере итеп кабул итүенне чамалыйм. («Шәрифем үзе белән ин кадерле кешеләремне дә алды» диюен дә шуны искәртә.) Һәм: «Шушы хәтле әрнү-сызланулар белән ничекләр яши алдың?» диюдән үземне көчкә тыеп, балаларың, оныкларың турында сорашуга күчәм. Шөкер, йөзенә тагын таныш чалымнар—җылы дулкын йөгерә.

...Без сәгатьнен уникенче киткәнен дә, төн җиткәнен дә сизмәгәнбез икән. «Маршрутка»лар да туктаган, җитмәсә. «Озатырга чыгуың гел кирәкмәс иде» диюем була, син теге очрашуда да әйткән, «җитмеш беренче елда Шәриф нигә мина бик салкын булды икән?» дигән соравынны кабатлыйсың. Эндәшми торуымны үзенчә аңлап: «Сәбәбе—башка хатын-кызмы?»—дип куясың. Аннары, гүя аклангандай: «Ул чактагы... ул чордагы тормышын мин бөтенләй белмим бит»,—дип өстисең.

Мин сүз әйтергә дә өлгермим, әллә каян гына килеп чыккан «маршрутка» туктый. Һәм мин, синен утыз биш ел дәвамында җавап эзләгән бу соравынны да алып, утырырга ашыгам.

Чыннан да... ул чакта Шәриф нигә бик салкын булды икән соң?

Әлеге сорауга җавап табу өчен тормыш чынбарлыгын күз алдына китерик: бу вакытта инде синең, Зөлфә ханым, ирен белән яшәвенә 17 ел! Гаиләң бөтен, балаларың үскән: кызына—16, улына 10 яшь. Һәм Шәриф, билгеле ки, үзенен бу балаларга чит-ят булачагын да, синен исә яраткан кешен (ягъни Шәрифен) һәм балаларың арасында бәргәләнәчәгенне дә бик яхшы аңлый. Мондый ярты-йорты бәхет өчен гаиләннен җимерелүен—юк, теләми инде ул, тәгаен теләми. Кавышу, бергә яшәү турындагы хыялга, димәк, нокта куелган.

Балаларың кечкенә чакта кайтуынны бик теләгән, сине көтә-көтә арыган, инде өмете өзелгән; бергә була алмавыгыз белән күпмедер дәрәҗәдә килешкән һәм әзме-күпме тынычланган Шәрифнен җитмеш беренче елда сина—бердәнбер музасына!— «салкынлык» күрсәтүен мин, мәсәлән, шулайрак аңлыйм. («Яраларны ачасым килми» дип, сине күрүдән куркып, аның институтка очрашуларга да йөрмәвен хәтерлә әле!)

Бу «салкынлык»нын, мондый «битарафлык»нын олы мәхәббәттән генә тууы һәм үзен оныттыру өчен Шәриф кулланган махсус бер ширма-битлек кенә булуы да бик ихтимал.

Ә ул чактагы тормышына килгәндә... янә архивына мөрәҗәгать итик. Андагы кайбер язмалардан күренгәнчә, Ленинградта синен белән очрашулардан рухи һәм иҗади илһам алып кайткан Шәриф—балаларың турында телеграмма алган мәлдә синен дә Ана кеше икәненне күргән һәм Ана күнелен бөтен тирәнлеге белән аңлаган драматург!—үзе белгән вакыйга-эпизодлары нигезендә «Әни килде» исемендә драма яза башлый. Үз хатларына, җибәргән фотоларга, «Мәхәббәт сагышы» китабына синнән бернинди дә җавап булмау аркасында, ул аны озак яза, һәм алтмыш сигезенче елда гына тәмамлый.

Инде син аның янына килгән җитмеш беренче елны алыйк. Г.Камал исемендәге Академия театры куйган «Әни килде» спектаклен—Казанда, Татарстанда, алай гына да түгел, бөтен татар дөньясында вакыйгага әйләнгән, Мәскәү тамашачылары да ярты сәгать дәвамында аягүрә алкышлаган спектакльне —Мәскәү тәнкыйтьчеләре: «Театр сәнгате шедеврь! Кешеләр күнелен чистартучы, рухын баетучы, кешелеклелекнен боек драмасы!» дип бәяләп, һәм драманы Шекспир әсәрләренә тиңләп, Шәриф Хөсәеновның үзен күкләрнен җиденче катына менгезгән бер чор бу! Һәм...

Һәм Шәрифен синен белән кавышу, бергә яшәү турындагы хыялына гына түгел, иҗат хыялларына да нокта куйган чор да бу. (Хәтерлә әле: «...мине яратуыңнан туктама, синен мәхәббәтен белән рухланып кына яза алам бит мин», ди Шәрифен сина илле алтынчы елдагы хатында.)

Әйе, әйе, Шәриф Хөсәенов олы иҗатына (40 яшендә!) нокта куя, әмма каләмен ташламый; «бәхетсез халкына», милләтенә хезмәт итүдә үтемлерәк юл таба: телевидение өчен сатира-юморга бай кыска-кыска сценарийлар яза, илнен

баткаклыкта булуын, кешеләрнең мохтаҗлыкта яшәвен күрсәтеп, моннан чыгу мөмкинлеген дә искәртеп, үткен дәлилләр белән ил-дәүләт җитәкчеләренә, редакцияләргә хатлар юллый. Һай, ул гаҗәеп хатлардагы фикер байлыгы!.. Акылны, фикерне, талантны, зыялылыкны эзәрлекләүче еллар, тоталитар заман юкса әле бу!

...Шәриф Хөсәеновның иҗаты синең белән, синең мәхәббәтең белән бәйле булган кебек, шәхси тормышы да, Зөлфә ханым, сиңа бәйле. Сиңа багланган өмете өзелгәннән соң, Шәрифнең үтә шәхси тормышына аның үзенә битараф булмаган ханымнардан бары берәүнең—Суфия Мифтахованың гына үтә алуы билгеле.

Бер-берсенә гомер буе «иркәм!» дип кенә эндәшүче бу икәүнең өйләнешмәве, гаилә корып бергә яшәмәве гаҗәпләндерә, шулаймы? Минем аптыравыма каршы Суфия ханым: «Шәриф—зур шәхес. Балаларым белән аның янында яшәүне мин ярый торган хәл дип санамадым. Аннары ул миңа гашыйк та булмады», дип аңлатты. Хәер, сиңа хатында Шәриф үзе үк җавап бирә ләбаса! «...Ярату—ул корбан сорый. Мин яратам һәм яратуым хакына бөтен барлыгымны корбан итәргә әзер. Бел, синең бәхетле икәнеңне күрмичә, «сине күрәсем килми, мин башканы яратам» дигәнеңне ишетмичә—мин өйләнмәячәкмен. Бу минем ныклы карарым. Шикләнмә, үз сүземдә торачакмын!»—ди ул. Һәм... һәм сүзендә тора: өйләнми! Сиңа булган мәхәббәт бәрабәренә гаиләсез кала, үзен ялгызлыкта яшәргә дучар итә, ягъни шәхси тормышын корбан итә.

Күкләр, Җирләр баш иярлек мәхәббәт түгелмени бу!.. Үзе исән вакытта ук легендага әйләнгән бүтән мәхәббәт каһарманын белмим мин.

Шулай да... шулай да холкы белән дә, тышкы кыяфәте белән дә сиңа охшаган туташ яки ханым очраса —бәлки өйләнер дә иде дигән уй килә. Чөнки... нәкъ Гөлнар Сәлимҗанова әйткәнчә, гаилә җылысына мохтаҗ иде ул. «Шәриф өебездә үзенә ямь һәм үзара аңлашу тапкангадыр инде, безгә тартыла иде. Аеруча якшәмбе көннәрендә килә торган иде ул безгә. Пешергән пилмәннәремне, пәрәмәчләремне бик ярата иде»,—дип искә ала Гөлнар ханым үзенең истәлекләрендә дә. Минем дә исемдә: шалтыратуларының берсендә үзенең әле генә дусларыннан—Гөлнар һәм Марсель Сәлимҗановлардан кайтуын әйтеп, аларда бик күңелле кич үткәрүе турында хозурланып сөйләве дә, һәм шундук ачынып: и-и, мин дә яшәдем инде, дию дә истә. Гаилә җылысында яшәмәүдән сызлану аһәңе түгелмени бу?!

Бигрәк тә соңгы елларында ялгызлыгы үзен нык сиздергәндер дип уйлыйм мин. Чөнки ул елларда Суфия Мифтахова белән дә күрешүләре сирәгәя: табиб эше, оныклар һәм авыру ана карау Суфия ханымның бөтен вакытын ала...

Бәлки өйләнер иде дигән уемны Фәнис Яруллинның Шәриф турындагы хатирәсе тагын да куәтли төшә. Фәнис әфәнде сиксәненче еллар башында Шәрифкә: «Нишләп шушы гомер өйләнми йөрисең инде»,—дигән сорау куя. «Ярый ла синең бәхетеңә Нурсөя очраган,—дип җаваплый Шәриф,—миңа андый Нурсөяләр очрамады шул». Ә туксан тугызынчы елның 30 июнендә Фәниснең телефон аша «Әни килде»нең яңа куелышы белән котлап: «Молодец!» дию енә каршы каты авыру хәлендәге драматург: «Былтыр кысканга быел кычкыру инде бу. Менә син молодец, Фәнис. Бертуктамый эшләдең дә эшләдең. Син миннән бәхетлерәк!»—дип, йөрәген ача.

«Син миннән бәхетлерәк!..» Шәриф бу сүзләрне, Зөлфә, беләсеңме, кемгә әйтә?! Армиядән имгәнеп кайтканнан бирле, ярты гасыр дәвамында урында яткан килеш, каләмен ике кулына кыстырып иҗат итүче кешегә!—янында әнә шул каләмне көчсез кулларыннан төшертмәүче сөйгәне—Нурсөясе булган әдипкә әйтә.

Нурсөя Шәрифкә тәгаен сине—әйе, әйе, Зөлфә, сине хәтерләткәндер, һәм бу хәл үз тормышына да анализ ясарга этәргәндер дип уйлыйм мин. Чыннан да, кыяфәте белән дә, күпмедер дәрәҗәдә холкы белән дә Нурсөя сиңа охшаган. Тәүге күрешүебездә үк күзгә ташланган таныш чалымнарын миңа менә кемне хәтерләткән икән бит!..

...Очрашуларыбыз саен кабатланган, җавабын тәгаен генә үзем дә белмәгән тагын бер соравыма ничек җавап табарга соң? Чыннан да, ни өчен мин Шәриф Хөсәенов турында язарга алындым; кемем иде ул минем: якын дустыммы, яки талантына, йә

үзенә гашыйк булган кешемме; әллә ин авыр көннәремдә үземә дустанә кулын сузуының әҗерен түләү максатыннанмы, әллә, журналист буларак, әхлак бетүгә юл тоткан, намус, мәхәббәт кебек изге төшенчәләр онытыла башлаган бу заманда ошбу бөек кеше һәм аның бөек мәхәббәте турында башкаларга да сөйләү, үзем белгәннәр белән уртаклашырга теләү ихтыяҗыннан кулыма каләм алдыммы?.. Белмим, белмим.

Ә минем эндәшмәвемне «йөрәгемне ачарга теләмәвем»ә юрап, син, ниһаять, үзеңчә фараз кыласың: «Шәрифнең сина тартылуы—бәхәссез; синдә ул мине, минем чалымнарымны күргән»,—дисең... Чыннан да белмим, бу турыда гел уйлаганым булмады; әмма, ышанасыңмы, язмыйча булдыра алмый идем инде мин. Хәер, ни өчен язарга алынуымны тәгаен генә белсәм, мөгаен, яза да алмас идем. Язмаларымда, күргәнеңчә, мин үзем дә күп кенә сорауларга җавап эзләдем, һәм кайберләренә таптым да. Шәриф Хөсәеновны бөек драматург һәм язучы иткән кешенең син булуын ачыклавым («Ак сагыш иясе», «Казан утлары», 2006, 3 нче сан) һәм... һәм менә, ниһаять, сине табуым!—үзе генә дә язарга алынуымның юкка түгеллеген күрсәтә.

Тик үземне җиде ел дәвамында бимазалаган сорауга гына әле һаман җавап табылганы юк. Һәм ин гаҗәбе: эзләнүдән туктый да, ошбу язмага нокта да куя алмыйм; һәм ачыклап бетермичә—куя да алмам, ахры. (Бәлки мин нәкъ шул сорауга җавап эзләп кулыма каләм алганмындыр да әле?!) Ул... ул сорау 18 июньнең (1999) җомга иртәсендә Шәрифнең шалтыратып: «Карале, Рәйсә, иртәгә мине больницадан чыгаралар; бу турыда Марсель Сәлимҗановка шалтыратып әйт әле. Монда кергәндә киемнәремне Шамил Закиров алып киткән иде. Китерсеннәр, слушай», диюеннән башланган иде. Дөрес, баштарак мин нигә Марсельгә йә Шамилгә түгел, миңа шалтыратты икән ул, дип уйлаудан узмадым. Ә аннары, больницадан 19ында түгел, 23 июньдә генә чыгуын белгәч, ныклап уйландым: димәк... димәк, үзенең авыру икәнен белдерү һәм мине больницага китерү өчен уйланылган «дипломатия» инде бу шалтырату! Димәк, миңа әйтәсе сүзләре булган! Сереме, гозереме, васыятеме?.. Һәм нәрсә турында?

...Менә ничәнче кат инде, ничәнче кат, җавап эзләп мин янә үткәннәргә, туксан тугызның июненә «йөгерәм», сәгатьләп-минутлап дигәндәй, шул көннәрне айкыйм. Рабит Батуллага Шәриф: «Иртәгә мине чыгаралар. Аннан үземнең больницага салырлар»,—ди 22 июньдә. 26 июньдә иртәнге 7 дә миңа шалтырата һәм:

—Слушай, өч көн буена кайда йөрисең чукынып? Мин сиңа больницадан чыккан чәршәмбедән бирле шалтыратам... «Әни килде»нең премьерасына чакыру билетларымны да таратып бетердем бит инде. Сиңа дигәннәрен дә бирергә туры килде менә. Өенә үк килеп сорагач, ничек буш җибәрәсең, слушай... Әнә, кайсы көнгәдер берне булса да калдыра алганмын әле,—ди ул.

—Борчылма, Шәриф, мин ничек тә керү юлын табармын. Бусы өчен дә рәхмәт! Килеп алырмын, яме!

—Киләсеңме?! Кайчан?!

—Кичке җидедә. Командировкага килгән кунакларымны Мәскәү поездына озатам да...

—Подъезд ишеген ачарга төшеп йөри алмыйм, ачуланма... И-и, Рәйсә, син бит әле берни дә белмисең...

...Әмма мин соңгарак калам. Аның ишеген җидедә түгел, сәгать тугызынчы киткәндә генә шакыйм. Һәм, шакып-шакып та җавап булмавына борчылып, дусларына да шалтыратам. Алар, больницалар аша белешеп, «Ул, тәгаен, өйдә, «үзен туйдырып бетергән» туганнары дип белеп, ишеккә дә килми, телефонны да алмый торгандыр», дип, мине юаталар. Тик мин тынычлана алмыйм; Аның ашкынып: «Киләсеңме?! Кайчан?!» дигән өмет тулы сүзләре йөрәкне яндыра, зиһенне бораулый, бәгырьне телгәли.

Икенче көнне... Икенче көнне миңа ишекне Суфия ханым ачты. Шәрифне урын өстендә күреп тетрәнүемнән айный төшкәч, кичен такси тота алмавым аркасында соңга калуымны аңлатып гафу үтендем. Ул исә: «Таксиның гаебе юк монда. Язмышым шундый инде минем»,—дип, мине гаҗәпләндерде.

...Минем такси тота алмавым, соңга калуым Шәрифнең үз язмышы белән бәйлеме?.. «Аның авыру икәнен сез кайчанрак белдегез?» дип, мин җавапны Суфия ханымнан да эзләп карыйм. «Кичә кич,—ди ул,—«Әни килде» спектакленең

премьерасына чакыру билеты калдырдым дип шалтыратты. Авыру икәнен дә әйтте».

Кичә кич!.. Димәк... димәк, мин сонга калгач кына!.. Әллә үзе янында минем утыруымны теләгән булганмы? Юктыр, юк! Бу очракта сабакташы, курсташы, врач һәм гомерлек җан дусты Суфия ханым кулайрак бит.

...Ошбу уемны яздым да, йөрәгем кысылып куйды, күнелдә, Зөлфә, синең үзәкләрне өзәрдәй аянычлы сүзләрең янарды: «Сонга калдым! Ә бит күнелем сизенгән булган...»

...Менә ул—җаннар ашкынуы, күңелләр тартылуы!.. Димәк, соңгы көннәрендә дә Шәрифең сине уйлаган, Зөлфә, һәм бу биотоклар сиңа барып ирешкән дә!.. Йа Раббым! Ике йөрәкнең бер булып тибүе түгелмени бу?!

Мине җиде ел бимазалаган сер—Шәрифнең миңа әйтеп өлгермәгән гозере дә, димәк, син ул, Зөлфә, син! Әйе, әйе, Шәрифең соңгы көннәрендә үзе янында тәгаен синең булуынны теләгән, минем сине чакырып кайтаруыма өметләнгән, моны эшли алуыма ышанган һәм... Һәм мин сонга калган кичкә хәтле сине күрү өмете белән яшәгән. Такси тота алмавымны үз язмышына юрар идемени ул югыйсә?! Ә язмышы—ачы, ак язмышы—фәкать синең белән генә бәйле!

...Тагын ике көннән, ягъни Ул туган 26 ноябрьдә без синең белән Анын бакый йортына баш иярргә баргач, мин күңелемнән генә Шәрифенә эндәштем: «Менә,—дидем,—дөньялыкта миңа әйтеп өлгермәгән амәнәтенне үтәдем: синең янына Зөлфәне алып килдем!»

* * *

...Гаҗәп: Шәриф әфәнде бер шалтыратуында миңа Тукай, Пушкин, Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салуын әйтеп, «Аларга бит инде берни дә кирәкми, без—исәннәрнең фәкать онытмавы гына кирәк», дигән иде.

«...Исәннәрнең фәкать онытмавы гына!..» Әйтерсең лә үзе турында да әйткән васыять бу.

Татарның ошбу мәшһүр улы Шәриф Хөсәенов, шөкер, бүген дә безнең күңелләребез түрендә, хәтер-хатирәләребездә һәм үзенең илаһи әсәрләрендә яши. «Әни килде» драмасының Галиәсгар Камал исемендәге Академия театры сәхнәсеннән төшеп торганы да юк. Әле шушы көннәрдә генә Аны белгәннәрне сөендереп, дусларының ярату, соклану, юксыну хисләре саркыган хатирә-истәлекләрен, шулай ук аның үзенең «Мәхәббәт сагышы» повестен һәм ил җитәкчеләренә, газета-журналларга язган гаҗәеп хатларын туплаган «Шәриф Хөсәенов» дигән китап дөнья күрде. Ә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры директоры Рәүфәл Мөхәммәтҗанов исә «Мәхәббәт сагышы»ның русчага тәрҗемәсен сорап мөрәҗәгать итте һәм әлеге әсәр нигезендә Мәнгелек Мәхәббәткә (ягъни Шәриф белән сиңа!) багышланган опера иҗат ителәчәген белдерде. Башка театрларның да «Зөбәйдә—адәм баласы», «Чулпан» пьесалары белән кызыксынуларын ишеттем.

...Инде синең күңелеңнең дә, Зөлфә ханым, Шәрифнең рухы белән тулы булуына инандым. Күкләрнең барча йолдызлары белән елкылдап балкыган Кабан күле дә, «Шәриф белән икегезнеке» генә булган Тукай урамындагы сандугачлы бакчалар да саклана ул күнелдә.

Газиз хатирәләр синең тулышкан күнеленнән күзләрең аша җиһанга да сирпелә: якты моң булып та бөркелә, үкенү-сызлану булып та түгелә, ак сагыш булып та саркый. Һәм бу сагыш—мәхәббәт сагышы—гүя «безнең ялгышларны кабатламагыз» дия-дия дөньяның барча гашыйкларын кисәтә дә кебек.

*2006 ел*

# Г. КАМАЛНЫҢ ТАТАР МАТБУГАТЫНДАГЫ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Галиәсгар Камал—XX йөз башы татар иҗтимагый һәм мәдәни тормышындагы үзәк фигураларның берсе. Актив иҗат эшчәнлеген XIX йөз азагында ук башлап җибәргән Камал киңкырлы талант иясе буларак танылa, ягъни берничә Әдәби «толпар»ны берьюлы «иярли», киң мәдәни «яссылык»та эшли. Ул бер үк вакытта нашир-мөхәррир дә, прозаик та, публицист та, драматург та, шагыйрь дә, хәтта рәссам да. Мондый киң колачлы шәхесләр сирәк була.

Хәлбуки, Г.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты белән кызыксыну соңгы 15-20 ел эчендә шактый сүрелде кебек. 1979 елда «Галиәсгар Камал турында истәлекләр», 1978—1982 елларда аның өчтомлык әсәрләр җыелмасы басылганнан соң бу юлда артык зур алга китеш күзәтелми. Бу күренеш Г. Исхакый, С. Максуди, И. Гаспринский кебек шәхесләрнең алгы планга чыгуы белән дә бәйле булса кирәк. Совет чорында исемнәрен уңай яктан телгә алырга да ярамаган җәмәгать эшлеклеләренең һәм әдипләрнең фигылияте бүгенге чынбарлыкта нииндидер, гайре табигый дип әйтерлек, кызыксыну һәм тикшеренү объектына әйләнде. Хәер, безнең тарихка, иҗтимагый тормышка һәрвакыт бер чиктән икенчесенә ташлану дигән алама сыйфат та хас булды. Ләкин бүгенге язмабызның максаты бу үзенчәлек турында түгел.



Г. Камалга матбугат җене «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен яңа гына тәмамлаган чорда кагыла. «Яза башлавым тарихы» дигән истәлекләрендә ул үзе бу хакта болай ди: «Кәрә 1900 ел... Иптәшләр белән бергәләп, юка кәгазь астына копировка кәгазьләре куеп, мәдрәсәдәге хәлфәләрнең житешмәгән якларыннан көлеп «Телескоп», «Мәнзарател-галәм» дигән газеталар чыгарып, төнлә белән җәмәгать сәкеләренә дә ташлыйбыз». Димәк, сүз язылып таратыла торган кульязма газеталар турында бара. Патриархаль җәмгыятьтә, мәдрәсә житәкчелегендә моның кебек эшләр ул чорда зур тәүфыйксызлык, бунтарьлык дип карала. Аның каравы, 20 яшьлек Галиәсгарның шәкертләр арасында абруе көннән-көн арта бара.

Бер-ике ел үткәч, Г. Камал Германиядән типография эшенә өйрәнеп кайткан Мәхмүт Алмаев белән якыннан аралаша башлый. «Сарай» номерларында торган килеш бу егет белән ул җилем басмадагы «Тәрәккый» исемле газета чыгара. Әлбәттә, монысы да укучы татар яшьләре арасында таратылып, шактый киң яңгыраш таба.

Шәкертләр дә Камалны, беркадәр остазлары санап, үз итәләр. 1903 елда Казанда укучы яшьләр җилем басма «Рәсемле милли гәзитә» чыгара башлыйлар һәм почта аркылы татарларның күренекле әһелләренә юллыйлар. Адресатлар арасында Г. Исхакый, Г. Камал кебек бунтарь шәхесләрнең булуы игътибарга лаек. Бу гаҗәп түгел, чөнки Г. Исхакый бу вакытта инде «Тәгаллемдә сәгадәт...», «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын берлә тормыш» кебек әсәрләре белән танылган булса, Г. Камалның

«Бәхетсез егет», «Өч бәдбәхет», «Кызганыч бала» әсәрләре халык теленнән төшми.

Мәгълүм булганча, муллалыктан баш тарткан Г. Камал, каенатасы Садыйк хаҗи ярдәме белән 1901 елда «Мәгариф» исемле китап кибете ача. Аннары бу кибет «Мәгариф көтепханәсе» дип аталып китә. Кибет-көтепханә әдипкә үзенең байтак ниятләрен тормышка ашырырга мөмкинлек бирә. Дини әдәбият таратудан баш тартып, ул биредә газета-журналлар, вак хикәятләр, язу-канцелярия әсбаплары сәүдәсенә керешә. Югарыда телгә алынган «Тәрәкъкый» исемле яшерен газета нәкъ менә шушы «Мәгариф көтепханәсе» аркылы шәкертләр арасында таратыла.

1905 елда ил-мәмләкәт революция гөрелтесенә күмелә. Шул чорда «Мәгариф көтепханәсе»нең эш колачы киңәя, күзгә күренеп радикальләшә. Сул партияләр (эсерлар һ. б.) чыгарган яшерен әдәбият Г. Камал көтепханәсе аркылы Казанның бөтен мәдрәсәләренә, бигрәк тә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә таратыла башлый. Яңа вәзгыять шартларында татар җәмәгатьчелеге монархы рөхсәт ителмәгән милли матбугат ачу хыялына ирешә. Ниһаять, 1905 елның 29 октябрендә адвокат С. Алкин наширлегендә Казанда беренче татар газетасы—«Казан мөхбире» чыга башлый. Й. Акчура, Г. Исхакый, Ф. Туктаров кебек атаклы шәхесләр белән берлектә газетада Г. Камал да язышa. Аерым алганда, биредә «Саип» имзасы белән аның «Азатлык» шигыре басыла (1905, № 8). Анда мондый юллар бар:

*Иске коллык кадалсын,*
*Аның көлен җил алсын,*
*Азатлык ялгыз калсын,—*
*Пәк соңарып кәлдия...*

Ләкин бу газетада язышу гына Г. Камалны канәгатьләндерә алмый. Өстәвенә, әдипне аның юнәлеше дә бик үк канәгатьләндермәгәнгә охшый. Ул үз мәсләгенә туры килердәй газета чыгару хәстәренә керешә. Ләкин бу җинел эш булып чыкмый. 1906 елның 1 февралендә Казан мулласы Г. Апанаев наширлегендә һәм мөхәррирлегендә «Азат» газетасы дөнья күрә. Газетаның фактик мөхәррире Г. Камал булган дисәк, ялгышмабыздыр. Биредә аның «Һади» имзасы белән «Безнең кирәк», «И, мөселман йокламагыл!», «Милләт көймәсе», «Йокыда», «Безем хәлләр», «Еламаган балага имчәк бирмиләр» кебек, заманы өчен дистәләгән актуаль шигырьләре, «Г. К.», «З. Г.-ва». «Саип», «Һади» псевдонимнары илә «Дума, дума, дума», «3 ноябрь манифесты ни бирә?», «Уртаклашу татарның табигатенә килешәдер», «Хәзрәтләргә ник тиябез?», «Имамнар һәм агайлар» һ. б. чәчмә әсәрләр, сәяси тәрҗемәләр басыла. Ләкин редакциядә мәсләк ягыннан бердәмлек булмый. Нашир Г. Апанаев газетадагы язмаларга бер төрле юнәлеш бирергә тырышса, Г. Камал һәм аның тарафдарлары икенчерәк, радикальрәк курсны кыйбла итә. Бер үк басмада уң һәм сул, либераль һәм демократик идеяләр бәрелешә. Мондый чуарлык озак дәвам итә алмый, әлбәттә. 56 саны дөнья күргәннән соң (30 май) Г. Апанаев газетаны үз теләге белән туктата. Бу карарга муллага ике-өч мәртәбә салынган штрафлар да йогынты ясамый калмый.

«Азат» тукталганчы ук Г. Камал үз наширлегендә һәм мөхәррирлегендә «Азат халык» газетасы чыгарырга рөхсәт алган була (1906, 2 май). Үз вазифасына тугрылык саклап, ул «Азат»ка язылган әбүнәчеләргә «Азат халык»ны җибәреп торырга вәгъдә итә. Бу хакта «Азат халык»ның беренче санында ук (1906, 4 июнь) «Идарәдән ихтар» (искәртү) басыла. Анда мондый юллар бар: «Нашир вә мөхәрриренең әмере илә туктатылган «Азат» газетасының мөштәриләренә мөддәтләре тулганчыга кадәр ошбу «Азат халык» газетасы күндереләчәктер».

Яңа газета искесенә караганда күпкә сулрак юнәлеш ала. Х. Ямашев, Г. Коләхмәтов һ. б. белән тыгыз хезмәттәшлек кылган Г. Камал «Азат халык»та байтак радикаль язмалар урнаштыра. Алар арасында «Мәшрутәнең асылы», «Социал-демократлар нәрсә өйрәтәләр?» дигән кебек социал-демократик характердагы материаллар була. «Г. К.» имзасы белән басылган «Революция булганчы Франциядәге халыкның тормышы ничек булган?» мәкаләсе, исеменнән үк күренгәнчә, шулай ук шактый радикаль язмалардан. «Азат халык»та «Һади»

псевдонимы астында «Вакыт житте» шигыре басыла. Анда мондый юллар бар:

*Вакыт җитте урыныбыздан кузгалырга,*
*Гыйлем, һөнәр коралларын кулга алырга,*
*Милләтемез адашып, катып бетмеш,*
*Инде кирәк адашканны юлга алырга...*

Цензура газетага гел кырын карый. Шунлыктан аерым саннар ике көнгә хәтле таратылмый тора. Унбишенче санның баш мәкаләсе хөкүмәткә каршы юнәлгән дип табыла, газета конфискацияләнә, Г. Камал хөкемгә тартыла. Суд редакторны бер айга ирегеннән мәхрүм итәргә, гражданский гауптвахтага ябарга хөкем итә. Г. Камал бу карар белән килешми, апелляция бирә, адвокат яллый. Нәтиҗәдә, суд гауптвахта җәзасын йөз сум штраф белән алыштыра. Г. Камал, бу штрафны түләп, зинданнан котылып кала. Ләкин «Азат халык» газетасы инде яшәүдән туктый.

Бу шартларда әдип шактый унайсыз хәлдә кала һәм, Исмәгыйль Рәмиев мәгълүматларына караганда, яна газеталар чыгарырга омтылыш ясап карый. 1906 елда ул «Дөнья» һәм «Әл-Бәян» дигән басмаларга рөхсәт алырга тырыша, ләкин хакимият мона юл куймый. Россиядә реакция янадан куәт ала башлагач, Г. Камал кебек «күз уны»нда торган шәхесләргә радикаль матбугат чыгару яисә житәкләү эшкә ашмастай хыялга әйләнә. Үз исемнәреннән газета-журналлар чыгару Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Ф. Туктаров кебек үткен каләм ияләренә дә насыйп булмый. Шунлыктан алар рәсми житәкчелекне «сәяси яктан ышанычлы» саналган мөхәррирләргә бирергә мәжбүр була, ләкин дилбегәне һәрвакыт үз кулларында тота.

Г. Камал икенчерәк юл сайлый. «Азат халык» туктатылгач, ул янадан «Казан мөхбире» газетасына кереп эшләп карый. Ләкин, күрәсең, идарәсенең тоткан юлы белән килешә алмый, шәхси мөнәсәбәтләрдә дә кытыршылыклар килеп чыга. Тиздән ул бу басмада эшләүдән читләшә.

Олуг максатка корылган шөгыльдән аерылгач, әдип рухи яктан зур гына ташламага барырга мәжбүр була. Бу хакта «Фикер» газетасында (1906, 1 октябрь) «Икене бер, берне юк итү» дигән хәбәрдә түбәндәгеләрне укыйбыз: «Галиәсгар Камалетдинов тарафыннан нәшер улына торган «Азат халык» гәзитәсе ни сәбәптәндер туктатылган. Хәзер инде Һади Максудов берлә мәзкүр Галиәсгар әфәнде икесе берләшеп, «Йолдыз» исемле гәзитә генә чыгарачаклардыр».


Бу хәбәр дөрес булып чыга. Г. Камал күренекле мәгърифәтче һәм педагог Һади Максудиның уң юнәлештәге «Йолдыз» газетасына секретарь булып урнаша. Социал-демократларның зур йогынтысын татыган, аларның партия программаларына түрдән урын биргән әдипнең либераль юнәлеше газетага кучүен өнәмәгән Г. Тукай «Дөнья бу, йа!» дигән шигырендә бу хакта болай ди:

*Социал «Азат халык»ны черносотенный ясап,*
*Һади абзый мәсләген мәсләк дидерткән дөньядыр...*

Ләкин Г. Камалның бу чорда башка чарасы калмаган, күрәсең. Әче телле шагыйрьнең әдипне бу рәвешле тешләп алуы ике олуг шәхеснең киләчәктәге хезмәттәшлегенә киртә була алмый. 1907 елның көзендә Жаек каласыннан Казанга күчеп килгән Тукай Г. Камал белән нәкъ менә «Йолдыз» редакциясендә очрашып таныша. «Һади абзый»ны эзләп килгән шагыйрь, ихтимал ки, башта бу газетага эшкә урнашырга теләгәндер. Ләкин 1907 елның 3 октябрендә демократик яшьләр органы «Әл-Ислах» газетасы пәйда булгач, ул «Йолдыз» тирәсендә башка күренми, бәлки Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, К. Бәкер һ. б. белән «Әл-Ислах»та хезмәттәшлек кыла башлый. Бу газетада Г. Камал да «Бер-ике сүз» дигән мәкалә, «Мулла булгач, чибәр жирдән кыз алып булмый» дигән фельетон белән катнаша, әлеге шәкертләр басмасына зур теләктәшлек белдерә, уңышлар тели.

Г. Камал «Йолдыз»да сәркятиплек кылса, «Дөнья» белән «Әл-Бәян» газеталарын гамәлгә куюда уңышсызлыкка тарыса да, яңа басма оештыру юнәлешендәге

тырышлыкларын ташламый. 1908 елның 3 августыннан ул, нашир һәм мөхәррир сыйфатында, Г. Тукай белән берлектә «Яшен» исемле сатирик журнал чыгара башлый. Реакция елларында мондый басмаларны оештыру чагыштырмача җиңелрәк бирелә, чөнки аларның эчтәлеге хөкүмәтнең эчке һәм тышкы сәясәтеннән шактый ерак торырга тиеш була. Шунысы игътибарга лаек: бу журналның редакциясе әдипнең үз фатирында урнаша. Журналны чыгаручысы да, язучысы да, рәссамы да Г.Камал үзе була. Ул төннәр буе утырып журнал өчен карикатуралар ясый, материалларны тиешле юмор һәм сатира калыбына сала. Әлбәттә, Г. Тукайның шул юнәлештәге әсәрләренә киң урын бирә. Үз язмаларына имзаларын «Яшенче», «Барика», «Сагыйка» дип куя. Ләкин Казан татар матбугатында күренекле урын били башлаган «Яшен» озак яши алмый, үз чыгымнарын каплый алмыйча, ун саны чыккач (1909 ел, 26 июнь) тукталып кала. Бу журнал Г. Камалның үз җитәкчелегендә чыккан басмаларның соңгысы була.


یولدز

شنبه و دوشنبه‌دن باشقه هر کون چغا طورغان سیاسی، اجتماعی وادبی گازیته‌در.

| ПОДПИСНАЯ ЦѢНА: | گازیته‌نڭ بهاسی: |
|---|---|
| 4 рубля на годъ. | بر یل اوچون ٤ صوم. |
| Адресъ: „Юлдузъ", Казань. | چیت مملکتلر اوچون ایکی اولوش. |
| Russie, Kazan, rédaction „Youldouz". | |

ОБЪЯВЛЕНІЯ: впереди текста на 3½ кв. за строку петита 40 коп., позади — 20 коп.

Телефонъ № 7-48.

*«Йолдыз» газетасы.*

«Яшен» тукталгач та ул Тукай белән хезмәттәшлеген дәвам иттерә. 1912 ел азагына кадәр, нигездә Тукай бер ялгызы эшләгән «Ялт-йолт» журналына ташка төшерү өчен карикатуралар эшләп бирә.

«Яшен» журналы тукталгач, Г. Камал янадан Һади Максуди канаты астына килеп сыенырга мәҗбүр була, ягъни «Йолдыз» газетасында сәркятиплек эшен янартып җибәрә. «Йолдыз» битләрендә әдипнең бик күп тезмә һәм чәчмә әсәрләре дөнья күрә, аларның байтагына «Яшенче», «Сагыйка», «Г. К.», «Г К» имзалары хас. Үзләренең әһәмияте ягыннан анын тәнкыйть мәкаләләре аеруча күренекле урын тота. Тулы имза, ягъни «Г. Камал» исеме белән басылганнары исәбенә «Габдулла Тукаев шигырьләре», «Помада мәсьәләсе», «Үги балалар», «Яшь гомер», «Ачлык кушты», «Яңа әсәр», «Татарча театр» һ. б. керә. Башка жанрдагы әһәмиятле язмаларын «Хөсәен әфәнде Ямашевның җеназа мәрасиме», «Иван Николаевич Харитонов», «Мөселман студентлары» һ. б. тәшкил итә.

1912 елның 9 октябрендә Беренче Балкан сугышы башлана. Анда бер яктан Балкан союзы дәүләтләре—Болгария, Греция, Сербия һәм Черногория, икенче яктан—Төркия сугыша. Ярты ел барган бу мөхарәбә 1913 елның 30 маенда Төркиянең җиңелүе белән тәмамлана. «Йолдыз» газетасы Г. Камалны Истанбулга үз хәбәрчесе итеп җибәрә. Ул елда Төркиядә каты суыклар була һәм бертуктаусыз яңгырлар ява. Бик аз акча белән килгән әдип Истанбулда бер фәкыйрь төрекнең миче-фәләне булмаган чарлагында яши, шундый шартларда үзен җибәргән газетага хәбәрчелек итә. Төркия дәүләтенең эчке хәленә бәйле ике дистәләп мәкаләсе «Йолдыз»ның 1912 елның декабрь һәм 1913 елның гыйнвар саннарында басыла. Берөзлексез яңгырлар, салкын һава һәм, күрәсең, Төркиянең хәрби

уңышсызлыклары өчен хафалану Г. Камалның сәламәтлеген нык какшата, көчле нерв авыруына китерә. 1913 елның февралендә «Йолдыз» хәбәрчесе Казанга кайтырга мәҗбүр була. Шәһәрдә атна-ун көн йөргәннән соң, бөтенләй аяк-кулдан калып, нерв авырулары клиникасына керә. Ел ярымнан артык вакыт түшәктә ятканнан соң, Г. Камал, ниһаять, аякка баса һәм үзенең актив иҗат эшенә кайта.

1913-1918 елларда Г. Камал, нигездә, драма әсәрләре иҗат итү һәм тәрҗемә белән шөгыльләнә, ләкин «Йолдыз»дагы сәркятиплек эшен дә ташламый, анда үзенең күп кенә тәнкыйть мәкаләләрен, чәчмә һәм тезмә әсәрләрен бастыра.

Совет власте елларында, Октябрь революциясенә, большевистик идеяләргә бирелгән әдип Казанда нәшер ителгән барлык татарча үзәк басмаларда («Эшче», «Безнен байрак», «Кызыл көрәшче», «Татарстан», «Кызыл Татарстан» һ. б.) эшли, анда күбесенчә кызыл идеягә буйсындырылган шигырьләр, Г. Камалның бу чордагы карашларын Октябрь революциясенең 15 еллыгы унае белән язылган «15 ел» шигыре шактый ачык чагылдыра:

*Җилферди дөнья йөзендә баш имәс көчле кызыл байрак, ялтырап,*
*Егылды канлы капитал дөньясы эшче аяк астына калтырап!*
*Күкләрне күкрәтеп, җирләрне тетрәтеп һөҗүм итте эшче дөньясы!*
*Мәңгегә, мәңгегә җимерелде каһәр төшкән капитал-коллык оясы!*

Мәгълүм булганча, 1929 елда Г. Камалның 30 еллык хезмәт бәйрәме унаеннан күп җирләрдән, шул исәптән чит илдәге татар эмигрантларыннан (Г. Исхакый һ. б.) котлау хатлары һәм телеграммалары алына. Шул унайдан әдип «Кызыл Татарстан» газетасында «Редакциягә хат» бастыра. Анда ул, аерым алганда, болай дип белдерә: «Ирекле Совет иленең дошманнары, контрреволюцияче татар ак эмиграциясе тарафыннан җибәрелгән тәбрик телеграммасын—үзем өчен тәбрик түгел, бәлки хурлык санаганымны әйтеп үтәргә тиеш табам...».

«Татар театрының атасы» Г. Камал үз үлеме белән дөньядан киткән аз санлы өлкән буын әдипләрнең берсе булды. Тагын 4-5 ел яшәгән тәкъдирдә ул Сталин җәһәннәменә озатылучы шәхесләр исемлегенең алгы сафларында булыр иде. Әдипкә һич югы «халык дошманы» буларак ээрлекләнгән Һади Максудиның «буржуаз» «Йолдыз» газетасында сәркятиплеген, Балкан сугышы вакытында Төркиягә хәбәрче сыйфатында баруын искә төшерерләр иде. Бу яктан ул, һичшиксез, бәхтияр шәхес. 1960 еллар башынача татар иҗтимагый фикеренә багышланган хезмәтләрдә демократик эшлеклеләр исемлегендә нигездә өч кенә шәхес искә алына килде: Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал. Һәрхәлдә, К. Фәсиев үзенең 1955 елда басылган «Из истории татарской передовой общественной мысли» дигән китабында безгә шушы шәхесләрне генә демократик язучылар сыйфатында тәкъдим итте, чөнки аларның берсенә дә 1937 ел мәхшәренә чаклы яшәргә насыйп булмаган һәм берсе дә «халык дошманы» исемен алырга өлгермәгән.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә мөмкин: Г. Камал, гаять кинкырлы талант иясе һәм иҗтимагый яктан актив шәхес буларак, XX йөз башы татар мәдәнияте тарихында күренекле роль уйнады, үзенең иҗаты белән аның милли тәрәккыятен билгеләүче аз санлы каләм осталарының берсе булды. Бу хосусият аның татар матбугатын барлыкка китерү, җитәкләү, үстерү буенча каһарман эшчәнлегендә дә әтрафлы чагылыш тапты.

**Равил ӘМИРХАН,**
*тарих фәннәре докторы.*

## *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# Г

**ГАБӘШ** (Гобәйдулла ибне Кәримулла әл-Әлдермеш әл-Болгари) (1785, Казан өязе Әлдермеш а. - 1874 тән соң), дин эшлеклесе, шагыйрь, каллиграф (хаттат). Чыгышы 6-н йомышлы татар гаиләсеннән. Х.-Г. Габәшинең бабасы. Башлангыч дини белемне Зур Кавал авылы мәдрәсәсендә мөдәррис Габдеш хәзрәттән ала. 1812 елда Бохарага укырга китә. Уку елларында язылган, хатыны Бибифатыйма бинте Сәйфелмөлек исеме 6-н аталган «Фатыйманамә» (Бохара, 1813, кулъязма рәвешендә) шигъри җыентыгы сакланган. 19 йөз башына караган аз санлы шигъри әсәрләренең берсе булган (135 бәйт, 270 юл) бу китапта авторның гаиләдә һәм җәмгыятьтә хатын-кызның билгән урыны турында карашлары һәм фикерләре урын алган.

Бохарадан кайтканнан соң, 1822 дә Г. Казан өязе Кече Солабаш авылы мәчетенең имам-хатыйбы була. Тиздән ул үзен югары белемле дин белгече, шәрекъ әдәбияты әсәрләрен күчерүче, оста каллиграф һәм кабер ташларына эпитафияләр язучы буларак таныта. 1864 тә Казан тюркологы Е.Малов болай дип яза: «Солабаш мулласы Гобәйдулла бине Кәримулла мөселманнарда кәтиб буларак билгеле. Ул кулъязмалар күчерә һәм кабер ташларына язу төшерә. Гобәйдулла кулъязмаларының кайберләре Казан ун-тында саклана». И.Ф.Готвальдның «Император Казан ун-ты китапханәсенә караган гарәб кулъязмалары тасвирламасы» («Описания арабских рукописей, принадлежавших библиотеке Императорского Казанского университета», 1855) китабында Г.нең түбәндәге кулъязмалары күрсәтелә: Шәрәфетдин бине Хисаметдиннең «Тәварихы Болгария»се (1832 елгы күчермә); 1844 елгы күчермәдә: Такыетдин Әбу Гомәр бине Габдрахман бине Госман бине Салихның (1181-1245) «Ысулел-хәдис»е, билгеле булмаган авторның «Кыйссаселәнбия»се, Мөхәммәд әл-Хәдиминең «Рисаләә фи мәбәхис әл-бисмилла»сы, Хисаметдин Әбелхәер бине Мөсләхетдин Мостафа Ташкөпризадәнең (1495-1560) «Шакаикел ногъмания фи зикр голәмә әд-дәүлә Госмания»се, Зәйнетдин Гомәр бине әл-Мозаффар бине әл-Вәрдинең (1349 да вафат) «Хәридел гаҗәеб вә фәридел гараиб»е; 1845 елгы күчерелмәдә: Хаҗи Мөхәммәд бине Мөхәммәд Парса әл-Хафизинең (1419 да вафат) «Әл-фусуль әсситтә»се, Мәүли Ибраһим бине Мари Шәбрәхитинең «Әл-арбагыйн әнНәвәви»се.

Ишан Нигъмәтулла әл-Әлмәтинең Казанга һәм Казан тирәләренә сәяхәт кылуы турындагы «Холасател бәян» (1889 да басыла) исемле шигъри әсәр авторы. Ул 19 йөзнең 40 елларында язылган дип фаразлана. Әлеге китапларда һәм «Фатыйманамә»дә автор тарафыннан күп кенә гарәб-фарсы алымнары кулланылса да, стильне гадиләштерүгә омтылыш, 19 йөзнең 1 яртысында татар әдәбиятында традициягә кергән шигырьне бизәкләр 6-н артык чуарлаудан котылырга тырышу нык чагыла.

Г. - гарәп галиме Габделкаһир бине Габдрахман Җирҗәнинең «Китабел-гавамил-иза» (1078) китабына фарсы телендә, гарәб теле грамматикасына (Мөхәммәд Нәҗип Түнтәри китапханәсеннән) шәрехнамәләр авторы. Алар Казан ун-тының Фәнни китапханәсе кулъязмалар бүлегендә саклана.

Г.ның уллары әтиләренең китап күчерүче һөнәрен дәвам итәләр. Өлкән улы Әхмәт Казанның Яңа бистәсендә яши. Казан ун-тында 1844 елгы кулъязмасы саклана. Кече улы Мөхәммәд 1850 дә Кече Солабаш авылының икенче мулласы (әтисе 6-н бергә) булып билгеләнә. Ул шулай ук китап күчерүче һәм кабер ташларына язу төшерүче буларак мәгълүм. Г. хезмәтләре бүтән каллиграфлар тарафыннан күчереп алынган.

Әд.: Малов Е. Миссионерство среди магометан и крещёных татар. К., 1892; Султан Габяши: Материалы и исслед. К., 2000; Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 2001; Кулъязмалар тасвирламасы. VII чыг. Татар әдипләре һәм галимнәренең кулъяз-

*Дәвамы. Журналыбызның 2005 ел, 4 санынннан басылып килә.*

малары / Төз. А.Фәтхи. К., 1969.

*М.В.Гайнетдинов,*
*Р.И.Шамсутов.*

**ГАБДЕЛВАҺАБ** бине МОСТАФА (18 йөз), шагыйрь. Оренбург губ.-сының Минзәлә өязе Дәвек авылында укыган елларында «Ике сукыр» (1780 ел тирәсе) балладасын яза. Кульязмасы ТРның Дәүләт музеенда саклана. Әсәрләренең төп темасы - мохтаҗларны кызгану, бозыклыкны тәнкыйтьләү. Балладаның чәчмә варианты Таҗетдин Ялчыголның «Рисаләи Газизә» (1795) китабында урын алган һәм татарлар арасында киң таныл-ган.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДЕЛМӘҖИД** (14 йөзнең 2 нче яртысы - 15 йөз башы), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. Кайбер мәгълүматларга караганда 1410 елда Кырымда яшәгән. Бүгенге көнгә Сәйф Сараи тарафыннан нәзыйрә язылган «Күңел» исемле газәлләренең берсе генә килеп җиткән һәм «Китабе Гөлестан бит-төрки» китабында сакланып калган. Йосыф-Зөләйха сюжетына нигезләнеп язылган поэма (сакланмаган) авторы.

Әд.: Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976.

**ГАБДЕССӘЛАМ бине УРАЙ** (Габдессәлам бине Уразмөхәммәд бине Колмөхәммәд бине Колчура; тәхәллүсе Габдүш) (1700, Казан өязе Мәңгәр а., хәзерге Әтнә р-ны Олы Мәңгәр а. – 1767 дән соң), шагыйрь, дин эшлеклесе. Ә.Каргалыйның бабасы. 1725 елдан Казан өязе Ташкичү а. яши һәм укыта, 1742-46 елларда авыл мәчете имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе. 1746 елдан Оренбург губернасы Каргалы бистәсендә мәдрәсә тота, озак еллар аның мөдәррисе була. Шәкертләренең берсе, 1755-56 еллардагы татар-башкорт халык күтәрелешен оештыручы – Батырша белән тыгыз элемтәдә тора һәм аның патшага язган хатында Г.нең исеме күрсәтелә. Г. – 40 шигырь авторы. Танылган шигырьләре арасында 1757 елда рус-герман сугышында һәлак булган татар солдаты турындагы - «Меллагол бәете». Әдәби мирасында мәхәббәт лирикасы күренекле урын алып тора; иҗтимагый-тарихи проблематика чагылыш тапкан. Иҗатында халык чуалышларында катнашучыларга теләктәшлек белдерә. Г. бине У. шигърияте татар халык иҗаты б-н тыгыз бәйләнештә булуы б-н үзенчәлекле. Шигырьләре күп күчерелмәләрдә тарала, кайберләре «Татар поэзиясе антологиясе»нә кергән (т.1-2, 1992).

Әд.: Ахметзянов М.И. Габдуссалям // Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). К., 1999; Әхмәтҗанов М.И. Татар кульязма китабы. К., 2000.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДЕЛМӘН** Сабир (1879, Самара губ., Богорыслан өязе, Котлымбәт а. - 22.12.1917, хәзерге Кыргызстан Респ-касы, Семиречинск өлкәсе Тукмак ш. ), шагыйрь. Чыгышы б-н крестьяннардан. 1902 елдан «Икъбалия» мәдрәсәсендә укыта (хәзерге Кыргызстан Респ-касы Карагол ш.). 1910 да Төркия, Мисыр, Сәгуд Гарәбстанына сәяхәт кыла. 1914 тә Россия армиясенә алына, 1 нче бөтендөнья сугышында катнаша. Яралана, авыру сәбәпле демобилизацияләнә. Шигырь, хикәя, публицистик мәкаләләре «Шура» ж-лында, «Кояш» г-тасында һ.б. басыла. Пржевальск шәһәрендәге Татар-кыргыз җәмгыяте әгъзасы булып тора. Җәмгыять хисабына үзенең социаль һәм антиколониаль яңгырашлы «Фөрьядлар» («Аһзарлар», Казан, 1908) исемле лирик шигырьләр җыентыгын чыгара. Китап, чыгу б-н үк, хакимият органнары тарафыннан җыеп алына, авторы төрмәгә ябыла. 1909 да балалар өчен язылган «Нәтиҗәи әхлак. Хикмәтле сүзләр вә хикәяләр» китабын бастыра. Китапта авторның үз шигырьләре һәм үгет-нәсыйхәт характерындагы мәкальләр урнаштырылган.

Әсәр.: «Әүлия ата»дагы иске әсәрләр турында // Шура. 1915. N8; Милләтнең юлбашчылары // Шура. 1915. N20; Мөхәммәт әфәнде // 1916. N14/15.

Әд.: Мурадымов Н. Ценная находка из Казани // Вечерняя Казань. 1990. 26 марта; Сабир әфәнде Габделмәновның вафаты // Олугъ Төркестан. 1918. 24 гыйнв.; Әхмәтҗанов М. Татар әдәбияты тарихына яңа исемнәр // Мәгърифәт һәм азатлык өчен көрәш. К., 1987.

*М.И.Әхмәтҗанов.*

**ГАБДИ** (Мескен Габди, Мелла Габди, Галим Габди) (псевд., чын исеме билгеле түгел) (1679 - 18 йөзнең 1 нче чирегe), шагыйрь. Казанда яшәгән һәм иҗат иткән дип фаразлана. 1927 елда шигырьләренең бер өлеше авторның исеме күрсәтелмичә «Безнең юл» ж-лында басыла. Автор 1709 да нәсер жанрында язылган, кульязма рәвешендә сакланган «Габди шигырьләре» исемле җыентыгы 1975 тә табылган-

нан соң гына танылa. Җыентыкта суфичылык рухында язылган 60 якын шигырь тупланган. Г. шигырьләрендә рухи мәсьәләләрдән тыш бик күп тормыш проблемалары да күтәрелә, җәмгыятькә карата тәнкыйть сүзләре урын ала. Гади халыкка карата якынлыгын белдерә, аның хәленә керә, түземлек тели, хакимнәрне гадел булуга өнди. Татар халкының иминле киләчәген иҗади хезмәттә, үзара ярдәмләшүдә күрә. Г. кульязмалары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты мирасханәсендә һәм Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең сирәк очрый торган китаплар һәм кульязмалар бүлегендә саклана.

Әсәр.: Габди шигырьләреннән үрнәкләр // Казан утлары. 1978. N10.

Әд.: Абилов Ш.Ш. XVIII йөз башы татар шагыйре Габди әсәрләре // Татар теле һәм әдәбияты. К., 1977. 6 кит.; Аныкы ук. Поэзиябез тарихына яңа исем // Казан утлары. 1978. N10; Татар әдәбияты тарихы. К., 1984. 1 том; Татар поэзиясе антологиясе. К., 1992. 1 кит.

*Ш.Ш.Абилов.*

**ГАБДРӘХИМОВ** Фәрит Ибраһим улы (8.1.1933, Башкортстан АССРның Бүздәк р-ны Арслан а.), шагыйрь, Башкортстан АССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). Башкорт һәм татар телләрендә иҗат итә. Башкортстан ун-тын тәмамлый (1963). 1965-69 елларда «Ленин юлы» г-тасы (Туймазы ш.) редакциясендә әдәби хезмәткәр, 1969-94 тә «Кызыл таң» г-тасында (Уфа ш.) әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Әсәрләре 1960 елларда басыла башлый. Шигырьләрендә якташларының матур образлары, туган төбәге табигате гәүдәләнеш таба. «Йөрәк уты» (Өфө, 1971), «Ерзәге йондоззар» (Өфө, 1975), «Алтын туй» (Өфө, 1982), «Күнел күзе» (Өфө, 1985), «Кичер мине!» (Уфа, 1995), «Син дә мин» (Уфа, 2000) җыентыкларына тупланган шигырьләре татар халкының гыйбрәтле язмышы турында уйланулар белән тулы. Г.ның күп кенә шигырьләре рус, чуаш, украин телләренә тәрҗемә ителгәннәр. Уфада яши.

Әд.: Хөсәен М. Табигатьтә бары да табигый // Ватаным Татарстан. 1993.15 янв.; Мулюков М. Керәм давыл уртасына // Тулпар. 1996. N6.

**ГАБДУЛЛА** бине ГАБДУЛЛА (Габдулла Болгари) (19 йөзнең 2 нче яртысы - 20 йөз башы), язучы, публицист. Татар һәм гарәп телләрендә язган. Бәхәс характерындагы ике китап авторы. «Гөҗәлә марзыйа фи бәянел Әшгарыйа» (1905) китабында Р.Фәхретдиновны һәм аның «Асәр» китабын ортодоксаль ислам тәгълиматы ноктасыннан чыгып, урта гасыр гарәп дин белгече Әбүл-Хәсән Гали әл-Әшгаригә (936 да үлә) ишарә итеп тәнкыйтьли. Китап ахырына Г. бине Г. үзенең шигырьләрен дә урнаштыра. Аның икенче китабы - «Изһар әт-тәэсүф» (1907) хатын-кыз эмансипациясенә, татарлар арасында сәнгатьнең үсүенә каршы юнәлтелгән, анда шулай ук җәдитчелек идеологы булган Г.Барудига һәм бу юнәлешне яклаган Ә.Н.Максудига карата тәнкыйди фикерләр урын алган.

*А.М.Ахунов.*

**ГАБДҮШ** Хөсәен Рәхимҗан улы (5.1.1901, Троицк ш., - 14.4.1944, Харбин ш., Кытай), язучы, журналист. Реаль училищедә укый (Петропавловск ш., Казакъстан). 1917 елдан соң Маньчжуриягә (Кытай) күчеп китә. «Милли байрак» г-тасында, «Ерак Шәрекъ», «Яңа милли юл», «Белдереш» (Хельсинки), «Казан» ж-лларында языша. Г.Камал, М.Фәйзи, Г.Исхакый пьесалары буенча спектакльләр куя, үзе аларда баш рольләрне башкара, татар мөһаҗирләре өчен әдәби кичәләр оештыра. Берничә пьеса, шул исәптән «Татар телендә беренче телеграф», хикәяләр һәм шигырьләр авторы. «Дүрт хикәя» (Токио, 1931) исемле җыентыкка кергән кайбер хикәяләре туган илне сагыну хисе белән сугарылган.

Әд.: Миңнегулов Х. Урал егете // Мирас. 1992. N9; Хөсәен Габдүш хикәяләре // Мирас. 1999. N7.

*Х.Ю.Миннегулов.*

**ГАБДҮШ**, псевд. **Габдессәлам бине Ураи.**

**ГАБИД** (Габидуллин) Гиз-эл (Гыйздулла) Лотфи улы (7.1.1918, хәзерге Оренбург өлкәсе Свердловский р-ны Хөсәен (Саиновка) а. -1955), шагыйрь. Богорыслан пед. техникумын тәмамлаганнан соң (1937) Оренбург өлкәсе Зианчура р-нында укытучы булып эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Фронт газеталарында хәбәрче була. Армия хезмәтеннән азат ителеп кайткач (1946), Үзбәкстан шәһәрләрендә балалар укыта. Г.ның сугыш елларында язылган шигырьләре «Алар сафта» (1961), «Беренче карлыгачлар» (1968) исемле күмәк җыентыкларга кертелгәннәр.

Әд.: Әпсәләмов Г. Г.Габид турында // Социалистик Татарстан. 1968. 18 февр.; Мәҗитов З. Һәр шагыйрьнең үз тавышы // Сугышчан поэзия. К., 1975.

**ГАБИДИ** (Габидуллин) Әзһәр Сәмигулла улы (26.9.1926, Сарман р-ны Чукмарлы а. - 22.8. 2001, Сарман р-ны Сарман а.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Минзәлә пед. уч-щесын тәмамлый (1950). 1950-80 елларда авыл мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбиятын укыта. Әдәби иҗат эше белән 1942 дән бирле шөгыльләнә. Республикада чыга торган газета һәм журналларда, күмәк җыентыкларда әсәрләре басылып килә. Балаларга багышланган «Без - яз дуслары» (1965), «Тапкырҗан табышмаклары» (1966), «Кошчыгым» (1981), «Калган эшкә кар ява» (1993) исемле шигырь җыентыклары авторы. Лирик шигырьләре «Таң сәгате» (1989), «Болыннарым» (1997) җыентыкларына тупланган. Г. ның шигырьләренә ихласлык, самимилек хас. Г. шулай ук публицистика һәм әдәби-тәнкыйть өлкәсендә дә эшләде.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә.

Әд.: Маликов Р. Чишмәләр дә бик тиз бәреп чыкмый // Заман. 1999. 6 сент.

*Г.М.Габделхакова.*

**ГАДЕЛ** (псевд., чын фам. Гаязов) Әхмәт Хади улы (2.2.1942, Мамадыш р-ны Акчишмә ав. туа), шагыйрь, кинодраматург. М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1977, Мәскәү) тәмамлый. 1966-82 еллар арасында Түбән Кама район газетасы хәбәрчесе, Балык Бистәсе р-ны Шомыртбаш мәктәбендә укытучы, ТАССР МС телевидение һәм радиотапшырулар комитетында тәрҗемәче, Республика халык иҗаты йортында һәм Мәдәният министрлыгында методист булып эшли. 1983-84 тә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры. 1992-97 елларда ТР Кинематография дәүләт комитетында, 1997-99 да ТР Язучылар берлеге рәисе урынбасары. 1960 еллардан басыла башлый. Армия тормышыннан алып язылган шигырьләре рус телендә «Поиск» исеме белән аерым җыентык булып басылып чыга. Заманча әчтәлекле, җылы бер аһәң белән өртелгән лирик шигырьләре «Күгәрченнәр» (1971), «Чам» (кырым татар телендә, Ташкент, 1978), «Көмеш кылган җыры» (1982), «Яшьлегем былбыллары» (1985), «Дәрт» (1992) җыентыкларына тупланган. Аның сценарийлары буенча һәм соавторлыкта 50 дән артык документаль һәм балалар өчен мультфильмнар төшерелгән. Ашхабад һәм Мәскәү шәһәрләрендә үткәрелгән Бөтенсоюз кинофестивальләр лауреаты (1984; 1987).

Әд.: Ахунов Г. Шагыйрь дөньясы // Социалистик Татарстан. 1992. 1 февр.; Хисматулла Р. Бердәнбер // Ватаным Татарстан. 1997. 14 март; Әхмәтҗанов М. Әнкәйләрдән килгән бу мәхәббәт // Мәдәни җомга. 1987. № 10.

**ГАДЕЛ** (Гадилев) Лотфи (Лотфулла) Кәрибулла угылы (22.10.1894, Вятка губ., Алабуга өязе Салагыш а. - 1915), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе. «Буби» мәдрәсәсендә укый. 1911 елда Казан татар укытучылар мәктәбенә керә. Укуын тәмамламыйча 1914 тә үз теләге б-н фронтка китә. «Сөембикә», «Аң», «Ак юл» ж-лларында, «Кояш», «Йолдыз» г-таларында «Көнчелек» (1913), «Аерылышу» (1914), «Ике хат» (1914) һ.б. хикәяләре басыла. Г.Тукай һ.б. иҗатына, тәрҗемә мәсьәләләренә караган әдәби-тәнкыйть мәкаләләр авторы. 1 нче бөтендөнья сугышында һәлак булган дип фаразлана.

*А.М.Ахунов.*

**ГАЗӘЛ** (гарәп. гыйшык-мәхәббәт), Урта һәм Якын Көнчыгыш, Көньяк-көнчыгыш Азия әдәбиятларында, Идел һәм Урал буе төрки телле халыкларның лирик поэзиясендәге шигъри форма. Гадәттә, һәрберсе тәмамланмаган фикергә һәм мөстәкыйль мәгънәгә ия булган 7-15 бәйттән (икеюллыклардан) тора. 1 нче бәйттә 2 юл рифмалаша, башкалары ба, ва, га, да: тәртибендә бирелә. Соңгы бәйттә, кагыйдә буларак, автор исеме яисә кушаматы искә алына. Г. жанрындагы иң камил әсәрләр безгә Рудәки, Сәгъди, Хафиз, Физули, Нәваи, Лотфи иҗади мираслары аша билгеле. Татар әдәбиятында урта гасыр шагыйрьләреннән Сәйф Сараи, Өмми Камал, Колшәриф; 19 һәм 20 йөзләрдә Ш.Зәки, Г.Кандалый, Акмулла, Г.Тукай, М.Гафури, Ш.Бабич һәм соңрак Н.Арсланов, Р.Гаташларның Г. жанрында иҗат иткән әсәрләре бар. Г. жанрына ш.у. Европа һәм рус шагыйрьләре дә (А.Фет, В.Брюсов, Гете, А.Платен һ.б.) мөрәҗәгать иткәннәр.

Әд.: Квятковский А. Поэтический словарь. М., 1966; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Дәвамы киләсе саннарда*

Сергей
Макеев

# БАРОН МЮНХГАУЗЕН—ЧЫНБАРЛЫКТА

Моннан 265 еллар элек, үзен мажаралы китап герое итеп тойган 17 яшьлек бер егет, Германиядән Рәсәйгә килә. Көндәлек язарга күнеккән булса: «Рәсәйгә бару юлына мин өйдән кыш уртасында чыгып киттем,»—дип башлап китәр иде ул аны. Күп еллардан соң аның «Коры җирдә һәм дингездә гаҗәп сәяхәтләр, сугышчан юллар һәм күнелле мажаралар» турындагы китабы нәкъ шулай башланып китә. Ә бу чакта ул, каретаның тәрәзәсенә сарган бәсне сулышы белән эретеп, зур кызыксыну белән очсыз-кырыйсыз кар дингезенә карап бара.

Егет Рәсәйгә хуҗасы—Брауншвейг принцы Антон Ульрихның пажы, ягъни принцның хезмәтче малае сыйфатында килә. Ерак һәм бик салкын кышлы булганга, башка пажлар Рәсәйгә килүдән баш тарта. Өстәвенә, андагы шәһәр урамнарында ач бүреләр һәм аюлар йөри, дип тә сөйлиләр бит.

«Брауншвейг герцогы сараенда күнелсезлектә утырганчы, Рәсәйдә тунуың хәерле!»—дип карар кыла тәвәккәл егет. Менә шул рәвешле Иероним Карл фон Мюнхгаузен 1738 елның февралендә Санкт-Петербургка килә.

## Кар һәм интригалар патшалыгында

Иероним инде кыска балаклы чалбар киеп йөрүче паж гына түгел; аның—бабаларын данга күмәсе килә: XII гасырда император Фридрих Барбаросса байрагы астында Тәре походында катнашкан рыцарь Хейно—аның нәселенә нигез салган бабасы. Тагын бер бабасы Хилмар фон Мюнхгаузен XVI гасырда ялланган гаскәрләр полководецы була; сугыш табышы аңа Везер елгасы үзәнендә берничә замок төзетергә җитә. Егетнең абзасы Герлах фон Мюнхгаузен—Европадагы иң яхшы Геттинген университетына нигез салучы, аның попечителе, министр...

Аһ, ул малай Рәсәйдә аны аю-бүреләр, боз булып туңган авазлар түгел—алардан да яманрак хәлләр көткәнен белсә иде!

Ул чакта Рәсәйдә Петр Iнең туганнан туганы Анна Иоанновна хакимлек итә. Ул, бөек абзасының эшләрен таныса да, Петрның вакытсыз вафат булган туганы Иванның балалары Петр һәм Екатерина нәселен күралмый—алар өчен Екатерина «әшәке катлам»нан була бит. Алар Екатеринаны «кер юучы» дип кенә атаганнар. Алар уенча, бары тик «ивановичлар» гына хакимлек итәргә тиеш була. Ә менә Анна Иоанновнаның балалары булмый: ул бик иртә тол кала. Хакимлекне Ивановлар ягыннан дәвам иттерү максатыннан, Анна Иоановна туганының кызы Анна Леопольдовнаны Европаның кайсы да булса бер принцына кияүгә бирү һәм тажны аларның баласына мирас итеп калдыру уе белән яна.

Брауншвейг принцы Антон Ульрих кияү булырга иң кулай кеше була. Ул—күренекле, белемле егет, билдекле һәм кыю офицер. Ләкин аны яучылау-димләү 7 елга якын сузыла. Никадәр генә абруйлы булса да, Антон Ульрих сәяси фикер йөртә дә, хисләрен яшерә дә, мәкер кора да белми.

Ә интригалар җитәрлек була: императрицаның куәтле фавориты Бирон, фельдмаршал Миних, канцлер Остерман, башка күп кенә сарай әһелләре, чит илләр дипломатлары—барысы да «үз уенын» оештыра, вакытлыча союзлар булдыра, элеккеге дусларын сата.

Әлеге драмаларда яшь Мюнхгаузен—бары статист, ягъни театр сәхнәсендә сүзсез

яки кечкенә рольне башкаручы. Ул әлеге пьесаларның эчтәлеген белми, бары тик кайбер башкаручыларны гына күрә һәм аларның кайбер репликаларын гына ишетә.

1738 елда яшь Мюнхаузен беренче мәртәбә дары исен исни, төрекләргә каршы сугышта принц Антон Ульрихны озатып йөри. Ул чакларда сугышлар бары тик җәйләрен генә булган, анда бару өчен армиягә далалар аша ярты Рәсәйне кичәргә кирәк була. Төрекләрнең союздашы буларак, кырым татарлары дала үләненә ут төртә; аларның юртак атлы отрядлары ялкын һәм төтен эченнән, җәһәннәмнән чыккан кебек, корымга батып чыгып, рус олауларына һөҗүм итә. Гаскәргә эчәр су, азык-төлек, сугыш кораллары җитешми... Ничек кенә авыр һәм куркыныч булмасын, Мюнхгаузен үзенең урынын армиядә күрә.

Тагын ярты ел яшь егет паж вазыйфаларын үти: һәр җирдә принц Антон Ульрихны озатып йөри, аның белән мәҗлесләрдә, бал һәм маневрларда катнаша. Бервакыт Петербургтагы парадта бер солдат кулындагы мылтык ялгыш атылып китә. Ул чакта шомпол мылтык көпшәсенә урнаштырыла торган була. Паж Мюнхгаузен ату тавышын һәм колак төбеннән нидер сызгырып үткәнен дә ишетә. Шомпол, ук сыман, принц атының аягына кадала. Ат та, принц та юлга егылалар. Бәхеткә, принц зыян күрми. «Өйгә кайткач, мажаралар сөйләгәндә, мондый хәлне уйлап та чыгара алмас идем әле!»- дип уйлап куя яшь Мюнхгаузен.

Бик озак ялына торгач, принц Антон Ульрих пажын хәрби хезмәткә җибәрергә ризалаша.

Бер елдан Мюнхгаузен—поручик, полкның беренче гвардия ротасы командиры. Ул эшнең мәгънәсенә бик тиз төшенә торган офицер булып җитешә. «Затлы, мөхтәрәм поручик әфәнде» кавалерия атларын һәм рядовойларны кайгыртучан була, башлыклардан—солдатлар өчен корал, киемнән башка кирәк-яраклар һәм атларга фураж өчен акчаны таләп итеп кенә тора, рапортлар яза, хисап тота: «Түбәнчелек белән, мина ярдәм итү өчен, корнет (кече офицер) җибәрүегезне үтенәм, чөнки... кешеләрне һәм атларны пөхтә тоту берүземнең генә хәлемнән килми». «Әлеге елның февраль аенда кешеләргә азык-төлек һәм атларга фураж алыну турында ике ведомость салам». Тик менә Мюнхгаузенга сугышта катнашу насыйп булмый. Рәсәй төрекләр белән тынычлык турында килешү төзи, ә 1741-1743 еллардагы швед кампаниясендә аның ротасы сугыш хәрәкәтләрендә катнашмый. Офицер кеше сугышсыз ничек үсә алсын инде?!

## Карьера үсеше туктала

1750 елда ул үзенең ин югары—ротмистр чинына ирешә. Ләкин моны яхшыга юрамый: хәрби карьерасы әллә ни үсеш ала алмый, һәм инде югарыда химаячеләре дә калмый.

Кызыклы очрашулар, тәэсирләр белән тормыш дәвам итә. 1744 елда Рәсәйгә княгиня Анхальт Елизавета белән аның кызы — бөек императрица Ектерина булачак Софья Фредерика Августа киләләр. Чик буенда аларны статный поручик барон фон Мюнхгаузен җитәкчелегендәге рус гаскәренең почетлы каравылы каршы ала. Их, шул чакта аңа карета тәрәзәсеннән бөек императрица булачак Екатерина ап-ак кулларын селтәгәнен белсә, тагын да мәһабәтрәк кыяфәт алган булыр иде ул! Ә Екатеринаның әнисе көндәлек дәфтәренә: «Үзем күргән кирасирлар полкын, чыннан да, үтә матур булган өчен мин бик мактадым»,—дип язып куя.

Аралашучан яшь баронның Санкт-Петербургта һәм Ригада дуслары күп була. Аларның берсе—Балтыйк буе дворяны фон Дунтен бервакыт Мюнхгаузенны үзенең имениесенә ауга чакыра. Поручик бик күп киек ата һәм үзе дә зур тетрәнү ала: хуҗаның кызы Якобинага гашыйк була ул. Шул ук 1744 елда Иероним белән Якобина өйләнешәләр.

Озак көткән ротмистр чинына ирешкәч, Мюнхгаузен ял сорап ала һәм хатыны белән бер елга Германиягә китә. Аңа мирас эшләрен туганнары белән хәл итәргә кирәк була. Мюнхгаузеннар—өч ир туган булып, аларның ике зур биләмәсе була; менә шуларны бүлеп кара инде син! Барон ялын тагын бер елга озайта, ләкин эшен тәгәлли алмый, яңадан хәрби җитәкчелегенә мөрәҗәгать итәргә базмый. Ул арада бер

туганы сугышта һәлак була, калган варисларга жирәбә тотасы гына кала—тиздән Иероним Мюнхгаузен Ганновер шәһәре янында—Везер елгасы ярындагы поместьеның законлы хужасы була. 1720 елның 11маенда туган өенә әнә шулай әйләнеп кайта ул. Айдан, янсә Төньяк полюстан кайткан кебек, Рәсәйдән әйләнеп кайта бит! Балигъ булмаган үсмерчак китеп, чын ир булып кайтып керә. Ә бит күбәүләр Рәсәйдән кайта алмады: берәүләр һәлак булды, икенчеләре шунда яшәргә калды.

Ә бу чакта кавалерия полкында тикшерү бара. Ротмистр Мюнхгаузен кайда? Ул юк. Урынлы сәбәп белән дә китмәгән, шунлыктан 1754 елда барон Мюнхгаузенның исеме полк һәм Рәсәй армиясе исемлегеннән сызыла.

## Мюнхгаузенның икенче тормышы

Шулай итеп, барон бай хужа (барин) булып китә. Башта ул ташландык паркны тәртипкә китерә, «грот» стилендә заманча павильон төзи. Ләкин аның бу һәвәслеге сүрелә, бәлки, акчасы да беткәндер. Күп булмаган табышлар белән байларча яшәп булмый шул.

Баронга күнелсез була башлый. Ә бит ул яшьтәш пажлар һәм офицер дуслары арасында үзәктә булырга күнеккән.

Баронның, мөгаен, ауга чыккач кына кәефе күтәрелә торган булгандыр—ялкынлы һәм оста аучы була ул. Ялга туктагач, Мюнхгаузен күрше алпавытларына гаҗәеп хикәяләр сөйли. Ул аларга дөп-дөрес хәлләрне дә сөйләр иде, сөйләрлеге дә бар инде анысы... Ике императрицага һәм бала патшага ундүрт ел хезмәт чорындагы фетнәләр, җәзалар турында сөйли башласа, тегеләр күнелсезләнә башлый. Аларга маҗаралар кирәк: «Руслар кар астында яши диләр, шул дөресме?»—«Дөрес !—дип эләктереп алып сөйләп китә Мюнхгаузен.—Бервакыт мин атымны казыкка бәйләп куйдым да карга ятып йокладым. Иртән уянып китсәм, мин жирдә ятам, ә атым колокольня тәресендә эленеп тора! Бөтен авыл кар астында калган булып чыкты, иртән кар эрегән иде инде.»

Менә шуннан китә дә инде! Күргән-ишеткән, укыган, уйлап чыгарылган һәрнәрсәне тегеләр рәхәтләнеп тынлый. Теге шомпол вакыйгасы да искә төшә ( ә барон хикәятләрендә ул, бер ук атып, бер көтү кыр тавыгы аулый бит). Мюнхгаузен хикәятләренең даны тирә-юньгә, аннары бөтен Германиягә тарала. Бер караганда, әллә ние дә юк бит инде. Нәкъ балыкчы ялганнары кебек. Кайбер мәзәкләрне китап-журналларда да укыганнары бар кебек...

Шулай да Мюнхгаузен хикәятләре башкача яңгырый. Аларның үзенчәлекле герое бар, һәм ул үзе күргәннәрне беренче заттан сөйли. Геройның исеме дә үзенеке, титулы да шул ук, биографиясе дә авторныкы белән тәнгәл. Болар барысы да Мюнхгаузен уйдырмаларына чынбарлык төсмере бирә, ә сөйләүче, «ышанасыңмы-юкмы» дигән булып, тынлаучы белән уйный һәм, билгеле инде, әлеге күнелле хикәятләр чын күңелдән көлдерә.

Өстәвенә, барон—бер дигән сүз остасы да, башыннан үткән вакыйгаларда катнашучы да. Мюнхгаузен—бергә ауга чыккан күрше алпавытларының гына түгел, зуррак публиканың да игътибарын җәлеп итә белгән. Геттингенда яшәгән бер замандашы Мюнхгаузенның «Пруссия короле» дигән ресторанда чыгыш ясавын хатирә итеп яза: «Гадәттә, аштан соң, ул үзенең пемзадан эшләнгән кыска мундштуклы зур трубкасын тартып җибәрә, алдына пары чыгып тора торган пуншлы стаканын куя да хикәятләрен сөйләп җибәрә иде. Куллары белән кечкенә көяз паригын боргалап, гәүдә хәрәкәтләре белән хикәятләренең эчтәлеген тулыландыра; йөзе дәртләнеп, кызарып китә; бик тә туры сүзле шушы кеше бу минутларда үзенең гаҗәеп уйдырмалары уенына тәмам бирелеп китә иде.»

1781 елда «Күнелле кешеләргә юл күрсәткеч» дигән журналда «M-h-s-n әфәнде» дигән имза белән беренче хикәятләре басылып чыга. Англиягә качып китәргә мәҗбүр булган әдәбиятчы һәм немец галиме Рудольф Эрих Распе берничә елдан якташының уйдырмаларын искә төшерә һәм «Барон Мюнхгаузенның Рәсәйдә гаҗәеп сәяхәтләре һәм походлары» дигән күнелле китап яза.

Икенче елында ук Германиядә күренекле шагыйрь Август Бюргерның немец

телендә «Барон Мюнхгаузеннын дуслары арасында, шешә янында сөйли торган күнелле мажаралары, коры жирдә һәм дингездә гажәеп сәяхәтләре, сугыш походлары» дигән— ул чакта мәдехле булганча озын атамалы китап басылып чыга (1786, 1788). Бюргер менә шулай Мюнхгаузенны Германиягә кайтара, фантастик мажараларга сатира өсти, яна сюжетлар кертә (мәсәлән, май кисәге бәйләнгән жеп белән үрдәк аулау, сазлыктан чыгу, ядрәдә очу). Бюргернын китабы сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да камилрәк була. Әнә шулай икенче—ягъни уйлап чыгарылган Мюнхгаузен барлыкка килә, ул чынбарлыктагысын каплап китә һәм чын хикәятчегә кыенлыклар да китерә.

Мюнхгаузен чыгырыннан чыга. Анын фантазиясен ничек шулай бозып күрсәтергә кирәк?! Ул бит тынлаучыларынын күнелен күрә иде, үзе дә алар белән бергә күнел ача иде!

## Соңгы мәзәк

Әнә шулай баронның популярлыгы ана кыенлык та китерә. Мюнхгаузенның уйдырмаларын анын күршеләре, дуслары, туганнары, таныш язучылары, галимнәр яратып кабул иткән. Ләкин «М-һ-з-н вакыйгалары (хикәятләре) тиз арада бюргерлар, ягъни шәһәр халкы, һөнәрчеләр, крестьяннарга барып ишетелә, ә алар ул хикәятләрне бөтенләй башкача кабул итәләр. Алар, бәлки, кычкырыбрак та көлгәндер, ләкин, баш чайкап: һәй ялганчы да инде! Барон бит әле үзе! Бу гөнаһлы бәндәгә хәтере кала боларнын.

Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, 1790 елда Мюнхгаузеннын үзара килешеп-ярапышып, 46 ел бергә яшәгән хатыны вафат була. Барон ялгыз калуын бик авыр кичерә. Ул дүрт ел тол яши, һәм кинәт... Менә шушы **кинәт** сүзе анын хикәятләрендә еш янгырый да инде!

Мюнхгаузен поместьесына анын дусты—отставкадагы майор фон Брун хатыны һәм кызы белән бергәләп кунакка килә. Яшь кыз Бернардинага бароннын күзе төшә! Ә менә фон Бруннар Мюнхгаузеннын поместьесына бик тә кызыга. 4 гак кына булса да, жире нинди бит—тын Везер елгасы ярында, таяк төртеп куйсан да чәчәк атарлык! Ә өе! Тагын өч йөз ел торачак. (Чыннан да, хәзерге көндә шул Йортта шәһәр идарәсе—бургомистрат һәм Мюнхгаузеннын кечкенә генә музее урнашкан.) Хужанын инде олы яшьтә булуы, бәлки, хәерлегә генәдер әле, тагын күпме вакыт кеше көлдерәсе калгандыр анын?

Тик әлеге никах барысына да бәхетсезлек кенә китерә. Бернардина, «нәзакатле чор» баласы буларак, җилбәзәк һәм акча туздырырга яратучан булып чыга. Ул баштан ук ир хатыны вазыйфаларына әһәмият бирми. Барон да... картлык—шатлык түгел шул. Шуна күрә, Бернардина балага узгач та, Мюнхгаузен баланы үзенеке итеп кабул итми. Шау-шулы аерылу мәшәкатьләре башланып, Мюнхгаузен бөтенләй бөлгенлеккә төшә. Шул тетрәнүләрдән ул инде аякка баса алмый.

Барон салкын, буш өендә ялгызы вафат була. Янында егерынын тол хатыны фрау Нольте гына була. Бервакыт ул бароннын ике бармагы юклыгын күреп, аптыраштан кычкырып җибәрә. «Аптырама,— дип тынычландыра аны барон.— Рәсәйдә ауда йөргәндә, аю тешләп алды аларны.»

Әнә шул соңгы мәзәге белән соңгы сулышын алгандай, Иероним фон Мюнхгаузен 1797 елнын 22 февралендә—77 яшенә житеп килгәндә вафат була.

Анын бурычларын икенче буын туганнары түләп бетерә. Ләкин ул үзеннән сон үлемсез Мюнхгаузенны—шәхси драмасы бәрабәренә туган комедияне калдыра. Әнә шул икенче Мюнхгаузен үзен тудырган автор исән чакта ук—әле атынын ярты гәүдәсенә төялеп, әле галәмәт балык корсагына урнашып, я туп ядрәсен иярләп—ерак илләргә һәм киләчәк гасырларга мәнгелек сәяхәткә чыгып киткән. Чын барон Мюнхгаузен үзенен сәяхәтләрен башлаган илгә—Рәсәйгә дә әйләнеп кайтты һәм шул сәяхәтләрдән башка анын шундый гажәеп хикәятләре дә тумаган булыр иде.

Ә болары инде—бөтенләй башка тарих.

***Гөлшат Салихҗанова***
*тәрҗемәсе*

*Котлыйбыз!*

## Равил Фәхретдиновка 70 яшь



Татарстанның Балтач районы талантларга бай төбәк. Бу яктан фән, икътисад, әдәбият-сәнгать өлкәсендә зур уңышларга ирешкән шәхесләр чыккан. Равил Габдрахман улы Фәхретдинов—шуларның берсе.

Ул 1937 елның 14 мартында Татарстанның Балтач районы Кариле авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. Әмма бөтен балачак, үсмер һәм яшь егет еллары Балтач авылында—район үзәгендә үтә, шунда урта мәктәпне тәмамлый. 1958-1963 елларда Равил Казан дәүләт педагогия институтында укый. Студент елларында ул җәмәгать эшләрендә актив катнаша, Тукай һәм Ленин стипендианты була.

Педагогия институтының татар теле, әдәбияты һәм тарих бүлеген кызыл дипломга тәмамлагач, Равил Фәхретдинов 1963 елда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы—Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына археология буенча аспирантурага укырга керә һәм аны уңышлы тәмамлап, шул институтта төрле елларда (1966-1996) кече, өлкән һәм төп гыйльми хезмәткәр булып эшли; Мәскәү дәүләт университетында археология буенча кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклый.

Равил Фәхретдинов—Татарстан, Идел буе, гомумән, Урта Евразия җирлегенең бөтен татар халкының урта гасырлар археологиясе һәм тарихы буенча танылган белгеч, ул—300ләп басма хезмәт авторы, шул исәптән 30дан артык китап: фәнни монографияләр, фәнни-популяр китаплар, мәктәпләр, гимназия һәм лицейлар өчен «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» исемле дәреслек, уку әсбаплары, күрсәтмә әсбаплар (Атлас), фотоальбом һ. б. Равил Фәхретдинов Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының, шулай ук Алтын Урда төньяк улусы археологик истәлекләренең тулы җыелмасын һәм картасын төзеп, бастырып чыгарды һәм бу ифрат кыйммәтле, бай академик басма фәндә беренче тапкыр эшләнде. Бу Җыелма (Свод) ике меңгә якын истәлекне үз эченә алса, аның яртысын диярлек автор үзе дистә ярым ел эчендә Татарстанның, күрше өлкә-республикаларның җирләрен җәяү йөреп эзләде, тапты, фәнни өйрәнде. «Свод»ка кергән истәлекләр аннан соң төзелеп «Татарстан АССРның археологик картасы» өчен төп нигез булды.

Равил Фәхретдинов халкыбыз тарихын җентекләп тикшереп фәнни басмаларда дөньяга чыгаручы күренекле галим генә түгел, ул әле 1920-1930 елларда Газиз Гобәйдуллиннар, Гали Рәхимнәр башлап җибәргән, әмма Сталин репрессияләреннән соң тукталып торган, милләтебез өчен бик тә кирәкле фәнни-популяр китаплар язуны, фәнни публицистиканы янадан аякка бастырды, гамәлгә кертте. Археология-тарих, җыр һәм гамәли сәнгать турында матур әдәби тел белән язылган «Җырчы» (Илһам Шакиров турында, 1973 ел), «Ташлар моңы», «Моңдадыр безнең бабайлар» (1992), «Кичке азан» (1997) китаплары әнә шуны раслый.

Бүгенге көндә Равил Фәхретдинов Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты баш гыйльми хезмәткәре, тарих фәннәре докторы, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт премиясе

лауреаты, ТРның атказанган фән эшлеклесе, «Татар археологиясе» журналының баш мөхәррире, язучылар берлеге әгъзасы.

Соңгы елларда ул Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты баш гыйльми хезмәткәре булып эшләде.

Галим каләмдәшебезне олы юбилей бәйрәме белән котлыйбыз, сәламәтлек һәм иҗади уңышлар телибез.

---

## Азат Вергазовка 75 яшь



Үз иҗатының тәмен белеп, дөрес итеп, сабыр яши каләмдәш дустыбыз.

1937 елны, Вергазовлар гаиләсе Пенза өлкәсеннән Татарстанга күчеп килгәндә, Азатка нибарысы биш кенә яшь була әле. Шуңа күрә дә ул Яшел Үзән районын үзенең икенче туган ягы итеп исәпли. Укытучылар династиясенә тугры калып, егерме елдан артык авыл мәктәпләрендә укытучы, мөдир һәм директор булып эшли. Ә инде 1974 елда ул иҗади эшкә—Казан телевидениесенең әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә килә.

Педагог һәм язучы профессиясе—икесе бербөтен. Азат Вергазовның киң катлам укучылар кулына барып җиткән «Дулкыннар ни сөйли», «Ташу», «Уяну» кебек повестьлары яшь буынны тәрбияләүгә турыдан-туры кагыла. Ул гел иҗади активлыкта яшәде, «Аҗаган» әдәбият-сәнгать журналы ачты (1990-98), иҗат яшьләрен Яшел Үзән шәһәре газетасы тирәсенә туплап, әдәби сәхифәләр алып барды.

Без аңа саулык, гаилә бәхете һәм иҗади уңышлар телибез!..



# Марс Ахунов

*Марс Ахуновмы?!.*

*Ул үзенең тормыш юлын афоризмнарга, табышмакларга, шигъри юлларга таркаткан. Илле ел буе матбугатта чыккан кече күләмле, зур мәгънәле иҗатын каршыңа өеп куйсаң—бөтен биографиясе күз алдына килә.*

*—Күпме һаваны ирекә чыгардым!—дип мактанган ди машина көпчәгенә кадалган бер кадак...*

*Сикәлтәле юлларыбызда кырык елдан артык йөк ташыган Марс Ахунов өчен зарланырлык, җан сөймәслек, көенерлек күренешләр көн кадагына әверелә барган. Сигезәр сәгатьлек эш көне белән санаганда кырык ел, ә шофер кешенең ерак рейслардан икешәр-өчәр тәүлек кайта алмый калган очракларын кушып санасаң, Марс Ахуновның хезмәт юлы күбрәк, гомере озынрак килеп чыга. Шуңа күрәдер, әле узган ел гына 70 яшьлек юбилеен үткәргән абзагыз болаерак язган:*

*Белдерү: «Сиксән яшьлек карт яшьлеген эзләп өеннән чыгып китте һәм кире кайтмады!»*

*Ул үзенең холкы-табигате белән «күзгә күренмәс» кеше. Юк-бар сәбәпләр белән мазасызлап йөрмәс, телефоннан афоризмнар сөйләп теңкәңә тимәс, гонорар сорап килмәс... Һәр җөмләсен аерым-аерым конвертка салып почта аша гына җибәрер.*

*Тымытык районының (хәзерге Азнакай) Югары Стәрле авылында туып, гомере буе Казанда яшәгән һәм бөтен редакцияләрнең дә үз авторына әверелгән Марс Ахуновның: «Уңышларга илтә торган юл һәрвакыт ремонтка ябылган булыр»,—дигән фикерен һич хупламыйм.*

*Рәхим ит, дустым, «Казан утлары» журналына юл ачык!*

***Камил Кәримов***

## ОЗЫН СҮЗНЕҢ КЫСКАСЫ

* * *

Ана сөте белән кермәгән—«Татарстан сэтэ» белән генә кермәс.

* * *

—Телевизор дип үлә инде балам: беренче программаны да карый, икенчесен дә, өченчесен дә...

—Ә укуы ничек?

—Берлесен дә ала, икелесен дә, өчлесен дә.

* * *

—Кызык, нишләп бу әбрәкәйдән подъезд исе килә икән, ә?!

* * *

Нинди генә яхшы ел да «икенче срокка» калмый.

* * *

Оптимист Яңа елны каршы ала, пессимист искесен озату белән мәшгуль.

* * *

Улына шылтырата алмыйча почтадан кайтып килгән бабай, телефон чыбыгына кунган чыпчыкларны күреп, әйткән ди:

—Әйтәм аны «линия буш түгел» дигәннәр иде...

* * *

Йоклыйсы да килә, Ватан да жәл...

* * *

Иптәш майор, сез капитан Иванов түгелме?

* * *

Хат аша сөешү—телефон аша чәй эчү ул.

* * *

Бер күгәрчен гараж идәненнән
Бензин тамган суны төшеп эчте...
Әллә түше анын бу су төсле,
Әллә бу су анын түше төсле?!

* * *

Каргыш: гомерен буе депутатлыкка кандидат булып йөргере!

* * *

Сандугачым сайрый счет-счет дип...

* * *

Урам «мәктәп» булган жирдә койма—«язу тактасы».

* * *

Итәккә ябышу—чалбарлы хатыннардан ваз кичү.

* * *

Акчанны жилгә ташла—әгәр дә жил синең якка иссә!

* * *

Кайтавазны каршы дәшүдә гаепләделәр...

* * *

Сукыр тычканга якты киләчәкнең поты бер тиен.

* * *

Елгала, судан кала, Менделеев таблицасындагы барлык элементлар да бар иде.

* * *

Айдан-айга бәяләрне күтәреп тормаса, хөкүмәтнең бар икәнен каян белер идек?!

* * *

Көнкүреш травмасы: атасының җилкәсеннән егылып төшкән.

* * *

Язганда бераз тотлыга иде ул.

* * *

Сай йөзгән кеше суны шәп болгата.

* * *

Боты—озын, акылы—кыска.

* * *

Дошманлашкан булып—дуслашты.
Исәнләшкән булып—хушлашты...

* * *

Бер депутат: «Миңа калса»,—дип сөйли. Синең кулыңа калырга язмасын инде...

* * *

Сәгате төгәл—гел бер вакытта туктый.

* * *

Ирем мунчага киткән иде, кайтмый да кайтмый, төшләремә дә керә башлады инде.

* * *

Кешене бизи торган урын—буявы кипмәгән эскәмия.

* * *

Халык шигырь укымый башлаганны ник Сөлтигә сылтыйсың?!

* * *

Күкнең дә иясе бар, суның да иясе бар, өйнең дә иясе бар, хәтта мунчаның, абзарның да иясе бар... илнең генә иясе юк.

* * *

«Төш юрау» китабындагы төшләрне күреп бетерү өчен егерме ел тоташтан йокларга кирәктер билләһи!

* * *

Әллә кайдагы атауның
Исемкәйләре Канар—
Анда бик еш йөрмә, Камәр,
Әллә кай җирең канар!

* * *

Хәзер төнлә ишек ачып урамга чыгу ачык галәмгә чыгуга караганда да хәтәррәк!



Ләлә Гыймадиева

# ҮСМЕРЛӘР ӨЧЕН ХИКӘЯЛӘР

## Әти кайтты...

Әйләнгечрәк булса да, өйләренә арткы тыкрыктан кайтты Сөмбел. Урамнан барса, кем дә булса очрар, сораштырыр дип курыкты. Битләре уттай кызышты, йөрәге сулкылдап типте. Йөгерергә тырышса да, аяклары никтер тыңламады.

Әтисе кайту хәбәрен ана тәнәфескә чыккач Хатирә апа житкерде. Мәктәптә техник хезмәткәр булып эшли ул, Сөмбелләрнең күршесендә тора. Сөмбелнең әнисен яратып бетерми, юк-юкта, әйткәләшеп алалар. Бу юлы ниндидер яшерен елмаю яткан иде анын йөзендә.

Кызый бәрәнге сабакларын аралый-аралый атлады. Үзе әнисен уйлады. Әтиләренең капка ачып керер көнен бергәләп көтте бит алар. Әнисенен елый-елый күз яшьләре кипте бугай инде.

Әтисенең чыгып киткән көне әлегедәй күз алдында Сөмбелнен. "Кабат бу йортка әйләнеп кайтмам, көтмәгез дә, эзләмәгез дә!"—диде. Әнисенен чираттагы "буран"ыннан соң әйтте. Әтисе эчеп кайткан көннәрдә мондый "буран" булмыйча калмый иде. Андый чакта әбиләре дә мыштым гына йөри, малаен да, киленен дә якламый. Сөмбел дә кайсы хаклы икәнлеген тәгаен генә әйтә алмый. Күрше Хатирә апа белән әрепләшкәндә әбисенен: "Ирләр эчми тормый, сабыр булырга кирәк иде",—дигәнен генә ишетеп калды беркөнне. Ә ник эчми тормый? Әтисе әйбәт булганда, әнисе дә гел елмаеп кына йөри бит, уен-көлке генә сөйләшә. Әбисенең дә сүзе бетеп тормый. Инде әтиләре эчеп кайттымы, йортка шыксызлык иңә. Андый чакларда күзе күрмәгән, колагы ишетмәгән жирләргә чыгып качасы килә Сөмбелнең...

Елдан арткан иде инде чыгып киткәненә. Кайдалыгын да белдермәде. Әнисе елады да елады. Әбисе ашау-эчүдән калды. Күрми үләрмен инде, дип борчылды. Тыныч кына яшәсәләр дә, араларында жылылык бетә баруын сизә иде Сөмбел...

"Әти кайткан... Минем әти кайткан..." Өй эчендәге шатлыклы ыгы-зыгыны күз алдына китерде кыз. "Тизрәк... Тизрәк..." Күнеле ашкына, йөрәге ашкына. Бөтен нәрсә үз урынына утырачагына, бик тә, бик тә рәхәт тормыш башланачагына ышана.

Баскычны атлап түгел, очып узды. Минут та үтмәс, әтисенен кочагына атылыр. Берни сорашмас...

Тик... нәрсә соң әле бу?

Әнисе тәрәзәгә карап баскан, йөзе күренми. Әбисе җайсыз итеп урындык читенә килеп тортелгән. Сулыгып, бөрешеп киткән шикелле. Ә өстәл артындагы озын эскәмиядә әтисе белән таныш булмаган нindидер бер апа утыра. Өй эчен җан өшеткеч үлем тынлыгы баскан.

—Кил, кызым, күрешик. Менә, апаң белән дә исәнләш.

Сөмбел кымшана да алмады. Дөньяның асты-өскә килгәндәй тоелды.

—Күрешик. Тагын кайчан очрашырбыз? Без озакка түгел бит. Менә, ризалыгыгызны алырга гына кайттык.

Йөрәгенең бозга әйләнә баруын сизде Сөмбел. Ризалык сорап кына эретеп булса икән аны. Өлкәннәр хыянәтен шулай ансат кына кичереп булса икән...

## Мин аңа бәхет телим

Әнә, ул бүген дә елмаеп, балкып килеп керде. Дөньядагы бар шатлыкны, бар сөенечне үзенә җыйнап алган диярсең. Төз, горур басып партасына узды, ипләп кенә букчасын ачты, китап-дәфтәрләрен таратып салды. Янәшәсендәге кызларга нидер дәште, көлешеп алдылар. Ул да булмады, яннарына безнең күрше малае Әмир килеп тортелде. Алар уйный-шаяра сөйләшә башлагач, түзмәдем: "Кыланчык!"—дип пышылдадым. Әкрен генә әйтсәм дә, тавышым ысылдап, зәһәрләнеп чыкканын үзем дә сиздем. Партадашым Галия дә аптырап карады.

—Кыланса да, аңа килешеп тора,—диде.

Бусы мине бөтенләй чыгырымнан чыгарды. Ник аңа килешә, безгә—юк? Матур булганы өченме? Бит урталарын чокырайтып елмая белгәне өченме? Әйбәт укыганы, укытучылар алдында ялагайлана белгәне өченме? Әтисе нindидер начальник бугай әле тагын, шуңа узынадыр. Әнә, миннән бер карыш та читкә атламаган Әмиренә чаклы аның тирәсендә бөтерелә башлады бит.

Башымны әллә ниткән томан уратып алгандай булды, күз кабакларым авырайды... Күралмыйм мин ул Әминәне!

—Көнләшү—яман гадәт, чирләп китүең дә ихтимал,—дип, Галия янә бер чәнечтереп алды.

Бусы урыныма утырткандай итте. Бетте. Булды. Шушы минуттан башлап, Әминәне белмим дә, күрмим дә. Галия сизәрлек булгач, чыннан да, адәм көлкесенә калуым бар. Тик кыланып йөрсен шунда. Миңа димәгәе... Безнең мәктәпкә быел гына килеп керде әле, кемлеген белеп бетергәч, шаккатудан туктарлар.

Шулай уйласам да, көне буе үземә дә, Әминәгә дә үчегеп йөрдем. Һәр алган "бишле"се эчемне пошырды. Укытучы абыйлар белән аеруча чытлыкланып сөйләшә кебек тоелды, үзенең начальник кызы икәнлеген сиздерәсе килә торгандыр, дип уйладым.

Өйгә кайткач та үз-үземне кая куярга белмәдем. Дәү әнинең: "Ни булды? Авырып киттеңме әллә?"—дигәненә мыгырданып кына җавап бирдем. Табынга да утырмадым, бүлмәмә кереп бикләндем.

Авырып киттем шул...

Икенче көнне класста кизү тору чиратым иде. Тәнәфестә бөтенесе дә чыгып беткәч, Әминәнең китап-дәфтәрләрен идәнгә чәчтем дә өстенә менеп таптадым. Ялгыш төшеп китеп, кемдер күрмичә узган, дип уйласын. Туздырсын әле дөньяларын...

Анысы да мин көткәнчә булмады. Идәндәге тамашаны күргә, Әминәнең йөзенә күләгә кунды, әмма ул берәүгә дә берни дәшмәде. Сүзсез генә әйберләрен букчасына җыеп тутырды.

Соңгы дәрес бетүгә, класстан иң беренче булып мин чыгып киттем. Киенү бүлмәсендә Әминәнең пәлтәсен эзләп таптым. Элгеч бавын тартып өзеп,

идәнгә төшереп җибәрдем. Күземә ак-кара күренми иде, атылып чыгып барганда Әмиргә килеп төртелдем.

—Мишәйтләп торма!—дип ысылдадым.—Әнә, Әминәң көтеп тора, шунын тирәсендә боргалан!—дидем.

Әмир сызгырып ук җибәрде:

—Фью! Әллә Әминәдән көнләшә инде!

Тагын шул сүз! Булды. Бетте. Үземне кулга алырга кирәк.

Әминә белән елмайган булып саубуллаштым. Шулай да сизгәндер, күзләремдәге зәһәрлекне, эчемдә кату булып утырган ачуны сизми калмагандыр.

Ник ачуланам? Ник көнләшәм? Үземне кулга алу чарасын белмим...

Иртән Әминәнең дәрестә юклыгын иң беренче мин абайлап алдым. Икенче, өченче көннәрне дә күренмәде. Инде мин канатланам, мин очынам. Шулай да шатлыгымны сиздермәскә тырышам. Класс җитәкчесе көн азагында Әмир белән мине үз янына дәшеп алды.

—Әминә сезнең урам башында тора бит, кереп чыгыгыз, ни булды икән? Эчемдә ут уйнаса да, йөземә чыгармаска тырышып, "ярар", дип пышылдадым.

Әминәләргә кайтышлый ук кагылырга булдык. Минем һич аякларым тартмый, шул ук вакытта Әмирнең дә үзен генә җибәрәсем килми.

Ишекне Әминә үзе ачты. Елмаймый, йөзе дә сулыгып калган кебек.

—Хәзер ярый инде, врач та яна гына чыгып китте әле,—диде. Нәрсә ярый? Кем ярый? Уйларым бүтәндә иде, анын әйткәннәренә бераз торгач кына төшенеп җиттем. Әнисе күптәннән урын өстендә ята икән анын. Әминә мәктәпкә киткәндә янына күрше карчыгы кереп тора икән. Соңгы вакытларда хәле аеруча начарланып киткән. Әминә, якынрак булсын дип, безнең мәктәпкә күчкән.

—Ә әтиен?—дип сораганымны сизми дә калдым.

—Зур түрә бит минем әти. Авыру әнине карап ятасы килмәде, китте. Күптәннән безнең белән тормый инде ул.

...Өйгә кайтып вак-төяк эшләремне карадым да, дәреслекләремне кочаклап, кабат Әминәләргә чаптым. Әнисе янында үзем утырып торырмын, ул ял итеп алыр. Аннары дәресләрне карарбыз...

...Көнләшәм мин аннан, бөтен барлыгым белән көнләшәм. Эче тулы сагыш була торып, балкып елмая алуыннан көнләшәм. Тормыш каһәрләвенә карамастан, башкаларга ачулана, рәнҗи белмәвеннән көнләшәм...

Мин анын бик бәхетле булуын телим.

**Редакциядән:**

*Бу көннәрдә каләмдәшебезнен юбилее. Аны ихластан тәбрик итәбез, сәламәтлек, яна иҗат уңышлары телибез.*

## *«Казан утлары» архивыннан*



*Г. Ибраһимов Киевта. 1913 ел.*



*Элеккеге «Галия» мәдрәсәсе укытучылары. Уфа, 1916 ел. Утырганнар (сулдан уңга): Фатих Сәйфи-Казанлы, Г. Ибраһимов, Зыя Камалый, Хуҗателхәким Мәхмүтов, Җиһанша Абдюшев. Басканнар: Гыйниятулла Терегулов, Әмин Хәсәфи, Зәкуан Богданов, Ибраһим Юманкулов.*



*Г. Ибраһимов һәм «Галия» мәдрәсәсендә анда укыган шәкертләрдән бер төркем, 1917 ел. Беренче рәт (сулдан уңга): Фатих Зәйни, Миргазиян Шаһабов, ?. Икенче рәт: Камил Сәгъди, Сәйфи Кудаш, Җиһанша Абдюшев (назир), Г. Ибраһимов, Әхмәт Мортазаев. Өченче рәт: Хәмзә Шәфиев, Абдрахман Гомәров, Әхтәф Каспранов, Абдулла Гомәров, Әхтәм Мансуров һ. б.*



*ТАССР Мәгариф халык комиссариаты каршындагы Гыйльми үзәк әгъзалары. Сулдан дүртенче– Г. Ибраһимов. Казан, 1926 ел.*




*Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләренең 1931 елда чыккан V томы.*



*Г. Ибраһимовның икенче хатыны Гөлсем Мөхәммәдова уллары Рөстәм белән. 1927 ел, 5 ноябрь (Рөстәмгә бер яшь).*



*Татарстан язучылары Г. Ибраһимов янында. Ялта, 1929 ел, сентябрь. Беренче рәттә (сулдан уңга): Д. Фәтхи, М. Әмир, Һ. Такташ, Г. Иделле. Икенче рәттә: К. Нәҗми, К. Тинчурин, Г. Нигъмәти, М. Гафури, С. Әдһәмова, Г. Ибраһимов, Г. Мөхәммәдова, Ш. Камал, Г. Гали, Г. Кутуй, З. Гали ("Кызыл Татарстан" журналисты). Өченче рәттә: Л. Рубинштейн ("Красная Татария" газетасы редакторы), композитор С. Сәйдәшев, И. Рәми, М. Гали, С. Кудаш, артист Ш. Шамильский, Г. Гомәр.*

## Ягъсуф Шәфыйков



Ягъсуф Долмагаян улы Шәфыйков 1937 елның 10 гыйнварында Татарстанның Актаныш районына кергән Түбән Карач авылында туа. Балачагы сугыш чорына туры килгән Ягъсуфка, замандашларына хас булганча, тормышның күп авырлыкларын татырга туры килә. Репрессияләр кичергән әтисе яшьли вафат була. Шуңа күрә, гаиләдә өлкән бала буларак, жиде класс тәмамлауга үсмер килеш тормыш арбасына жигелергә туры килә Ягъсуфка. Башта туган авылында, соңрак Сарапул шәһәрендә ат белән йөк ташучы, слесарь, шофер булып эшли. Укуын армиядә дәвам итә, демобилизациядән соң кичке урта мәктәпне тәмамлый. Озак еллар узгач, 1971 елны Казан финанс-экономика институтында читтән торып укый, диплом ала. Ягъсуф Шәфыйковның тормыш һәм хезмәт биографиясе бай: яшәгән урыннары да байтак (Удмуртия, Пермь өлкәсе, Чаллы, Ростов өлкәсе, Краснодар крае, Казан), эшләгән вазифалары да житәрлек (газета корреспонденты, «Атоммаш» заводының төзелеш идарәсе начальнигы урынбасары, «Краснодарагропромстрой» идарәсенең механизация һәм транспорт идарәсе начальнигы урынбасары, «Татаринформ» хәбәрчесе, Чаллы шәһәр администрациясенең жәмәгатьчелек белән бәйләнеш идарәсе начальнигы...). 2002 елдан бүгенгә кадәр ул «Татарстан» журналының бүлек редакторы булып эшли.

Ягъсуф Шәфыйков әдәби иҗат эшенә соң килде. Яшьрәк чакта да язу эше ят булмаса да, аның төп әсәрләре соңгы ун еллыкка карый. Чагыштырмача актив иҗат итә: соңгы ун ел эчендә төрле нәшриятларда унбер китап чыгаруы күп нәрсә сөйли. Төп китаплары: «Мин бер могжиза белән», «Хуш, Агыйдел», «Семнадцать встреч в конце века», «Бер очрашу бер гомер», «Калаларда таш казарма», «Казан университеты» һ. б. китапларның һәммәсе дә диярлек татар һәм рус телләрендә басылган. Я. Шәфыйков ике телдә дә иркен иҗат итә. Аның әсәрләре актив гражданлык позициясе булган публицистика белән сугарылган. «Мин аны Татарстанның икътисадый һәм иҗтимагый тормышын кулларында тотучы даирәләр тормышы, республикабызның XX гасырның икенче яртысындагы иҗтимагый актив көчләре эшчәнлеген тарихка теркәп калдыручы документаль әсәрләрнең остасы дип атар идем» дип яза Гәрәй Рәхим үзенең тәкъдимнамәсендә.

2006 елның 27 октябрендә Ягъсуф Долмагаян улы Шәфыйков Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

♣

## Камил Тангалычев



Тангалычев Камил Габидулла улы Мордовиянең Ельников районы Акчеево (Күгеш) дигән татар авылында 1968 елны туа. 1985 елны урта мәктәпне тәмамлауга ул «Колхозчы трибунасы» («Трибуна колхозника») исемле район газетасының үзхәбәрчесе булып эшли башлый, шунда беренче мәкаләләрен, шигырьләрен бастыра. 1990 елны Мордова педагогия институтының рус теле һәм әдәбияты факультетын тәмамлый. Шуннан бирле аның тормышы журналистикадан һәм әдәби иҗаттан аерылгысыз. Ул байтак еллар «Советская Мордовия», «Мордовия» газеталарында эшләде. Бүгенге көндә «Мордовия — 7 дней» газетасында җаваплы вазифа башкара.

Камил Тангалычев рус телендә иҗат итә. Аның «Рябиновые бубенцы» (1992), «Мой поводырь» (1998), «Ближняя деревня» (2001), «Дорога в Казань» дигән шигырь китаплары, «Лунная мастерская» (1999), «Грядущая земля» (2000), «Стихия» (2004), «Ягода репейника» (2006) исемнәрдә эссе-уйланулары тупланган җыентыклары дөнья күрде. Үткән ел Мордовия китап нәшриятында аның «Сайланма әсәрләре» басылып чыкты. Камил Тангалычевның очерклары, публицистик мәкаләләре, әдәбият турында эсселары «Независимая газета», «Литературная Россия» газеталарында, шулай ук «Дон», «Север» журналларында еш басыла.

Ул Татарстанда чыга торган басмаларда да актив катнаша. Иҗатының кайбер үрнәкләре «Казан утлары», «Идел», «Казань» журналларында, «Татарский мир», «Мәдәни җомга» газеталарында басылып укучыларга ирешә.

Камил Тангалычев рус телендә иҗат итсә дә, татарның рухи дөньясыннан аерылмаган язучы. Ул — журналыбызның актив укучысы һәм авторы. Кадәри хәл татар әдәбиятын русча чыга торган басмаларда пропагандаларга тырыша. Якташлары — татар әдәбияты классиклары Һади Такташ, Шәриф Камалларның юбилей бәйрәмнәрендә Мордовия республикасы җәмәгатьчелеге алдында махсус докладлар ясады, матбугатта мәкаләләр бастырды. Шулай ук, Мордовиядә татар һәм рус телендә чыга торган «Юлдаш» газетасында бүгенге татар шагыйрьләре турында аерым рубрикада мәкаләләр циклы бастырып килә. «Туган теле, тирән фаҗига белән өртелгән татар язмышы, татар авыллары, Сыркыдылар турында күп шигырьләрендә уйлана ул, үзен укып та җанын аңламаячак әнкәсен сагынып, ачынып, шигъри хатлар яза, җинел генә милләтен, телен алмаштырган күп тәти егетләрдән аермалы буларак, «тел белгән сихри беләү»гә кабаттан юллар да эзли... Тел югалту авырлыгын тою әрнүләрен сөйли аның шигырьләре...» дип язды аның турында шагыйрь Рәдиф Гаташ.

Ул — Мордовия Республикасының атказанган язучысы исемен йөртә. Бөтенроссия күләмендәге берничә әдәби конкурста җиңүче булды. 2005 елны «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә» дигән медаль белән бүләкләнде.

Камил Тангалычев байтак еллар Россия Язучылар берлеге составында булса да, татар язучылары аны үз араларына алырга булдылар. Язучыларның үткән елның 29 ноябрендә узган идарә утырышында ул Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп кабул ителде.

♣

Хөрмәтле редакция!

Мәктәпкә укырга кергәнче үк укырга өйрәнгән идем. Үсә төшкән саен әдәби әсәрләр уку минем «ипиемә» әйләнде. Керосин булмаган елларда җәен ай яктысында укый идем. Әдәбиятка мәхәббәт мине, урта мәктәпне тәмамлап 10 ел торгач, Казан Педагогия институтына китерде. 40 еллык хезмәт чорымның соңгы 25 елы мәктәптә үтте.

«Казан утлары»—иң көтеп алган, яратып укыган журналларымның берсе. Чөнки язучы, шагыйрьләрнең «табадан гына төшкән» әсәрләре шунда дөнья күрә. Читтән торып укыганда журналның «Публицистика», «Әдәби тәнкыйть», «Китап күзәтү» бүлекләрен бик көтеп ала идек.

Хәзер журналны китапханәдән генә алып укырга туры килә. Бер сүзен дә калдырмыйча укыйсы килсә дә, Президент М. Шәймиев берәүнең сүзләрен искә алганча: «...хәзер вакыт бар, әмма күз күрми».

Мин укыткан чор татар теленең иң каһәрләнгән, түбәнсетелгән чоры иде. Ата-аналар гына түгел, мәктәптәге хезмәттәшләрнең дә кайберләре татар теле укытуны кирәксезгә саныйлар иде.

Хәзер газета-журналларда сүзләрнең дөрес язылышына бик игътибар итмиләр бугай. Сәгатьләр саны аз, материал күп булган чорда укучыларга дөрес язылыш кагыйдәләрен онытылмаслык итеп өйрәтү тиешле күләмдә булмагандыр да. Инде нәрсә укысаң да дөрес язылмаган сүзләр очрый да, ул китап яки журналны укуның тәме югала, аны кырыйга куеп торасың.

«Казан утлары»нда бигрәк тә алынма сүзләргә кушымчалар ялгау бик дөрес димәс идем...

Хәзер дөрес язу кагыйдәләре үзгәргәндер дә. Мин—үткән гасыр кешесе, лаеклы ялга чыкканыма да ике дистә елга якын.

Әхмәт Рәшиткә 70 яшь тулу уңае белән бирелгән язманы бик кызыксынып укыдым. Күренекле кешеләрнең тормыш юлында да гади укучының үз тормышы белән чагыштырырлык вакыйгалар бар икән.

Авылдагы 7 еллык мәктәпне тәмамлагач, ике кыз, бер малай 12 чакрым ераклыктагы Яна Кенәр урта мәктәбенә укырга киттек. Аякта—чабата, өстә—телогрейка, квартирда торам. Әтиегез сугышта үлмәгән дип ел саен мәктәпкә 150 сум түләтәләр. Энем техникумда укыган өчен түли. Әтинең ашказаны авыртып, сугыштан кайтардылар да, 43 яшендә вафат булды ул.

Безнең гаиләдә 3 бала булган. 1,5 яшьтә энебез үлгән. 3 балагыз юк дип ялгызлар налогы да түләткәннәр. Әшли башлагач, мин дә күп еллар түләдем ул 6 процентлы налогны. Ә. Рәшит шикелле кая булса да язып карарга кирәк булгандыр, бәлки...

**Тәгъзимә ГАТАУЛЛИНА,**
*Арча районы, Шура авылы.*

## Авторларыбыз игътибарына

**Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кулъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.**

**Хатлар, исә, җиңел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.**

## БӨТЕН ИЛ ЗУРЛАДЫ

20 январьда Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең 70 яшьлек юбилее зурлап билгеләп үтелде. Татарстан Президентына котлау сүзен шәхсән житкерү өчен Казанга РФ Президенты Владимир Путинның һәм федераль министрлыклар, төбәк губернаторлары кебек мәртәбәле кунакларның килүе үзе күп нәрсәне анлата.

Россиянең сәяси-икътисадый тормышында кин янгыраш алган бу вакыйга Казан Ратушасы бинасында үтте.

Россия дәүләтчелеген ныгытудагы һәм республикабызның социаль-икътисади үсешендәге казанышлары өчен Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен» I дәрәҗә ордены белән бүләкләнде.

Шул ук көнне башкаланың Пирамида күнел ачу үзәгендә бәйрәм тантанасы узды. Бәйрәмгә дәрәҗәле кунаклар һәм Республиканың күренекле кешеләре чакырылган иде. Бу тантанада бер төркем язучылар да катнашты һәм чыгыш ясады.

## ХАЛЫКАРА ТАНЫЛУ

11 февральдә Әр-Риядта, Россия Президенты Владимир Путинның Согуд Гарәбстанына визиты барышында, Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевкә король Фейсал исемендәге Халыкара премия тапшырылды.

Владимир Путин алдында лауреатка бүләкне Согуд Гарәбстаны короле Абдалла ибн Абдел-Азиз тапшырды. Минтимер Шәймиевкә 2007 ел өчен (һиҗри буенча 1427 ел) король Фейсал исемендәге дәрәҗәле Халыкара премияне тапшыру турындагы карар 13 январьда игълан ителгән иде.

Согуд Гарәбстанында 1975 елга кадәр идарә иткән король Фейсал исемендәге фонд элегрәк премияне Россия галимнәре Жорес Алферов һәм Юрий Манинга тапшырган булган. Әлеге премия ислам дөньясының Нобель премиясе санала. Ул ислам дөньясы һәм, гомумән, кешелек файдасына булган зур казанышлар өчен күренекле сәясәтчеләр, җәмәгать эшлеклеләре, фән һәм әдәбият вәкилләренә бирелә.

Фейсал премиясенең күләме 200 мең доллар. Бу акчаны Татарстан Президенты хәйрия эшенә юнәлтергә ниятли.

## БЕЗНЕКЕЛӘР—ТӨРКИЯДӘ

Истанбулда «Россия—Ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркеменең өченче утырышы булды.

«Россия—Ислам дөньясы» төркеме бу юлы өч проектны раслау өчен җыелды. Шуларның берсе—«Ислам—христиан дөньясында казанышлар өчен» премиясен бирү өчен мөселман һәм христиан вәкилләре комитетын оештыру. Истанбул утырышында шулай ук эш төркеменең яна концепциясе дә кабул ителде, «Россия—Исламский мир: партнерство цивилизаций» журналы, төрле дин һәм милләт вәкилләре экспертлары төзегән толерантлык проектлары турында китаплар һәм сайт тәкъдим ителде.

Истанбулда Россия делегациясенә Минтимер Шәймиев җитәкчелек итте. Аның составына шулай ук РФ Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле Александр Коновалов керде. «Россия—Ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркеменең Мәскәүдә узган беренче утырышында ЮНЕСКО каршында цивилизацияләр бәйләнешы буенча консультатив орган булдыру төп темага әйләнгән иде. Икенче утырышы исә Казанда узды. Татарстан башкаласында узган утырышта катнашучыларга Россия мөселманнарының тормышы белән танышу мөмкинлеге бирелде.

«Россия—Ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркеменең Истанбулдагы утырышында Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев «Россия—Ислам дөньясы» дигән доклад белән чыгыш ясады.

«Ислам дине пәйда булганда мөселманнар әле аз була. Бүгенге кебек зур финанс ресурслары да булмый. Шуна да карамастан, ихтыяр көче белән ныгытылган белем хисабына ислам ярты дөньяны яулады.

Без барыбыз да Европадагы процессларны игътибар белән күзәтеп барабыз. Анда—төрле телләр, һәр милләтнең—үз культурасы, тарихы. Германия һәм Франциядә генә искә төшерү дә җитә. Ә минем ислам дөньясында охшашлык күбрәк. Хәтта татар телендә дә Коръән терминнарыннан башка сөйләшеп булмый. Мәдәнияте һәм теле ягыннан бик тә охшаш дисталәрчә гарәп дәүләтенең яшәп килүен инде әйтеп тә тормыйм. Без хәзер дөньяда яна процессларны күрәбез. Ислам дөньясы анардан аерылырга, аларга каршы килергә һәм алардан калышырга тиеш түгел»,— диде республика Президенты.

## ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ— РУХИЯТЕБЕЗ КӨЗГЕСЕ

Президент М. Шәймиев Казан Кремлендә әдәбият һәм сәнгать әһелләре белән очрашты. Ул узган елгы Әдәбият һәм сәнгать елына йомгак ясау булды, дип әйтергә мөмкин. «Без үзебезнен мәдәниятебез белән дөньякүләм масштабка чыгарга тиеш. Сәнгатьтәге уңышларыбызны Интернетта да күрсәтергә вакыт житте. Милли сәнгатьтән куркырга кирәкми. Үзебезнең милли йөзебезне югалтсак, кире кайтара алмабыз»,— диде М. Шәймиев.

«Әдәбият һәм сәнгать елында уздырылган чараларны безнең министрлык эше генә дип әйтү дөрес булмас иде. Минем башка министрлыклар хезмәтен дә билгеләп үтәсем килә»,— диде үз чыгышында Премьер-министр урынбасары—мәдәният министры З. Вәлиева.

«Бер ел Әдәбият һәм сәнгатькә багышланды да шуның белән эш тәмамланды, дип нокта куярга ярамый. Әдәбият, мәдәният, сәнгать безнең күнелдә гел яшәргә тиеш. Ул быелгы Хәйрия елында да дәвам итсен»,— дип өстәде Президент М. Шәймиев.

Очрашуда Язучылар берлеге рәисе И. Ибраһимов, Композиторлар берлеге рәисе Р. Кәлимуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Р. Фәйзуллин, Казан дәүләт консерваториясе профессоры, жырчы З. Сөнгатуллина, Татарстан Республикасы дәүләт фольклор музыкасы ансамбле житәкчесе А. Фәйзрахманов, Татар дәүләт фольклор үзәге директоры Ф. Жәүһәрова үзләрен борчыган мәсьәләләр турында сөйләде.

Әлеге очрашуда Президент аппараты житәкчесе Ю. Камалтынов, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р. Ратникова катнашты.

## ТАРИХ ИНСТИТУТЫНА—10 ЕЛ

* * *

Татарстан Фәннәр академиясенен Ш. Мәржани исемендәге Тарих институты ачылуга 10 ел тулды.

Бу унайдан Фәннәр академиясендә һәм Тарих институтында төрле чаралар булып узды. Шуларның берсе—ТР Фәннәр академиясе президиумының киңәйтелгән утырышы иде. Анда республиканың фән һәм мәдәният оешмалары вәкилләре, ижат әһелләре, киң жәмәгатьчелек катнашты.

Тарих институтында бүген дистәгә якын фән кандидаты, дистәдән артык фән докторы эшли. «Татарстан Фәннәр академиясенен Тарих институты бүгенге көндә Россиянең иң дәрәжәле фәнни үзәкләреннән санала»,— дип билгеләп үтте әлеге утырышта мәгариф һәм фән министры Р. Шәйхелисламов үз чыгышында.

Фәннәр академиясе президиумының киңәйтелгән утырышында Премьер-министрның беренче урынбасары Р. Моратов катнашты һәм чыгыш ясады.

* * *

Ш. Мәржани исемендәге Тарих институтында шулай ук зур тантана булып узды. Анда институт хезмәткәрләре һәм галимнәре, күпсанлы коллегалары исеменнән котлаулар кабул итеп, бүләкләр алды. Катнашучылар арасында Татарстан Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән, Финанс министрлыклары вәкилләре, ТР Фәннәр академиясе президиумы әгъзалары, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, Казан шәһәре мэриясе h. б. күп кенә оешмаларның вәкилләре бар иде.

Чыгыш ясаучылар Тарих институтының 10 еллык эшчәнлеге дәвамында башкарган саллы-саллы эшләре арасында Казан шәһәренең 1000 еллыгын ачыклап дәлилләүне иң зур, хәлиткеч бер нәтиҗә буларак билгеләп үттеләр. «Россиянең күп кенә шәһәрләре хәзер үзләренең туган елларын Казан тарихы белән чагыштырып кабаттан билгелиләр»,—диде бу унайдан Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров.

Тарих институтының 10 еллыгы аны ачылганнан бирле житәкләп килгән Рафаэль Хәкимгә 60 яшь тулган көнгә туры килде. Институт директорын хезмәттәшләре һәм коллегалары кайнар котлады. Тантанада катнашучылар Рафаэль Сибгат улының коллективны туплауда, аңа юнәлеш бирүдә, эшне оештыруда искиткеч зур роль уйнавын билгеләп үтте.

## ТЮРКОЛОГЛАРНЫҢ III БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Алабуга дәүләт педагогика университетында «Төрки халыкларның телләре һәм әдәбиятлары: тарихы һәм бүгенгесе» дигән тюркологик конференция үткәрелде.

Конференциядә Казан, Чаллы, Алабуга, Уфа, Стәрлетамак, Чабаксар, Әстерхан, Пермь, Тубыл шәһәрләреннән, шулай ук Карачай-Черкәс, Кабарда-Балкар, Адыгей, Саха-Якутия, Хакас республикаларыннан күренекле галимнәр һәм аспирантлар катнашты.

Пленар утырышта тюркологиянең актуаль проблемалары, дөньяда телләрнең торышы, телне саклау һәм үстерү, халыкның этногенезын ачыклауда тарихи истәлекләр һәм топонимнарның әһәмияте турында докладлар тыңланды.

Секция утырышларында төрки халыкларның теле, әдәбияты, фольклоры; тел тарихы, ономастика һәм топонимика; төрки телләрне башка телләр белән чагыштырып өйрәнү; тел һәм әдәбиятны укыту турында чыгышлар булды. (Конференциягә 98 доклад тәкъдим ителгән иде.)

Тел тарихы—халык тарихы ул. Евразия территориясендә яшәгән һәм яшәүче төрки, славян, угыр-фин, Кавказ, Балкан халыкларының тел, этнография, мифология, архео-

логия, эпиграфия материалларын чагыштырма-тарихи планда өйрәнү кайбер бәхәсле мәсьәләләрне ачыкларга ярдәм итә.

1000 еллык тарихы булган Алабуга шәһәрендә тюркологларның очрашып, бергәләп фикер алышуы аеруча әһәмиятле.

## БАШ МӨХӘРРИРЛӘР ҖЫЕНЫ

Язучыларның Мәскәү янындагы Переделкино иҗат йортында Россиядә һәм Бәйсез дәүләтләр илләрендә чыга торган әдәби журналлары баш мөхәррирләренең халыкара семинары булып узды. Баш мөхәррирләрнең өч көнгә сузылган бу җыенын Россия Федерациясенең матбугат һәм мәгълүмат агентлыгы булышлыгы белән «Дружба народов» (баш мөхәррире—А. Эбаноидзе) оештырды. Төп тема: «Әдәби журналларның бүгенге хәле» дип билгеләнгән иде. Семинарда Украина, Белоруссия, Әрмәнстан, Әзербайҗан, Казахстан, Үзбәкстан илләрендәге әдәби журналлар җитәкчеләре катнашты. Күпсанлы докладларда һәм бәхәсле чыгышларда сүз, асылда, язучы хезмәтенең халык өчен ни дәрәҗәдә хаҗәтлеге, әдәбиятның иҗтимагый тормыштагы урыны турында барды.

Семинарда Татарстаннан «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин катнашты һәм чыгыш ясады.

## КИТАПЧЫЛАР КИҢӘШӘ

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексының киңәшмәләр залында «Россия регионнарында хәзерге нәшрият эшен үстерү һәм аның көндәшлеккә сәләтлелеген күтәрү юллары» дигән темага фәнни-гамәли конференция булып узды. Анда Россиянең төрле төбәкләреннән 30га якын нәшрият вәкиле катнашты. Конференциядә Мәскәүдән Россия китап нәшер итүчеләр ассоциациясе президенты К. Чечнев, матбугат буенча Федераль агентлыкның китап күргәзмәсе һәм китап укуны пропагандалау бүлеге башлыгы А. Воропаев, Мәскәү матбугат институтының китап сәүдәсе кафедрасы мөдире Б. Ленский килгән иде.

Конференциядә катнашучыларны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республика Журналистлар берлеге рәисе Р. Ратникова, «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры И. Әхмәтҗанов тәбрикләде.

## МӘШҺҮР ТАТАРЛАР

Бөтендөнья (сервер: tatarlar.ru) үткәрә торган «Ел татарлары» дигән еллык интернет-конкурсның нәтиҗәләре игълан ителде.

«Ел Татары»—Интернет челтәрендә иң демократик конкурслардан санала, чөнки аның нәтиҗәләре фәкать укучыларның үзләре тарафыннан бәяләнә.

«Татарлар—2006» Ел Татары конкурсының төрле номинацияләрендә 12 кеше җиңүче дип табылды. Алар—зур хезмәт башкарып, татар дөньясында киң танылган шәхесләр.

Җиңүчеләр арасында сәясәтче Камил Исхаков, шагыйрь Равил Фәйзуллин, меценат Мансур Шакиров, музыкант Айдар Гайнуллин, эшмәкәр Мөслимә Латыйпова, тренер-спортчы Зиннәтулла Билалетдиновлар бар.

## ПРЕМИЯ ИЯЛӘРЕ АЧЫКЛАНДЫ

15 февральдә—Муса Җәлилнең туган көнендә шагыйрь исемен йөрткән республика премиясенең ияләре ачыкланды.

Быел бу премиягә «Алтынчәч» дип исемләнгән циклдагы иҗаты өчен рәссам Булат Гыйльванов, «Саташу» дигән спектакль өчен Чаллы дәүләт татар драма театры режиссеры Фаил Ибраһимов һәм артистка Чулпан Садыйкова; талантлы балаларны һәм сәләтле яшьләрне эзләп табудагы мактаулы эшләре өчен «Йолдызлык» эстрада сәнгате телевизион яшьләр фестивале проекты; шагыйрьләр Газинур Морат «Төнге әверелеш» дигән шигъри җыентыгы өчен һәм иҗади яшьләр белән актив иҗтимагый эш алып барганы, шулай ук «Кояшны кочкан малай» исемле китабы өчен Ләбиб Лерон лаек булды.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» БҮЛӘКЛӘНДЕ

Татарстан Мәдәният министрлыгы Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залына бер төркем журналистларны җыйды. Очрашу былтыргы «Әдәбият һәм сәнгать елы» нәтиҗәләренә багышланган иде. Татарстан Премьер-министр урынбасары—Мәдәният министры З. Вәлиева үзенең чыгышында журналист-язучыларның мәдәни тормышны матбугатта яктыртуларын, гомумән, иҗади хезмәтләрен югары бәяләде. Кайбер басмалар һәм аерым журналистлар бүләкләнүгә дә лаек булды. «Әдәбият һәм сәнгать елы»н уздыруда нәтиҗәле хезмәте өчен «Казан утлары» журналы Мәдәният министрлыгының дипломы һәм акчалата премия белән бүләкләнде.

## ОЛУГ ШАГЫЙРЬ БЕЗНЕҢ ЯКТАШ УЛ

Чабаксарда Чуашстанның халык шагыйре П. Хузангайның тууына 100 ел тулуга багышланган тантана булды. Анда Татарстаннан мәдәният министрының беренче урынбасары А. Гайнетдинов, Татарстанның халык шагыйре Р. Харис, Язучылар берлеге идарәсе рәисе урынбасары Ә. Закирҗанов һәм Әлки муниципаль районы башлыгы Ф. Дәүләтшин җитәкчелегендәге район делегациясе катнашты; тантаналы кичәдә Президент М. Шәймиев котлавын мәдәният министрының беренче урынбасары А. Гайнетдинов укып ирештерде.

Чуаш әдәбияты классигының юбилей бәйрәме Татарстанда да киң билгеләп үтелде. Әлки районының ул туган авылда (ул хәзер шагыйрь исеме белән Хузангай-Сихтермә дип атап йөртелә) зур тантаналар узды.

### ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

6 февраль көнне Казанның С. Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залында танылган балалар шагыйре Рафис Корбанның 50 яшьлегенә уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды.

Кичәдә юбилярны мәдәният министрының беренче урынбасары А. Гайнетдинов, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе И. Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре Р. Миңнуллин, Казан «Әкият» курчак театры директоры Р. Яппарова һәм баш режиссеры И. Зиннуров, шулай ук күпсанлы каләмдәшләре, якташлары, хезмәттәшләре котлады.

Кичәдә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры һәм филармония артистлары катнашты, мәктәп укучылары, балалар бакчасына йөрүче балалар аның шигырьләренә язылган җырларны башкарды.

### РУХИ МИРАСНЫ САКЛЫЙК

«Матбугат белән йөзгә-йөз». Татарстан Милли музеенда узган очрашу әнә шулай дип аталды. Музей директоры Гөлчәчәк Нәҗипова үзенең чыгышында: «Матбугат белән бергә эшләгәндә генә безнең хезмәтебез күзгә күренә»,— диде. Ул быелгы Хәйрия елында үзләренә ярдәм кирәклеген дә әйтеп узды: «Музейда төзекләндерү эшләре көтелә. Шунлыктан, кайбер фондлар вакытлыча ябылырга мәҗбүр,—житәкче үзен борчыган тагын бер мәсьәләгә тукталды. —«Казаннан читтәге авылларга күренекле шәхесләрнең әйберләрен илтәләр. Аларны бирәдә саклау урынлы булыр иде»,— дип белдерде. Соңгы вакытта музейга тамашачыларның аз йөрүе күзәтелә икән. Элек озын-озын чиратлар булса, узган ел йөз мең кеше биредә булган. Бүгенге көндә анда 800 меңләп берәмлек экспонат саклана. Хезмәткәрләр ел ахырына «Татар киемнәре», «Экология» күргәзмәләре эшләргә уйлыйлар.

### КАТЛАУЛЫ ЯЗМЫШ КАЙТАВАЗЫ

Бөтендөнья татар Конгрессы башкарма комитеты бинасында күренекле татар мөһаҗире Солтан Гарифның шәхси архивында сакланган документларны Татарстан Милли архивына тапшыру тантанасы булды. Анда әлеге документларны, Алманиягә барып, мөһаҗирнең үз кулыннан алып кайткан галим, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев Солтан Гарифның катлаулы язмышы турында сөйләде. Документларны Татарстан Милли архивы директоры Л. Горохова кабул итеп алды.

—Солтан Гариф сугыштан соң чит илләрдә калган мөһаҗирләрнең бер вәкиле, аның язмышы чит илләргә китәргә, чит илләрдә калырга мәҗбүр булган, илгә кайта алмаган бик күп татар мөһаҗирләре язмышы белән уртак. Ул 19 яшендә илдән киткән. Озак еллар буена Алманиядә «Азатлык» радиосында эшләгән, татар халкының азатлыгы өчен шуннан торып көрәшкән,— диде И. Гыйләҗев. —Хәзер аңа 83 яшь. Без бу документлар аша татар халкының тагын бер аянычлы—татар халкының сугыштан соңгы мөһаҗирләре тарихын өйрәнә алачакбыз.

Солтан Гарифның шәхси архивын тапшыру тантанасында Бөтендөнья татар Конгрессы башкарма комитеты рәисе Р. Закиров, галимнәр, архив хезмәткәрләре, журналистлар катнашты.

### ЯШЬ ЯЗУЧЫЛАРГА ЯРДӘМ

«Казан утлары» журналы һәм «ИДЕЛ-ПРЕСС» полиграфия-нәшрият комплексының генераль директоры Ислам Әхмәтҗанов яшь һәм башлап язучыларга иҗатларын халыкка житкерү өчен тагын бер мөмкинлек тудырганнар. Комплексның матди ярдәме белән узган ел азагында Гөлзадә Бәйрәмованың «Әле кайчан гына...» дигән беренче китабы нәшер ителде. «ИДЕЛ-ПРЕСС» һәм «Казан утлары» белдергәнчә, бу матур башлангыч күркәм традиция рәвешен алачак.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

Әдәбият өлкәсендәге казанышлары, актив җәмәгать эшчәнлеге өчен язучы Дәүләтов Зөфәр Мирхәйдәр улына «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* **Бакый Урманче.** «Илдар әнисе Сара ханым белән».

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы **Роза Мулланурова**.

# Яңа китаплар




**Зиннур Мансуров.** Күнелдә фидаи яшәсә: Әдәбият, сәнгать һәм яшәеш турында уйланулар. — Казан: «Мәгариф» нәшр., 2006. — 495 б.: фот. б-н. Тиражы — 2000 данә.

«Әдипләрне ниләр генә тынычсызламый: милли дәүләтчелегебезне торгызу зарурлыгы да, ана телебезнең тәшвишле язмышы да, әдәбият-сәнгать мәсьәләләре дә, халык тормышындагы эреле-ваклы канәгатьсезлекләр дә... Җанымны борчыган хәл-күренешкә карата мөнәсәбәтемне ачыктан-ачык белдереп баруны җаваплы бурычым дип санадым», — ди шагыйрь үзенең китабына язган кереш сүзендә.

Күренекле шагыйрь һәм мәдәният эшлеклесе Зиннур Мансуровның югары зәвык белән эшләнгән, дүрт бүлектән торган бу китабына яшәешебездәге көнүзәк мәсьәләләргә кагылышлы уйлан-күзәтүләре, әдәбият-сәнгать тормышына тәнкыйди күзлектән карап язылган мәкаләләре, төрле буын каләм ияләренә багышланган иҗат портретлары, аерым китаплар уңаеннан фикер-карашлары тупланган.




**Мансур Мортазин.** Дөнья дилбегәсе кем кулында? — Сәяси-публицистик язмалар. — Казан: «Идел-Пресс» нәшр., 2006. — 464 б. Тиражы — 2000 данә.

Мансур Мортазин — татар дөньясында танылган журналист. Иҗатчының тормыш һәм иҗат юлы да шактый бай һәм гыйбрәтле: студент, солдат, Себер якларында укытучы, радиожурналист, «Татарстан яшьләре» газетасы хезмәткәре, «Аргамак» журналы баш мөхәррире, «Ватаным Татарстан» газетасы җитәкчеләренең берсе...

Дөнья дилбегәсе кем кулында? Мансур Мортазин үзенең бу китабында дөнья дилбегәсен кулга төшерергә теләүче илбашлары, чиновниклар, байлар, аларның сәяси карашлары, кешеләргә карата мөнәсәбәтләре һәм якты киләчәккә өметләнеп яшәүче халыкның соңгы дистә еллардагы хәл-әхвәле, хыял-омтылышлары, акланмаган өметләре турында уйлана, шул чордагы вәзгыятькә анализ ясый.



Роза Мулланурова

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)